ISSN 0206—41



# Казан утлары

1.1987



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1

1987

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## Бу санда

Г. АХУНОВ. Идел кызы. Роман . . . . . 3
ЗӨЛФӘТ. Чиксезлеккә багам. Шигырьләр . . 102
М. ЮНЫС. Таңда Босфор аша. Повесть . . 108
Н. ДӘҮЛИ. Мина белән солдат очрашуы. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 142

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Н. АРСЛАНОВ. А. С. Пушкиннан яңа тәрҗемәләр . . . . . . . . . . . . . 147
Ю. СЕМЕНДЕР. Мәгърур имән кебек . . . . 149

КПССның XXVII СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

С. ИБРАҺИМОВА. Безгә ничек хезмәт күрсәтәләр? . . . . . . . . . . . . . . 152

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

А. И. ДЕМИДОВ. Борынгы Бүләр җирендә. (Алексеевск районы) . . . . . . . . . 156

БЕЗНЕҢ ӘХЛАК

Ф. ЛАТЫЙПОВ. Нәфес баткагында . . . . . 159

Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Р. ХӘЙРЕТДИНОВ. Олы юл башында . . . . 171

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. КУКУШКИН. Гомер китабының битләре 175

РЕПЛИКА

Җ. РӘХИМОВ. Шөбһәләнерлек булмасын! . . 186

Культура тормышы көндәлеге . . . . . . . 189

Китаплар дөньясында . . . . . . . . . . 191

Тышлыктагы сурәтләр . . 192

*Баш редактор*
**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**ӘХӘТ ГАФФАР**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*
**ТУФАН МИННУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*
**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**
**НУРИХАН ФӘТТАХ**
**РИЗВАН ХӘМИД**
**НИЛ ЮЗИЕВ**
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

## В нашем номере:

Вторая книга романа Г. АХУНОВА «Дочь Волги» (начало). Повесть М. ЮНУСОВА «Через Босфор на рассвете». Стихи ЗУЛЬФАТА, Н. ДАУЛИ.

«Дружба литератур — дружба народов» — новые переводы стихотворений А. С. ПУШКИНА. Статья Ю. СЕМЕНДЕРА к 80-летию чувашского поэта П. ХУЗАНГАЯ.

В рубрике «Татарстан — родной мой край» выступление первого секретаря Алексеевского райкома КПСС А. И. ДЕМИДОВА.

«Решения XXVII съезда КПСС — в жизнь!» — статья С. ИБРАГИМОВОЙ о проблемах бытового обслуживания населения.

«Наша мораль» — очерк Ф. ЛАТЫПОВА «В трясине наживы».

К 100-летию Г. Ибрагимова статья Р. ХАЙРУТДИНОВА «Начало большого пути».

В рубрике «Литературная критика» творческий портрет поэта РОБЕРТА АХМЕТЖАНОВА.

Реплика Дж. РАХИМОВА об исследованиях в области ономастики.

«В мире книг».

На наших обложках — ювелирное искусство татарского народа и архитектурные памятники Казани.

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Г. Салихҗанова. И. Ихсанова.*

Производствога бирелде 30.10.1986 ел. Басарга кул куелды 11.12.1986 ел. ПФ 05475. Офсет ысулы белән басылд. Кәгазь форматы $70\times108\ ^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 62449. Заказ В-461. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1987 ел.

## Гариф Ахунов

# ИДЕЛ КЫЗЫ

РОМАН ИКЕНЧЕ КИТАП

**Җиденче башлам**

## I



Аҗаганлы Казан киче Кабан күле өстендә яшен шәүләләрен биеткәндә, Солтан Айдаров техникум бинасыннан урамга килеп чыкты. Чыкты да баскан җирендә катып калды. Аҗаганның яңа бер җилфердәве аны сукырайтып җибәрде. Күз камаштыргыч ут өермәсе сүнеп, якындагы күл өсте, яр буйлап тезелгән карт өянкеләр караңгылыкка чумгач, ул — азаккы мәртәбә — үзе әле генә чыккан бинага әйләнеп карады: ике катлы агач йорт инде тоныкланган, җил-яңгырлардан, кар-бураннардан караеп беткән бүрәнәләре белән күздән югалган, ул йорт хәзер Айдаров өчен юк иде инде.

Аны бүген партиядән чыгардылар.

Иртәгә ул биргә килмәс. Җир төзүчеләр техникумының директоры булып, күрсәтмәләр бирмәс. Аның урынына башка кеше килер, башка кеше күрсәтмәләр бирер.

Өйгә кайтырга кирәк иде. Миңгерәүләнеп, беркавым басып торгач, техникум ихатасыннан ерак түгел генә урнашкан Нәби картлар өенә таба юнәлде. Чикмәнле, какча гәүдәле, аз сүзле, кайчан карама кулына чыбыркы тоткан Нәби карт менә хәзер өеннән бөкрәя төшеп килеп чыгар да: «Киттекме, иптәш дилектыр?» — дип эшәр төсле тоелды аңа. Хәзер Солтанга тугрылыклы булып калса, әнә шул бер кеше — ат йөртүче Нәби карт кына калачак. Казаннан ун чакрымнар ары Аргы Кабан буена урнашкан Җир төзүчеләр техникумына җәйге чөлләләрдә дә, көзге яңгырларда да, кышкы бураннарда да йөртте бит ул аны. Казаннан көн саен китерде, көн саен илтеп куйды. Тәҗрибә участокларына, кырларга алып чыкты. Директоры белән бергә уҗымнарның дәррәү тишелүенә куанды, яңгырсыз елларны, сортлы бодай соңга калып тишелгән чакларда, борынын салындырып, ләм-мим бер сүз дәшмәстән, шомырт агачыннан ясалган чыбыркы сабы белән каты кәсләрне, түмгәкләрне төрткәләп йөрде. Авыр итеп күрсенде. Игеннәрнең кадерен белгән, гомерен буразнада үткәргән кешеләр генә аның төсле итеп күрсенә ала.

---

ГАРИФ АХУНОВ *(1925) — прозаик. РСФСРның атказанган культура хезмәткәре, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, «Хәзинә», «Хуҗалар» романнары, повесть һәм хикәяләр, пьеса һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре авторы. Казанда яши.*

Хәзергеләр әнә синең ун ел буена тырышканнарыңны бер минут эчендә юкка чыгардылар. Мөгыйн Галләмовның бер битлек гаризасы җитте сине партиядән чыгару өчен. Мөгыйн белән Солтан, әле революциягә хәтле үк, Таминдар бай мәдрәсәсендә укыганнар иде. Мәдрәсә малайлары Мөгыйнне күп белгәне, коръәннең барлык сүрәләрен үз файдасына аңлата алганы өчен Нух пәйгамбәр дип исем биргәннәр иде. Тора-бара «пәйгамбәр» дигәне онытылды, Нух Галләмгә әйләнеп калды. Пәйгамбәр исемен йөртүче Галләмов изгелек белән явызлык арасында чайкалды. Колчак килгән заманда, гражданнар сугышы чорында ак офицерлар погонын да тагып йөрде, аның өчен Алабуга төрмәсендә биш ел утырып та чыкты. Ни хикмәттер, Нух Галләм судан коры чыга, юешләнгән репутациясен еракка яшерә белә иде. Күрәсең, табигать мул итеп биргән булдыклылык, шуның өстәвенә җиңел сөяклелек аны коткарып килгәндер. Алабугада, Уфада, Уралның кайсыдыр бер каласында буталганнан соң ул Казанга Наркомземның кадрлар бүлегенә кайтып урнашты. Дүртбиш ел эчендә энергияле, каты куллы, төптән уйлап эш йөртә белә торган башлык булып танылды. Аның белән югарырак урындагы түрәләр дә исәпләшә башладылар. Солтан аны инде акылга тәмам утырган, совет платформасын тулысынча кабул иткән дип уйлый, җае чыккан чакларда ул аңа булыша да торган иде.

Бүген аны Нух Галләмнең гаризасы нигезендә партиядән чыгардылар. Беренче мизгелдә Солтан моны берничек тә аңлый алмады. Ул аңа Мөгыйн Галләмовның арттан килеп пычак кадавы кебек явызлык булып тоелды. Әйе, явызлык! Нух эшне бик каты белеп эшләгән, тыштан карaганда, ул Солтанга ташлаган гаепләргә һич тә бәйләнерлек түгел. Галләмовның гаризасы буенча болай булып чыга: Солтан Айдаров — 1930 елны авылга күмәк хуҗалык төзү өчен җибәрелгән вәкил — ярлы-ябагайны колхозга көчләп керткән. Мисалы — күмәк хуҗалыкка тупланган «Кызыл Зартугай»ның колхоз межасын билгеләргә кирәк булгач, землемер баганасы чокырына төшеп яткан Садыйк ярлыны чокырдан наган белән атып, куркытып чыгарган. Иптәш Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» исемле мәкаләсендә сүз әнә шундый кешеләр, властьтан намуссыз рәвештә файдаланучы, партия исеменә тап төшерүче ялган коммунистлар турында бара. Мондый кешеләр Совет властеның терәге булырга тиешле ярлы крестьянны, аларның союзнигы булырга тиешле урта хәллене социализм строена каршы аякландыралар, халык арасына ризасызлык орлыгы чәчәләр. Ул гынамы? Айдаров кебек политик сукырлар җылы канатлары астына мулла кызын сыендыралар, аның әнисен себер китүдән саклап калалар. Боларның барысы, төптән уйлап караганда, Айдаров Солтанның Алабуга Өязе Пәнҗәр төбәгендә партия эшендә эшләгән абыйсы Айдаров Шәяхмәткә таянып эшләнә...

Солтан аклана ала иде. Тиеш тә иде ул акланырга. Землемер чокырыннан куып чыгарылган кеше бит аның үз этисе Садыйк, байларга куштан булып йөргән Садыйк. Ничәмә еллар колхозга керми бер тилмертте ул Солтанны, кеше арасында оятлы итте. Инде бер кишәрлек җире «Кызыл Зартугай» колхозы межасына туры килгәч, авыл кулаклары коткысы белән землемер чокырына төшеп ятты. Ә бит Солтанга колхоз җирен керделе-чыктылы итеп түгел, тигез һәм гомерлек итеп сызарга кирәк иде. Мулла кызы дигәне бит инде Совет вузында белем алды, үзе хәзер врачлар тәрбияли... Солтан шуларны сөйлисе иде — сөйләтмәделәр.

Солтан, үзенә яла яккан гаризаның эчтәлеген менә хәзер күңеленнән барлый-барлый, әнә шул уйлары белән үзен ярсындыра-ярсындыра, Нәби картның йортына барып җитте.

Йортның чолан ишегендә амбар бикли торган зур кара йозак эленеп тора иде. Күңелен баскан авырлыктан, нишләргә белми аптырапюгалып калганнан Солтан бер мизгел баскыч төбендә таптанып торды.

йозакның биклеме-юкмы икәнен белергә теләгәндәй, аны ике куллап тотып тартып карады.
Әкрен генә кире кузгалды.
Ә нигә ялынып торырга әле Нәби картка? Атны бит ул үзе дә җигә ала. Зартугайда — үсмер малай чагында ук — ул әтисе белән бергә сука сукалады, тырма тырмалады, ашлык чәчте. Аның Иж тугайларын яңгыратып, җырлый-җырлый атка атланып кайтканын әллә каян таныйлар, инеш басмаларында кер бәләкләгән хатын-кызлар, эшләреннән туктап, Солтанның җырын ерактан ук көтеп алалар, картлар исә, башларын чайкап: «Ай-һай, моңлы булып үссә дә үсәр икән Садыйк малае!» — диләр иде...
Күңелендә кузгалган изге истәлекләрен ат йөртүчесе Нәби картка булган үпкә-рәнҗеше алмаштырды. Шушындый көнне чыгып олакмаса, аз гына сабыр иткән булса, укасы уңар идемени? Менә хәзер җыелыштагылар чыгарлар, аңа сүз кушып, хәленә кергән булып сөйләшерләр. Кемгә кирәк үзеңне кызгандырып, мескен булып бөрешеп торулар?! Нәби карт менә хәзер аны җигүле ат белән көтеп торса, Айдаров бу шыксыз ишегалдыннан җилләр уйнатып чыгып киткән булыр иде...
Солтан ат абзарына ашыкты. Абзарның ишеген каерып ачуга, борынга җылы тирес исе килеп бәрелде. Әмма, башка чаклардагы кебек, Җирән кашка аны кешнәп каршы алмады, сайгак идәндә таптанып, сөенечен дә белдермәде — ул бүген анда юк иде.
Тик шунда гына Айдаров инде бүтән берәүгә дә кирәк түгеллеген, бу йортка, бу ихатага, бу атка хуҗа түгеллеген аңлады.
Ул, башын иеп, абзардан чыкты. Аҗаган инде ярсулы җилфердәвеннән туктаган, ара-тирә, онытылганда бер генә, офыктан алсу яулык болгап ала; әнә шул чагында офыктагы берсе өстенә берсе өелгән кызылкаракучкыл-шәмәхә болытлар эчкә шом салырдай куркыныч булып, әкиятләрдә сөйләнелгән Каф таулары булып күренәләр, дию, пәриләре, җиде башлы аждаһалар, агулы еланнар искә төшә иде.
Кинәт, Солтанны сискәндереп, ат кешнәп җибәрде.
Кичке тынлыкта бу шундый да көтелмәгән, шул ук вакытта көтелгән дә, җанга ятышлы газиз тавыш иде ки, Солтан баскан урынында тораташ кебек катып калды.
Ат икенче мәртәбә кешнәде.
Солтан аның Җирән кашка икәнен аңлап, җаны-тәне белән тоеп, тавыш килгән якка таба йөгерде. Абзар ихатасының тәбәнәк таш коймасын бер селтәнүдә сикереп чыкты. Йөгергән уңайга күреп алды: алгы аякларындагы тышавы өзелгән, йөгән тезгене җирдән сөйрәлеп барган Җирән кашка, башын югары чөеп, ихата буенда чабып йөри иде.
— Җирән кашка, Җирән кашка! — дип дәште Солтан.
Ат хуҗасын таныды. Уйнаклап бер тибенеп алгач, кешни-кешни, Солтан янына чабып килде. Айдаров аны, йөгән тезгененнән эләктереп, койма буена китерде, ярсынган атны башыннан, ялларыннан сыйпап тынычландырды, аннары, күз ачып йомганчы сикереп атланды да кырга чыгып чапты.
Куе тыгыз җил битенә китереп бәрде, пиджак чабуларын җилфердәтеп, аркасына кереп тулды. Хәзер аңа кая барса да барыбер иде. Атны үз иркенә куеп, чөңгереп җибәрде. Шул ук минутта дөньясын онытты. Өермәләнеп-дулап, ат чапкан уңайга ашкынулы-ярсулы булып, малай чактагы бер вакыйга — гомер буе хәтерендә сакланган вакыйга күңелендә яңарды.

... Саклау урманы буеннан Зартугайга таба җиде ат чаба. Иң алда — Мөгыйн, малайлар телендә йөргән кушаматы белән әйткәндә, Нух Галләм. Ул Таминдар байның Тимеркүк алашасын беренче итеп китерергә сүз биргән. Аның үз сүзен өскә чыгарасы, баш килсә дип вәгъдә ителгән укалы зәңгәр түбәтәйне эләктерәсе килә. Нух Галләм атланган

Тимеркүк башка атларны ярты чакрым чамасы артка калдырып чаба. Солтанның Сары биясе иң артта. Гарьлек. Азаккы булып килсәң — дөньяда яшәмә дә!

Солтан атның корсагын ялан аяклары белән ныгытып кысты, үзе Сары биянең ялына ята төште. Шуны гына көткәндәй, чаптар җиргә ятып бетеп диярлек, гөрс-гөрс итеп, бер алганда ындыр табагы хәтле җирне алдырып чаба башлады. Хәзер инде Солтан аның өстендә сикерми дә, артка калуны да башына китерми, биткә өзлексез бәргән тыгыз җилдән, җилкән булып кабарган күлмәгеннән башканы сизми.

Ул, калкына төшеп:

— Сары бия, җаным, әйдә, әйдә! — дип кычкырды.

Сары бия башта Алмачуарны узды. Аннары Кара туры белән Акбүз ат артта калдылар. Чаптарның үзендә дә бәйге дәрте кузгалды бугай, ул хәзер әйткәнне дә, куалаганны да көтми, канатлы коштай оча иде.

Зартугай күренә башлаганда, аңардан нибары Тимеркүк кенә алда иде инде.

Нух Галләм Сары биянең гөрселдәп килүен тойды ахрысы — артына борылып карады һәм, ат өстендә калкынып, Тимеркүкне уңлы-сулы камчылый башлады.

Сары бия бер тында Таминдар байның алашасын куып җитте. Нух Галләм моны сизде, Сары бия Тимеркүк белән тигезләшүгә, селтәнеп торып, Солтан атының башына камчы белән сукты. Сары бия мондый әшәкелекне көтмәгән иде, ул өркеп читкә сикерде, Солтан ат өстеннән чак-чак кына авып төшми калды.

Солтанның теш казналары кысылып килде. Ат ялына ятып бетеп ул чаптары белән беректе, бирешмә, җаным, бирешмә, дип ялварды.

Сары бия әле һаман чаба, ләкин инде бер мәртәбә башына камчы алганлыктан, Тимеркүкне узарга һич кенә дә теләми иде.

Нух Галләмнең аты хәлдән тайган. Әмма атны каулаучы үзе бик уяу — баш өстендәге камчысын яшен урынына уйната иде.

Йөрәге атылып чыгарга җитеп ярсынган Солтан:

— Һә-ә-әәәәәәйй!!! — дип сөрән салды.

Ул арада ат өстендә калкынган Нух Галләм камчысын янә баш өстенә күтәрде, әмма ул селтәнеп өлгергәнче, Солтан аның үз битенә камчысы белән орды. Малайның ачыргаланып кычкырганын һәм ат өстеннән капчыктай ишелеп төшеп калганын гына күреп өлгерде.

Сары бия Солтанны Зартугайның басу капкасы төбенә, кулларына бүләк тотып торган мужиклар янына китереп җиткерде...

... Инде менә Мөгыйн Галләмов шуның үчен ала. Унбиш елдан соң да онытмаган. Ул онытмаган, онытмаячак, табигате шундый. Ә башкалар нәрсә карый? Алар Айдаровның Азин дивизиясендә Совет властен яклап сугышканын белмиләрмени? Илгә иминлек килеп, тыныч көннәр урнашкач, Әгерҗе һәм Пәнҗәр төбәкләрендә җир төзүче булып эшләгәндә, Айдаровны кулаклар сәнәк белән чәнечтеләр. Шуны онытканнармыни аңа каршы кул күтәрүчеләр? Ярар, Нух Галләмнең аңа карата ничәмә-ничә еллар куенында кара елан итеп асраган үче бар ди. Ул үч үсмер малай чагыннан, ат чабышында битенә камчы ярасы алудан ук килә ди. Ә бит партоешма секретаре Мәснәвиевнең аңарда берниндн дә үче юк. Ул соң аек баш белән уйлап карарга тиеш түгел идемени? Айдаровның нинди тырышлык белән техникумны оештырганын, белгечләр, педагоглар туплаганын үз күзе белән күрмәдемени ул? Нигә дип ул Нух Галләм коткысына бирелә?

## II

Нурия бу кичне ире Солтанны бик озак көтте.

Гомердә булмаган бер ашкыну белән көтте. Күңеле аның нигәдер

тыныч түгел, сул күз кабагы да тартып тора иде. Сул күз кабагының беркайчан да җүнлелеккә тартканы юк.

Диван читенә чүмәшеп, челтәр бәйләп утырган әнисеннән:

— Андый-мондый Солтан көндез кайтып китмәгәндер бит? — дип сорады.

— Юк, балам, күренмәде, кайтса, күргән булырыем, — диде әнисе. Тез өстендә яткан ак челтәрен бер читкә сыпырып куеп, Шәмсениса абыстай аяк өсте басты, яшел хәтфә камзулының төймәләрен капты-ра-каптыра, чаларган чәчләрен яулык астына кыстырып, сорыйсы итте:

— Нигә алай дип әйтәсең, бәбкәм? Ул-бу юктыр бит?

— Эчем поша. Җанымны куяр урын тапмыйм, — диде Нурия әкрен генә. — Нишләп кайтмый инде бу? Кайларда йөри инде бу?

Ул, башына яулык салып, урамга, ирен каршы алырга дип чыгып китте. Юкса, өй эче бик тә бөркү тоела, аның саруы кайный, биредә түзеп утырырлыгы юк иде.

Ул киткәч, Шәмсениса абыстай эчкәрге бүлмәгә керде. Алты яшьлек Шәфика бәләкәй караватта, кулларны як-якка ташлап, чайрап йоклый, аның шешмәгрәк кабаклы күзләре, түгәрәк кара тутлы бите, шомырт кара бөдрә чәчләре әтисе Габбасны хәтерләтә иде.

Шәмсениса абыстай, сабыйдан күзен ала алмыйча озак кына карап торгач, авыр итеп бер көрсенде, ишекне әкрен генә ябып, олы якка чыкты.

Тагын кул эшенә тотынды.

Уйлары әллә кайларга китеп бардылар...

... Габбас мулланың фаҗигале үлеменнән соң Шәмсениса абыстай Нуриясенә карата аеруча игътибарлы булып китте. Сәламәтлегенең көннән-көн какшый баруын белсә дә, ул аны кызына сиздерми, иртән иртәрәк торып, кичен соңрак ятарга тырыша. Зартугайдан Казанга килгәннән соң узган сигез ел вакыт эчендә аңар йорт эшләрен тулысынча диярлек үзенә башкарырга туры килә, Нуриясе көндезләрен медицина институтында укыта, кичләрен тагын институтына китеп, куяндыр, мәчедер ише хайваннарны ярып, галимлек эшенә әзерләнә.

Шәмсениса абыстай соңгы елларда калҗаеп киткән карт куллары белән кызының керләрен уа, ашын пешерә, атнасына ике мәртәбә төнлә ипи чиратына чыга; институттан соң кызының башы бераз ял итеп алсын дип, ул Нурия белән Солтанга театр билетлары алып куйгалый — шуның белән бердәнбер кызының һәм шактый ук каты бәгырьле киявенең күңелен йомшартырга, аларның мәшәкатьле тормышларына ямь өстәргә тырыша иде.

Гаять дәрәҗәдә түзем, кайгы-хәсрәтне башкалар өстенә аудармый торган Шәмсениса абыстай үз гомерендә читләргә күз яше күрсәтмәде — ничәмә-ничә буыннан килгән затлы нәселенә тап төшерүдән, җебегән әлләзи булып күренүдән курыкты.

Габбас мулланың асылынып үлү хәбәрен ишеткәннән соң да ул кызы Нурия алдында бер генә (бары тик бер генә мәртәбә!) кайнар яшьләрен түгеп, сыгылып төшеп елады. Анда да Габбас мулланың кече хатыны Хәнифәдән туган баланы, инде ятим калган Шәфиканы кызганып өзгәләнде:

— И бәләкәччием, нәни сабыем, нишләрсең икән инде син? Кемнәргә әтием дип дәшәрсең икән?

Аның сагышларын, шул «бәләкәччие» өчен өзгәләнүен күреп йөргән Нурия, озак та тормастан, Шәфиканы үзләренә алдырды.

Тормышны болыт баскан, аеруча күңелсез һәм эчпошыргыч булып тоелган көннәрендә Шәфиканы тез башына утыртып сөю, көн саен аяклы зур көзге алдында аның чәчен тарау Шәмсениса карчыкның җанына юаныч була иде. Ул хәзер әнә шул сабый өчен яши, әнә шул сабый өчен тормышка чатырдап ябышып тора иде...

... Кинәт ишек кыңгыравы шалтырады. Шәмсениса абыстай сискәнеп китеп урыныннан торды, барып ишекне ачты һәм Солтанны күрүдән артына егылып китә язды. Аның каршысында чәчләре тузгыган, өсте-бите буялган, чалбарының төбе ертылган кияве басып тора иде.

Ләм-мим бер сүз дәшмәстән, ул эчкә узды. Үзенең бүлмәсенә кереп, эчтән бикләнде.

Аның артыннан ук Нурия дә кайтып керде.

— Солтан юкмы әле?

— Кайтты. Үз бүлмәсендә,— диде Шәмсениса абыстай. Башы белән бүлмә ягына ымлады.

Нурия барып ишекне шакыды.

Җавап бирүче булмады. Катырак шакыды. Эчтән:

— Нәрсә кирәк? — диде Солтан тавышы.

— Әтисе, матурым, ач әле.

— Иртәгә, — диде тонык тавыш.

Иренең тоткан җиреннән сындыра торган гадәтен белгәнгә күрә, Нурия ишекне бүтән шакымады, сорау-мазар да бирмәде. Солтанның тормышында ниндидер бер куркыныч хәл булганлыгын аңлап, әнисен кухня ягына алып чыгып китте. Озаклап сорашты. Күңеле алгысыды — йокысы качты.

Ире — эчкәрге бүлмәдә, үзе залда йокысыз төн үткәрделәр.

Шәмсениса абыстай бәләкәче Шәфика янында төн үткәрде. Аның да күзенә йокы кермәде.

Таң алдыннан гына уяулы-йокылы булып алдылар.

Нурия баш очында әнкәсенең ягымлы, көйле тавышын ишетте.

— Тор, бәбкәм, тор инде, эшеңә соңга каласың бит.

— Кияваңне уяттыңмы? — диде Нурия, күзен уа-уа.

— Уяттым.

— Тордымы?

— Юк.

— Нишләп?

— Белмим. Нәрсә дип әйтергә дә аптыраган. Йокысыннан да тормый кияү, дәшми дә, ята да ята,— дип тезеп китте гадәттә аз сүзле Шәмсениса абыстай.

Бу хәл Нурияне җылы урыныннан ашыгып торырга мәҗбүр итте. Ирен ул үзе уятты.

— Әтисе, ни булды сиңа, матурым? Бу ни хәл бу? Өстеңне дә салмыйча йоклагансың түгелме? Ярабби, кайда ерттың бу чалбарларыңны? Битләреңне кайда буяп бетердең?

Солтан күзенең берсен генә ачып, иренеп кенә хатынына таба карап алды да стенага таба борылып ятты.

Нурия, аның янына утырып, маңгаена кулын куйды.

— Әллә авырып киттеңме, ходаем?

— Китмәдем.

— Ни булды соң? Әйт инде, зинһар. Эшеңә соңга каласың бит. Нәби абзый килеп тә житкәндер инде. Аты белән урамда көтеп тора торгандыр.

Солтан торып утырды. Күлмәк изүе ачык, аннан аксыл-саргылт йон баскан күкрәге күренә, кылдай каты сары чәчләре балчык белән аралашып укмашкан. Нурия хәзер генә игътибар итте: иренең күзләре кызарып, шешмәкләнеп тора, димәк, ул төннең төн буе бер кәррә дә йокы күрмәгән...

— Әтисе, әйт бәгърем, тилмертмә безне. Ни булды?

Солтан, күзләрен кыса төшеп, сынап, хатынына карады, аннары башын түбән иде.

— Мине партиядән чыгардылар.

— Ә эштән? — диде өнсез калган Нурия.

— Партиясез кешене кем соң директор итеп тотсын?! Аңламыйсыңмыни? — диде Солтан ниндидер рәнҗүле салкын тавыш белән.

Нурия, тез буыннарының хәле китүен тоеп, әкрен генә урыныннан торды, стенага тотына-тотына ире янынннан чыгып китте.

Ул Солтанга ничек ярдәм итәргә кирәклеген белми иде әле. Ләкин күңелендә бөтен ачыклыгы һәм кискенлеге белән бер уй һөешып өлгерде: бу бәхетсезлеккә ул битараф карый алмый, әтисенә карата ясаган хатасын кабатлый алмый; сине партиядән чыгарганнар икән, үз көнеңне үзең күр, минем әле галим буласым, диссертация яклыйсым бар дип әйтә алмый. Аннары бит белеп тора: аның Солтаны, холкы белән кирерәк, төрпәрәк кеше булса да, күңеле белән начар кеше түгел. Кыю кеше, эшен ярата, хезмәтне бәхет дип таныган кешеләрне ихтирам итә белә. Мулла кызын гомерлек юлдаш итеп сайлаганнан соң да, үзен Нурия өчен табалаган чакларда да бер генә мәртәбә дә үкенгәне булмады.

Кулны кушырып утырудан мәгънә чыкмас, чарасына керешергә кирәк. Җыенып, өстен-башын рәтләп, институтка китте.

Профессор үз кабинетында иде. Ләкин аңа кадәрле Майский янына лаборант Таня Атаманова кереп өлгергән иде. Көткән чагында — минуты ай, сәгате елдай. Остазының бушаганын көткән арада Нурия күңелсез уйлар уйлап алырга да өлгерде. Татьяна белән профессор икәүләшеп аның урынына башка кандидатура эзлиләрдер кебек тоелып китте аңа... Аннары ул сеңлесе Шәфика турында уйлый башлады. Аны кая куярга? Үзләрендә калдырыргамы, әллә кирәдән Зартугайга илтергәме? Бирәдә калдырыр идең — Солтанның бик күңелсез чагы. Аның көйсезлеге балага тәэсир итмәсме? Зартугайга илтергә чыксаң, бару-кайту өчен генә дә бер атна вакыт кирәк. Июнь аенда, студентлардан имтихан алганда, профессор сиңа бер атна вакыт бирер дисеңме? Әллә Солтанның үзен генә җибәрәсеме икән? Алай дисәң, мондый хәсрәтле чагында ул авылдашларына күренеп йөрергә теләрме бит әле?.. Ләкин бармый калырга да ярамый, әтисенең төсе булган Шәфиканы ул, хәлләр ачыкланганчы, бер ел булса да Зартугайда тотарга, хәлләр ачыклангач, тагын үз яннарына алдырып, Казан мәктәбендә укытырга тиеш.

Нурия уйлары белән мавыгып киткән икән, ишектән тирләп-пешеп, кызарынып килеп чыккан Атамановане күргәч, ашыгып урыныннан торды:

— Нәрсә, Таня, әллә профессорның кәефсез чагымы?

— И җаным, кереп тә йөрмә, йоннарны туздыра картлач, әллә сул ягы белән торган инде йокысыннан! — дип бик хәтәр үртәнеп, авызын чалышайтып узып китте Атаманова.

Нурия аптырап калды. Керергәме, юкмы? Нишләргә дә белмичә, ишек төбендә таптанып тора иде, кулына тоткан калын кара кысалы күзлеген кулъяулыгы белән сөртә-сөртә, кабинетыннан Майский үзе килеп чыкты.

— Уразаева?! — диде ул гаҗәпләнебрәк.— Әллә йомыш бар идеме? — Күзлеген борын өстенә атландырды, кесәсеннән яшел тышлы бәләкәй блокнот чыгарып, нәрсәдер эзләп азапланды, тапмады, очлы кәҗә сакалын тырпайтып, башны югары-текә тотып сорады: — Бик ашыгычмы? Алайса, кәтегез. Мин хәзер — телефоннан гына сөйләшеп алам да, дөресрәге — телефоннан сөйләшергә секретарема заказ бирәм дә... Хәер, туктале, нигә дип мин сезне ишек төбендә тотам? Менә бит ул картлык, ә... Сез, Нуруся, кабинетка керегез дә, мине көтә торыгыз, мин хәзер...

Профессор әйләнеп керде. Ишек буендагы урындыкта ничектер бөрешебрәк утырган шәкертен култыклап алып, өстәл янына китереп утыртты. Рәсми дә, бер үк вакытта рәсми дә булмаган кайгыртучан тавыш белән әйтте:

— Тыңлыйм, Нуруся.

— Сез мине, зинһар өчен... гафу итә күрегез, Александр Николаевич... — дип тотлыгыбрак сүз башлады Нурия, йөзе шундук алсуланып кабынды. — Мин ни... үз исәбемә... бер атнага ял сорарга дип кергән идем...

Профессорның чал кашлары астына тирәнгә яшерелгән яшькелт күзләренә нур керде, алар чаткыланып кабындылар да Уразаевага, аның уңайсызлыктан алсуланган яшь һәм чиста йөзенә төбәлделәр.

— Нәрсә, күгәрченкәем, диссертация яклар алдыннан бераз гына ял итеп, нервыларны тынычландырып алу теләге тудымы әллә? Була торган хәл. Без яшь чагында... — дип уйнаграк тавыш белән башлаган иде, тик Уразаеваның бер дә чырае яктырмавын күреп, тукталды, шаян сүзләрен үзендә тотып калырга мәҗбүр булды. Сакалын учлады, күе зәңгәр җирлеккә нечкә генә ак сызыклар сызылган өр-яңа костюмының төймәләрен берсен дә калдырмыйча төймәләп куйды. Шуннан соң бик җитди чырай белән урыныннан күтәрелеп, салкын чандыр бармаклары белән Нуриянең — профессор белән бер үк мизгелдә аяк өсте калыккан шәкертенең инбашларына кагылды:

— Утырыгыз, утыр. Ни булды, күгәрченем? Әллә безнекеләрдән берәрсе рәнҗеттеме?

Тавышында борчылу, хәвефләнү, әле генә уйнак тавыш белән сөйләшә башлаганы өчен гафу үтенү сыман бер нәрсә дә бар иде.

Нурия, идәнгә төбәлеп, беркавым дәшми торды, керфек төпләрен әчеттереп күзенә яшь бөялүен тойды, моңарчы саклап торган ныклыгын чайпалдырып, күз яше белән әйтте:

— Ирем Солтанны... партиядән чыгарганнар... Нишләргә инде миңа, Александр Николаевич?..

— Батюшки! Ничек алай килеп чыкты соң ул? Аргыгы белән сул коммунист иде түгелме иregез? Колчакка каршы сугышкан, кулакларны кырган, колхозлар төзегән... Техникумдагы эше дә әйбәт бара дип сөйләгән идегез түгелме?

— Белмим инде. Нәрсә дип әйтергә дә белмим. Бәлки, минем зыяным тигәндер...

— Ничек аңларга боерасыз моны?

— Мулла кызы бит мин...

— Булса соң?! Менә мин дә дворян малае.

— Коммунист кешенең мулла кызына өйләнүен бик өнәп бетермиләр.

Профессорның йөзе бик кинәт караңгыланды. Кулларын артка куеп, ул шкаф яныннан әйләнеп килде. Тагын Нуриянең каршысына басып, сөякчел чандыр кулын аңа таба сузып әйтте:

— Борын салып йөрергә ярамый. Юк! Ярамый. Хәзер сез, Нурия Аббасовна, тормышның дилбегәсен үз кулыгызга алырга тиеш. Үз кулыгызга! Авыр чакта миңа таяна аласыз. Мин сезне яклармын.

## III

Тау асты урамыннан Казан суы буена чыкканчы ташландык тимерләр, аунап яткан иске мебель калдыклары, кеше буе булып үскән әремнәр, шайтан таяклары арасыннан барырга кирәк.

Аннары аксыл таллар, яшен сугудан янсә давыллар каерудanмы ботаклары сынып, гарипләнеп калган карт өянкеләр башлана.

Солтан Айдаров көн дә саен диярлек әнә шул чүп-чар өеме, гарип өянкеләр яныннан Казан елгасы тугайларына балык тотарга йөри; беренче көннәрне бик тә шыксыз, җанга ятышсыз булып тоелган ул күренешләргә әкренләп күз ияләште. Нәрсәгә генә ияләшми адәм баласы?!

Әле җир төзүче булып эшләгән заманнарда ук алган, инде төсләре уңып, кайбер урыннары сизрәп калган юл кожаның көн дә саен кия тор-

гач, кожанга шул хәтле ияләнде Солтан, хәтта кием-салымның да адәм баласына кыенлык килгән чагында дус һәм иптәш була алуына ышанды.

Тал чыбыгына чорнап куйган кыл җепне сүтеп, кармакка суалчан каптыргач, иплəп кенә су өстенә ыргытасың. Калкавыч таллар янында-гы күләгәле урынга килеп төшә дә тыныг кала. Беренче мәлгә син дә тынасың, калкавычка җан кергәнен, аның бата-чума уйнаклавын көтә-сең. Көтә-көтә арыйсың, уйларың үз юлы белән ага башлый...

«Райкомда якларлар, күрәләтә батырмаслар», — дип өмет иткән идең. Өметең акланмады. Суконный райкомының бюросы җыелыш карарын раслады һәм синең партбилетыңны өстәлгә чыгарып салуны таләп итте.

Бу инде өметнең сүнүе иде. Һәм син үзеңне көпә-көндез таланган төсле хис иттең. Синең дөньяда торасың килми, башкалар белән тү-гел, хәтта нинди яратып өйләнгән, ничәмә еллар гөрләшеп чүкердәшеп яшәгән хатының Нурия белән дә сөйләшәсең килми, юк кына нәрсәгә дә кабынып китәсең, шул сәбәпледер син аны ничәмә-ничә мәртәбә рән-җеп еларга, кайнар күз яше түгәргә мәҗбүр иттең бит инде. Андый чак-та үзеңнең дә йөрәгеңнән каннар тамды. Ләкин тормыш аяусыз, тормыш синең бәгыреңне талап торды.

ВКП(б) сафларында булу — синең яшәвең иде бит. Синең көрәшең, бөтен барлыгың иде.

Беренче айларны син кино-театрларга, җыелышларга, гомумән, ха-лык күп җыела торган урыннарга бармаска тырыштың. Андый урында кайсыбер танышыңның очравы, төзәлмәгән яраңа саксыз кагылуы мөм-кин иде. Ләкин, дөнья булгач, гел өйдә генә бикләнеп ятып та булмый. Кибетләргә чыгарга, азык-төлекне кайгыртырга кирәк. Китаплар һәм микроскоп җене кагылган Нурияңнең күзенә ак-кара күренми хәзер. Гаиләдә килеп туган рухи кризистан һәм матди мохтаҗлыктан ул сине фәнни диссертациясен яклап коткармакчы була, алдына-артына кара-мыйча ашыгып, каударланып яши. Иртән торасың — ул юк, кичен ята-сың — тагын юк. Кайдадыр, төнге уникеләр тирәсендә, йокылы-уяулы килеш син коридор ишегенең ачкыч белән ачылганын ишетәсең, хаты-ныңның кухня ягында ашык-пошык кына аш җылытуын, ашык-пошык кына тамак ялгап алуын тоеп ятасың. Рәхмәтле күңелең аны кызгана. Шушындый тормыш өчен яратылган кешемени инде ул?! Син гаиләңне туйдырып, өстен-башын карап, халык арасында затлы итеп йөрткән заманнарда Нурияң алай кабаланмый, дәрәҗәсен белеп кенә киенә, тумыштан чибәр, нурлы, ак тиреле йөзенә, көйрәп торган шомырт кара күзләренә, зифа буена каурыйлы ак эшләпә, билдән өздереп торган креп-дешин күлмәк бик тә килешә; биек үкчәле туфлидән, башны текәрәк тотып узып киткән чагында ир-атның күзе ихтыярсыз аңа иярә иде түгел-ме соң?

Габбасның төпчеге Шәфиканы алар — Шәмсениса белән Нурия — үчта гына йөртәләр, ихлас ярату белән яратканга ул аларның юанычы, күңел бөеклеге, бәйрәме иде. Син техникумнан чыгарылгач, бәләкәчнең шуклыгын, курчак бәбиләре белән сөйләшеп, шаулап уйнавын күтәрә алмас булдың. Син гаепле түгел идең моңа, синең кыл кебек тартылган нервыларың түзмәде. Һәм сизгер күңелле Нурияң бәләкәчне Зартугайга кайтучы авылдашы артыннан әниләренә кайтарып җибәрде. Өй тынып калды. Шәмсениса карчык үз эченә бикләнде. Нурияң эшенә күмелде.

Тора-бара, синең дә хәсрәтең кими төшкәндәй булды. Урамда очрап, хәл-әхвәлеңне сорашкан танышларыңа яки Зартугай якларыннан килеп чыккан элекке сабакташларыңа син, бик артык җәелеп китмичә генә: «Ярый, бер көе генә яшәп ятабыз», — дип әйтә башладың. Газаплы, мәшәкатьле булса да, тормыш салмак бер җаена төште шикелле... Хәер, син генә аны шулай уйладың, үзеңне шуңа ышандырырга тырыштың. Кылына кагылмаган чакта гына скрипка зыңламый, зыңлап китсен өчен, аңа аз гына кагылу да җитә. Шулай бер көнне, базардан кайтып килеш-

ли, бер абзый очрады сиңа. Иңбашына өч-дүрт яшьлек кыз баласын күтәргән. Син шул кеше артыннан аңа орынып диярлек бара идең. Кыз бала, этисенең җилкәсенә салган башын күтәреп, сиңа дәште:

— Дяденька, ты умный или дурак?

— Так себе, доченька, — дигән булдың син.

Ул чагында бу бик тә гадәти бер сүз булып тоелган иде сиңа. Кем белә, бәлки, сабый бала, нәкъ менә сабыйлыгы аркасында, олылардан отып калган сүзен механик рәвештә әйткәндер. Әмма өйгә кайтып, радионы тоташтыргач, синең иң яраткан җырың «Олы юлның тузаны»н Гөлсем Сөләйманова үзәкләрне өзерлек итеп җырлап җибәргәч, тамагыңа төен килеп тыгылды, әллә кайчангы истәлекләрең белән бергә, бүгенге хәсрәтең өскә калкып чыкты. Теге көнне очраган кыз баланың: «Акыллымы син, абый, тилеме?» — дигән сүзләре күңелеңдә кабат яңарып, җаныңны ачыну-ачыргалану белән тутырды. Ә бит син йомшак кеше түгел идең.

Әйе, нык иде синең характер. Моннан унбиш еллар элек, көзге караңгы бер төндә, син, үзегезнең бәләкәй чаптарга атланып, әтиеңнән рөхсәт-мазар да сорап тормастан, Азин дивизиясен эзләп киткән идең. Тоташтан ике ел буе кургаш яңгыры астында яшәдең, җир өстен снаряд актарганны, колак төбендә пуля чыелдаганнарны күрдең. Ике ел буена юеш окопларда ятарга, баш өстеңдә яшендәй кылыч уйнатып, атакага барырга, үлем белән йөзгә-йөз очрашырга туры килде. Язмыш сине караңгы гүргә салырга ашыкмады. Ә бит чынлап торып уйласаң, синең кара гүрдә ятасы көннәрең күп булды.

...Октябрьнең томанлы бер киче. Караңгылык эченнән һожар ялкыны йолкып алган өянкеләрнең, йөзәр яшьлек карт каеннарның ябалдашларында чагыла сугыш гарасатының шәүләләре. Кама иделендә «Ваня-коммунист» пароходы яна. Авыл артындагы калкулыктан, Тугызбүй якларыннан туплар ухылдаганы ишетелә. Кама иделендә янган хәрби пароход, ярдәмгә чакырып, өзлексез үкерә:

— Гу-гу-гууууу... Гу-гу-гууууу...

Дошман снаряды төшүдән зур бер чокыр хасил булган урында, салам түбәле агач йортның коймасы буенда, Азин атыннан сикереп төште:

— Айдаров, минем янга!

Ауган койманың теге ягында, болдыр буендарак, чалкан яткан берәүне күрделәр.

Якын килгәч, тетрәнеп киттеләр.

Койма буенда ук — япь-яшь кыз. Күлмәк итәге әдәпсез кайтарылган, ап-ак тулы боты буйлап кып-кызыл кан юлы сузылган.

Азин кызның күлмәк итәген ипләп кенә япты, Солтанга сугышчыларын чакырып китерергә кушты.

Кызны, арбага салып, урам буйлап алып киттеләр.

Авыл уртасында Азин сугышчыларны сафка тезәргә боерды.

Быргы тавышы, пожар ялкыннары биегән авыл урамнарына сибелгәч, командир, кызыл тасмалы папахадан, бөркет канатлары төсле җәелгән киң җиләннән, озын кунычлы сафьян итектән, арба өстенә сикереп менде, сугышчылар өстенә ут кебек кайнар сүзләрен ташлады:

— Иптәшләр! Кызыл сугышчылар, бөркетләрем! Без менә хәзер генә ак офицерларның, ак генералларның адәм әйтеп, адәм ышанмастай палачлыкларына шаһит булдык. Арбада яткан унҗиде яшьлек кыз бала — өченче көн сугышта һәлак булган пулеметчы Василий Кондратьев кызы. Ул кызның генерал-килмешәкләргә нинди зыяны тигән?! Ул бит мылтык тотып сугышкан кеше түгел, ул әле тормышын башлап җибәрергә дә өлгермәгән кыз бала. Аны аклар көчләгән. Ул гына җитмәгән аларга — үтереп үк киткәннәр. Күпме түзәргә мөмкин?! Дошманның кем икәнен без аңа мылтык белән, эчен актарып салган кызыл

штыклар белән аңлатыйк! Җир йөзеннән сорыкортларны, палачларны, хезмәт кешеләренең канын кашыклап эчкән ерткычларны рәхимсез рәвештә кырсак кына, аларга карата һәр адымыбызда нәфрәт уты саклasak кына җиңүгә ирешә алырбыз. Канга — кан! Үлемгә — үлем! Соңгы сулышка кадәр, дошманны себереп түккәнчегә кадәр! Алга, бары тик алга гына!

...Ул көннәргә инде унбиш елдан артык вакыт узып киткән. Күпме җилләр искән, күпме болытлар агылган, күпме сулар аккан. Пулеметчының мәсхәрәләнгән кызы, Азинның пожар ялкыннары эчендә сөйләгән утлы сүзләре, Тимер дивизиянең дошман гаскәрен Кама ярында, куып җитеп, кырып ташлавы, ярсып кешнәгән атлар, җирдә аунаган канлы гәүдәләр, ыңгырашкан яралылар әле дә күз алдыннан китми Солтанның...

Шуларны уйлагач, аның зиһене ачыла төшкәндәй була. Ул җир йөзендә моңарчы әрәмтамак булып яшәмәвен, социализм иленә файдалы кеше булганлыгын аңлый. Аңа ничектер җиңелрәк булып китә.

Икенче бер мизгелдә ул янә кемнәргәдер үпкәли. Райкомда әңгәмә вакытында әйтә алмый калган сүзләрен күңеленнән кабатлап, үзен-үзе ярсыта. Ярый, техникум партҗыелышында сине партиядән чыгарырга дип карар кылсыннар ди. Син кемгәдер ярамаган, кемнеңдер синнән аласы үче бар, ә бит райкомда андый кеше юк, өлкә комитетында да, Үзәк Комитетта да андый кеше юк. Ул оешмаларда аның анкетасы бар, автобиографиясе бар, аларда акка кара белән аермачык итеп язылган: Солтан Айдаров — Алабуга өязе, Пәнҗәр районы, Зартугай авылының ярлы крестьяны Садыйк семьясында туып-үскән; үзе дә, абыйсы Шәяхмәт Айдаров та революцияне яклап сугыштылар, олы абыйсы Мөхәммәтша Ижевск шәһәрендә кызыл гаскәрләр өчен корал койды, эшче намусына тап төшермәде диелгән. Алар гаиләсендә, алар нәселендә Совет властена каршы чыккан бер генә кеше дә юк бит. Әйтик, әтисе берара байлар куштаны булып йөргән икән, анысы да наданлыктан, гомер буе ачлыкка, хәерчелеккә дучар булып, кая барып сыенырга белмәгәннән генә бит...

...Солтан, әнә шулай иксез-чиксез уйларына бирелеп, Казан суы буенда утыра.

Өйгә балык алып кайтканы юк аның. Алып кайтса да песигә бирерлек комкорсаклар гына алып кайта. Әмма көн саен болын тугайларына чыгу, Казан суы буенда япа-ялгызы утырып кайту аның күңелен тынычландыра, кирәкмәгән гамәлләрдән, артык адымнардан саклап килә.

Шулай бер көнне уйларын уйлап, су өстендә тыныч кына яткан калкавычына күрер-күрмәс күзләре белән текәлеп утыра торгач, ул, үзе дә сизмәстән, борынгы бер моңлы җырны сузып җибәрде:

Олы юлның тузанында
Калды баскан эзләрем,
Ерак калган яшьлегемне
Шул юллардан эзләдем...

Иртәнге саф һавада, Казан суы тугаенда, тавышы аның көчле һәм тигез булып чыга, сулышы киң, җырлавы рәхәт иде.

— Слу-шааай! — дип кинәт дәшкән тавышка сискәнеп, артына борылып караса, — кып-кызыл майкалы, яланаяклы, колга буе бер әүлия янында басып тора.

— Слу-шааай! Искиткеч шәп мондый тавышны син каян алдың? Әрәм ята бит бу тавыш. Слу-шааай...

Солтан аның моңсу дөньясына рөхсәтсез килеп кергән бу әрсез кешегә:

— Ә син кем буласың? — диде.

— Артист мин, артист, — диде Колга. — Ә син кем? Каян килде сиңа шундый да көчле, житмәсә әле шундый да моңлы тавыш?

Сөйләшеп киттеләр. Килүчебезнең исеме Мөслим, фамилиясе Кунафин икән. Филармония артистларын авылларга алып йөри икән.

— Слу-шааай, әйдә минем бригадага. Валлаһи дип әйтәм, бер ел тулар-тулмаста мин сине республикага танытам. Синдәге төсле тавыш булсамы, и жүлә-әәр, синдәге төсле тавыш булса, мин бригадамны инде әллә кайларга, Каф тавы артларына илтеп житкерә алган булыр идем...

Бер ел тулар-тулмаста ул Солтанны данлы жырчы итәрме-юкмы, анысы билгеле түгел иде әле, әмма алар ул көнне Казан елгасы буенда кул сугып вәгъдә куештылар, һәм Солтан Айдаров филармония артистлары белән авылларга чыгып китте.

Башка вакытта булса, Солтан моңа, әлбәттә, риза булмас иде, профессиональ сәнгать белән һәвәскәрлек сәнгатенең аермасын ул яхшы белә. Әмма сине бер жиргә дә эшкә алмаган чакта, ә синең эшлисең, илгә файдалы кеше буласың килгән чакта эшнең тегесе ярый, монысы ярамый дип бигүк сайланып тора алмыйсың.

Беренче көннәр, сүз дә юк, Солтанга канәгатьлек алып килде. Айлар буе сагышлы-шомлы уйларыңа батып ятканнан соң халык арасына чыгу, илгә кирәкле эш эшләвеңне тою рәхәт иде. Элекке мәчетләрнең манарасын кисеп төшереп ясаган авыл клубларына тыгызланып тулган халыкның, тормышларын авыл белән бәйләгән кешеләрнең сиңа гөрләтеп кул чабуларын, синең моңлы да, ашкындыргыч та жырларыңның алардан күз яше бәреп чыгара алуын тоеп тору — кайсы гына жырчының күңелен күтәрмәс.

Ул арзанлы такмаклар, зәвыксыз жырлар белән дан казанырга тырышмады. Халыкның гасырлар буена килгән озын моңлы жырларын репертуарына кертте. Биредә, әлбәттә, Солтан әле малай чакта ук басуда жырлаган, заманында Хафиз солдатны таң калдырган «Иделкәем алтын», «Олы юлның тузаны», «Кара урман»нар да бар иде.

Баштарак барысы да бик көйле барды. Әмма концертлар бары тик концерт кына булмайча, жыр-бию өлеше башланганчы бригаданың бер егете, партия өлкә комитеты жибәргән лектор, халыкка илдә һәм дөньяда барган яңалыкларны сөйли башлагач, Солтанның күңеленә тагын вәсвәсә төште.

Уралда, Себердә, Төньяк котыпта дөньяда тиңе булмаган батырлыклар эшләнә. Совет очучылары полюска барып житкәннәр. Геологлар Уралда, тайга урманнарында, Себер киңлекләрендә һәм Кола ярымутравында казылма байлыклар эзлиләр. Магнитка төзелешендә татар егете Галиуллин дан казанган, Мәскәүдә метрополитеннар сафка керә — авылларда инде ул хакта жыр чыгарганнар («Их, метрополитен, яратам, ни хәл итим»). Березники каласында Идел-Кама грузчигы Мирсәет Ардуанов завод салган, ул төзегән татар-башкорт егетләренең бетончылар бригадасын Урал төзүчеләренең кызыл кенәгәсенә керткәннәр...

Баштарак боларны Солтан ишетми, ул концертның жыр өлешендә генә катнаша иде. Соңга табарак, лектор башка бригадага күчеп, илдә барган бөек төзелешләр — Днепрогэс, Чиләбе трактор заводы, Магнитка, Березники хакында, Алексей Стахановлар, Валерий Чкаловлар, котып баһадирлары турында үзе халыкка сөйли башлагач, аның элекке ярасы янә дә кузгалды, моңлы жыры белән халыкны моңландырып йөрүе бик бәләкәй нәрсә булып күренә башлады.

Ул кемнәрнеңдер социализм эшенә турыдан-туры катнашуларын, яңа жәмгыять үссен, ныгысын өчен жан-фәрман тырышуларын, ә үзенең гел читкә этәрелүен, булган барлык көченә һәм сәләтенә эшли алмавын аңлап, аны тормыш агымыннан алып ташлаучыларга чамасыз рәнжеде.

Шуннан соң инде аның филармония бригадасы белән йөрүе кирәксез бер эш булып калды.

## IV

Шәфиканы авылга кайтарып җибәргәнгә өч айлар чамасы вакыт узганнан соң, урамда шаулап яфрак коелган чагында, кияве Солтан якын бер иптәшенә китеп баргач, карчык шулай кичкырын кызы Нурия янына килеп утырды.

Озак кына дәшми утыргач, керфекләре коела башлаган, төпкә баткан моңсу күзләрен күтәреп, Нуриягә әйтте:

— Кызым, карале, җәй үтеп тә китте бит. Урамда — сентябрь. Әллә көннәрне тәмам суытып бетергәнче тәвәккәллим микән?

— Нәрсәне? — диде Нурия аңламыйча.

— Бик матур булып үсеп килә бит ул. Бигрәкләр дә матур бит ул...

— Кемне әйтәсең, әни? Ачыграк итеп сөйлә әле. Минем бит башым анатомия белән тулган.

— Соң инде... ни бит инде... аңламаган булып кыланма инде... Шәфиканы әйтәм бит... — диде Шәмсениса абыстай. Ул аяк өсте торып басты, бик сәер такмаклап, ашыгып сөйли башлады: — Үләм бит инде. Саргайтыплар бетерәсез бит инде. Көннәр буе япа-ялгызым, кичләр буе япа-ялгызым. Син шул мәетләр яра торган җиреңә китәсең дә олагасың, кияү кайчан карама су буенда... Кайтса кайта, кайтмаса кайтмый — әвене янган кеше төсле. Үзем карадым бит мин ул Шәфиканы, үзем кендек әбисе булдым... Бер күрергә тилмертеп үтерәсез бит инде...

Нурия сизенеп йөри: әнисе «бәләкәчне» Габбас мулла төсе итеп сагына.

— Әгәр инде вакытыбыз юк дип әйтәсез икән, беркая да чыгып йөри алмыйбыз дисез икән, ике дә уйламыйм, үзем барып алып кайтам, хәтта ки юлга-мазарга акча да сорамыйм. Әнә бер көнне Черек күл артындагы Сәүбаннарга барганыем, былтыр үлгән әниләренә бөтен коръән чыгарттырдылар, уч тутырып акча бирделәр. Әле менә бәләкәчемне апкайтырга кирәк була-нитә калса дип кенә әйтми торадырыем. Анысы гына җитмәсә, артык-портыгымны сатармын. Әллә ни гомерем калмагандыр, аларны бит үзем белән зиратка алып китәсе түгел...

— Карале моны, карале бер генә! Нәрсәләр сөйли бу, ә?! — диде Нурия күзләрен түгәрәкләндереп. — Кияվең партиядән чыгарылган коммунист, кызың институтта укытучы. Авызыңны чамалабрак ач син, әнкәем. Бирерләр сиңа коръән чыгартуны, ник барганыңа үкенеп бетә алмассың!

— Ачулансаң да барам, эт итеп тиргәсәң дә... — диде карчык, кычкырып елап җибәрмәс өчен, авызын кулы белән каплады. Нурия аның җыерчыклы саргылт бите буйлап аккан күз яшьләренә карап, күңеле тетрәп, әкрен генә әйтте:

— Шәфиканы алып кайтырга рөхсәтем юк. Зартугайга сәфәр кылып кайтырга рәхсәт бирәм...

Әнисе Шәмсениса Зартугай якларыннан танымаслык булып үзгәреп кайтты. Сүзсез калды, моңсуланды. Ләкин Нурия вакыты җитми сорарга базмады.

Шулай бер кичне бик озак алъяпкыч итәге астына кулларын куеп утыргач, Шәмсениса абыстай иң яшерен серен әйткән сыман, шыпырт кына:

— Беләсеңме... тегенең тагын ике малае туган бит. Игезәкләр, — диде Нуриянең колагына.

— Кемнең ул «тегенең»? — диде Нурия сәерсенеп.

— Бигрәк аңгыра бәрәңгә әйләнеп барасың син, кызым. Кемнең булсын, Хәнифәнең, яшь әнкәңнең... — диде Шәмсениса абыстай, кызының бер үк сүзне кат-кат сөйләтүенә кәефе китеп.

Соңгы хәбәр Нурияне өнсез калдырды.

— Йа ходай! Бар икән күрәселәребез! Син ни сөйлисең, әнкәй? Нигә, Хәнифә түти җилдән бала тапканмыни?!

— Нигә җилдән тапсын? Әткәңнән авырлы булып калган. Әхмәт белән Мәхмүт дип кушканнар атларын. Аңламыйсыңмыни, тол хатынга инде, шулай булгачыннан, Шәфика кирәк түгел. Әнә шул ике малайны карап-багып үстерә алса, рәхмәт әйтерсең.

Нуриянең башы әйләнеп китте. Күңеленә берьюлы томырылып, өермәләнеп шатлык та, хәвеф тә кереп тулды. Ике малай! Игезәкләр! Габбас нәселе, Уразаевлар! Ярабби, димәк, аның кыз туганы гына түгел, ир туганнары да булачак. Габбас яши болай булгач, Уразаевлар яши!..

Шәмсениса түтинең Зартугайга барып кайтканнан соңгы үзгәрүе бер Хәнифәгә генә бәйле түгел иде. Авылда аның яшьтәшләре, бергә гомер иткән карчыклар гүр иясе булганнар. Баксаң-күрсәң, ул үзе генә калып бара икән ләбаса...

Озакламый аны тагын сагыш басты. Ул инде урамга ипи чиратларына чыга алмый, Нурия аны чиратка чыгарырга курка да. Аллам сакласын, шунда ялгышып башка берәр җиргә китеп барса... Хәзер аның телендә Шәфика да Әхмәт белән Мәхмүт. Кайчакларда ул төнлә Нурияләр бүлмәсенә килеп керә:

— Кызым, кияү, торыгыз әле, тор. Ишек шакыйлар бит, Шәфикам уеннан кайтты ахрысы, ишек төбендә торып туңа күрмәсен, — дип саташкалап та сөйләп куя иде.

Ул хәтта бер тапкыр көндезен, көзге суыкта урамга күлмәкчән генә чыгып, бәләкәчен эзләп йөргән.

Нурия институт лабораториясеннән соң гына өйгә кайтып керсә, әнисе караваt буенда үзен-үзе кочаклап, үзалдына сөйләнеп утыра:

— Без әле синең чәчләреңне үрербез. Без әле сиңа матур күлмәкләр тегеп киертербез.

Нуриянең җаныннан шомлы бер уй узды: харап булган бу, авырган. Акылдан ук язуы микәнни?

Мөмкин хәтле йомшак тавыш белән:

— Әнкәй, нишләп идәндә утырасың? — диде Нурия.

Шуны гына ишетүе булды, Шәмсениса абыстай дерт итеп сискәнде дә идәнгә авып китте.

Нурия, йөгереп килеп, аны култык астыннан иңләп кенә күтәрде, көч-хәл белән караватка китереп салды. Маңгаена кулын куйды — ут кебек кайнар. Температурасын үлчәде — утыз тугыз ярым.

Сабыйларда һәм өлкәннәрдә бик авырдан уза торган үпкә ялкынсынуы башланганны сизеп, профессор Майскийга йөгерде.

Остазы булышлыгы белән Казанның атаклы терапевты Әбүбәкеровны чакырттылар. Килде терапевт, озаклап карады, маңгаеннан күзлеген алып, тартма эченә салып куйгач, Нурия белән бергәләп күрше бүлмәгә керде һәм әйтте:

— Врач Уразаева, әнкәгезнең яше олы, йөрәге шәптән түгел, атеросклерозы да көчле, төрле хәл булуы мөмкин, һәр сәгать әзер булып торыгыз,— диде, дару рецептларын Нуриягә тоттырды.

Институттан Нуриягә әнисен карау-багу өчен дип ял бирделәр.

Әнисе ятып тора, Нурия аның янында утыра. Урынын кабарта, җылы сөтне, компотны өзми.

Әнкәсе, сөт эчкәч, йокыга талгандай була, күзләрен йомып ята. Ул да түгел, күгелҗем төскә кергән күз кабакларын ачып:

— Шәфика бакчадан кайтмадымы әле? — дип сорый.

Аны тагын да ныграк борчымас өчен, Нурия тыныч һәм ягымлы тавыш белән:

— Юк әле, кайтмады әле, — ди. Күңеленнән уйлый: «Шул бала белән саташып авырды инде мескенем...»

Бераздан авыруның исенә кияве төшә:

— Кызым, Солтанга ашарга пешердеңме?

Авырый башлаганына бер атна тулганда, җомга көнне иртән ул Ну-

риянең озын чәч толымын, кулына алып, әкрен генә сыйпаштыра башлады:

— Кайгырма, балам, үлем үкенечсез булмас.

— Ни сөйлисең син, әни?

— Белеп сөйлим мин, балам. Үлем килгәненә үкенмим. Бер генә ел алдан килгәненә хәсрәтләнәм. Синең бит менә галимлегең якланмаган килеш кала. Кыен булыр инде үзеңә генә. Шәфика кызыбызны да алып кайта алмадык...

Өйлә вакытларында Нурияләргә Зәйтүнә мөгаллимә килде. Ул төз гәүдәле, алсу битле, нәзакәтле итеп киенгән иде. Ләкин Шәмсениса абыстай аның буен-сынын да, нәзакәтле киемнәрен дә бәяләрлек түгел иде шул инде. Чөнки инде ул берәүне дә аермый, кызы Нуриянең генә кулын үз кулыннан җибәрмичә тотып ята иде.

Бәхилләшергә дип күрше карчыклары җыела башлады.

Нурия, ым кагып, Зәйтүнә апасын үзе янына чакырды:

— Апа, ясин чыгартырга кирәктер бит инде? Абыстай кеше иде бит, — диде.

— Чыгартыйк, бәбкәм, безгә рәнҗеп китмәсен, — диде Зәйтүнә мөгаллимә.

Кичке сигезләр тирәсендә Шәмсениса карчык, үлем алды газапларыннан артык интекмичә, сабыр гына җан бирде. Нурия әнисенең кулны ныграк кысып куюыннан вакыт җиткәнне аңлады.

Карчыклар көрсенешеп куйдылар. Белгән догаларын укырга керештеләр. Аваз салып еларга итенгән Нурияне шундук тыйдылар. Мәрхүмәнең гәүдәсен теге дөньяда күз яшьләре күлендә йөздерәселәре килмәде.

Аяклы зур көзгене кижеле зур сөлге белән каплап куйдылар...

## V

Габбас мулланың тол калган Хәнифәсен Зартугайлар, ире асылынып үлгәч, бик тә кызганганнар иде.

«Элекке заманда да гомере асраулыкта узды, мулла йортында да рәхәтлек күрә алмады, инде менә совет чыккач та бәхете юк.

Ире белән икәүләп җир тырмашып салган үз йортында торырга да хакы юк бит мескенкәйнең. Аны да тартып алдылар...» — диде халык.

«Бигрәкләр дә бәхетсез икән Габбас, мордар үлем белән китүе генә җитмәгән, нәселен саклап барырдай ир баласы да калмады бит, ичмасам», — дип офтанучылар да булды.

Әмма алар ялгышалар иде.

Габбас мулла вафат булып, берме-икеме ай узуга Хәнифә үзенең Габбастан йөкле булып калганын сизде. Тагын берничә айдан авылның бер башыннан бер башына, өйдән-өйгә хәбәр таралды:

— Габбасның кече катыны бала табачак!

— Габбасның кече катыны зинадан бала табачак!

— Парабби, Габбас, исән булса, бу хурлыктан тагын бер мәртәбә асылыныр иде.

Гайбәтне күпертү дигәндә, авылдан да ышанычлырак урын юк. Анда син тәрәзә шакысаң — төн кунды, төн кунсаң — гөнаһ кылды, диләр. Ләкин бер хикмәте бар — булмаган корым биткә ягылмый бит ул.

Төп-төгәл вакыты җитеп, Зартугайда каз өмәләре башланган бер чорда Хәнифә дөньяга игезәк ике малай китерде. Берсеннән-берсе таза, берсеннән-берсе көр тавышлы, төс-битләре белән дә коеп куйган Габбас инде менә! Тупырдашып үсә, мин сиңа әйтим, ике игезәк! Авыл халкының күңеле канат какты. Хур итмәде Хәнифә аларны. Габбасның нәселен саклап калды.

Зартугайлар, дәррәү кубып, «силсәвит» Мәрдән белән «партионный

башлык» Каһармановның якасыннан урап алды. Даешь йортны Хәнифәгә — монда хәзер мулла-мунтагайның дәһеле юк. Батрак Хәнифәгә, аның балаларына йортны кайтарыгыз. Юкса Мәскәүгә язабыз!

Мурзин да, Каһарманов та андый янаулардан гына тез буыннары сыгылып төшә торган адәмнәр түгел иде. Үз гомерләрендә, кулакларны йортларыннан себереп чыгарган чакта, шөкер, алар янау-куркытуларны күп ишеттеләр. Кыска көпшәле кулак мылтыгыннан атылган пулялар да аларның колак яныннан сызгырып узгалады. Ләкин бу янау белән ул замандагы янауның аермасы бар. Болар белеп яный, закон нигезендә яный. Төптән уйлап баксаң — Хәнифә бит, чыннан да, авылның иң ярлы кешесе кызы, муллага да маена сикергәннән түгел, ничарадан бичара гына чыккан кеше. Аннан тагын шул ягы да бар бит әле — авыл халкының ышанычы белән уйнарга ярамый. Бер уйнарсың — узар, икенче узар, өченче мәртәбәсендә ул сине башың белән җиргә мәтәлдереп төшерер.

Озын сүзнең кыскасы — колхозны да екмаска, Хәнифәне дә ятим балалары белән адәм рәтле яшәтергә кирәк.

Һәм менә, игезәкләр туганга биш-алты ай узуга, мулла йорты дип тартып алынган ике катлы, чарлаклы йортның аскы катына ике кара чутыр малае һәм алты яшьлек Шәфикасы белән бергә Хәнифә кайтып утырды.

Йортның өске катын да даулап караган иде халык. Пәнҗәр төбәгендә райком секретаре булып эшләгән Шәяхмәт Айдаровка ходатайлар да барып йөргән иде, мулла-мунтагайны, бай-бәтчәне җен урынына күргән «ата коммунист» Шәяхмәт сүзне озакка сузып тормаган:

— Игезәк бала таптымы? Бик яхшы! Без алардан совет граждан-нары ясарбыз! Бүреккә салсаң да бүре булып кала торган буржуйчыклар кирәкми безгә. Йортнымы? Йортны бер эш тә эшләтмисез. Канцелярия өске катта калсын, Хәнифәне аскы катка урнаштырыгыз. Совет власте берәүгә дә ачтан үләргә ирек бирми, шул аскы катта ук сепарат ачыгыз. Габбас мулланың ятимнәре шунда туенып, аякка басар, калган ягын вакыты җиткәч кайгыртырбыз!

Бу сүзне ходатайлар сәгате-минуты белән партячейка секретарена һәм колхозлар оешканнан бирле председатель булып эшләгән Миңнулла Батыршинга җиткерделәр.

Әнә ничек үзгәрә дөньялар: Хәнифә өйле генә булып калмады, колхозның сепаратын тотучы да булып китте бит әле.

Элекке елларны, революция дигәннәре булганчы, авыл мужикларының җыелып гәп суга, ил-көн хәбәрләрен сөйләшә, сугыш-орышлар китергән яман эшләрне уртага салып сөйләшә торган урыны каравыл өе булса, хәзер, колхозлар оешкач, ир-ат белән хатын-кыз тигез хокуклыга әйләнгәч, андый урын булып сепарат йорты калды.

Хәнифә өчен дөньяның күңеллерәк заманнары килде.

Хәзер көн саен авылның түбән очыннан да, югары очыннан да Хәнифә йортына кеше агыла. Иртәнге якта ирләр, кичке якта — хатын-кыз.

Авыл тутырып көтү кайткач, Зартугай үзәннәренә, якындагы урманнарга көтү күтәргән тузан ятып, җылы сөт исе борыннарны кытыклап тынгач, берәм-берәм дә, парлашып та, төркемнәре белән дә яшь киленнәр, яшь кызлар Хәнифә йортына агыла башлый. Сепаратка сөт аертыр өчен генә килми кызлар. Авыл урамнарын балкытып, алмалы көянтәләрен иңенә салып, яшел чирәмле урамнардан көязләнеп узар өчен, мыек кына чыгып килгән егетләрнең күз явын алыр өчен дә килә. Яулыкларның кәттәсе, чулпыларның көмеше, чыңлау тавышы әллә кайлардан ишетелә торганнары сандык төпләреннән чыга башлады.

Хикмәти хода, ни сәбәптер, әнә шул урамнарны балкытып килә торган көмеш чулпылы кызлар, бигрәк тә яшь киленнәр Хәнифәнең әле таушалмаган, озак еллар бикләнеп яткан яшьлеген өскә калкытып чыгардылар. Үз йортына чын хуҗадай кайтып утыру сәбәп булгандырмы,

игезәк ике малай табу килештеме — ул күзгә күренеп яшәрде, тәненә ит кунды, бит алмалары теләсә кайсы мут ирнең авыз суларын китерерлек булып алсуланды.

Зартугайларның телендә хәзер яшь киленнәр түгел, Зартугайларның телендә хәзер Хәнифә. Ирләр тел шартлата: ай хода, бирсә дә бирер икән кешегә мөлаемлыкны! Бирсә дә бирер икән хатын-кызга затлылыкны! Баксаң-күрсәң, аксөяк морзалар нәселеннән дә түгел бит, егерменче елны ачтан үлгән Рамазан солдат кызы...

Житте бер көн, Зартугай ирләре, юк йомышны бар итеп, колхоз кәнсәләренә килә башладылар. Бүген-иртәгә кияүгә чыгасы кыз-кыркын, сепарат хуҗасы Хәнифә алдында үзләрен кимсетергә теләмичә, алъяпкыч белән күлмәкләрнең бала итәклесен тектерделәр, чабатаның унберлесен, һич югы тугыз юкәдән үргәнен киеп алдылар.

Хатын-кыз мәсьәләсендә үзен төшеп калганнардан санамаган, мутлыгы, күрше тавыгын каз дип, күрше хатынын кыз дип санавы белән дә дан алган Бүре Бадулның Хәнифәгә беренче булып күзе төште. Ләкин гыйшкың никадәрле көчле булмасын, койрык чәнчеп, көпә-көндез, тиктомалдан Хәнифә йортына барып кереп булмый. Бадул җай эзләде. Тол хатынның берәр йомышы чыкмый калмас дип өметләнде. Чыннан да, андый йомыш озакламый чыкты. Көннәрдән бер көнне сепарат ватылып китте. Тимерче Лотфига әйтеп карадылар, колхозга беренче тракторны алып кайткан күпер төбе Госманга гозерләнеп бардылар — берсе дә булдыра алмый. Бу хәбәр Бадулга барып житте.

Бадул атна буе кырылмаган куе кара сакалын чалгы пәкесе белән кырып ташлады. Чебеннәр чуарлаган аяклы зур көзге каршысына басып, кыек якалы, ак сәдәфле кара сатин күлмәген киде; көндезен басудан — чүп утаудан кайткан Җамалттәй, иренең кияү егетләредәй мутланып, мыек чылгыйларын бөтерә-бөтерә, көзге каршысында торуына гаҗәпләнә куйды:

— Ни булды сиңа, җен карты? Кая болай баш кода кебек киендең? Кызыбызны кияүгә биргәнгә биш былтыр, олы улыбыз башка чыкты, Җиһангир, Тәхәви, Мифтах әле үсмерләр генә...

Бүре Бадул хатынына бер генә ысылдады:

— Син, кортка, бот араңа дилбегә эләккән корчаңгы бия төсле тыпырчынма, яме,— диде ул теш ыржайтып.— Күпне белсәң, тиз картаерсың.

Башка сүз әйтүне кирәк тапмады, өермәләнеп өйдән чыгып китте. Урамнан да ата күркә төсле кабарынып барды. Хәнифәләр йортының урыс капкасына килеп җитеп, капка келәсен күтәргән чакта гына, анда да бер генә мизгелгә, икеләнеп алды, шуннан соң ныклы адымнар белән, алма үләне мул булып үскән ишегалдының сукмагыннан, киртә казыкларына киптерергә элеп куелган чиләкләргә күз сала-сала, болдырга таба узды.

Чолан буена килеп житүгә Бадул кинәт туктады. Ак халатлы, матур гына йомры гәүдәле хатын, иелә төшеп, сепарат тәлинкәләрен тастымал белән сөртә иде. Вакыт-вакыт иелеп, тәлинкәләрне алган чакта, халат итәге югарырак күтәрелеп, бик матур булып ачылып калган ботлары күренә, әнә шулар Бадулның һушын ала иде.

Ул чолан ишегенә бөтен гәүдәсе белән ятып, каты итеп тамак кырды.

Сепарат юучы хатын сискәнеп китте, тураеп басты. Бадул аның ак халатын төртеп торган йомры күкрәкләрен, эшләүдәнме, иелүдәнме алсуланып киткән аксыл-түгәрәк йөзен, утлы күмердәй көйрәгән зур чиста күзләрен күрде.

— Карасана, күрми дә торам, кунак бар икән ич,— дип сөйләнәсөйләнә, Хәнифә ак халатының сызганып куелган җиңнәрен төшерә башлады.

— Ни, кодача... сепарат төзәтәсеме-ниме... дигәннәрие...

Хәнифәнең йөзе кояштай балкып китте.

— Әйе шул, Гыйбадулла абзый. Сепаратны төзәтәсе бар иде шул. Берсенең-бер кулыннан килми торган эш булып чыкты бит әле ул. Тимерче Нотфига да, күпер төбе Госманга да әйтеп карадылар, булмый диләр. Инде менә син карап кара.

Сүтеп киштәләргә тезгән тәлинкәләргә, сепарат эчендәге механизмнарга күз төшереп алгач та Бүре Бадул үзенең биредә берни дә майтара алмаячагын аңлады.

Аңа хәзер булдыра алмаячагын чын күңелдән әйтеп, кайтып кына китәргә кирәк иде дә бит, юк шул, китә алмый, ике игезәкне тапканнан соң тулып пешкән чибәр хатынның буй-сыны, ак халаттан балкып янәшә басып торуы аны тәмам шаштыра иде.

— Хәнифә...— дип, ярым пышылдап дәште ул.— Кил әле, әнә шул чиләкне алып бир әле.

Аны-моны сизеп өлгермәгән Хәнифә ак калай чиләкне алып бирде.

— Мин сепаратны сүтәм, син аның шөрепләрен шушы чиләккә тутырырсың, яме,— дип Бүре Бадул сепаратның өстенә үк иелде; адәм баласында була торган гадәти бер кызыксыну белән Хәнифә дә иелеп карады. Бүре Бадул кинәт, киек җәнлек җитезлеге белән, Хәнифәнең беленнән эләктереп алып, аны үзенә тартып китерде, тәмәке исе аңкытып, үбәргә үрелде. Көтелмәгән бу һөҗүмнән коты чыгып калган Хәнифә ике кулын уч ягы белән Бүре Бадулның битенә терәде. Бадул хәзер аны үбә дә алмый, берни күрми дә, ярсып типкән йөрәгенең дөпелдәвен генә ишетә иде.

— Хәнифә... җаным... бәгърем... бул минеке. Җефаккә төрәм, балмайда гына йөздерәм...— дип кайнар сүзләр пышылдады ул.

— Җибәр диләр сиңа! Җибәр, кычкырам! — диде Хәнифә, янап,— яхшы чакта җибәр, Бүре тәре!

Эшләрнең инде үгетләү белән барып чыкмавын аңлаган Бүре Бадул, аны биленнән тагын да катырак кысып, хәлен алмакчы иде, әмма эшләрнең инде гади бер шаярудан узганлыгын аңлап алган Хәнифә бөтен көченә артка каерылды да, ике кулын бергә йомарлап, Бүре Бадулның борынына китереп орды.

Бүре Бадулның күзеннән көлтәсе белән очкын сибелде, куллары кинәт хәлсезләнде.

Ул башыннан очып төшкән укалы түбәтәен иелеп алган чагында, чолан ишеге төбенә халык җыелганын күреп, болай булгач, бетте башың, Гыйбадулла, дип коты чыгып уйланды.

Хәнифә, ни булганны аңлап җиткерә алмыйча, келәшчәдәй каты куллар кысудан авыртып калган билен язып, тураеп басты, Бүре Бадулның кан баскан күзләренә нәфрәтләнеп карады; шул ук мизгелдә Габбасының зират каенында чайкалып торуын да күз алдына китергәч, моңарчы күргән-кичергәннәре, хурлану-кимсенүләре бугазына кайнар төен булып килеп тыгылгач, түзмәде, кычкырып елап җибәрде.

Кемнәрдер аны юатырга теләделәр, кемнәрдер Бүре Бадулны сөйрәп алып чыгып киттеләр. Хәнифә боларны күрмәде, ишетмәде, белмәде, чәчләрен йолка-йолка, ярсый-ярсый елады.

Ул елап туктаганда, чолан төбендә берәү дә юк иде инде. Чишмә суы белән битен юды, озаклап сөртенде, аннары, ачык бер карарга килеп, ныклы адымнар белән үзләре йортының өске катына — колхоз канцеләренә күтәрелде.

Хәзер ул мескен хәлдә түгел, үзен һәм балаларын яклый алырлык хәлдә иде. Кәнсәләр ишеген ачып керүгә, куе зәңгәр түтенгә күмелеп утырган Миңнуллага ябырылды:

— Оятсызлар! Тол катын бу дигәченнән дә мыскыл итәргә дә ярый ди торгансыздыр! Ыстырамга калдырыйк әле моны дип алдан пыланнар корып, кәмит уйнарга тотындыгызмыни?! Кара син боларны, нилэр кыландыралар, минем өскә югары очның Бүре Бадулын җибәрәләр! Талап үтерсен ди торгансыздыр, кешелеген калдырмыйк ди торгансыздыр.



*Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

Тол катын бу дигәченнән дә, ярдәмчесез дигәченнән дә...— Ул үз сүзләреннән үзе ярсып, гарьләнеп һәм сабырсызланып кычкырды да кычкырды, башыннан яулыгын йолкып алды һәм миңгерәүләнеп калган председательнең зур чөгендер борыны төбендә шул яулыкны шашынып селкергә тотынды.

Сепарат йортында булган хәл сәгате-минуты белән Зартугайга таралды. Авыл советы башлыгы Мәрдән Мурзин, Бүре Бадулны кәнсәләргә чакыртып, шунда стена буена чүгәләгән авыл картлары алдында эт итеп сүкте, төрмәгә яптырып кую белән янады, соңыннан, хатын-кыз азатлыгына кул сузганы өчен, утыз тәңкә акчалата штраф салырга дип карар чыгарттырды.

Шушы вакыйгадан соң Хәнифәгә нәфселәрен сузган ир-ат үз эченә йомылды, теләген теле белән дә, кулы белән дә белдерә алмады.

Ләкин — дөнья бу! — Хәнифәнең дә йөрәген яндырырдай, күңел тойгыларын яшь кызларныкыдай кабызып җибәрә алырдай кеше бар икән әле.

Зартугайга Чишмәбай кайтып төште.

## VI

Элек тә сәеррәк кеше иде Чишмәбай. Соңгы елларда бигрәк тә сәер сүзләр йөрде аның хакында.

Берәүләр аны, герман әсирлегеннән котылгач, Себер шахталарында ташкүмер кискән икән дип, икенчеләре, Колчак армиясендә безнекеләргә каршы сугышып йөргәндә, өтерманга эләккән, тайгада урман аудара икән дип сөйләделәр.

Тора-бара имеш-мимеш онытылды. Вакыт бик күп узды бит. Революция булганга гына да унҗиде ел!

Уйламаган-көтмәгән җирдән, 1934 елның яз башларында, Зартугайга Чишмәбай үзе кайтып төште.

Авылда аның туган-тумачасы да, эти-әнисе дә юк иде, әле революциягә кадәрле үк үзе эшләп киткән тегермән йортына кайтып ауды.

Өстенә башкорт ярмәге киеп алган, арка-җилкәсе калынайган кырык яшьләрендәге Чишмәбай берәү белән дә җәелеп сөйләшми, кайчандыр кара булган, инде борчак оны кунгандай төссезләнгән чәчләрен сыпыргалап, уфтанып кына куя, ялгызы калган чакларда тегермән арыгы янына, таллар буена утырып, камыштан ясалган кураен уйный, тегермәнгә килгән кешеләр, атларын тугарып, ашарга кушкан араларда, курай моңын тын калып тыңлыйлар иде.

Халык моңа үзенчә бәя бирде. Еракта, күз күрмәгән, колак ишетмәгән илләрдә булу кешене үзгәртә торгандыр. Башкача иттерә торгандыр. Ни дисәң дә кайткан бит әле менә, ничәмә-ничә еллар үткән булса да кайткан, югыйсә, бер генә кешесе дә юк бит инде Зартугайда...

Беркеме дә юк дип ялгышалар иде, әлбәттә. Зартугайда әле бик яшьли, үсмер чагында ук күңеле төшеп йөргән бер кешесе бар иде Чишмәбайның. Хәнифә бар иде. Ул аны кызның үзенә әйтмәде, әйтерлек идемени аның хәле! Үзе ялчы, өе балчык, кеше кулындагы бер кол иде бит ул. Таминдар бай тегермәненең колы иде. Баш күтәрми эшләде, тамак ялына еллар буе тегермән тарттырды, күңел тойгыларын, язгы гөрләвекләр белән бергә уянган хисләрен ул елына бер мәртәбә — тегермән арыкларын ачып, яз башлауда, боз өстенә учаклар ягып, Иж елгасын балкытуда гына күрсәтә ала иде. Аннары ел буена ул тагын йомыла, ел буена башын иеп йөри, көне-төне тамак ялына эшли иде. Кем белә, германга плен төшүе дә, бәлки, шуңа булгандыр. Бәхетсез башка кайда да бер түгелмени?! Хәнифәне Габбас мулла кече хатынлыкка алгач, җимерелде аның дөньясы, җимерелде аның яз башлаулары!

Рәчәйдә, Австрия кырларында туп авазлары тынып, заманалар тынычлангач, немецларның бер хәлле хуҗалыгында хезмәтче булып эшләгән

чагында, ул Зартугай буйлары, Иж суында гөрләп эшләгән тегермәнне сагынды, аның су шаулавын тыңлыйсы, тегермән ташларының келтерәп кенә әйләнеп утыруларын күрәсе килде. Сагыну-жирсү тойгысы бигрәк тә язларын, өй кыекларыннан тамчы тама башлагач, инешләр кузгалгач, күккә сабан тургае күтәрелгәч үзәкне өзеп җибәрә, әсир егет, җанын кая куярга белмичә, хуҗасының җиләк-җимеш бакчасына чыга, арып хәлдән тайганчы, иртә таңнан кояш батканчыга кадәр эшли; хуҗалыкны алып бару ягыннан, эшкә җаптәшлек ягыннан педант дәрәҗәдәге төгәл немец карты Россиядән килгән бу кешенең үзендә бер көн эчендә таулар актарып ташлый алырдай көч таба алуына аптырап, аңлый алмыйча йөри иде.

Әсирләрне Россиягә кайтара башлауга, Чишмәбай беренче булып юлга чыкты.

Менә шунда аның җанын Хәнифәне күрү, аның белән бер генә мәртәбә булса да сөйләшеп утыру өмете биләп алды, ләкин шул ук вакытта Хәнифәнең Габбас мулла хатыны икәнен белү аның күңелен җәрәхәтли, әсирлектә күргән газап-михнәтләре янына әнә шул йөрәк сагышы да килеп кушыла иде. Икенче бер кешенең хатыны булган сөйгәнеңне читтән күреп йөрү күңел газапларын йөз мәртәбә арттырачак, моңа түзеп булмаячак иде.

Шуңа күрә ул әсирлектән туган-үскән авылына түгел, тоткындагы иптәше Исәнгол белән бергә башкорт авылына кайтты.

Унҗиде еллар чамасы яшәде ул анда. Йорт салмады. Кешеләргә бура бурады, түбә япты, тегермән куласаларын яңартты, канауларын төзек итеп тотты; язмышыннан зарланмыйча, Кандыр суы буена салынган алты ташлы тегермәннең тәмәке төтеннәреннән ысланып беткән тәбәнәк йортында гомер кичерде. Башкортлар аның эшкә җаптәшлеген, алтын куллы булуын яраттылар, үзләре белән кымыз эчәргә чакырдылар, курай уйнарга өйрәттеләр, кыз димләделәр.

Ул риза булмады, тегермән йортында буйдак килеш яши бирде.

Курайда ул «Кара урман»ны, «Ашказар»ны, «Колый кантун»ны уйнады. Башкортның кураен гына түгел, юмартлыгын, дала кебек киң сулышлы җырларын, җир җимертеп бии белүен яратты ул, урманнар уртасына сибелгән зәңгәр күлләрен үз итте. Бәлки, язмышына буйсынып, анда гомерлеккә дә калыр иде, олыгаям бит, әллә башлы-күзле булыйм микән, дип тә уйлана иде ул.

Тик шундый иләс-миләс көннәрендә Кандыр буена зур бер эш белән килеп чыккан Айдар Шәяхмәте аның уйларын чуалтты.

Әллә кайчангы яшьлек тойгылары язгы ташкыннардай кузгалган, сагынуларына дәва таба алмаган Чишмәбай, аңа хас булмаган бер сабырсызлык белән, ашкынып һәм тотлыга-тотлыга, Зартугай хәлләрен сорашырга тотынды.

Айдар Шәяхмәте гади генә итеп, коп-коры сүзләр белән әйтеп бирде: авылда колхоз төзегәннәр. Таминдар байны чит илгә качып барган чакта тотып атканнар. Бай тегермәне, аның биләмәләре, җәйге утарлары — барысы да дәүләт карамагына күчкән, совхоз оештырганнар.

— Ә Габбас мулла? — диде Чишмәбай ашыгып.

— Габбас мулла байларга да ярамады, безнең теләкләрне дә аңлый алмады, мәрхүм.

— Үлдемени?

— Әйе. Асылынып үлде.

— Кит аннан?! Ә катыны?

— Шәмсениса абыстайны әйтәсеңме?

— Юк ла...— диде Чишмәбай, үзе шундук кып-кызыл булып кызарды.— Нишлим мин Шәмсениса белән. Хәнифәне әйтәм...

Эшләрнең кая таба барганын Шәяхмәт аңлады, мыек астыннан гына елмаеп, Чишмәбайга күз кысып куйды: беләбез, янәсе, дуганы кай якка бөккәнеңне.

— Хәнифәгә ни булсын, яши бирә. Ике малай алып кайтты.

— Кемнән?

— Имеш-мимеш тә йөргән иде халык арасында, ләкин соңыннан ачыкланды. Малайларның икесе дә кара чутыр, икесе дә шешмәк кабаклы — Габбас токымы икәнлекләре әллә каян кычкырып тора.

— Хәнифә ялгызы гына яшимени?

— Ялгызы.

Айдар Шәяхмәтенең соңгы сүзләре Чишмәбайның күңелен айкап салды. Шул хәбәрдән соң ул төн йокыларын оныотты. Сары сагышка батты, тамактан язды. Таллар буена чыга да курай уйный, арык буена бара да су өстенә карап тора. Инешне тутырып йөзгән каз-үрдәкләр дә, баш өстендә талпынган тургайлар да тегермән суларының шаулавы да — барысы да хәзер аның җаны аша уза, сагышландыра...

Беренче көннәрне түзде, узар диде — узмады.

Җаны аеруча сулкылдап сыкрагач, инде биредә бер генә көн дә түзәрлеге калмагач, тәвәккәлләп юлга чыкты.

Үзен нинди язмыш көткәнен белмичә чыкты ул юлга.

Аны менә нинди язмыш көтә иде.

Габбас мулла йортының өске катына колхоз кәнсәләрен урнаштырып, аскы катына сепарат куйгач, Хәнифәне ятимнәре белән шунда урнаштыргач, житәкчеләр, инде озакка көйләндек дип уйлаганнар иде. Ләкин яши башлагач, кичәге фикерләренең бүгенгә ярамаганлыгы билгеле булды.

Йортның түбәнге катында сепарат гүли, авыл хатыннары сепаратка кичләрен генә түгел, көндезләрен дә киләләр, әбәт чиләгенә яки чүлмәкләргә җыелган сөт өстеннән май язып, көрәк оны биреп китәләр, авыл зур булганлыктан, йорт янында бер генә көн дә кеше өзелеп тормый. Димәк, идарә йортына хатын-кыз, ягъни кирәкле-кирәксез кеше гел килеп тора. Шау-шу, бәхәс, дәгъва. Анысына да түзәр идең, Пәнҗәрдән, Алабугадан, Казанның үзеннән түрә-кара өзелми, аларны каршыларга, аларны урнаштырырга, аларны ашатырга-эчертергә кирәк. Халык, бигрәк тә хатын-кызлар, артыгы белән кызыксынучан, берне биш итеп сөйләүчән; күпне күрәләр, күпне беләләр, телләрен тыя белмиләр. Өстәвенә председатель Миңнуллага тол хатынның артыгы белән чибәр, артыгы белән әрем телле булуы да ошамый. Кәнсәләргә килеп җәнҗал куптарганнан соң ул аны күралмас дәрәҗәгә житте — идарәгә эшкә килгән чагында капка төбендә генә очратса да яки урам чатында аның ак чиләкләрен, чытыр ак яулыгын күрсә дә каннары кайный башлый.

Хәнифә аркасында Бүре Гыйбадулласының ямьсез эше Пәнҗәргә хәтле барып житте. Миңнуллага авыл коммунистлары алдында гына түгел, райком бюросында басып торырга, Айдар Шәяхмәтенең маңгайга тереп биргән сорауларына җавап табарга туры килде.

Шуннан соң Миңнулла, авыл советы башлыгы Мәрдән Мурзин белән киңәшеп, идарә йортын башка урынга күчертергә мәҗбүр булды.

Мәрдән абзый — зурдан кубып уйлый торган кеше.

— Син, Миңнулла, булгач-булгач, кулак-куштаннан, мулла-мунтагайдан калган иске йортлар белән булашма инде. Пәнҗәр төбәгендә урман күп, шыңгырдап торган яңа бүрәнәдән салдыр колхозның төп йортын, шунда бәрәттән силсәвит йортын да буратып җибәр. Замана йортлары яңача булырга тиеш,— диде ул.

Аның сүзен хупладылар. Җәйге җылы көннәрдә диләнке кисеп, буралар бурап, авылның иң биек урынына, элекке мәчет булган тирәгә берьюлы ике бина салып куйдылар. Тәрәзә йөзлекләренә агачтан юнып йолдыз кадакладылар, аны кызылга — байрак төсенә буядылар. Йолдыз, озак та узмый, халык теленә керде. Читтән килүчеләр колхоз идарәсен яки авыл советы йортын сорасалар, ә-ә-нә тегендә, тау башында тәрәзәләре йолдызлы ике йорт булыр, шунда барыгыз, дип әйтә башладылар.

Тик әле моның белән генә тынычланмады Миңнулла. Ул тол хатын Хәнифәнең өй эчендәге чүпне тышка чыгарганлыгына гаять дәрәҗәдә ачуы килеп, туктале, мин аны төнәтим әле, дигән уйны күңелендә асрый башлады. Янәсе, үзе генә киерелеп яшәмәсен.

Мәрдән Мурзин һәм тагын Имам Каһарманов белән озаклап киңәшкәч, Хәнифәләр йортының өске катына Зартугайга әле бер-ике ай элек кенә килгән, вакытлыча авыл очындагы ялгыз карчыкта яшәгән тегермәнче Константин Иванович Павловны гаиләсе белән урнаштырырга булдылар.

Тик моның ахыры ни белән бетәсен алар күз алдына китермиләр иде шул.

Тегермәнченең хатыны Полина — иске диндәге кеше иде. Ул, өйгә керү белән, түр башына, почмакка, элек шамаил булган урынга, бик пөхтәләп алтын путалы иконалар элеп куйды, икона астына кичләрен шәм яндырып куя торган булды. Константин үзе, әле Полинага өйләнгәнче, озак еллар татар авылында яшәгәнгәдер (әтисе дә тегермәнче иде, ул да гомер буе татар авылында яшәде), татарчаны су кебек эчә, бер динне дә тотмый, җыен-сабан туйларында авыл яшьләре белән бергә, татар җырларын җырлый-җырлый, урам әйләнеп йөри иде.

Константин белән Полинаның сигез яшьлек Шура исемле кызлары бар иде, икенче көнне үк Хәнифәнең Шәфикасы белән дуслашып алып, ул көннәр буе аларның аскы каттагы өйләреннән чыкмый ята башлады. Полина — иске дин кешесе — чит-ят квартирага керергә бер дә атлыгып тормый, шунлыктан Шураны көн дә саен кичләрен әтисе күршеләрдән алып чыгарга мәҗбүр иде.

Константин Хәнифәләргә ишек шакып килеп керә:

— Әссәламегаләйкүм, күршеләр! Көнне әйбәт кенә уздырдыгызмы? Минем Шурочкам сезне бик алҗытып бетермәдеме әле?

Ул, күн итекле аякларын аерып басып, баһадирларча гәүдәсе белән ишек төбендә торып кала.

Хәнифә аны табын янына утырырга кыстый башлый:

— Утырыгыз инде, килегез, Кәчтәнтин абзый, аштан олы булырга ярамый бит.

«Кәчтәнтин» уңайсызлана, баскан урынында кадаклап куйгандай тик тора. Өйдә ир-ат булса, ул утырыр иде, бәлкем, үзе белән бергә шешәсен-мазарын да кыстырып керер иде, өйдә ир-ат юк шул,— шунысы өзә үзәкне.

Хәнифә жиңги инде көйсезләнә башлаган, кайтмыйм дип киреләнгән Шураны иплән кенә, көйләп кенә кайтарып җибәргәнче, Константин ишек төбендә басып торырга мәҗбүр. Дөрес, кайтып китсә дә, беркем аңа бер сүз әйтмәс иде, әмма ниндидер билгесез көч аны җибәрми — баскан урында торырга куша.

Хәнифәнең оялып кына сөйләшүе, Кәчтәнтин абзый, әйдә инде, түрдән уз инде, дип кыстаулары бик тә якын аның күңеленә. Ул аның Шураны киендергән ягымлы кулларын тотар иде, Хәнифә җаным, белмисең бит, кадерлем, бу дөньяда синнән дә чибәр, синнән дә мөлаемрак хатын юк бит, и булачагы да юк, дип әйтер иде. Тик ул сүзләрне ул үлсә дә әйтә алмый, ул — хатынлы ир.

Константин кызын көн саен диярлек алмага төшә. Биек баскычлар буйлап, кызын җитәкләп менгән чакта, әллә ниткән уйлар уйлап бетерә. Полинага карата салкынаюын, аны теләп иркәләмәвен, тегесе кирәкмәгән сүз әйтсә, гасабилануын, ярсып китәргә торуын уйлый. Нилектән шулай соң әле бу? Элек алай түгел иде бит...

Көн артыннан көн үтә. Константин инде Хәнифәләргә керергә кичләрен генә түгел, көндезләрен дә атлыгып тора. Тегермәндә мөшкәгә бодай капчыгы бушатканда да, улактан аккан җылы онның мамыклымы-түгелме икәнен уч төбендә сынап караганда да сизә. Әйе, ул ерып чыга алмаслык кара урман уртасында бер ялгызы торып калды.

Нәкъ шул көннәрне Зартугайга Чишмәбай кайтты.

Бу кешене Константин бер күрүдә үз итте. Ачык якты чырае, аз,

сөйләшүе, киңәш сораган чакта, күңелгә ятышлы итеп әйтеп бирүе, гомумән дә, күпне күргән, дөньяның ачысын-төчесен татыган кешегә охшап торуы да үз иттерде бугай ахры аны.

Нәрсәгә генә тотынмасын, Чишмәбайның кулы ята. Константин Павловның ярдәмчесе булып эшли башлаганның икенче көнендә үк ул, колхоз идарәсенә барып, агач материалына нәрәт яздырып алып кайтты, колхоздан өч олау алып, тегермән янына китертте, Зартугайның күптәнге такта яручысы Шәмгун белән түбәгә яраклы такта итеп ярды; тегермән бинасының мүкләнгән, черегән такталарын кубарып, яңаларын кадаклады. Эшли башлавына унбиш-егерме көн уздымы икән, Аксагыз тауларының итәгендә агып яткан җиде чишмәнең улакларын төзәтте, төптән бәреп чыга торган вак чишмәләрне юшкыннан тазартты, чишмә әйләнәсендә урмандай куе булып үскән бөтнек үләнен чалгы белән чабып алып киптерергә куйды.

Бу хәл Константинны гаҗәпләндерми кала алмады.

Ул авыл мужикларының тоташ үз йортын кайгыртканын бик яхшы белә, шуны гел күреп-күзәтеп йөри, моны табигый дип саный иде. Ә бу, бичара, торырга ни куышы, иркәләргә ни хатыны юк дигәндәй, Зартугайның чишмәләрен тазартып йөри, беркем кушканны да көтмичә, тегермән бинасының түбәләрен сипли. Исәр дияр идең, акылы бик түгәрәк...

Әнә шундый уйлар белән яши Константин. Көнлекче Хисмәй Каюмының кайчандыр Зартугай чишмәләрен берләштереп, икенче бер тегермән тарттырырлык су җыярга, ярты чакрымлы канау казып, аны тегермән куласасына кадәрле китерергә хыялланып йөргәнен, шул сәбәпле Чишмәбай кушаматы алганын белми. Дөньяның байлыгына кемнәрдер хуҗа булып, хәерчелектә кемнәрдер иза чигәргә дучар ителгән заманнарда андый хыялларның күгелҗем томаннарга күмелеп калганлыгын Чишмәбай гына белә, Чишмәбай гына шул яшь чакларын үзәкләре өзелеп искә төшерә. Константин аларны белми, алар өчен өзелми. Әмма менә хәзер аларның икесенең дә уртак тойгылары бар: алар икесе тиң Хәнифә өчен өзеләләр.

Зартугайга кайтканына ике ай тула дигәндә, Чишмәбай тегермәнчегә әйтте:

— Карале, Константин Иванович, тегермәннең куласасы эштән чыга язган, әллә яңасын әмәллибезме? — диде.

Павлов моны үзе дә белә, тик ялгызы гына тотынырга шүрләбрәк йөри, балта тотарга оста булса да, заманында әтисеннән күп нәрсәгә өйрәнеп калса да, исәп-хисапка, куласа хәтле куласаның сызымнарын сыза алуга ул үзен әзерлекле түгел дип исәпли иде. Ә монда ярдәмчесе үзе әйтеп тора ләбаса!

— Ярар,— диде тегермәнче.

Һәм алар иртәгесен икәүләшеп эшкә тотындылар. Башта бер-ике көн Чишмәбай кәгазьгә сызган сызымнарны тикшерделәр, үлчәделәр, барладылар, агачның ниндиен алырга кирәклекне иске куласадан карап белделәр.

Көннәрдән бер көнне, тегермән тарттырырга килүчеләрне генә түгел, осталарның үзләрен дә тел шартлатыр дәрәҗәдә мавыктырып һәм сокландырып, гигант тәгәрмәч барлыкка килде.

Ике оста, икесе берьюлы тәмәке кабызып, дөресрәге — Чишмәбай, борынгы заманнардагы гадәте буенча, «кәҗә тоягы» төреп, Константин зур кара төрепкәсенә ут алдырып, үзләре юктан бар иткән куласа өстенә килеп утырдылар.

Иртәгә председатель Миңнулладан ярдәмгә алты-җиде кеше сорап, аны урынына куярга кирәк. Ләкин бүген осталарның күңелләре ташыган чак, шәт, яңа куласаны аз гына «чылатып» алсаң да зыян итмәстер...

Тегермән өе гаилә белән торыр өчен әзерләнмәгән булганлыктан, аның зур миче дә, аш-мазар пешерерлек казаны да юк иде.

Константин Иванович, кичен эшнең күп булачагын, бүген өйгә кай-

тып йөри алмаячагын әйтеп, хатынына язу җибәрде. Тегермәнгә килгән бер абзыйның малае Полина түтәйдән ярты бөтен ипи, бер чүлмәк кәбестә ашы, бер түтәрәм ит алып килде.

Киңәшле эш таркалмас. Ярты сәгать эчендә табын әзер булып, кәбестә ашы пар бөрки, әрчеп куелган бер баш суган авыз суларын китереп, ашъяулык өстендә агарып ята иде.

Икәү бергәләшеп чүлмәктән аш ашадылар...

Константин Иванович агач кашыкны бер читкә куйды, көтмәгәндә, кинәтрәк сорарга итте:

— Карале, братан, Чишмәбай синең үз исемеңме? Әллә кушаматмы? Кстати, сезнең халыкта андый исем юк шикелле? Миңлебай, Тимербай. Тагын бүтән бай бармы? Минемчә, юк.

— Чишмәбай — кушамат. Беләсеңме, кушамат. Аны миңа герман сугышы чыгар алдыннан тактылар. Каюм минем чын исем. Каюм, беләсеңме? Миңа чишмә җене кагылган иде, мин чишмәләрдән елга ясамакчы булдым, тегермән тарттырырга хыялландым, Константин Иваныч. Таминдар бай, муены астына килгән нәрсә, минем чишмәләремне тартып алды. Инде менә үзен теге дөньяга олактырганнар, жәлке, кәнишне, ну, ни хәл итмәк кирәк, дөнья шулай яратылган,— куласа әйләнеп тора, бүген син көчле, иртәгә — мин...

— Син шушы авылныкымыни? — диде Павлов, сүнгән тәрепкәсенә ут кабызып.

— Әйе,— диде Чишмәбай.

— Моңарчы кайларда йөрдең соң син?

Чишмәбай күңелендәге уйларын яшерми әйтерлек хәлгә килгән иде.

— Син бит бернәрсә дә белмисең, Константин Иваныч,— диде ул, башын аска иеп, берара тын утырды, аннары башын күтәреп, тегермәнченең күзләренә карады, карашы моңсу иде.— Белмисең шул син... Хәнифәне эзләп кайттым мин. Мин бит аны кырлардан эзләдем, Германия кырларыннан. Көтүләрдән эзләдем. Мин анда көтү көттем. Эт көтүе...

— Тукта, соң син анда ничек эләктең?

— Белмисең, Константин... Син дә белмисең, Хәнифә дә белми, берегез дә белми. Син сорама, мин әйтмим, вәйт. Сорама. Белдеңме? Мин бит аны егерме ел буе эзләдем. Кандыр буйларыннан, Димнән, ә ул Иж буенда иде. Ике малай, ха-ха-ха! Ике баһадир! Менә мин аларны карарыем, көне-төне багарыем, аякка бастырырыем...

«Бу дөньяда кешене кеше иткән, аны хайваннан аерган ике нәрсә бар: берсе — хыял, икенчесе — мәхәббәт»,— дип уйлады Константин Павлов.

Ул кинәт айнып китте.

«Туктале, Хәнифәгә гашыйк кеше бер ул гына түгел икән ләбаса! Бер ул гына түгел икән. Аны әнә кайлардан эзләп кайткан кеше бар икән. Их, Константин, син кая үреләсең? Синең соң ул сылу белән уртак тел табасың бармыни? Уртак тел тапсаң да, Полинаң сине аңа бирәчәкмени?..»

Тегермәнче капыл гына урыныннан торды. Тәрәзә төбендә яткан картузын алып башына чәпәде.

— Сау бул, Чишмәбай! Бәхет синең юлдашың булсын...— диде дә ашыгып чыгып китте.

Тагын бер атнадан гаиләсе-ние белән Пәнҗәргә күченеп китте.

Чишмәбай моны берничек тә аңлый алмады. «Юмарт җанлы бу урысны мин нәрсә белән рәнҗеттем икән соң?» — дип әллә ни гомер тәшвишле уйларына бирелеп йөрде.

## VII

Җәйге җылы төн.

Көндезге эсседән әлсерәгән җир өстенә рәхәт бер талгынлык җәелә.

Офык буйларында — болытлар өем-өем; аларның шәфәкъ алсуы кабынган итәкләре көйри; төнге тынлыкны Зартугайдан Пәнҗәргә бара торган атлы арбалар да, печән өстенә утырган ир-ат белән хатын-кызның үзара әкрен генә, быдыр-быдыр сөйләшкән тавышлары гына бозып куйгалый.

Шәфика, әнисенең җылы ботларына башын төртеп, йокымсырап бара. Аңа озакламый сигез яшь. Мәктәпкә керәсе елы. «Аллы-гөлле чәчәкләр төшергән буяулы букча алырбыз,— диде әнисе.— Май белән йомырканы гына исән-имин сатып җибәрсәк...»

Арба тәгәрмәчләре келтери. Әле тигез юлдан баралар, әле казылмага туры килеп, «дырк» итеп китәләр. Әнисе аны үчтекиләп үстергән иде. Арба тәгәрмәчләре әнисенең такмагын кабатлый:

Тигез юлдан баралар,
Әкрен генә баралар,
Казылмага төшәләр —
Сикереп-сикереп китәләр...

Төн караңгылыгында атларның пошкырганы, арттагы олауда Сәүбән картның моңаеп җырлаганы ишетелә.

Аннары олаулар урманга керә. Дилбегә тоткан Чишмәбай абзый Шәфиканың әнисенә ниндидер әкрен, серле тавыш белән сөйли. Бу урманда кайчандыр качкыннар яткан. Юл йөргән кешеләрнең каршысына чыкканнар. Ярлы-ябагайга тимәгәннәр. Байларны гына талаганнар. Күп булган алар — мылтык-пугачлар белән коралланганнар. Аларның байлардан аласы үче булган...

— И-и-и, син бит фартизаннарны сөйлисең. Алар бит кеше талаган кеше түгел, алар бит эрвәлүтсә өчен кан койган кеше. Заманында әнә безнең авылның Бүре Гыйбадулласы да фартизаные. Хәзергесе вакытта Пәнҗәрдә түрә булып утырган Айдар Шәяхмәтен үлем пырахутыннан коткарып калган дип сөйлиләрие...

Чишмәбай абзыйсы белән әнисенең сүзләре, урман авазлары белән аралашып, Шәфиканың күңеленә сеңә бара. Урмандагы качкыннар, уфылдаган байгышлар, Айдар Шәяхмәтләре — барысы бергә бутала торгач, Шәфиканың күңеле әллә кайларга — Каф тау артларына, дию пәриләренә, ак бүреләргә барып тоташа. Сигез яшьлек бала, шушы зур дөньяны нәни күңеленә сыйдырып бетерә алмыйча йоклап китә...

Ул уянганда атлар инде туктаган. Печән өстендә Шәфика үзе генә йоклап ята. Арыш басуы ягыннан кеше тавышлары ишетелә. Кемнәрдер арыш арасыннан чыга, кемнәрдер көлешә. Аларның өзек-төтек тавышлары, Шәфиканың янә дә күңеленә эләгеп, аңлаешсыз сәер дөнья тудыралар.

— Габбас Хәнифәсен әйтәм, үзенә кирәкне тапкан бит.

— Теләсә кемнең күзе төшәрлек, ярабби! Тулып пешкән ләбаса!

— Төшәрлек, җаным, төшәрлек. Хәзрәт белән бер дә генә рәхәт күрмәде шул.

— Кит инде, кит, әстагыфирулла! Түземсез дигәченнән дә... арыш араларына кереп...

Якыннан гына Бүре Бадулның карлыккан калын тавышы ишетелә:

— Кузгалдык, җәмәгать! Бетмәс монда мулланың тол катынын сагалаучылар!

— Нәстә, көнчелегеңә көч килдеме әллә, Гыйбадулла абзый?

— Тьфү, телеңә тилчә чыккыры! Минем үз Җамалым да кызларга биргесез. Тупырдатып дүрт малай, ике кыз тапты! На-а-а, үнгыры, бер кабыргаң биш булгыры!

Олаулар кузгалып китә. Чишмәбай абзыйсы белән әнисе, йөгереп килеп, печән өстенә авалар. Авыр мышныйлар. Алгы олауларда әле һаман көлешәләр. Бу көлешү Шәфикага аңлашылмый, әмма кайсыдыр канаты белән аның җанына кагыла, күңелен шомландыра. Шуңа күрә әнисенең аның өстенә иелеп: «Баламдыр шул, сабыемдыр шул. Берни дә белми бит

ул. Аңа әле ике дөнья бер, уртасы камыр»,— дигән сүзләренә ул дәшми, йоклаганга салышып ята. Тик инде ул дөньяның яктырып килгәнен, атларның дәртлерәк пошкыра башлавын, өскә япкан җәймә аша тәнгә иртәнге дым, салкынчалык үтеп кергәнен сизә...

Олаучылар атларга дәртлерәк дәшә:

— На-а, малкай!

— Әйдәле, кәҗә катыгы! Катырак элдерт әле! — һавада чыжылдап чыбыркы шартлый.

Әлеге тавышларга, чыбыркы шартлатуларга ияреп, Чишмәбай абзыйсы да дилбегәсен болгый, тик ул атка сукмый. Шулай да ат юырттырып китә, ә тәгәрмәчләр әнисенең Шәфиканы үчтекиләп сикерткәндәге такмагын кабатлыйлар:

Әкрен генә баралар.
Каты юлдан баралар...

Юлның авыр өлеше, казылмалы-сикәлтәле өлеше башлана.

...Алгы олаудагы ике кеше — Миңнулла Батыршин белән Имам Каһарманов үзара гәпләшеп баралар.

— Адәм баласын һич кенә дә аңлый алмассың,— ди Миңнулла,— гаҗәп әкәмәт сәер яклары бар аның. Габбас Хәнифәсен генә мисалга алып кара: Бүре Гыйбадулласы кул суза башлагач, бөтен Зартугайны сасытып, каравыл кычкырды. Колхоз кәнсәләренә килеп, җәнҗал чыгарды һәм әпәйттеки минем күземне чукып чыгарырлык итеп өстемә килде. Ә үзе, баксаң-күрсәң нишли, ә? Герман пленыннан кайткан байгыш Чишмәбай белән арыш арасына кереп йөри, мөрәвәтсез! Йә, Имаметдин абзый, менә син партийный секретарь, нинди киртәгә сыя торган эш инде бу, ә?

Каһарманов, чикмән якасын төшерә-төшерә, беркавым дәшми бара, аннары гәҗит кәгазенә'эре бөртекле бакча тәмәкесен шыбырдатып салып, кәгазьне төрә, төкереклэп ябыштыра, шырпы сызып ут кабызгач, тирән итеп эчкә төтен ала да тончыга-тончыга сөйләп китә:

— Беләсеңме, Миңнулла, хикмәт нәрсәдә? Сталбыйт, Бүре Гыйбадулласының эчендә явыз бүре утырып тора. Нигә авыз ерасың? Сыйнфый сизгерлек җитми синдә, председатель. Ерткычлык, явызлык бар Гыйбадулла Ядкаровта. Хайвани зат бар — и кришке! Нәрсә син, Миңнулла, әллә шуны белмисеңме? Йә, фикер йөртеп карыйк: Габбас муллада асраулыкта яшәгәченнән дә әллә син Хәнифәне аңгыра дип, дөм сукыр надан дип беләсеңме? Кем аңа явызлык белән, кем изге ният белән килә — аермый дисеңме? Аермас сиңа — бар! Бүре исен бер чакрымнан сизә ул. И каравыл кычкыра! Әнә бит сепаратка куйдык. Сталбыйт, бер эшен дә ялгыштырмый, как наять алып бара. Югыйсә бит ни латинча, ни урысча язу яза белми. Габбас мулланың олы катыны Шәмсенисадан эләктереп калган гарәпчәсе белән сукалый. Йие, кем күпме сөт аерткан, кем күпме көрәк оны тиешле, кемнәр малның кадерен белә, кемнәр ата ялкау — төнлә уятып сора, күзен йомган килеш әйтеп бирә ала.

— Торып тор,— ди Миңнулла, иртәнге салкыннан куырыла төшеп.— Торып тор, Имаметдин абзый. Синеңчә болай булып чыга: Бүре Гыйбадулласы мулланың тол калган катынын мыскыллар өчен килгән, Чишмәбай аны арыш арасына чәченнән сыйпар өчен алып керә. Шулаймы?

— Алай да надан кеше син, Миңнулла! Сталбыйт, бозык та кеше. Әйтәм бит, сыйнфый сизгерлек җитми синдә. Бүре Гыйбадулласын ал да, Хәнифәне ал. Алар икесе ике урманның җиләге бит, ике категория кешесе. Гыйбадулла Ядкаров гомер буе үз өенә ташыган, бармаклары аның гел үзенә таба кәкере. Ә Хәнифә, Рамазан солдат Хәнифәсе? Гомере буе асрау, гомере буе кеше рәхәтенә эшләгән...

— Нәрсә, алайга китсә, Хәнифә белән Чишмәбай, чын исеме кем әле аның, авызын корт чаккыры, Каюммы әле, пар килгәннәр димәкче буласыңмы?

— Хикмәт мин әйтүдә түгел, Миңнулла. Сталбыйт, алар тумыштан ук бер-берсе өчен яратылганнар. Әгәренки бик беләсең килсә, элекке заманнарда байлар, югары сыйныф кешеләре, берсендә малай, икенчесендә кыз туса, бала чактан ук колакларын тешләтеп куя торган булганнар. Кайсыдыр бер китаптан укыдым. Ә шуннан ары, балалары балигъ булганчы, алардан күзләрен дә алмаганнар.

— Анысы шулайдыр,— диде Батыршин, бигүк килешеп бетмичә.— Шулайдыр анысы. Бай кеше ни генә кыланмас. Аның үз закуны үзе белән. Акча сикерткән аларны. Акча йолып та калган. Хәзер бит байлар заманасы түгел. Хәнифә менә хәзер, мисал өчен әйтик, уйнаштан бала табып, шуны синең белән минем муенга атландырып куйса...

Каһарманов ачы итеп бер сүгенде, аннары көлеп җибәрде.

— Әйтәм аны баядан бирле кирәмәтеңне киртәләп, таякка чабата кайтарып барасың. Бала багудан куркасың, сталбыйт. Син инде, Миңнулла, әйле-шәйле маташтырма, туп-турыдан топ пошел диген дә, җаваплылыкны өстемә алырга куркам, шүрлим, диген. Куркасың икән, үзең генә курык син, председатель, үзең генә шыр җибәр. Нигә әле монда Хәнифә? Нигә син Хәнифәгә яла ягасың? Чишмәбайга да яла якма! Эш кешеләре алар, намуслы кешеләр! Табарга язган булса, баласын да табар Хәнифә, Чишмәбайга кияүгә дә чыгып куяр. Әнә бит ире Габбас асылынып үлде дип тормады, тупырдатып ике игезәк малай тапты. Бәлки, син аларын да уйнаштан тапты диярсең, ә? Туты! Әйтмисең, сталбыйт, телең күтәрелми, намусың кушмый. Әнә шул игезәкләрне карарга-багарга, шуннан ары кеше итеп үстереп җиткерергә йорт башлыгы кирәкме-юкмы? Кирәк дисең, тә-ә-әк. Шуңы көнгә тикле Хисмәй батрак малае Каюм, сталбыйт, ул буладыр Чишмәбай, ни өчен япа-ялгызы, үзенүзе кочаклап йөргән дип беләсең? Тиңе табылмаган, сталбыйт, өмете Хәнифәдә.

Бераз гына дәшми барды. Аннары, дилбегә кагып, атны чаптырып җибәрде дә өзеп кенә әйтте:

— Карга кебек каркылдап, гайбәтче катыннар кебек лыгырдап, корыны бушка әйләндереп йөрү килешми безгә, Миңнулла. Син — колхоз башлыгы, мин яхшымы-яманмы, партия оешмасы белән җитәкчелек итәм, халыкның күзе безгә төбәлгән, бездән нидер көтә. Сталбыйт, җайлы җаенча, статьясын статьяга туры китереп, ике пролетарның тормышын бергә кушыйк та авыл советы кенәгәсенә теркәп куйыйк. Яши бирсеннәр үзләре белгәнчә.

Көйгән икмәк күңелдән китми дигәндәй, Миңнулла Хәнифәнең җәнҗалын һаман да оныта алмый иде әле. Ул тагын үз киресен киртәләде:

— Син иптәш партийный секретарь, ни өчендер мулланың толына якты күз белән карый башлагансың әле. Өч-дүрт ел элек кенә алай түгел идең бит син. Нәрсә, Чишмәбай Хәнифәгә йортка керә булып чыгамыни инде?

— Соң, йортка керсә, ни булган?

— Халык бит әйтә, йортка кергәнче, ди... Кая кер ди?

— Җыен ямьсез сүзне халыкка сылтыйсың да торасың син, Миңнулла,— диде ачуы кабарып җиткән Каһарманов.— Син, туганкаем, бер нәрсәне исеңнән чыгарма, председатель икәнеңне. Быел бит синең ат абзарлары саласың бар. Аны бит сиңа Мәнди анасы килеп салмас, син, сталбыйт, яклашып барган Бүре Гыйбадулласы бармагын да селкетмәс. Әнә шул Чишмәбай белән Пәнҗәр урыслары салыр безгә ат абзарларын.

— Причум монда Чишмәбай? Причум монда Пәнҗәр урыслары? — дип Миңнулла тагын киреләнә башлаган иде, аның уйланмый әйткән сүзләре Каһармановның мыегын чуалтып җибәрде:

— Мин сиңа нәрсә әйтәм, председатель! Чишмәбай башкорт даласында курай уйнап кына яткан дип беләсеңме әллә? Ятмаган! Көне-төне эшләгән, көне-төне! Белештем мин, Айдаров Шәяхмәттән белештем, райком секретареннан. Башкорт ягында Чишмәбай чарлаклы йортлар

салган. Балта остасы, калайчы, тугымчы, түбә ябучы — тагын әллә нит-кән һөнәрләрен хутка җибәргән. Белдеңме? Сталбыйт, Чишмәбай — алтын куллы кеше. Һөнәр иясе. Андыйларны көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмассың. Инде кулыбызга килеп кергән икән, ычкындырмыйк. Андый кеше җирдә аунап ятмый. Адым саен очрап та тормый. Безгә бит, кабатлап әйтәм, ат абзары дигәченнән дә, корчаңгы алаша яба торган өч метрлы ялгыз хуҗалык абзары түгел, өч йөз, биш йөз ат яба торган коллективный конюшни кирәк. Белдеңме инде, исәрбаш?

— Белдем,— диде Миңнулла үртәнеп.— Өйрәтергә бик остарып киттең әле син, Имаметдин абзый. Элек алай түгел идең, киңәш-табыш итә идең.

Каһарманов, председательнең чырае караңгыланганны күреп, бераз сүрелә төште:

— Нәрсә белдең, яле әйтеп кара?

— Ярарсана, яшь дигәченнән дә, бөтенләй бетереп ташлама әле син мине, Имам абзый. Мин үзем дә җәмәгать каралтылары белән төннәр буе саташып чыгам. Агач каян алырбыз? Менә нәрсә борчый мине...

— Иң әүвәле безгә, Миңнулла, төзү материалын түгел, төзүчене үзен табарга кирәк. Райком секретареның кылын тартып карадым мин. Менә шулай-шулай, мәйтәм, Айдаров иптәш, җәмәгать каралтылары саласы бар иде бит. Агач материалы таба алырбызмы?

— Агачын табарбыз. Төзүчеләрегез бармы? — ди бу.

Сталбыйт, безгә Чишмәбайны теләсә нинди юл белән, хет Хәнифәгә өйләндереп, үзебездә алып калырга кирәк. Нужәли син Чишмәбай сынатыр дип уйлыйсың?

— Сынатмас. Егет жилле, чикмән билле!

— Менә син, Миңнулла, бу юлы халык мәкален урынлы кулландың. Сталбыйт, Чишмәбайның безгә кирәкле кеше икәненә ышандың инде?

Миңнулла үрелә төшеп, ат өстендә чыбыркы уйнатып алды:

— На-а-а, уңгыры! Бер кабыргаң биш булгыры!

## VIII

Озакламый алар халык теленә керделәр. Йорт саен аларны сөйлиләр: басу юлларында — сүз шул хакта; су буенда сүз шул хакта; Зартугай хатыннары, кер белән бергә, аларны да салкын суга салып чайкыйлар, затсызлар, бәндәдән оялмасалар, ичмасам, алладан куркырларые диләр.

Халык тегермәнгә төпләнгән Чишмәбай янына агыла. Хатын-кызлар куна тактасы, уклау, кер бәләге, тукмак ясатырга, иске тырмаларына яңа теш куйдырырга киләләр; ир-ат балта сабы, чүкеч сабы ясата, тегермән ташында балтасын, өтергесен кайрый, тәрәзә рамнарын төзәттерә, кыскасы — килә, сылтавын таба.

Йомыш белән килүчеләр Чишмәбайның күз төпләренә кунган көрән тимгелләргә, аның ябыгып, суырылып калган озынча йөзенә, тегермән оны кунган төсле аксыл кыска чәчләренә бер үк вакытта кызыксынып та, өнәмичә дә карап торалар. Дөнья шулай яратылган — берәүләрнең баш түбәсеннән ашкан бәхете икенче берәүләрнең гомерлек бәхетсезлеге булып тоела...

Хәнифәгә кеше сүзен ишетү авыр. Габбас муллага яшь хатынлыкка чыкканнан соң ишеткән сүзләре дә бик житкән иде югыйсә! Шуңа күрә ул төннәрен, кеше-кара йоклагач, ындыр артлатып кына үзләренә килеп чыккан Чишмәбайны бөтенләй күчеп килергә чакыра, ялвара, тегесе моңа күнмәгәч, үпкәләп, эчке күлмәктән килеш, болдырга чыгып утыра...

Еракта тонык кына булып, тегермән суының шаулаганы ишетелә. Ишегалды чирәмнәреннән мул булып алма үләне исе, дымлы җир исе килә. Җәйге төн күкрәк тутырып сулыш ала.

Сепарат әйләндереп арыган беләкләренең талгын гына сулкылда-

вын тоеп, Хәнифә болдырда озак утыра. Күңелендә сәер бер сиземләү бар: еллар буе игътибар да итмәгән тегермән суының шавын тыңлавы аңа никтер рәхәт...

Пәнҗәр базарына **аның** белән бергә барып кайтканнан соң ул җан тынычлыгын җуйды. Гел дә генә **аны** күрәсе, дөньясын онытып сөйләшәсе, **аңа** сыенып тын гына утырасы килә.

Җәйге тымызык кичләрдә, дөнья әкрен һәм серле, шыпырт авазлар белән тулып торган чакта, ул аның үзләреннән китмәвен, кеше-карадан качып, карак кебек, ындыр артларыннан йөрмәвен тели, ялына-ялвара, сәгатьләр буе үзен кочаклап болдырда утыра, тавышсыз гына елый...

Чишмәбай йортка керергә риза түгел. Ул Хәнифәнең тегермән йортына күчеп килүен үтенә.

— Балалар бар бит. Бигрәкләр дә бәләкәй бит ул тегермән йорты. Күрше авыллардан килгәннәр тәмәке тарта, сүгенә. Нәрсә, мин анда балаларымны тәмәке төтененә ыслатыймммыни?!

Балалар кебек үпкәләшеп аерылалар.

Көн артыннан көн уза, заяга узган гомерләренең каруын кайтарырга теләгәндәй, алар көн саен очрашалар, төннәре йокысыз, көннәре әрнүсагышлар белән уза...

Тегермән йортына күчәргә риза булмагач, Чишмәбай Хәнифәне авыл советына барып, заманча язылырга, ирле-хатынлы икәнлекләрен халык алдында расларга теләде.

Анысы да барып чыкмады.

Хәнифә, заманында яшь абыстай булган кеше, бары тик дин кушканча никахлашып, мулла чакырып, алдым-бирдем ясап өйләнешүне генә дөрес дип таба. Монысы Чишмәбайның җененә килешми. Батрак булып яшәгән заманнарындагы мәхрүмлекләре, бай-бәтчәдән күргән кимсенүләре — барысы, барысы мулла-мунтагай рөхсәте белән эшләнде дип белә ул. Динчеләрне күрергә дә, ишетергә дә теләми.

Шулай да көннәрдән бер көнне, Хәнифә бик уфтанып, күз яше белән елап, Чишмәбайны каргый башлагач, өстәвенә йөкле икәнен дә әйткәч, Чишмәбай биреште — никах укытып өйләнергә булды. Әмма, нишләсәм дә эшләдем, ирлегемне иттем, катынның артына типтем, дигәндәй, никахны Габбас мулла салган йортта түгел, тегермән йортында укытты Чишмәбай.

Башта ул моңа авыл советы председателе Мәрдәнша абзыйдан рөхсәт алды. Габбас мулла урынына Яуморзадан килгән яшь мулланың япа-ялгызын гына чакырып, шәригать кушканча, барлык гамәлләрен үтәтте. Аннары авыл советына барып, заманча язылышып кайтты.

Шул ук көнне аны котларга Мәрдәнша абзый килде, үзе белән бергә Миңнулланы да алып килде. Колхоз башлыгы башта килмәс өчен юк-бар сәбәпләр уйлап чыгармакчы иде, аяк терәп карышкан иде, Мәрданша абзый эшне бик коры тотты:

— Болай булса, Батыршин, сиңа колхоз җитәкчесе булудан китәргә туры килер. Бу мәсьәләне мин, пнимайыш, Каһарманов иптәш алдына кабыргасы белән куярмын. Кара син аны — нинди эрәя! Каян килгән купич! Ике батрак чәчләрен чәчкә бәйләп, башлы-күзле булганнар — ул аларны, пнимайыш, котларга теләми. Юу-у-уук, Миңнулла-зазнайка, узды андый заманалар, ярлы-ябагайны мыскыл итә торган заманалар узды. Син моны чыкмаган мыегыңа урап куй! Йә барасың тегермән йортына, ике парны колхоз исеменнән котлыйсың, йә мин сине пралитар сыйныфына каршы кеше итеп рәислектән кудыртам.

Батыршин килде. Тик ул өнәми килгәнлеген барлык гамәле белән күрсәтергә тырышты.

Иң әүвәл ул Хәнифә түти белән эре генә, теләр-теләмәс кенә исәнләште. «Килен кеше» зур калай кружкаларга, тегермән йортында булган бердәнбер савытларга мәтрүшкә чәе ясап китергәч, калын-мул иреннәрен чәйнәштереп торды да әйтте:

— Сүз ир-ат арасында булачак, Хәнифә Хисмәева. Син өеңә кайтып, сепаратыңны юа торсаң да була.

Никахлашу хөрмәтенә чук кебек киенеп килгән Хәнифәбез, председательнең сүзләреннән гарьләнеп, үз йортына кайтып киткәч, Миңнулла «яшь кияү»гә ябырылды:

— Моңарчы без синең этлекләреңә күп түздек, Каюм Хисмәев! Моннан соң түзмәбез!

Уйламыйча әйтелгән шушы авыр сүзе белән ул ямьле көннең ямен җибәреп ташлады.

— Нинди этлекләремә? Әйт әле, пожалысты, нишләгән мин? Колхоз милкен урлаганмы, әллә булмаса, тегермәннең көрәк онын сатып эчкәнме? — Чишмәбайның чәйле кружка тоткан көрәктәй зур, тамырлары бүртеп торган кулы дерелди, маңгаена тир бәреп чыккан иде.

— Рәнҗемә, Чишмәбай, без сиңа матур сүзләр сөйләргә дип түгел, тормыш-кормыш турында гәп сугарга дип килдек. Батыршин гомер буе агач авыз булды, шул агач авызлык аңа рәхәт тә күрсәтмәде. Өйләндең, авылның иң чибәр җиңгәчәсен бичәң иттең — котлыйбыз, ягъни мәсәлән, тәбрик итәбез. И синең тәбрикләнергә пулный хакың бар. Хакы юк дип бер адәм дә әйтә алмас. Синең катының закунный — силсәвит кенәгәсенә теркәлгән. Хәер, сүз ул хакта түгел, сүз шул хактадыр ки, пнимайыш, Зартугайның күз өстендәге кашы кебек, иң булдыклы, иң җаятәш җиңгәчәсен хәләл җефетлеккә алдың син. Шулай булгачыннан, мәгълүмдер ки, бәхетле яшә и тигез гомер ит. Инде дә килеп, кияү балакай, моннан арыгысы көндә сиңа билне катырак буып, җиңнәрне ныграк сызганып тотынырга туры килер эшкә. Ягъни мәсәлән, турыдан гына ярып әйткәндә, сиңа иртәгесе көннән Зартугайның җәмәгать каралтыларын җиткезү хакында баш ватарга туры киләчәк. Бу җәһәттән Каһармановның да, менә Батыршин Миңнулланың да, минем дә фикерләребез уртак. Ужил урманыннан диләнке алдык. Менә — нәрәте кесәдә. Дөнья күрмәгән кеше түгел син, урман диләнкесен үзең карап кистерерсең. Синең карамакка ун олау, егет-җиләннең иң тазалары, и, шуннан ары килеп, олаулар башлыгына Гыйбадулла абзый Ядкаровны билгелибез.

— Бүре Бадулнымы?

— Нәкъ үзе.

— Мин аның белән бармыйм.

— Барырсың,— диде Миңнулла, аның тагын ачуы кабара башлады.— Кемне башлык, кемне урман кисүче итеп куюны без синнән сорамабыз, Хисмәев!

Чишмәбайның икенче мәртәбә хәтере калды. Ул аяк өсте басты, чандыр яңагында сеңерләре уйнаклый башлады.

Эшнең җүнлелеккә бармаганын сизеп алган Мәрдәнша абзый бу юлы, колхоз председателен читкәрәк этеп, үзе янә алгарак чыкты.

— Гафу ит, Чишмәбай, Миңнулланың дорфалыгына исең китмәсен. Бөкерене кабер генә төзәтә! Олаулар өчен син җавап бирәсе түгел, Бүре Гыйбадулласы җавап бирәсе. Синең карамакта — диләнке. Төзү материалын вакытында кистерү. Килештекме?

Чишмәбай ваклана торган кеше түгел иде.

— Ярар,— диде ул.— Бүре Гыйбадулласы өчен сез, җитәкчеләр, үзегез җавап бирәсез, мин ул җаваплылыкны өстемә ала алмыйм. Мин аның кулы чиста түгеллеген беләм. Урманнан бүрәнә дөрес китәр, авылга дөрес кайтсын. Ашау яклары ничек булачак? Урман эше авыр, суган суы суырып кына урман кисеп булмый. Коры паек бирәсезме, әллә безнең белән повар-мазарлар да барамы?

Миңнулла тагын эшне бозып җибәрә язды:

— Кайнар аш ашыйсың килсә, урманга абыстаеңны алып барырсың. Ул сиңа патша пылавы пешереп ашатыр.

Бу сүзләрдән Чишмәбайның бөтенләй хәтере калды.

— Беләсезме, нәчәлнек абзыйлар,— диде ул «нәчәлнек» сүзенә юри басым ясап.— Минем бернинди дә абыстаем юк. Элекке заманда, байгуралар халык өстендә чыбыркы шартлаткан чагында гына аны абыстай итәргә теләделәр. Абыстай чыкмады аңардан. Чыкмады! Сез бит авыл советы кенәгәсенә аны абыстай, мине мулла дип язмадыгыз. Чыгышлары ягыннан икесе дә ялчы, икесе дә бөкреләре чыкканчы бил бөккән батрак дип яздыгыз. Әллә шулай түгелме? Әллә сез безне алдадыгызмы? Юк, дисез? Алай булгачыннан, нәмәгә дип таякка кыршау сугып утырасыз?

Авыл советы башлыгы Чишмәбайның сүзләренә килгәннән бирле колап салып, аның үз дәрәҗәсен белеп сөйләшүенә, Миңнулланың аз гына кыек сүзен дә ычкындырмавына сокланып утыра иде. Бу юлы ул аның соңгы сүзләреннән рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Авызын зур ачып, шаркылдап көлде.

— Бернинди абыстай да, бернинди мулла да юк. Рабучи-керәстиян сыйныфы вәкилләре Каюм Хисмәев белән Хәнифә Хисмәева, элекке фамилиясе белән әйткәндә Уразаева, аннан да элеккерәк фамилиясе белән әйткәндә Рамазанова бар. Без менә шушы яңа оешкан закунный гаиләгә өр-яңа эш тапшырабыз: «Кызыл Зартугай» калхузының җәмәгать каралтыларын салуны. Шул җаваплы эштә башлап йөрүне. Син шуңа ризамы, рабучи-керәстиян сыйныфы вәкиле иптәш Хисмәев?

— Бер шарт белән,— диде Чишмәбай, аскы иренен тешләп уйлап торгач.— Әгәр сез минем шул шартымны үтәмәсәгез, урман кистерүгә дә, җәмәгать каралтыларын салуга да керешмим.

— Әйт шартыңны! — диде Миңнулла, тәмәке төреп.

— Шартым минем бик әллә ни куркыныч түгел, әмма-ләкин...

— Әйт, дидек бит инде сиңа, кәнсә кәнис! Нәрсә силсәвит Мурзинның авызына карап каттың? Монда бит әле Батыршин бар — калхуз башлыгы. Акчаны сиңа силсәвит түләми, мин түлим.

— Әйт, Каюм энекәш, сузма,— диде Мурзин, көлемсери биреп.

— Йорт салырлык бүрәнә бирегез миңа. Акчасын эшләгән эшемнән тотып калырсыз.

— Йорт нигә сиңа, алла бәндәсе,— диде председатель, кайнарланып.— Габбас мулланың ике катлы, чарлаклы йортын калдырып чыктык бит инде. Кәнсәләрне башка урынга күчердек, күрмисеңмени?

— Юк, җәмәгать, минем ул йортка аягым тартмый. Көчләмәгез мине,— диде Чишмәбай, Миңнуллага түгел, Мәрдәнша абзыйга төбәлеп. Тавышы аның никтер юашланып чыкты һәм кинәт өзелде.

Авыл советы башлыгы, такыр итеп кырдырган зур башын сыпыра-сыпыра, уйга калды, йөнтәс чал кашлар астыннан күзләре сәер елтырап китте:

— Үз йортымны булдырам дисеңмени?

— Мин дә кеше бит...— диде Чишмәбай.

— Кайдарак салырга ниятең?

— Тегермән эргәсендә булыр дип ниятләнәдерием. Көне-төне шунда яткач, йортның шундарак булуы мәслихәттер инде аның...

Мәрдән абзый кояшта төсе уңган аксыл кепкасын кулына йомарлап тотты, җылынып, ягымлыланып киткән коңгырт-уйчан күзләре белән Миңнуллага төбәлде:

— Нишлибез, персидәтел?

— Салсын. Рас үз йорты белән яшисе килә, яшәсен. Тик бит ул чагында мулла йортын калхузга тапшырырга туры киләчәк, туганкай.

— Алырсыз. Миңа ике йорт нигә кирәк? Балалар бакчасы юк дип кайгырадырыегыз түгелме соң?

— Менә бу акыл! Валлаһи, акыл бу! Ул чагында безгә, ник Хисмәевкә йорт салдырдыгыз дип, беркем дә бәйләнә алмас.

Миңнулла белән Мәрдәнша абзый, өсләреннән авыр йөк төшкәндәй, иркен сулап куйдылар.

## IX

Колхоз председателе Миңнулла Батыршинның соңгы көннәрдә кешеләр белән төрпәрәк сөйләшүенең тагын бер сәбәбе бар иде. Яз башында матур гына башланып киткән көннәр җәй урталарында шактый ук үзгәрде.

Яңгырлар бетте.

Июнь башыннан бирле, өч атна була торгандыр инде, күк йөзендә болыт әсәре күренми. Баш өстендә көннәр буе янып торган кояш халыкны инде хафага сала башлады. Тагын бер-ике атна шулай торса, үләннәр корыр, агачлар саргаер, ил өстенә афәт килер.

Көт тә тор, шулай булачак.

Гомер буена өметен күктән көткән крестьянны күмәк хуҗалык белән өметләндердек. Бергә яшәгәндә, бергәләп иген иккәндә, хәсрәт-кайгыларны бергәләп бүлешүе дә ансатрак, дип өйрәтеп килдек.

Игеннәр дәррәү тишелгәч, крестьян хуҗалыкларына җан кергән иде бит. Әйткән сүзне теләбрәк тыңлый башлаганнар иде.

Яңгырлар туктады. Игеннәр әлсерәп утыра.

Күпне күргән картлар, кулларын каш өстенә куеп, әледән-әле күк йөзенә төбәләләр. Кичләрен офыкка карап торалар.

— Кояш тагын кызарып баеды. Тагын аяз булыр,— дип үзара көрсенешеп куялар.

Зартугайның инде картаеп бара торган исәре Майттыпыра җөмга көнне төш вакытларында, ертылып, умырылып беткән сәләмә җиңен селки-селки, капка-коймаларга чукмар башлы артыш таягы белән суга-суга, кычкырып узды:

— Нишләп йоклап ятасыз, майттыпыралар?! Нишләп сез яңгыр боткасы ясамыйсыз? Ач каласыз бит, ахмаклар! Кем сезне туйдырыр? Ходай тәгаләне рәнҗеткән имгәкләр, кем сезгә ипи сыныгы китереп бирер?

Майттыпыра кузгалдымы — ни дә булса булырын көт тә тор. Йә яңгыр ява, йә бөтенләй корыга китә.

Шомланып көтә башладылар.

Көткәннәре бушка китмәде. Иртәгә Салагыш базары буласы дигән көнне, кичен уйламаган җирдән болыт килеп чыкты, каракучкылланды, тамырланды — ерак туп авазларын хәтерләтеп, күк гөлдерәргә тотынды. Гөлдерәүләр күбәйде, күкне урталай ярып, яшен сызылды. Төн житеп бетәргә дә өлгермәде, җилләп-давыллап яңгыр килеп житте, чиләкләп коярга тотынды...

Иж елгасында су артты. Бәрәңге бакчаларын ермачлап, гөрләвекләр агып төште. Адашып кырда калган бозауларны, сарык бәтиләрен, инешне чыккан чагында, ташкын суы агызып алып китте. «Хәерлегә булсын. Башы-аягы шул булсын...» — диде халык.

Беренче көнне күкрәп, дулап тотынган яңгыр икенче-өченче көннәрне генә тынычланды. Болытлар сиekләнды. Аннары аязды.

Дым муллыгыннан, суга туенудан кинәнгән игеннәр буйга сикерделәр. Елга тугайларындагы әрәмәләр, тал-тирәкләр ямь-яшел булып күперде, болындагы айравык үлән бер атна эчендә бил тиңентен булып үсеп житте.

Зартугай халкы печәнгә әзерләнә башлады. Иген-таруның, болыннардагы үләннең шаулап-күпереп китүенә сөенгән карт-коры, чалгы селтәячәк гайрәтле ирләргә дип, тәкә симертә, яшь киленнәр Салагыш базарыннан бизәкле тырмалар, ак яулыклар кайтарта, алъяпкычларына тамбур җебе белән болын чәчәкләре чигә, гармунчы егетләр көмеш телле тальяннарын осталардан төзәттерә башладылар...

Мондый чакта бала-чаганың күзенә йокы керми. Печән өстендә, колхозлар чыккач, күмәк эш бала-чаганы бигрәк тә үзенә тартып алды. Кырыкмыш тайга атланып, шыбын тарттыру дигәннәре бар. Ике җәп-

лекәле агач сәнәк белән печән кабарту дигәннәре бар. Күрсә, сине авыл халкы шунда күрә инде! Кем малае быел печән чүмәләсе тарттыра? Карасана, Бүре Гыйбадулласының төпчеге Мифтах түгелме? Ул да шулай шыбын тарттырырлык булганмыни инде? Гражданнар сугышыннан соң гына туганые түгелме соң әле?

Мифтах быел, кырыкмыш тайга атланып, бөтен болынны бер итеп чабып йөрисе көннәрен өзелеп көтте. Һе, андый бәхет теләсә кемгә тими ул! Аргы очның Фатих тегүчедән тектереп алган ал сатин күлмәкнең якасын чишеп, Иж буенда, олылар белән беррәттән, мир казаныннан аш ашыйсың, печән өмәсенә дип суйган үгезнең зур бер сөяген сиңа китереп тоттыралар.

Ун яше тулып килгән Мифтахетдин быелгы печән өстен әнә шундый хыяллар, шундый ашкынулар белән көтте. Тик бригадир Ишбүләк абыйсы аның бераз кәефен алды бит әле. «Сиңа мин, Мифтах энекәш, чүмәлә тарттыруны ук вәгъдә итә алмыйм, аның ансына унлап малай атлыгып тора. Әммәдәки, минем сүзне тыңлап, быел басуга чүп утарга йөргәнең, кәнүшнидә атларны кыргыч белән чистартырга булышканың өчен, печәнгә алып төшәм. Ике җәплекәле агач сәнәгеңне әзерләп куй, яме».

Баштарак иреннәре салынып төшсә дә, тора-бара Мифтах печән кабарту белән дә килеште. Ишбүләк абыйсы бит ул сүзне аның иптәш малайлары Шәйнур белән Шәкүр барында әйтте.

Әйтүен әйтте дә бит, бер бәхетең булмаса, булмый икән...

Инде бөтен нәрсә әзерләнеп беткән, инде ике көн рәттән пыяла ватыгы һәм зур игәү белән Мифтах сәнәкнең сабын да шомартып куйган иде. Гөнаһ шомлыгы, тагын өч көннән печәнгә төшәсе дип торганда гына әнисе Мифтахка урманга барып кайтырга кушмасынмы!

Бәхетсезлекнең башы әнә шуннан башланды да инде.

— Умарталыктан әтиеңне чакырырсың. Кайтып бер күренеп китсен,— диде Җамалттәй, аннары болай дип тә өстәде: — Тукта, чәчрәми тор, шунда бер уңайга, каен җиләге очрамасмы, печән өстендә кунактөшем килсә, җиләк белән чәй эчүдән дә хозуррак бернәрсә дә юк ул...— дип Мифтахның кулына җамаяк китереп тоттырды.

Мифтах иптәш малае Шәйнур янына чапты. Лапаста иске тырмага яңа теш куеп азапланган Шәйнурны урманга барырга гозерләнеп күндерде. Кояш пожар каланчасы биеклеге күтәрелүгә, алар икәүләшеп урман юлыннан йөгерәләр иде инде.

Һәрнәрсәгә үз бәясен бирми түзә алмый торган Мифтах кына, иптәшенең сары сипкелле битенә, бакыр төсле кызыл башына мыскылчан караш ташлап:

— Бодай буынга сикергән. Димәк, шушы атнада печәнгә төшәләр,— дип үзенең Шәйнурдан белдеклерәк булуын күрсәтеп узды. Аннары ул, Шәйнурга ләм-мим бер сүз әйтмәстән, томырылып чаба башлады.

Шәйнур аның чапканын белә. Әнә теге җәелеп үскән ялгыз караманы узгач та колхозның борчак басуы башлана. Борчак дигәндә кайсы малайның тыныч кала алганы бар?!

Беркавым йөгергәч, малайлар туктадылар.

Алда, күз күреме җирдә, зур яшел келәм төсле, борчак басуы җәелеп ята, аның аргы башы урманга ук барып тоташа, ә бирерә, юлны гына сикереп үтүгә, бармак юанлыгы яшел кузаклары белән күзне яндырып, атна буе көткән бәхет аяк астында елтыраша иде.

Малайлар, дөньяларын онытып, борчак җиренә сикерделәр.

Әфләтүн карт, борчак басуларының гомерлек каравылчысы, Алабаен ияртеп, урманган җиләккә кереп киткән иде. Басу ягына килеп чыгуга ул үзеннән байтак еракта өтер чаклы гына ике карамчыкның борчак җиренә килеп кунаклаганнарын күрде.

Әфләтүн карт улы Сөнгатулланы үз янына чакырып алды.

— Әнә, күрәсеңме? Аргы башта ук — ялгыз карама буенда... Ча-

кырылмаган кунаклар басу таптый. Алабайны үзең белән ал да шөр йөгерт әле шуларның эченә. Кара аны, кулың белән кагыласы булма, бәласеннән баш-аяк. Куркыт кына, ишетсен колагың,— диде.

Ләкин Сөнгатуллада күпне күргән этисе акылы юк иде шул. Янында эте дә булгач, ул үзен чамадан тыш көчле дип саный иде. Малайларның кечерәге, Шәйнур исемлесе, Алабаен ияртеп килгән Сөнгатулланы күргәч, сикереп торып арыш арасына йомылды. Икенчесе, олырагы исе дә китмичә, киндер күлмәгенең изүенә әле һаман да борчак кузагы тутыруын белде.

Сөнгатулла яшь иде, сабырсыз иде, аңа әле унсигез яшь тулып кына килә иде, тамырларында аның кайнар кан ага иде.

«Ах син! Әле син маңка башыңнан олыларны тыңламаска өйрәндеңмени?» — дип, күңеленнән бик хәтәр ярсынып, малайга этен өстерәп җибәрде.

Гаҗәп хәл — үҗәт малай бу юлы да каушамады, ашыкмый гына урыныннан торды, җиргә иелеп, таш алды, ул да түгел, үзенә таба һау-һаулап килгән Алабайга йодрык чаклы ташны шундый итеп тондырды, тегесе сыртына таш эләгүдән дөнья бетереп чинап җибәрде, шыңшып-зарланып, җирдән шуыша-шуыша, иясе янына китте.

Сөнгатулланың малайга котырып ачуы чыкты.

«Ах, син әле шулаймыни? — диде ул күңеленнән.— Борчак урларга керүең генә җитмәгән, син әле этне имгәтеп маташасыңмыни? Күрсәтим әле мин сиңа күрмәгәнеңне!»

Егет ике сикерүдә малай янына килеп җитте, җилкәсеннән умырып тотып:

— Нәрсә син урлашып йөрисең, малай актыгы? — диде.

Менә шунда ул кинәт тукталып калды. Малайның күзләре ут булып яна, куе кара кашлары тетрәнгәли иде.

— Ник син урлашасың? — диде Сөнгатулла икенче мәртәбә. Бу юлы үзе дә сизмәстән ипләбрәк әйтте.

— Ә синең ни эшең бар? — диде Мифтах, усаллашып.

— Нишләп эшем булмасын! Калхуз милке бит ул.

Мифтах дәшмәде, аякларын аерып баскан килеш, кашларын җыерып, Сөнгатуллага, бүре баласы кебек, маңгай астыннан карап тора башлады.

— Ник дәшмисең, карак? — диде Сөнгатулла. Ун яшьлек малайны җиңә алмаганга аның үз-үзенә ачуы килә иде.

— Ә син убырлы! — диде малай, тешен ыржайтып. Тешләре вак, тигез, эрләннеке төсле.

«Убырлы» — Әфләтуннар нәселенең бик ерактан килгән кушаматы, Сөнгатулланың бу кушаматны инде берничә мәртәбә кызлар авызыннан ишетеп гарьләнгәне бар иде.

«Ах, син әле шулаймыни? Үртәшә дә беләсеңмени әле син, селәгәй малай? Менә сиңа телеңне тыймасаң!» — Сөнгатулла кизәнеп торып малайның яңагына салып җибәрде, тегенең йомгактай бөтерелеп, борчак җиренә барып төшкәнен, ләкин шундук резин туптай сикереп кире торганын күрде.

— Убыр! Убыр! — дип кычкырды малай, борыныннан шаулап аккан канны күлмәк итәге белән сөртеп.— Җавап бирерсең, убырлы тәре! Бүренекеләр диләр безне. Кулыңны бик тиз кыскартырбыз! Әти синең эчәгеңне агызмаса, шушы кояшның чыраен күрмим!

Шунда гына Сөнгатулла кем малаена кул япканын аңлап, нәкъ шул мизгелдә Әфләтун картның да сүзләрен искә төшереп, агарып катты. Хәзер монда калу куркыныч иде, бу малай урманга керәчәк, умарталыкта эшләгән этисен чакырып алып чыгачак, Бүре Бадулның тимер кулларыннан берәүнең дә ансат кына котылганы юк әле.

Сөнгатулла этисе янына барып та тормады, ат юлына чыгып, туп-туры авылга элдертте.

Ләкин ул Зартугайга кайтып кына котыла алмый, Бүре Бадул аны, теләсә, җир астыннан да куптарып чыгарачак иде.

Һәм ул шулай булып чыкты да.

...Печәнгә ике кеше төшә алмады. Берсе Мифтах, икенчесе — Сөнгатулла. Алтмыш яшәр Бүре Бадулы унсигез яшьлек тап-таза егетне шундый итеп кыйнаган, аның кара көймәгән җире юк, алгы яктагы ике теше сынып чыккан, ул урыныннан кузгала алмыйча ыңгырашып ята иде.

## X

Шәяхмәт Айдаров, ярым хәрби гимнастеркадан, галифе чалбардан, озын кунычлы күн итекләрдән, ачык тәрәзә буенда, йөзен җиләс җилгә куеп, басып тора.

Июнь ахырларында була торган яңгырлы җылы җәйнең үлән исләре, өлгергән иген исләре, Пәнҗәр урамнарыннан күтәрелгән җылымса тузан белән кушылып, борыннарны кытыклый, күңелдә уйлар кузгата. Их, менә хәзер болыннарга, су буйларына чыгасы иде, карагайлы урманнарда ял итеп йөрисе иде. Дөньяны онытып. Берни уйламыйча! Болар, әлбәттә, хыял. Төштә генә үтәлә торган теләкләр.

Дөньяларны онытып гамьсез йөрмәгәнгә биш елдан артып китте бугай инде...

Утызынчы елларның башы районда күмәк хуҗалыклар төзү, активистларны үтергән кулак калдыкларын аулау, Минзәлә белән Алабуга өязләрендә кабынган сәнәкчеләр фетнәсен бастыру, элекке мәчетләрне клубларга, уку йортларына әйләндерү белән узды.

Яңа көн яңа таләпләрен куйды. Кулаклардан тартып алган йортлар гына җитми башлады. Ызансыз басуларда шаулап, кыр тулып утырган игеннәрне саклау өчен амбарлар кирәк, аннан элгәре колхоз ашлыгын суктыру өчен өсте ябулы зур ындырлар, сугу, җилгәрү машиналары кирәк; күмәк хуҗалык атларын, мөгезле эре терлекләрне, нәселле сарыкларны асрар өчен абзарлар, ферма каралтылары саласы бар; чәчү әйләнешен өйрәнү, иген игүне яңача, фән кушканча алып бару таләп ителә иде.

Боларның барысын белгечләр белән осталар гына башкарып чыга ала. Ә бит белгечләрне әзерлисе, ай саен, көн саен, ел саен әзерлисе бар. Балта осталарын, ташчыларны әйткән дә юк, әле бит аларны аерым бригадаларга тупларга, бригадирларын билгеләргә кирәк.

Моның өчен белем кирәк, бик күп белем кирәк, укытучылар кирәк, яңа заманга, социализм дөньясына лаеклы кешеләр кирәк.

Уйлый башласаң — башлар әйләнә, зиһен чуала.

Районлагы чәчү әйләнешләрен тәртипкә салу, Казандагы Җир төзүчеләр техникумына Пәнҗәр районыннан яшьләрне күбрәк кертү хакында Шәяхмәт энесе Солтанны чакыртырга, аның белән бик иркенләп бер сөйләшергә әзерләнеп беткән иде инде, ләкин бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, Солтанны урыныннан алганнар, партиядән чыгарганнар дигән хәбәр килде.

Шәяхмәт моңа, әлбәттә, ышанмады. Ничек инде алай булсын? Солтан бит җаны-тәне белән советчыл кеше. Гражданнар сугышын узды, югары мәктәп тәмамлады, колхоз төзегән елларны кулаклар кулыннан яраланды. Юк, бу — ялгыш, бу — дошман эше. Болай булгач, Солтанны үз янына чакыру район эшләрен җайга салу өчен түгел, аның үзенең эшләрен җайга салыр өчен кирәк...

...Шул уйларына бирелеп тәрәзә буенда басып торган чагында, кабинет ишеген каерып ачып, «Кызыл Зартугай» колхозы председателе Миңнулла Батыршин килеп керде. Кергән мәлгә башындагы кепкасын

йолкып алып, сарык йоны кебек укмашкан чәчләрен тәртипкә китерергә тотынды.

— Исәнмесез, Шәяхмәт абый! Вакытсыз йөргәнем өчен гафу үтенәм. Каюмны больницага алып килдем.

— Кем ул Каюм?

— Сез аны исеме белән белми торгансыздыр. Зартугайда аңа Чишмәбай гына диләр. Безгә ул башкорт ягыннан кайтып төште. Герман сугышына хәтле Таминдар бай тегермәнендә ялчы булып эшләгән иде...

Шәяхмәт Айдаров, тәрәзә янагыннан кубып, өстәл янына килде, аннан ниндидер рәсем алып, Батыршинга сузды:

— Шушымы?

— Нәкъ үзе. Ул сезгә каян килеп эләкте?

Айдаров, бер күзен кысып, икенчесен зур итеп ачты, аның кыегая төшкән усал йөзеннән, кыегайганга күрә тырпаеп калган сары мыегыннан Миңнулла аның революция өчен сугышып йөргән усал чакларын искә төшерде.

— Йә, утыр, сөйлә. Берсен-бер калдырмый сөйлә. Нәрсә сез анда кешеләрне сугыштырып ятасыз? — дип, мәсьәләне кинәт кабыргасы белән куйды райком секретаре.

Тегесе кинәт уңайсызланып, Айдаровның Зартугайда әле кичә генә булган хәлләрне белүенә аптырый төшеп, урындыкка утырды, тирләп киткән битен кепкасы белән сөрткәләп азапланды. Озак дәшмәде.

— Йә?! — диде сабырлыгы бетә башлаган Айдаров.

— Урманнан диләнке алганыек, сездән яздырган нәрәт буенча. Ну, вәт... диләнкене кисәргә, агач материалын калхузга кайтарырга кирәк бит инде. Авыл советы, партоешма, калхуз идарәсе, өчебез бергә киңәшеп, Каюм Хисмәевне, ягъни Чишмәбайны шул эшкә билгеләдек. Грамытный, намуслы.

— Алары безгә мәгълүм. Мәсьәләгә якынрак кил,— диде Айдаров. Ике йодрыгын берьюлы өстәлгә китереп куйды.

— Якын кил дип, иптәш Айдаров, нәрсәсенә якын киләсең аның? Сугышканнар...

— Кем белән?

— Бүре Бадул белән.

— Теге заманда Алабуга урманнарында партизан булган Гыйбадулла Ядкаровмы?

— Әйе, нәкъ үзе.

— Әле һаман шулай сугышырлыкмыни ул? Алтмышын тутыра түгелме соң инде?

— Алтмышын тутырса тутыра, минем кебек ун кешене рәттән тезеп куйсаң, бер сугуда барыбызны стенага очыра ала әле ул.

— Һы. Ник сугышканнар?

— Габбас мулланың тол калган абыстаен — Хәнифәне бүлешә алмаганнар.

— Кайсысы башлаган?

— Чишмәбай.

— Кызык та, кызганыч та дигәндәй, ник башлаган, тик торганнанмы?

— Тик торганнан түгел шул. Бүре Бадул Чишмәбайны мыскыллаган, бетле хәерче дигән, мулла калдыгына өйләндең дигән.

Миңнулла тагын тирләп чыкты. Бу юлы кесәсеннән таушалып беткән кулъяулыгы чыгарып, муенын, битен, колак артларын сөртергә тотынды.

«Бирсә дә бирер икән адәм баласына сабырлыкны... Әллә бу мине юри үрти, юри әкрен кылана инде»,— дип кәефе китеп уйлады Шаукымлы Шәяхәт. Ул урындыгын дөбердәтеп урыныннан торды, Миңнулланың әле һаман кулъяулыгы белән битен сөртеп азапланган зур кара кулларына төбәлде.

— Йә, нигә туктадың? Сөйләп бетер. Сөйлә, дидем бит инде мин сиңа, конца концов!

— Дөресен генә әйткән чагында, эшләр болай тора, Айдаров иптәш. Сугышу, әлеге дә баягы, Хәнифә аркасында. Габбас мулланың тол калган катыны...

— Аңар бит инде Чишмәбай өйләнде.

— Әйе, өйләнде. Ләкин Чишмәбай Габбас мулладан калган ике катлы йортка керүгә төше-тырнагы белән каршы.

— Анысы аңлашыла. Ир-ат йортка керүне хурлык саный. Хәзер кайда торалар?

— Хәнифә — үзләрендә, Чишмәбай — тегермән йортында.

— Ә нигә сугышканнар?

— Менә, иң глауный хикмәт тә шунда шул, иптәш Айдаров: ник сугышканнар? Әгәренки бик беләсегез килсә, Бүре Бадулъ элек-электән хатын-кыз мәсьәләсендә нәфселе булды. Шулай бер көнне бу, сепарат төзәтү сылтавы белән килә дә, Хәнифәгә ябыша.

— Ничек ябыша? Конкрет сөйлә.

— Бүренең бит куллар тимер кебек. Эләктереп ала да тол катынны... ни... үзең беләсең...

— Соң шуннан? — диде Шәяхмәт Айдаров, янә дә ачуы кабара башлап. Ул Миңнулланың сүзләрендә Хәнифәне бигүк өнәп бетермәүне сизеп алды.— Шуннан нәрсә булды?

— Хәнифә дә төшеп калганнардан түгел,— диде Миңнулла, аклангән сыман.— Ике йодрыгы белән берьюлы моның борынына китереп ора, каравыл кычкырып, халыкны җыя. Минем янга да акырып-бакырып килгән иде.

— Нинди җәза бирдегез? — диде Айдаров коры гына.

— Кемгә?

— Давай, Батыршин, башыңны җүләргә салып утырма! Азгын Гыйбадуллага нинди җәза бирдегез?

— Утыз сум штраф салдык.

— Аз. Бик аз. Бер-ике ай, әйе, әйе, кимендә бер-ике ай Салагыш кутузкасында төнәтеп чыгарырга кирәк иде.

— Әйттем мин Мәрдән абзыйга. Бер юлга җитеп торыр, дигән булды. Дөресен генә әйткәндә, кирәге дә кирәгие Бүренең. Диләнке кискән чакта атлы олауларга башлык итеп куярга исәп тотканыек. Юк бит кешесе, Гыйбадулла абзый кебек үткенен каян табасың?

— Акладымы штрафыгызны?

— Зерә дә нык аклады менә. Чишмәбай тегеңәр әйтә, бүрәнәне кулазак арбага икене түгел, өчне салып ташырга кирәк, ди, ә теге әйтә, кит моннан, Габбас мулланың корчаңгы кияве, ди. Чишмәбай тегеңә әтәч булып куна. Бүренең бит йодрыклар бер потлы гер чаклы, бер сукса, теш казнаңны бөтенләе белән кубарып чыгара ала. И суга да! Ун минут эчендә Чишмәбайның сөяген көл итеп ташлый. Менә больниска алып килдем.

— Нәрсә, диделәр?

— Сынган-сытылган төше юк, төзәлер диделәр. Бер биш көн өйдә ятарга туры киләчәк.

— Җинаятьчене кая куйдыгыз?

— Участок милиционерына тапшырдык. Дапруслый калды...

— Милиционер кем?

— Нажия Уразаева.

— Булдыргансыз икән. Анысы тагын утын ватып ташласа? — Айдаров, ияген кулы белән учлап, кашларын җимереп, ишекле-түрле йөри башлады. Кинәт туктады: — Ярар, бар, җик атыңны. Калганын юлда сөйләшербез. Болай булгач, мин дә сезгә бармый булдыра алмыйм.

Миңнулла чыгып киткәч, ул секретарь кызны чакыртып, аңа күрсәтмәләрен әйтте, кирәкле язуларым калмыймы дип, өстәл тартмала-

рын актарганда, күңелсез генә уйлады: «Кешеләр үзгәрә. Ә бит Гыйбадулла Ядкаров мине граждannар сугышы чорында үлем баржасыннан коткарды. Нәрсә, ул аны шул табигый көче, бунтарьлыгы аркасында гына эшләдеме икәнни? Аңлы рәвештә түгелмени? Ләкин бит колхозга да беренче булып керде. Колхоз таралган чорда да башлап йөрмәде. Нәрсә бу? Ничек аңларга моны? Иң кирәкле кампанияне, урман кисүне өзгән, ә бит без «Кызыл Зартугай» колхозын җәмәгать каралтылары житештерү буенча бөтен районга үрнәк итеп әзерләмәкче идек...»

## XI

Бүре Бадул — яланаяк, яланбаш, куллары артка каерылып бәйләнгән хәлдә — йөзе белән стенага карап баскан.

Участок милиционеры Нажия Уразаева — гимнастеркалы; күн итекле, башына йолдызлы фуражка кигән — тыенкы бер ярсу белән допрос ала:

— Гражданин Ядкаров! Жинаятьче дип саныйсызмы үзегезне?

Стена буеннан гыжлап чыккан, карлыккан тавыш ишетелә:

— Санамыйм!

— Гражданин Ядкаров! Исегезгә төшерәм: Сез Хисмәев Каюмга кул күтәргәнсез. Аны колхозга урман кискән чагында хезмәт вазифасыннан аергансыз. Физик көчегез белән масаеп, алдынгы колхозчыны, беренче кул балта остасын канга батырып кыйнагансыз. Сез боларны таныйсызмы?

— Мин әле аңа әз тамыздым. Аерып алмасалар, мин аны үтерә идем.

— Ник?

— Габбас мулланың тол катынына өйләнгәне өчен. Ике катлы чарлаклы йортның хуҗасы булырга теләгәне өчен.

— Хисмәев мулла йортын алмаячак. Сез алдашасыз, гражданин Ядкаров! Намуслы кешегә яла ягасыз. Мулла йортында балалар бакчасы булачак.

— Ышанырлар дип беләсеңдер, мулла көчеге! Тот капчыгыңны!

— Яп авызыңны, корткыч!

— Япмасам, нишләтерсең? Атарсыңмы?! — Бүре Бадул кинәт стенадан куба, йөзе белән милиционерга таба борыла: — Мә, ат! Үтер — мә! Төкерәм мин сиңа! Төкерәм мин синең наганыңа! Төкерәм мин синең ише закун капчыкларына!

Шул минутта гөрселдәп наган атыла. Көпшәдән чәчелгән ут көлтәсе сүнүгә, бүлмәне куе зәңгәр төтен каплап китә.

Ишектән кешеләр йөгерешеп керә. Уразаева, тешен ыржайтып, наганын баш өстендә болгый-болгый, аларның юлларына аркылы төшә.

Керүчеләр чигенә.

Бүлмә эче тынып кала.

Уразаева шул мизгелдә халыкны аралый-аралый бүлмәгә кереп килгән дәү бәдәнле, сары мыеклы, ярым хәрби френчлы бер кешене күреп ала.

— Сабыр, иптәшләр, сабыр. Юл бирегез әле миңа.

Участок милиционеры шул мизгелдә Айдаровны танып ала, райком секретаре белән көрешмәкче булып кулын суза, ләкин Айдаров аның кулын һавада асылындырып калдырган көе, идәндә яткан Гыйбадулла Ядкаров өстенә иелә, исән икәнен аңлап, ишек төбендәгеләргә дәшә:

— Ике кеше! Живо! Тоткынның кулларын чишегез.

Участок милиционеры Уразаева төтеннең таралганын, Бүре Бадулны ике кеше күтәреп торгызуын, кулындагы бауны чишүләрен мыскыллы бер елмаю белән күздән үткәрә.

Төтен таралып бетүгә, ишек төбенә иелгәннәрнең арасыннан ике метрлы гәүдәсе белән Әфләтүн карт алга чыга.

Ул әле милиционерга, әле райком секретарена таба башын борып, ачулы сөйләнә:

— Әгәр дә мәгәр, бу адәм тәганәсен җәзасыз калдырсагыз, Мәскәү хәтле Мәскәүгә барып җитәм. Бандит бит ул. Юлбасар! Ул минем Сөнгатулламны гарип ясады. Судьялар әйткәннәр, алтмыш яшьлек карт унсигез яшьлек егетне кыйный аламыни дигәннәр. Көлке! Валлаһи газим, көлке! Әфләтуннныкылар кем дә Бүренекеләр кем! Безнең тамак гомер буе ипигә туймады, хәзер дә туйганы юк. Бүре Гыйбадулласы гомер буе урлап ашады, кеше талады. Нишләп сикермәсен ул! Нишләп ул кешеләргә котырган бүре төсле ташланмасын. Бүренекеләр — гомергә бүре. Иман юк аларда, алладан җәяүләп качкан денсезләр. Җәзасыз калдырсагыз, Казанына да, Мәскәвенә дә барам, соңгы кәҗәмне сатып барам, гаделлекне җирдә яткызып калдырмыйм.

Айдаров участок милиционерына халыкны таратырга боера.

Ишек төбендә халык таралып, тавышлар тәмам тынгач, Гыйбадулла Ядкаровны ике кеше култыклап алып, өстәл янына утыртып куйгач, райком секретаре милиционер каршысына басып, таләпчән усал тавыш белән сорый:

— Участковый Уразаева! Ни өчен сез совет демократиясен бозасыз? Минем бит сезгә: киртә сикермәгез, закон рамкаларында эш йөртегез дип ничәмә-ничә тапкыр әйткәнем бар.

Уразаева, кулын чигә турысына күтәреп, честь бирә.

— Иптәш райком секретаре, мин сезгә фуражкамдагы кызыл йолдыз белән ант итеп әйтәм, бу кеше гуманлы законнар кулланып эш итүдән узган. Моны үзе төсле бүре законнары кулланып кына җиңеп була. Бая кергән Әфләтүн бабай дөрес әйтә, аның улы Сөнгатулланы ул гарип ясаган. Каюм Хисмәевне урын өстенә ятарлык итеп кыйнаган. Ник? Чөнки моңарчы җәзасыз калып килгән. Районнан килгән түрәләрне ачы балда коендырган. Беләсезме, нишләтергә кирәк андыйларны? Стенага терәп атарга! Атарга андый контрларны — төбе-тамыры белән юк итәргә!

— Участковый Уразаева! Сез ни сөйләгәнезгә хисап бирәсезме?

— Бирәм, иптәш секретарь. Сез килеп җитмәсәгез, мин аны... Үзем себер китсәм китә идем, аны җир йөзендә калдырмый идем. Рәхмәт әйтсен, җиңелчә курку белән котылды.

Нажия Уразаева, тешләрен шыгырдатып, йодрыкларын төйнәп, өстәл буенда йокымсыраган төсле утырган Бүре Бадулга шундый итеп кизәнде, тегесе урыныннан сикереп торырга, кап-кара сакал баскан җәенке битен куллары белән капларга мәҗбүр булды.

— Но-но-но-но!

— Уразаева, сез китә аласыз,— диде Айдаров, бу юлы тыныч-сабыр тавыш белән әйтте.— Минем Гыйбадулла абзый белән икәүдән-икәү генә сөйләшәсе сүзем бар.

— Сөйләшегез, миңа димәгәе, кочаклашып үбешегез! — Участковый ишекне каты ябып чыгып китте. Ләкин шундук кире борылып керде: — Юк, иптәш Айдаров, мин сезнең үзегезне генә бандит белән калдыра алмыйм.— Аякны аякка бәреп, тураеп басты.

Райком секретаре аның егетләрдән дә болайрак төз басып торуына, кояш ашаган, җилләр кискән кара туткыл битендәге ирләрчә ныклыкка сокланып карады.

«Революция казанышларын яклар өчен теләсә кайчан эшафотка китәргә әзер бу. Бөркет!» — дип яратып уйлады.

Җиңелчә ым кагып, чыгып торырга кушты.

Участковый, иренен тешләп, теләр-теләмәс кенә чыгып китте.

— Йә, Гыйбадулла Ядкаров, без менә икәүдән-икәү генә калдык. Без бер-беребездән тел яшерә торган кешеләр түгел дип беләм. Икебез

дә революция өчен сугыштык. Җир кешесенә ирек дауладык. Оныткан дип уйламагыз, мин сезнең егет заманнарыгызны онытмадым, мине үлем баржасыннан коткарганыгызны. Егетлек теләсә кемгә тәти торган сыйфат түгел.

Гыйбадулла Ядкаров сөзәк маңгае астыннан зәһәр елтыраган үткен соры күзләрен Шаукымлы Шәяхмәткә төбәде, сүзләрен теш арасыннан кысып чыгарды:

— Салкын суда арыш боламыгы болгатмыйк, Шәяхмәт. Чират синеке, авылдаш. Рәхмәтеңне бише белән кайтарырга җае чыгып тора. Коткар мине бу мулла көчегеннән.

Айдаров башын читкә борды, әле һаман тәрәзә буенда өелеп торган халыкка күз сирпеп алгач, кистереп кенә әйтте:

— Сүз ул хакта бармаячак, Гыйбадулла абзый.

— Нәрсә хакында барачак?

— Ни өчен син, революция солдаты, башка сыймый торган эшләр эшлисең? Торып тор, сорауны хәзер мин бирәм. Ни өчен син, Гыйбадулла Ядкаров, авылда башбаштаклык эшләп ятасың? Нәрсә, сиңа Совет власте законнары закон түгелме? Нигә син авылдашларыңны кыйныйсың, җәмгыятькә файдалы эштән аларның гайрәтләрен чигерәсең?

— Син мине әгитләмә, Шаукымлы Шәяхмәт. Син белгәнне без дә беләбез. Урыс Пәнҗәрендә дәү түрә булып утырам дигәченнән дә борыныңны түшәмгә хәтле чөймә. Рәхмәтеңне белдерәсең килә икән, үзеңне үлемнән коткарганны онытмагансың икән — дустың итеп, коткаручың итеп сөйләш минем белән. Ул чагында, бәлкем, мин дә җанны ачармын сиңа. Совет влачы дип кычкырып йөргән бушбугазлар синнән башка да җитәрлек авылда.

Айдаровның теш казналары кысылып килде. Бүре Бадул моны сизде. Габделхәлим купецлар, Таминдар байлар белән исәп-хисапны өзгән усал Шәяхмәт, революционер Шәяхмәт утыра иде аның алдында. Сөрмәле озын керфекләр белән каймаланып алынган якты-зәңгәр күзләрендә аяусыз очкыннар биешеп алды аның. Биеште, ләкин шундук сүнде. Заманы ул түгел. Заманы башка... Кулың кыскарак, Айдар Шәяхмәте! Урта хәлле крестьян — ярлы-ябагайның союзнигы дип атала хәзер. Бәлкем, әле ул, урта хәлле крестьян — кумәк хуҗалыкның иң зур терәгедер? Теш казнаңны кысу түгел, бүре булып уласаң да, берни кыра алмыйсың, Айдар Шәяхмәте!

Бүре Бадулның усаллашып утыруын райком секретаре да сизеп алды. Тик ул аны тагын бер мәртәбә яхшылык белән алдырырга исәп тотып карады.

— Мин сине берничек тә коткара алмыйм, Ядкаров. Син моны аңларга тиеш. Хәер, аңлыйсыңдыр, акылсыз адәм түгел син. Коткарсаң син үзеңне үзең генә коткара аласың. Үкенеп. Гаебеңне танып! Намуслы юлга басып кына. Синең өчен хәзер иң беренче, иң дөрес юл — гаебеңне тану. «Кызыл Зартугай» колхозы кешеләре алдында, гомуми җыелышта. Йә син шул эшне эшлисең, йә сине кылган җинаятьләрең өчен судка бирергә туры киләчәк. Аңлата алдыммы? Башка юл юк сиңа, Ядкаров.

— Аңладым. Аңламаган кая!— диде Бүре Бадул, сумаладай куе кара сакалы эченнән мыскыллы елмаеп.— Шулаймыни?!— диде усал тавышка күчеп.— Акылың алтын икән синең, Айдар Шәяхмәте! Беләбез без синең тәртәне кай якка борганыңны! Башта мине гаепле итеп чыгармакчы, шуны үз телем белән шаһитләр алдында әйттермәкче, аннары өтерләнгә яптырып, ялгыз камерада черетмәкче. Булмас аның! Булмас, Айдаров! Син белгәнне мин күптән чыгарып элгән. Без дә аңгыра бәрән түгел, законның кем ягында икәнен беләбез. Әнә синең энең Солтан этисе хәтле этисен зимләмир чокырыннан мылтык атып чыгарган ие, төшкәннәрме эзенә? Очырганнармы фиркасеннән? Совет влачы син генә түгел. Казан бар, Мәскәү бар. Уразаеваны узындырган өчен дә башыңнан сыйпамаслар!

Бүре Бадул аяк өсте күтәрелде, йөзе явызлыктан чалшайган, күзенең карасы эчкә кереп беткән, агы гына акаеп калган иде.

— Участковый!— дип кискен итеп дәште Айдаров.

Милиционер Уразаева честь биреп кереп басты.

— Тыңлыйм, иптәш секретарь!

— Гражданин Ядкаровны бүген үк, бер минут та кичекмәстән, Пәнжәргә илтеп тапшырыгыз. Аның эшен сез тикшермәссез. Аңладыгызмы мине? Юкса ул Уразаевлар нәселенә ачу саклый. Ядкаровның эшен районның суд тикшерүчесе Антон Петрович Черемасов алып барыр.

— Алып китәргә рөхсәтме, иптәш секретарь?

— Рөхсәт.

— Кузгал!— дип ачы тавыш белән команда бирде участковый Уразаева. Ядкаровның урман аюыдай авырдан гына кузгалуын сабыр гына карап торгач, өстәде:— Живо! Анда синең тел ачкычыңны табарлар. Черемасов кулыннан ычкынган бандитның әле дөньяга килгәне юк.

... Алар чыгып киткәч, Айдаров папирос кабызды. Зәңгәр төтенгә уралып, үз уйларына бирелеп утырды.

«Ай-һай күп эшлисе бар әле авылда. Кем уйлаган Гыйбадулла Ядкаровны кешеләрне имгәтеп ятыр дип? Революцияне яулап алу гына аз икән, әле аны үстерергә, тирәнәйтергә кирәк икән. Ленин ул хакта актык сулышына тикле юкка гына борчылмаган икән...»

Ул, кискен бер карарга килеп, идарә бүлмәсенә керде. Үзен өстәл янынннан торып каршы алган Батыршинга:

— Мурзин белән Каһармановны чакырт. Эшләрегезне карарга чыгабыз,— диде.

## XII

Чишмәбай, авырудан терелгәч, ныклы бер карарга килде. Әгәр аның сәламәтлеге ныгып җиткән булса, моннан соң да ул үзеннән көлдерергә теләмәсә, быел, менә шушы матур җәй аенда, бер генә көнгә дә кичекмәстән, үз йортын салып керергә тиеш.

Баштарак күңеленә берекән уйдан — йортны тегермән янына ук салу уеннан кире кайтырга туры килде. Ник дисәң, Габбас мулладан калган ике малай, бер кыз тегермәнгә килгән мужиклар арасында аунамаслар бит инде. Аларның тәмсез сүзен, сүгенү-каргауларын ишетү сабыйларга ник кирәк? Озакламый аның үз улы да дөньяга килер. Әйе, беренче баласының малай булуын тели ул. Чишмәбай аңар чишмәләр җырын өйрәтер; сандугач сайрауларын, тургай талпынуын, инеш-елгаларның моңын, табигать дөньясының матурлыгын таный белер ул. Шушы дөньяның патшасы, алласы булыр.

Нинди илләр, нинди ерак җирләр күрде Чишмәбай, нинди генә милләт кешеләре белән очрашмады — аларның барысында да ул гади халыктан, үз кул көче белән көн күрә торган хезмәт кешеләреннән дә матуррак, киң күңеллерәк, кунакчылрак берәүне дә очратмады.

Аның улы да шундый булыр. Азамат ирләр нәселеннән булыр ул. Дөньядагы иң зур, иң куәтле тегермәнне алты ташлы, ике куласалы тегермәнне үзенә буйсындыра белер ул. Тегермән улагыннан аккан мамыктай йомшак, җылы онны учына тотып караган чакта ул шушы оннан пешкән икмәкне ашыйсы кешеләрне күз алдына китерер.

Ә хәзер, ул теләккә ирешер өчен, шул көннәргә тикле барып җитәр өчен, хыялдагы күгелҗем томаннарны ерып чыгарга, күз камаштыргыч зәңгәр биеклектән җиргә төшәргә, нарат сагызы исе аңкыткан сап-сары бүрәнәгә үзең беренче булып балта чабарга, ап-ак йомычкаларның тирә-юньгә очканына җаның-тәнең белән сөенеп, алны-ялны белмичә эшләргә кирәк.

Председатель Миңнулла, авыл советы башлыгы Мәрданша һәм ул үзе — өчәүләшеп — булачак йортның урынын билгеләделәр.

— Тегермән эргәсендә булсын,— диде Миңнулла.— Килгәнне-киткәнне күреп торырга, күз-колак булырга яхшы!

— Юк, авылның бөтенләй башка башында булсын. Адәм баласына ял итәргә дә кирәк ләбаса!— диде Мәрданша.

Чишмәбай күрсәнде.

Күктәге кояшка карады, тегермән буасы ясаганнан соң җәелеп киткән Төчкәнеч инешенә карады, хыялында Иж елгасын кичеп чыкты, колак артын кашып торгач, ашыкмый гына әйтте:

— Минемчә, минем өй, чүтәки, тегермәннән ерак булмаска тиеш. Мин аның ашлык тузаны очкан җирдә, тегермән эргәсендә үк булуын теләмим, әлбәттә; әммәдәки, мин аның Ужил урманы ягындагы аргы очта булуы белән дә риза түгел. Әгәр дә мәгәр, сез миңа, тегермән буеннан бер өч йөзме, дүрт йөзме сажин ераклыкта, ягъни мәсәлән, биш-алты минут эчендә тегермәнгә килеп җитәрлек төштә, үзем төзәткән чишмәләр буенда урын бирсәгез, мин сезгә гомерем буе рәхмәтле булырыем.

— Әйдә, шулай булсын, без сиңа үзең теләгән төштә йорт салырга рөхсәт итәбез,— диделәр башлыклар.

Чишмәбай Аксагыз тауларының итәген — Төчкәнеч инешенә таба канау сузган зур гына чишмә янын сайлады. Язгы ташулар да, чишмә чылтыравы да, канау буенда күкрәп үскән бөтнек исләре дә булачак. Кеше кулы-аягы тимәгән торфлы җир, бытбылдыклар чутылдашкан, тартарлар тырылдаган Зирек әрәмәсе — болар барысы Чишмәбайның җанына бик тә якын, иренмәсәң, булсынга эшләсәң, ул тирәләрне шау чәчәкле җиләк-җимеш бакчасы итәргә дә була бит әле. Шөкер, германнар җирендә ул бакчаларны күп күрде, җирнең кадерен белүчеләрне, башлары йомры, исәп-хисаплары түгәрәк кешеләрне байтак очратты. Анда ашъяулык кадәре генә җирдән дә никадәрле уңыш алганнарын, җиргә чатырдап ябышканнарын үз күзе белән күреп кайтты бит ул...

Чишмәбай сораган Олы Чишмә янына җиткәч, Миңнулла, бер учлам бөтнек йолкып алды, аның яфракларын учы белән уып торгач, озаклап иснәде, аннары чишмә улагына ятып, тыны кысылганчы салкын су эчте, күтәрелде, кул аркасы белән иреннәрен сөртеп алгач, әйтте:

— Йә, Каюм Хисмәев, синең бу йорт урының бәрәкәтле булсын! Тик безне, Мәрданша абзаң белән икебезне, онытмассың, бөтнек алырга килсәк, ихатаңа кертерсең,— дип, авыл советы башлыгына күз кысып алды.

Тагын ике көннән мәсьәләне колхоз идарәсендә карадылар. Законча булсын. Актыктан Хисмәев Каюмга тиешле-тиешсез урын бирдегез дип бәйләнеп йөрүчеләргә юл калмасын.

Чишмәбай ул кичне, тегермән йортыннан чыгып, куласага су җибәрә торган арык янында су шаулавын тыңлап утырды. Күктәге йолдызларга карады. Гомер буе гаделсезлектән интеккән, күз төпләренә бик иртә капчыклар асылынган йөзе бу юлы хәсрәттән түгел, шатлыктан, гаделлекнең өскә чыгуыннан кинәт үзгәреп китте, иреннәре дерелдәде, тегермән оны сеңгән иске күлмәгенә тамчы-тамчы яшь тамды.

Иртәгәсен ул үзенә кулалмашка Зартугайның бик шәп дүрт балта остасын — ике картны һәм ике гүәрдин егетне сорап алды. Зартугайга кайтканнан бирле күзе төшеп йөргән кешеләрне идарәдән сорады.

Бирделәр. Хәйләкәр һәм астыртын акыллы Миңнуллага җәмәгать каралтылары салыр өчен кадрлар кирәк иде. Беренче кул балта остасы, столяр, рамчы, пыялачы, калайчы, тагын-тагын әллә кемче Чишмәбай кул астында һөнәргә өйрәнерләр, нәрсәнең нәрсәгә яраганын үз күзләре белән күрерләр.

Ике көн эчендә, инде урак өсте булуга карамастан, ул — нәкъ ике көн эчендә — Чишмәбайга кирәкле бүрәнәне ташытып куйды.

Менә шуннан соң Аксагыз тавы итәгендә көннәр буе,— иртә таңнан караңгы төшкәнче,— балта тавышлары яңгырап торды.

Дөньяда тырышлыкның, булдыклылыкның, ару-талуны белмәүнең нәрсә икәнен күрсәтеп тә карадылар осталар! Бер атна тула дигәндә, сап-сары бура калкып чыкты; түбәлек һәм түшәм-сайгаклык такта ярып, аны кояш астына челтәрләргә өйделәр; былтыр талкыган киндер калдыкларыннан бүрәнә мүге әзерләделәр. Эш тәмам кызып җиткән иде. Бүгенле-иртәгәле уракка төшәсе булганга, аз гына бүленеп торырга туры килде. Колхоз идарәсе Чишмәбай бригадасына әзерлекне барларга кушты.

Урак машиналарын, арба сиртмәләрен, тугымнарны, камыт-ыңгырчакны, дугаларны, кыскасы, урып-җыю вакытында кирәк булачак һәммә нәрсәне тикшереп чыгарга кирәк иде.

Идарә йорты алдына тезеп куелган арбалар, канатларын югары күтәргән урак машиналары — жаткалар, лабогрейкалар, өемнәргә өелгән тырмалар, тешәлгән ураклар, бәйрәм-сабантуй көннәрендәгечә чуклы-чачаклы киемнәрен кигән хатын-кыз, ак тула оек өстеннән яңа чабата киеп, кыска киндер алъяпкыч япкан, күлмәк якаларын чишеп, җиңнәрне сызганып куйган ирләр, сусыл үләндә айлар буе йөреп көрәйгән байталларның авылны яңгыратып кешнәп җибәрүләре, һәр бригада турысына эленгән ал байраклар, кызыл комачка язылган плакатлар, «Кызыл Зартугай» җитәкчеләре белән бергә әлеге әкәмәтне карап йөргән Салагыш комиссиясе — беренче мәртәбә колхоз авылында уздырылган смотр, ягъни урып-җыюга әзерлекне ярышташлары белән бергә тикшерү — халыкны кузгатты, җилкендерде, ду китерде!

Башкаларны әйткән дә юк, басуларның колхоз оешканнан бирле каравылчысы булган Әфлатүн карт, ике метрлы буе белән чал сакалын селкетеп, Зартугайның җүләре Майттыпыра белән кулга-кул тотынып, такмак әйтеп йөрде:

Иш булдык, куш булдык,
Зур тормышка кушылдык!

Чишмәбай исеме ул көнне теллардән төшмәде:

— Булдыра бит, ә! Булдыра! Куллары алтын икән, билләһи!

— Тырыша җегет, утлар уйната!

— Тырышмыймы соң, калхуз бушлайтын йорт салып бирсен әле. Андый бәхет кемгә тәтегән?!

— Йортны анысы, җаным, бушлай салмаслар. Алдарсың бар хөкүмәтне, бише белән кайтарыр әле...

— Кит моннан, коткы салып торма, калхузга да эшли Чишмәбай, үзенекен дә булдыра. Җегет дисәң дә җегет ичмасам!

Районнан смотрга дип килгән Шәяхмәт Айдаров, колхоз җитәкчеләре белән бергә, Чишмәбайның да кулын кысты:

— Молодец, иптәш Хисмәев, булдырасыз! Бригадаңа райком бюросы исеменнән рәхмәт белдерәм.

Халык алдында белдерелгән рәхмәт үзенекен итте. Председатель Миңнулла Чишмәбайдан атны да, осталарны да кызганмады.

Август башларында йортның түбәсен ябып, ишек-тәрәзәләрен куйдылар.

Чишмәбай ап-ак йомычка белән тулы ишегалды уртасында биленә таянып, яңа гына салынып беткән йортына беркавым карап торды да, зур бер кәрзин белән икәүләшеп, чәрәшә-чәрәшә йомычка сөйрәп барган ике кара чутырны — дүрт яшьлек игезәкләр Мәхмүт белән Әхмәтне кәрәктәй дәү куллары белән үзенә көрәп алды. Ул да түгел, үги әтисе янына оялчан гына елмаеп, башын муенына яшереп ун яшьлек Шәфика да килеп җитте.

— Менә, балакайларым, безнең яңа йортыбыз булды. Игелеген күрергә язсын инде...— диде Чишмәбай.

Бүлтәйгән, чүмәлә хәтле булган корсагын ике кулы белән каплый төшеп, капкадан кереп килгән Хәнифә түти иренең соңгы сүзләрен хуплап:

— Ярабби, ярабби...— диде.

## XIII

Яңа йортка тагын ике атнасыз күчә алмадылар.

Чишмәбай элеккечә, борын-борыннан килгән авыл йортларындагыча бөтен өйне тутырып сәке ясарга теләмәде. Хәнифә белән үзләренә түр якка агач карават, өстәл, урындыклар әмәлләде, балаларга почмак якка калын такталардан сәке җәеп бирде.

Калганын көтмәделәр. Өйнең бизәклисе, чуарлыйсы әйберләре — киштәләре, чоланнары — болары күп иде әле, бик күп иде, насыйп булса, табигать сәламәтлектән аермаса, барысы да үз җае белән булыр дип, шөкерана кылып, яңа йортка күченделәр.

Күченеп кенә бетүләре булды, яңа йортның капкасы төбенә тарантаслы бер ат килеп туктады.

Хәнифә түти күрде моны беренче булып. Күрде дә хатын-кызга хас рәвештә, аптырашка калды:

— Йа, аллам, кем булыр бу! Бер дә безнең якларга охшаган кешеләр түгел бу, Каюм. Карасана, кемнәр булыр бу, ә?

Чыннан да, килүчеләр авыл кешеләренә охшамаган иде.

Тарантастан озын алсу күлмәкле, ак эшләпәле, урта яшьләрендәге бер хатын кулына нининдер кәрзин тотып төште. Киемнәренә, вәкарь белән генә вак-вак атлап килүенә караганда, бу як кешесенә охшамаганы әллә каян күренеп тора иде.

Тарантастан төшкән чикмәнле карт дугадан атның йөгән тезгенен чишә башлауга, ишегалдында йөргән ике ташбаш урамга ташландылар. Ләкин Шәфика аларны узып китте.

— Нурия апа! Нурия апакаем! — дип ул җан-фәрманга йөгереп килде дә апасына сарылды.

Ташбашлар да килеп җиттеләр. Бармакларын авызларына кабып, Шәфика апалары кочаклаган чит-ят апага бик тә сәерсенеп карап тора башладылар.

— Болар кем, сеңлем? Әллә Әхмәт белән Мәхмүтме? — диде Нурия, балаларга төбәлеп.

Ул арада Шәфика аңына килде, апасыннан аерылды.

Нурия кәрзиннән бер кәгазь төргәге чыгарды, аны сүтеп, башта Шәфикага, аннары Әхмәт белән Мәхмүткә уч тутырып печенье бирде.

Малайлар, күчтәнәчләрен күтәреп, әниләренә күрсәтергә йөгерделәр.

Каерып ачып куйган урыс капкадан кергән чакта, Хәнифә белән Чишмәбай да чоланнан ишегалдына килеп чыктылар. Үзләренә нинди кунак килгәнне беренче булып төшенеп алган Хәнифә янә дә бер мәртәбә дөнья бетереп аваз салды:

— Ярабби! Нурия, гөлкәем, син түгелме соң бу?! И аллам, йа ходаем, сине дә күрер көннәр бар икән! Ничекләр кайтасы иттең? Бигрәкләр дә мактап йөрисең икән. Яңа өебезнең бусагасын, болай булгачыннан, син беренче булып атлап керәсең инде...— дип, Нурияне кочаклаган килеш елап җибәрде.

Нуриянең дә күзләре дымланды, тик ул үзен шундук кулга алып, Чишмәбайга таба борылды.

Ә Чишмәбай исә, затлы киемле, бер чакрымнан ислемай исләре аңкытып торган кунак хатын белән ничек итеп күрешергә икәнен дә белмичә, балта-көрәк сабы тотып бирчәйгән дәү кулларын сузаргамы-юкмы дип икеләнеп калган иде.

Нурия беренче булып үзе күреште:

— Түти, Чишмәбай кияү шушы буламыни инде? Тукта, миңа кем тиешле соң ул? Әти дисәң, без бер чордарак үскән идек шикелле, кем дип әйтергә дә белмим бит әле мин сине, туганым?

— Сезнең никахыгыз миннән олырак, үзегез миннән яшьрәк бугай.

Мин сезгә Нурия апа дип дәшәрмен. Сез ничек телисез, шулай дип әйтерсез,— дип Чишмәбай, авыл гадәте буенча, ике куллап күреште.

Кучерга атын ишегалдына алып керергә булышты.

Юл уңаенда Хәнифәгә, әле һаман да аптырау халәтеннән чыга алмаган хатынына, кыска гына итеп боерды:

— Карале, сиңайтәм, кунакны ишегалдында тотма инде, өйгә алып кер. Мин хәзер тегермән йортына сугылам. Он алып кайтырмын,— дип үз юлына китеп барды.

Ул әйләнеп кайтканчы, олаучы карт атын тугарып, аны печәнгә кушканчы, Хәнифә белән Нурия бер-берсен бүлдереп, гаҗәпләнү-соклану, аһылдау-уһылдауларын да онытмыйча, эч серләрен бүлешергә өлгерделәр.

— Менә, гөлкәем, шулай. Әнкәң мәрхүмә, Шәмсениса көндәшемне әйтәм, авыр туфрагы җиңел булсын, бик тә сабыр холыклы, дөньяның бер акыллы кешесе иде. Язмыштан узмыш юк, бәбкәм, дип юата торганые мине, әткәңә үсмер кыз гына булып кияүгә чыккач. Җылатмый торганые, булганына шөкерана кылырга кирәк дип әйтә торганые. Хак булган икән. Тегермәнче Чишмәбай белән чәчләребез чәчкә бәйләнер дип кем уйлаган? Алда тагын ниләр күрәсе бардыр, әлегә бик ипле, бик эшчән, чит кеше балалары дими. Мәхмүтем белән Әхмәтем өчен дә, Шәфикам өчен дә өзелеп кенә тора... Берәү булса, үз балаларына да ул хәтле ягымлы булмас иде,— дип, Хәнифә түти, ихтыярсыз, күперенке корсагын сыйпап куйды.

Нурия — врач кеше — Хәнифә түтинең инде бала табар чагы да җитеп килгәнен күрде. Корсаклы хатыннарның, гадәттә, битенә тут төшә, иреннәре зураеп, күпереп кала торган була. Хәнифәнең битендә андый тапларның эзе дә юк. Ул балага узуны, йөк күтәрүне үзе өчен кыенлык дип тә карамый булса кирәк. Табигать тәгалә (материалист Нурия Уразаева күптән инде аллаһы тәгалә дип уйламый иде), әйе, табигать тәгалә аны, күрәсең, нәселне алып барыр өчен, табигатьнең үзе төсле үк көчле, талантлы итеп, төрле-төрле шартларга яраша белә торган итеп яраткан ахрысы.

Гаҗәеп нәрсә бу табигать дигәнең: үзенең яраткан бер талантлы баласына барлык илаһилыгын, барлык бөеклеген җыя да бирә!

Нурия кайчандыр кече әнисе булган, аны карап-багып үстергән Хәнифә түтәе турында, бәлки, беренче мәртәбәдер, әнә шулай олы итеп, яратып, ихтирам белән уйлады. Моның шулай икәнен төшенеп алгач, үзе өчен гүя ачыш ясагандай булды. Әнә шул ачыш өйгә кәрзин белән йомычка-шакмак алып кергән, нәзек куллары белән самавырга килеп тотынган Шәфика сеңлесенә күчте. Тагын да зуррак ярату булып, заманында әтисенә әйтә алмый калган иркә сүзләр булып, мәрхәмәтлелек булып күчте.

— Сеңлем, ускәнем, матурым, карачы миңа! Энеләрең кая киттеләр соң? Мин бит сезгә бүләкләр дә алып кайткан идем бит әле,— дип кәрзиненә үрелде.

— Мәхмәй белән Әхмәй чишмә буена киттеләр.

— Нишлиләр анда?

— Син биргән печеньены суга манчып ашыйлар.

Нуриянең үзәкләре өзелеп, тамагына тагын төен килеп тыгылды.

— Син, апам, курыкма. Хәзер кайталар алар. Син бит китмисең әле, әйеме?

— Юк, балам, китмим әле. Китсәк тә без бергә китәрбез.

— Әйем. Минем укыйсым бар. Чишмәбай абый миңа букча алып бирде инде! — дип, Шәфика фанердан ясалган, аллы-гөлле буяулар белән чәчәк төшерелгән сумканы апасына китереп күрсәтте.— Матур бит, апам, әйеме? Мин аны яшереп кенә тотам. Ату Әхмәй белән Мәхмәй букча өчен сугыша башлыйлар. Матур бит, әйеме, апам? — дип ул икенче кабат сорады.

— Бик матур, ускәнем. Чәчәкләре дә бик матур. Сабы да каештан. Үзе тагын нинди җиңел икән. Моны мин дә күтәреп йөри алам,— дигән булды Нурия апасы. Хәнифә түтәенә күз кысып.— Каяле, гөлием, без синең букчаңны котлыйк әле,— дип ул сеңлесенең букчасына төсле карандашлар белән ике юка дәфтәр салды.

Шәфика, балаларга хас сабырсызлык белән букчадан карандашлар тартмасын, дәфтәрләрне тартып чыгарды, берәм-берәм актарып карады, шешмәгрәк кабаклы шомырт кара күзләрендә сөенеч очкыннары биешеп алды.

Ул арада Мәхмүт белән Әхмәт тыннары кысылып өйгә кайтып керделәр.

Нурия аларны үз яннарына чакырып алды, икесен ике тезенә утыртып, аркаларыннан сөйде, баягы кәрзиненнән ука белән чиккән ике яшел түбәтәй алып, энеләренең башына кигертте.

Малайлар, түбәтәйне башларыннан салып, әйләндереп-әйләндереп карадылар, аннары тагын кунак апаларының тезенә үрмәләделәр.

Чишмәбай белән олаучы карт кайтты.

Хәнифә түти самавыр кайнатып китерде. Сөтләре бар икән, аны да чыгардылар. Күкрәккә терәп ипи кисте Хәнифә түти. Нурия каладан алып кайткан күчтәнәчләр дә табынга куелды.

— Җитешегез әле. Тартынып утырмагыз, яме. Менә кәнфитен дә алыгыз. Үз күчтәнәчен ашаган кеше озын гомерле була ул,— дип Хәнифә түти, алчакланып, тәмле теле белән кыстый-кыстый, самавыр артында чәй ясап утырды.

Чәйдән соң, Хәнифә, Нурия, балалар, Габбас мулла каберенә барып, зыярәт кылып кайттылар. Халыкта дин әле көчле икәнен белгәнгә күрә, аның рухани хисләренә кагылмас өчен, Нурия зират эченә кермәде, шәригать кануннары буенча хатын-кызга зиратка керергә ярамаганын белә иде ул.

Габбас мулланың кабере аргы очтарак икән.

Хәнифә түти кулын сузмыйча гына (ырым буенча зираттагы бер агачка да, бер кабергә дә бармак белән төртеп күрсәтергә ярамый, кулың корый!) башы белән ымлап:

— Әткәңнең кабере әнә шунысы, быел язын Чишмәбай чардуганын яңартты, күрәсеңме әнә, яшь каен үсеп утыра.— диде.

Нурия, агачлар шавына һәм чигә турысында типкән кан тамырының сулкылдавына колак салып, рәшәткә буенда озак кына басып торды.

Әткәсе кабереннән арырак, юан бер каен ябалдашында карга оялары бар, анда каргалар каргылдаша иде.

— Әнә теге зур каенлысы кем кабере? — диде Нурия, шомланып.

— Анысы бабаң каберендә үскән каен. Әтиең Габбас әнә шул каен ботагында асылынып тора иде мин килгәндә,— дип Хәнифә, гүя, чит кеше белән булган фаҗигане сөйләгәндәй, гадәти генә итеп әйтеп куйды.

Әнә шул гадәтилек, әнә шул дөньяви фанилыктан Нуриянең башы әйләнеп, күңеле болганып китте. Аяклары хәлсезләнде.

— Түти, кайтыйк, булмаса...— диде ул.

Нурия Зартугайда һич югы бер атна торырмын дип кайткан иде. Әтисе каберенә зыярәт кылгач, авылда ни әнисе, ни әтисе ягыннан бер генә кешенең дә калмавына ышангач, иртәгесен үк китеп барырга булды.

Нигәдер аның җаны ашкына, тизрәк Казанга кайтып җитәсе килә иде.

Чишмәбайдан гафу үтенеп, Хәнифә түтине, балаларны үзе белән бергә йоклатырга гозерләнде.

Аңлы кеше иде Чишмәбай — рөхсәт итте. Ул үзе олаучы карт белән бергә тегермән йортына китте.

Бала-чага йокыга талгач, җиделе лампа яктысында Хәнифә белән Нурия бер-берсенә әйтергә кирәкле сүзләрен сөйләштеләр.

— Түтәй...— Күңелендә җиде-сигез ел буена җыелып килгән иң газиз тойгыларын кайчандыр кече әнисе булган кешегә әйтеп калдырасы килде Нуриянең.— Түтәй, син үз гомереңдә бик күп төрле кимсетелүләр, мәхрүмлекләр күрдең. Минем әнинең көндәше булып яшәү дә сиңа ансат булмагандыр. Мин аларны элегрәк, яшьлегем аркасында, аңламый идем. Инде менә үзем бер мәртәбә әни булып карагач, балам вафат булгач, аңладым. Шәмсениса абыстаең сиңа бәхил булып үлде. Аның бар өзелгәне Шәфика иде. «Бәләкәччәем» дип йөртә иде ул аны. Гел менә ике сабый иде алар. Түтәй! Бир син безгә Шәфиканы, без аны тәрбияләрбез, укытырбыз. Җәйләрен синең янга алып кайтырбыз. Бир син безгә бәләкәчне...

Чүмәлә хәтле корсагына ике кулын кушырып куйган килеш, Хәнифә бик аптырап әйтте:

— Ә мин нишләрмен? Ул бит нәкъ менә бала карый торган кыз булып үсеп җитте бит инде. Кем минем кечкенәмнең бишеген тирбәтер? Кем миңа самавырга шакмак алып керер? Бик бирерием дә кана, әнә шуларын да уйларга туры килә бит аның, Нурия гөлекәем...

— Беләсеңме, түтәй, мин сиңа юлын өйрәтәм. Синең бу алпавыт йорты чаклы йортың булгач, колхоз сезгә янганнан соң эти белән бергә салган йортны бирми торгандыр бит инде.

— Бирмәс шул, бәбкәм. Бирерлек булса, анда балалар бакчасы ачабыз дип ду килмәсләрие.

— Димәк ки, шулай булгач, ул йортта сепарат тоту да бетә диган сүз. Син эшсез каласың. Нәниең туар. Сине кыр эшенә йөртә башласалар? Бер Шәфика гына синең ике малаеңны, яңа туган сабыеңны карап өлгерә алырмы?

— Алмас шул,— диде Хәнифә түти. Аның җыерчыксыз, түгәрәк-алсу йөзенә күләгә төште.

— Алмый дисең. Син, түтәй, болай ит, председатель Миңнуллага барып гозерлән, мине әнә шул безнең йортта ачыла торган балалар бакчасына тәрбияче, һич югы аш пешерүче итеп куегыз диген. Шуннан да кулай урын булмас сиңа, түтәй. Әхмәт белән Мәхмүтне дә, яңа туган сабыеңны да үзең белән шунда йөртерсең.

— Карале, укыган кеше укыган кеше шул,— дип кулларын җәеп җибәрде Хәнифә түти.— Мин моны иртәгә үк Чишмәбайга да, Миңнуллага да әйтеп карыйм әле. Чыннан да! Менәтерәк вәйт бу акыл!

Алар таң әтәчләре кычкыра башлаганчы сөйләшеп яттылар.

Бер-берсенә ышанып, күңелдәге барлык серләрен әйтеп сөйләштеләр.

— Иртә белән ирең барында җәелеп булмас, алдан ук биреп куйыйм әле, менә сиңа бер йөз тәңкә акча — ике малаеңа күлмәк-ыштан алырсың. Әтинең кабердәге чардуганны буясын Чишмәбай, яме. Ул бик тә булдыклы, акыллы кешегә охшап тора, тигез матур гомер итегез, еллар имин булсын,— диде Нурия.

— Ярабби, әйткәннәр хак булсын, фәрештәләрнең амин дигән сәгатьләренә туры килсен,— диде Хәнифә түтәй.

Икесе тиң рухи тазарынып, дөнья ваклыкларыннан арынып, йокыга талганнар иде, тегермәннән олаучы Бәдретдин карт белән Чишмәбай кайтып керделәр. Бәдретдин картка бүген төш вакытларында Пәнҗәргә кайтып җитәргә кирәк. Шәяхмәт Айдаров шулай кушып җибәргән икән.

Ул чәй кайнаганны да көтеп тормады, бер сынык ипи белән бер кружка сөтне генә мүкләп куйды да үз юлына китеп барды.

Нурияне Әгерҗегә кадәрле Чишмәбай илтеп куярга тиешле булып чыкты. Моның өчен хәсрәтләнмәде Чишмәбай, председатель Миңнулла аңа атны һичшиксез бирәчәк, ник дигәндә, җитмеш төрле һөнәр иясе — колхозда иң кирәк кеше. Бу көннәрдә Каюм Хисмәев тегермән тарттырып кына калмый, ватылган-сүтелгән машиналарның әверхәләрен, җилгәрүләрен бер карусыз ремонтлап, төзәтеп тора.

Әгерҗедән кайтуны Нурия үзе уйлап чыгарды. Поезд аны бер көндә алып кайтып җиткерәчәк, пароход белән булса, ике тәүлек, бәлки, аңардан да күбрәк кайтырга туры килүе мөмкин.

Нурия Шәфиканы үзе белән алып китү мәсьәләсен тиз хәл итте: Хәнифә түти аның белән инде кичтән үк килешкән, ә инде Чишмәбай кебек акыл иясе чит кеше баласына баш була алмый иде.

Әгерҗе станцасына ат белән китереп, поездга утыртыр алдыннан Нуриягә ул бер генә сүз әйтте:

— Шәфика кызыбызны артык булганнан бирә дип уйлый күрмәгез, кулларым исән чакта, эчемдә җаным бар чакта мин Габбас абзый балаларын беркайчан да ким-хур итәчәк түгел.

Поездга утыргач, Нурияне моңарчы булмаган киеренке хисләр биләп алды. Бер якта — көрәктәй дәү куллары белән, йомшак кына итеп сөйләшүе белән Чишмәбай басып тора, икенче якта — бәләкәй кыз Шәфика, ташбашлар Мәхмүт белән Әхмәт, яңа туачак бала. Моңсу. Әллә ничек бик моңсу да, күңелне биләп алган ашкынулы да.

Җир тетрәтеп чапкан корыч айгыр, юл буендагы яшь каеннарны сискәндереп, дөньяга гайрәтле аваз салганда, синең иркенлегең, азат ил баласы булуың искә төшә; шаңдау урманнарга бәрелеп кире кайта:

— А-а-а-аааааааааааааа...

Август аеның биек зәңгәр күгендә йөзгән, офык буйларына өелешкән болытлар Нуриянең күңелен әллә кайларга алып китәләр. Каракучкыл урманнар, әнә шул зәңгәр күк йөзе, шушыларның барысын да үз тавышына буйсындырып чапкан корыч айгыр аның утыз дүрт еллык гомеренең аерым кисәкләрен ак болытлар итеп тә, кара болытлар итеп тә аралап күрсәтәләр.

Вагон тәрәзәсенә маңгаен терәп, поезд яныннан йөгерешеп узган чакрым баганаларын бер-бер артлы күңеленнән уздырып, аның сеңлесе Шәфика кайта. Чәчләре — шомырт кара, этиләре Габбасныкы төсле көдрә, вак көдрә түгел, дулкын кагып торган эре көдрә.

Шушы ун яшьлек кызыйның язмышы хәзер Нурия кулында. Ул аны карарга, үстерергә, ул аны кеше итәргә тиеш. Белемле булыр аның сеңлесе. Әтисенең фаҗигале үлеме алдындагы бурычы шундый Нуриянең. Зартугайда әле аның дүртәр яшьлек ике энесе торып калдылар. Ярабби, алары да коеп куйган этиләре бит. Табигать әллә аларны Нуриянең җанын сагыш белән, моң белән тутырыр өчен шулай яратты микән?..

— Сеңлем, үскәнем, карачы миңа бер генә! Чишмәбай абыең әйбәтме?

— Әй-бә-ә-әт...

— Син аны яратасыңмы соң?

— Ул бит миңа букча алып бирде.— Тәрәзәдән аерылып, апасына беркавым карап торгач, өстәде: — Әхмәй белән Мәхмәйне ул әле муенына атландырып та йөртә, идәндә ат булып мүкәләп йөри.— Шул сүзләрне әйткәч, Шәфика кул чабып көлде, энеләренең Чишмәбай абыйсы муенына атланып йөргән чакларын күз алдына китерде бугай. Аннары кинәт кенә чырае бозылды, иреннәре кыйшаеп китте, күзеннән эре яшь бөртекләре тамды.

Нурия каушады. Кирәкмәгән сүз кузгатканга үзен гаепле һәм әдәпсез итеп сизде.

— Ни булды, үскәнем? Әллә берәр җирең авыртамы? — дип сеңлесен кочаклап алды.

— Ю-у-ук, а-вырт-мыый.— диде Шәфика күз яше аралаш.

— Ашыйсың килде мәллә, матурым? Әйт, үскәнем, яшермә, мин бит синең бертуган апаң.

Шәфика бүтән дәшмәде, бите буйлап аккан күз яшьләрен кулы белән яңагына сылый башлады.

Нурия, сумкасыннан кулъяулык алып, аның битен, кып-кызыл бу-

лып кызарган күзләрен сөртте, шуннан соң тагын да йомшаграк, тагын да юашрак тавыш белән сорады:

— Ни булды, күбәләгем, әйт, балам, әйт.

— Чишмәбай... абыйны... сагындым...— диде Шәфика көч-хәл белән, аннары битен кулы белән каплап, кычкырып елап җибәрде.— Әхмәй белән Мәхмәй миннән башка нишләрләр инде менә? Мин бит аларны уйната торганыем. Йоклата торганыем. Чишмәбай абый миннән башка... нишләр инде менә? Мин бит аңа тегермәнгә чүлмәк белән аш илтә торганыем...

Сеңлесе Шәфиканы Нурия бик озак тынычландырды. Вагондагы кешеләр дә аңа борылып-борылып карадылар. Ләкин Шәфика, авыл белән араларын өзгән барлык балалар төсле, тыела алмыйча елады...

**Сигезенче башлам**

**I**

Нурия Габбас кызы Уразаева 1935 елның 5 апрелендә кандидатлык диссертациясен яклады.

Шуннан соң аңа кафедра җитәкчесе Александр Николаевич Майский ассистентлык вазифасын йөкләде.

Студентларга көн саен дүртәр сәгать лекция сөйләү, ике сәгать буена практик эш алып бару — микроскоп белән эшләргә өйрәтү, бака яру, куянны дару биреп йоклату, анатомичкага алынган мәетнең тән төзелеше белән таныштыру — болар барысы да бер төенгә төйнәлеп, Уразаеваның бер генә дә буш вакытын калдырмыйлар иде. Өйдән ул иртүк чыгып китә, төнлә генә кайтып керә башлады.

Озакламый аны профорг итеп сайладылар.

Ихтимал, монысы да профессор Майский тәкъдиме белән эшләнгәндер.

Үзен кафедра профоргы итеп сайлаган җыелыш Нурия Уразаеваның күңеленә шактый ук дәрәҗәдә хуш килсә дә, ул монын үзенә нинди мәшәкатьләр китерәчәген белми иде әле.

Элегрәк, ничәмә-ничә еллар, син бары тик үз гаиләңнең тыныч-имин яшәвен кайгыртып килсәң, инде менә хәзер, профорг итеп сайлангач, бөтен бер кафедраның тыныч-имин, сау-сәламәт һәм матур яшәвен кайгыртырга тиешле булып чыктың. Ә ул җиңел түгел икән. Ирең Солтанны көйләү, аның чыгымчылыкларына түзү — бер хәл. Бөтен бер кафедраның галим-голәмәсе, врач-педагогы синең көчсез нәфис җилкәңә берьюлы килеп ава икән, һәр көн, һәр сәгать син шул зур гаиләнне кайгыртырга бурычлы! Яшь чагыңда җырлаган җырларыңны, биегән биюләреңне инде син онытып бетерә язган идең, кайчандыр Солтан Габәшидән алган музыка дәресләреңдә күксел томаннар артында калган иде. Син — профорг, син аларны да күңелеңдә яңартырга тиеш булып чыктың! Сәнгать кичәләренә үзең башлап җан өрмисең икән, кем аңа җан өрер? Җыелыш артыннан җыелыш, кичә артыннан кичә, врач-педагогларның ял вакытларын оештыру — тәмле телле, шаян табигатьле булуны, көләч йөз һәм ягымлы сабырлыкны таләп итте.

Озакламый аны, кафедра җитәкчесе белән берлектә, институтның проректорына чакырдылар.

«Тагын нәрсә булды икән?» — дип хәвефләнеп уйлады Нурия.

Проректор Сапаров — такыр башлы, базык бәдәнле, йөзендә беркайчан да елмаю эсәре булмаган илле яшьләрендәге доцент — аларны өстәл янышнан кузгалмый гына каршылады.

Нурия Уразаева үзе өчен түгел, профессор Майский өчен уңайсызланды. Ни генә димә, Казанның атаклы галимнәре нәселеннән килә торган Майскийны,— мединститутта гына түгел, башка вузларда да

авторитет санала торган Александр Николаевичны проректор аяк өсте басып каршылый алган булыр иде. Байтак вакыт республика Сәламәтлек саклау комиссариатында җаваплы эштә эшләү, хәзергесе көндә күз авырулары клиникасында, тагын кайсыдыр клиникада өстәмә вазифалар алып баруы, күрәсең, Сапаровка үзен бик зур түрә итеп санарга юл калдырадыр. Профессор Майский, көмеш башлы кара таягын култык астына кыстырып, өстәл буена килеп баскач һәм үзе башлап исәнләшкәч кенә, ул иренеп диярлек урыныннан күтәрелде, килүчеләрнең икесенә дә урын күрсәтте.

— Безнең ачыклыйсы кайбер нәрсәләр бар, һәм алар эш белән бәйле, Александр Николаевич. Мин сезне борчырга мәҗбүрмен,— диде проректор, такыр башын кулы белән сыпырып.

Ул ике авыз сүз әйтүгә, чакыртуның сәбәбе ачыкланды. Кандидатлык диссертацияләре Мәскәүгә — Югары аттестация комиссиясенә җибәрелә торган иптәшләрнең анкеталарын барлау икән бу.

Нурия Уразаева, рабфакта һәм институтта укыган чагында андый тикшерү-барлауларның ни икәнен үз җилкәсендә татыганга күрә, сөйләшүнең шактый ук күңелсез булачагын алдан ук сизенде. Үзен мөмкин хәтле тыныч һәм сабыр тотарга булды.

Проректор иң әүвәл кафедра мөдире белән сөйләшүне зарури дип тапты ахрысы — профессор Майскийга төбәлеп:

— Әйтегез әле, Александр Николаевич, сез кул астыгызда аспирантура узган Уразаевадан канәгатьме? — дип сорады.

Профессорның, ватык диванга утырган төсле уңайсызланып, җыерылып килүен күргәч, тагын берничә сүз өстәүне кирәк тапты:

— Гафу! Мин моны сездән фәнни җитәкче итеп кенә түгел, абруйлы профессор, өлкән туганыбыз бөек рус халкының вәкиле итеп тә сорыйм.

Майскийның уңайсызлануы аңа карап кына бетмәде. Ул күзлеген салды. Нурияне чамасыз дулкынланырга мәҗбүр итеп, күзлекне озаклап сөртте, ләкин киредән кимәде, яшел постау япма белән капланган өстәл өстенә куйды.

Майский, әллә шәкертенең бу күңелсез сөйләшүгә шаһит булуыннан уңайсызланып, әллә бүтән сәбәбе булганга, тамак кыргалады, чаларган очлы сакалына тотынгалады, тик шуннан соң гына тешкә тия торган ачы рәнҗешле тавыш белән сүз башлады:

— Сезгә, проректор, нинди характеристика кирәктер — мин моны белмим. Мин, Суфиян Бикмөхәммедович, бер нәрсәне аермачык итеп, фән кешеләре теле белән әйтә алам: минем шәкертем Уразаева Нурия Аббасовна аспирантлык срогын бик төгәл узды, беренче гыйльми хезмәтен ике ел эчендә үрнәк рәвештә туплап бетерде. Мин аннан соң да шәкертемнең хезмәтен яклауга куярга ашыкмадым. Тагын бер ел көттердем. Аның моңа түземлеге җитте. Мондый сыйфатның байтак кешегә җитешмәвен басым ясап әйтергә тиешмен. Инде Уразаева Нурия Аббасовнаның татар хатын-кызларыннан гистологиягә килгән беренче карлыгач икәнен дә искә алсак, мин аңардан канәгать түгел дип әйтә аламмы? Алгарак күчик. Мин, сез әйткәнчә, хөрмәтле проректор, рус халкының вәкиле буларак, җирле халыктан, патша заманында җәберләнгән мөселман хатын-кызларыннан үземә шәкерт сайлап алганмын икән, мин аңардан канәгать түгел дип лаф ора аламмы?

Проректорның елмаюны белми торган соры күзләре мул кашлары астыннан елтырашып алдылар. Ул, стенага китереп терәтелгән кеше төсле, башын боргалап торды.

— Сез, Александр Николаевич, ни өчендер миңа үпкәләгән төсле сөйлисез. Ышаныгыз, минем сезне үпкәләтергә, сезнең абруегызга тап төшерергә уйлаганым юк. Минем кулдан килә торган нәрсә дә түгел ул. Чөнки сез фән дөньясында безнең илдә генә түгел, Европа күләмендә дан казанган, авторитет саналган галим,— дип, бу юлы усаллыгыннан бераз арткарак чигенергә мәҗбүр булды проректор.— Мин бит вазифа

кешесе, проректор, шулай булгач, минем бер соравыма төгәлрәк җавап бирергә тырышып карагыз әле.

— Әйтегез, Суфиан Бикмөхәммедович.

— Уразаеваның кандидатлык диссертациясен Бөтенсоюз аттестация комиссиясе раслар дип ышанасызмы? Ягъни Югары комиссия раслар-лык дәрәҗәдә компетентлымы аның хезмәте?

Профессор, ниһаять, чыгырыннан чыкты.

Бәйләнчек бер чебенне куып җибәргән төсле, кулына тоткан таягын селтәп, ул һөҗүмгә күчте:

— Хөрмәтле коллегам, неужели сез аңламыйсыз? Әгәр мин Нурия Аббасовнаның диссертациясеннән бер бүлекне, кстати, иң көчле язылган бүлекне, Германиядә чыга торган „Anatomischer Anzeiger" журналына тәкъдим иткәнмен икән, ә менә бүген шул авторитетлы журналдан: «Сез тәкъдим иткән материал фән өчен дә, практик эш өчен дә файдалы»,— дигән хат алганмын икән, мин шәкертемнең диссертациясе компетентлы түгел дип әйтә аламмы? Мин әлегә ул хакта шәкертемә педагогик такт йөзеннән әйтми тора идем. Сез мине әдәп кагыйдәләрен бозарга мәҗбүр итәсез. Менә ул хат! Менә карагыз! — дип, калтыранган куллары белән пиджагының эчке кесәсеннән сургучлы мөһер сугылган зур бер конверт тартып чыгарды.

Проректор конвертны кулына алды, төрле ягыннан әйләндергәләп карады, эченнән кул кисәге кадәрле генә кәгазьне алды, анда язылган язу өстеннән күз йөгертеп чыкты. Әллә хуплап, әллә өнәмичә, иренен турсайтып торды, конвертны сүзсез генә хуҗасына кайтарып бирде.

Шул эшләр эшләнгән арада Нурия битенә ялкын капканын тойды, чигә турысында бер тамырның сулык-сулык тибә башлавын ишетте.

Күз кырые белән генә хатның үзенең дә карап аласы килгән иде, тыйнаксыз булудан куркып, башын читкә борды. Ул арада инде хат профессорның пинҗәк кесәсенә кереп югалган, өстәлдә, пыялаларын ялтыратып, кара кысалы зур күзлек кенә ята иде.

Хәзер инде Сапаровның коңгырт-соры күзләре Нуриягә төбәлде.

— Сезнең, Уразаева, чыгыш ягыгыз ничек? — диде ул бик тә гадәти сорау биргән сыман.

Нуриянең остазы алдында һич югы бер мәртәбә батыр булып, кыюмөстәкыйль булып күренәсе килде. Тавышына аз гына мыскылчанлык галәмәте өстәп:

— Чыгыш ягым әйбәт минем, Суфиян абый, мулла гаиләсеннән,— диде.

Гади дә, шул ук вакытта зәвыклы итеп киенгән, шомырт кара чәчләрен зур бер төен итеп баш артына төйнәп куйган бу чибәр ханымның чамадан тыш «батыр» җавабы проректорга ошап бетмәде.

Ул, рәсми вазифа үтәүче кеше, Уразаеваның күзләренә тишеп карады («чибәрлегең белән алдый алмассың!»), тавышына борыч өстәп әйтте:

— Төгәлрәк, конкретрак, әдәплерәк җавап бирүегезне үтенәм, Уразаева.

— Миңа инде, Суфиян абый, чыгышымнан курыкмаска да була торгандыр дип беләм. Әтиемнең фаҗигале рәвештә үлгәненә биш ел. Әнием остабикә дә дөнья куйды. Әтинең яшь хатыны, мине карап-багып үстергән Хәнифә түтәй — ярлы кеше баласы, колхозда эшли. Үзе төсле үк ярлы кешегә икенче мәртәбә кияүгә чыкты. Димәк, биография минем бәйләнерлек түгел. Рабфакта мине бер мәртәбә, институтта ике мәртәбә тикшерделәр. Сезнең өчен шул җитмәгәнмени? Бәлки, минем әтием ат карагы булгандыр, мин алар өчен, революция булганга унсигез ел узгannan соң да җавап бирергә тиешмени? Ирем минем — үтә чыккан ярлы кеше баласы, гражданнар сугышы герое.

— Бер генә минут! — диде Сапаров, Уразаевага тагын да тишебрәк карап, алга сөрлекте.— Бер генә минут! Ирегез Солтан Айдаровның партиядән чыгарылуы сезгә мәгълүмдер?

— Мәгълүм.

— Сез моңа ничек карыйсыз?

Нурия җавапны әзерләп өлгерер өчен, ридикюленнән бәләкәй ак кулъяулыгы чыгарып, тирләп киткән борын өстенә кагылып алды:

— Ничек карыйм дисезме? Мин иң әүвәл сездән сорамакчы идем, Суфиян абый, сез моңа ничек карыйсыз? Сез бит аның белән бергә гражданнар сугышы узган, Азин дивизиясендә булган кеше. Ул сезне, әйтсәм әйтим, батыр холыклы сугышчы дип саный, шул көннәрен искә төшергән чакта, беренче итеп сезне телгә ала.

Проректорның кәефе кырылды. Карале, ул сорау аласы урында бу әрсез бичә аңардан сорау алырга азаплана түгелме? Юк, моңа юл куярга ярамый. Һич кенә дә ярамый!

— Сез, минемчә, вазифагызны дөрес аңламыйсыз, Уразаева. Сез мәсьәләдән читкә тайпыласыз,— диде ул, тагын да алгарак иелә төшеп.— Ирегезнең партиядән чыгарылуына с е з ничек карыйсыз? Мине, җаваплы урындагы кеше буларак, менә шул кызыксындыра. Боргаланмагыз, туп-туры җавап бирегез.

Сорауның куелышыннан, дорфалыгыннан профессор Майский куырылып килде. Урыныннан торып, ишекне каты ябып чыгып китсә дә булыр иде аңа, ләкин шәкертенең ныклыгы, отыры үҗәтләнә баруы, проректорны төп башына утыртып килүе аны тулысынча биләп алды. Юк, ул монда булырга тиеш, бер генә сүз әйтмәсә дә, киңәш-мазар итмәсә дә, ул үзенең шәкертенә янәшәдә утырып торуы белән булса да әхлакый, рухи ярдәм итәргә тиеш. Бюрократлар, сукыр чиновниклар, бактерия микроблары ашап бетермәсен аның шәкертен!

Нурия дә бу минутларда үз-үзе белән тартыша, газаплы минутлар кичерә иде. Проректор Сапаровның маңгайга бәреп әйткән соравына ничек җавап бирүенә карап аның киләчәге билгеләнәчәк. Ул яки ярашырга, җайлашырга, җирдән шуышырга, йә булмаса туры сүзле, гаделлек хакына авырлыкларга түзәрдәй көрәшче булып калырга тиеш. Әгәр ул хәзер, этисе ярдәм сорап килгән чактагы шикелле, икеләнсә, Солтаны өстенә — бөтен барлыгы белән Совет власте яклы, аның өчен кирәксә гомерен дә кызганмаячак кешегә тап төшерсә, ул чагында галим булуының гына түгел, дөньяда яшәп торуының да кирәге калмый.

— Мин Солтан Айдаровның партиядән чыгарылуын очраклы хәл дип саныйм. Мин аңар ышанам. Ышаначакмын. Шушы җавап канәгатьләндерәме сезне, Суфиян Бикмөхәммедович?

— Әйе,— диде проректор.— Бу җавапта төгәллек бар. Билгеле бер позиция бар бу җавапта. Сезнеңчә ничек, Александр Николаевич?

— Мин хөрмәтле коллегам, дөньяга үз карашлары булган принципиаль кешеләрне ихтирам итәм. Мине моңа Швейцариядә яшәгән чагында Володя өйрәтте.

— Кайсы Володя? — диде Сапаров, тагын профессорга төбәлеп.

— Владимир Ильич.

— Сез аның белән бергә булдыгызмыни?

— Бергә булдым.

— Нәрсә белән исбат итә аласыз? Дәлилегез?

Дәлилем бар минем. Һәм бик көчле. Гражданнар сугышы чорында, унтугызынчы елны, мин бер ахмаклык эшләдем. Дворян булганы өчен, әтиләре безнең семья белән аралашып яшәгәне өчен ак офицер Лаврентьевның фамильный көмеш иярен, фамильный пистолетын һәм кылычын медицина институты чормасына яшерергә рөхсәт иттем. Моны белделәр. ЧК мине атарга хөкем итте. Шушы атылудан мине Владимир Ильич коткарып калды. Чөнки ул миңа Швейцариядә чакта әйткән иде: Саша, синең урының, күгәрченкәем, революциядә түгел, синең урының фәндә, дигән иде. Ул минем ялгышымны гафу итте, мине үлемнән коткарды. Мин аңар рәхмәтле. Һәм шулай ук минем аның алдында йөзем дә ак. Мин ул әйткәнне үтәдем. Утыз биш ел буена фәнгә турылыклы хезмәт итәм. Мин Владимир Ильичның тагын бер васыятен онытмадым:

интернациональлек бурычымны үтәп, татар балаларын фәнгә алып килдем. Талантлы шәкертем Уразаева Нурия Аббасовнаның фәнни эшенә җитәкче булдым. Кандидатлык диссертациясен ул уңышлы тәгалләде, бик әйбәт яклады. Мин аңа, бер минут кичекмәстән, докторлык диссертациясенә керешергә боердым. Әйе, әйе, үтенмәдем, боердым! Ул мине аңлады. Андый кешеләр сирәк. Әйе, сирәк алар! Әгәр сез, Суфиян Бикмөхәммедович, гади бер формальность аркасында, Уразаеваның әтиләре рухани булган дигән сылтау белән, яки аның ирен бүген партиядән чыгарганнар дигән тагын да зуррак сылтау белән, талантлы татар кызын эшеннән туктатасыз икән, минем, фән кешесенең, сезгә булган ихтирамым бетәчәк! Гомергә, мәңгегә! Тагын да начаррагы — минем совет строена булган иманым какшаячак. Мин моны ачык әйтәм, сезнең үзегез әйтмешли, вазифа кешесенең күзенә карап, туп-туры әйтәм. Чөнки инде минем бу дөньяда күп яшисем калмагандыр...

Хәлләрнең шулай бик кинәт кискен борылыш алуыннан аптырап калган проректор, башка бер генә дәлиле дә калмагач, ни дип тә әйтергә белмичә:

— Анысы, Александр Николаевич, бераү дә... җир йөзенә мәңгеләккә килмәгән...— дип, борын астыннан мыгырданып кына куярга мәҗбүр булды.

## II

Солтан Айдаровны партиягә кайтару мәсьәләсе һаман да кичектерелеп килде. Ул, чамасыз борчылып, партия өлкә комитетына ђарды. Аны Үзәк Комитетка юлладылар.

Айдаров Үзәк Комитетта булды. Аңа борчылмаска куштылар. Җитәр вакыт — хәл ителер диделәр.

Ләкин вакыт җитмәде дә җитмәде.

Бер елга сузылган борчылу, йокысыз төннәр, көн яктысында хатынының күзенә күтәрелеп карарга уңайсызланып, җан газабы кичереп уздырган аяусыз минутлар, урамнарда күкрәк киереп йөрисе, беләкләр талганчы эшлисе урында эшсез аунау, урманда посып яткан качкындай, өйдә бикләнеп ятулар — болар барысы да Солтанның сәламәтлегенә китереп сукты.

Төн урталарында ул берәр сәгатькә генә йокыга куерып ала да, исәр кеше төсле кинәт торып утыра, ашыгып-каударланып, Нуриясен уята башлый:

— Әнисе дим, әнисе...

— Нәрсә булды? Йокла инде.

— Йоклап булмый бит.

— Нишләп йоклап булмый?

— Сул кабыргам сызлый...

— Йа ходаем, нәрсәләр генә уйлап чыгармыйсың син, Солтан.

Нурия, күзләрен уа-уа, торып утыра, аңгы-миңге килеп, иренең майкасын салдыра, кабырга тирәләрен баскалап карый:

— Авыртамы?

— Юк.

— Ә бу төштә?

— Анда да авыртмый.

— Кайда авырта соң?

— Белмим...

Нурия кухняга чыга. Анда озак кына юанып, сөтле чәй әзерләп китерә. Иренә йокы даруы алып килә.

— Әтисе, менә шушы даруны эчеп кара әле.

Солтан аның дару тоткан кулын этеп җибәрә:

— Туйдырды инде даруларың да!

Нурия иренә үпкәли, рәнҗи, аның көйсезләнүен хатынының сәламәт

булуыннан, тыныч йоклый алуыннан көнләшүе, үч алуы дип саный. Гарьләнеп, рәхмәтсез генә уйлап, үзе дә әллә ни гомерләр йоклый алмыйча ята...

Иртәгесен аның күңеле үкенү хисе белән тула. Нигә дип яман уйлады әле ул аның турында? Солтаны урынында булса, үзе нишләр иде? Гамьсез-битараф йөри алыр идеме? Әнә, Солтан күзләрен йомып, ләкин йокламыйча, ара-тирә уфылдап, көрсенгәләп ята. Күперенке иреннәре, балалар ирене төсле, үпкәле турсайган; кылдай каты коңгырт-сары, юк, инде хәзер коңгырт-сары түгел, вакытсыз чал кунудан ала-кола төскә керә барган чәчләре чуалган...

Нуриянең, керфек төпләрен ачыттырып, күзенә яшь килә, һәм ул, ирен тагын да ныграк борчуга салмас өчен, ашыгып кузгала, кухня ягына чыгып китә.

Аның эшкә барасы, аңарчы чәй кайнатасы, иренә ризык-мазар әзерләп калдырасы бар. Сеңлесе Шәфиканы уятасы, тамагын туйдырып, мәктәпкә озатасы бар.

Институтта укыганда да, шифаханәләргә практикага йөргән чагында да авыруларның психологиясенә беркадәр төшенгән иде ул. Чирле кеше гел үзен генә уйлый, гел үзен генә кайгырттыра. Анысы — табигый хәл: җаны сау түгел. Ә менә врач андый чакта нишләргә тиеш? Александр Николаевич үзенең лекцияләре вакытында: врач кеше авырулар белән ягымлы мөгамәләдә булырга, врачта авыруларга карата иммунитет барлыкка килергә тиеш дип өзлексез әйтә, кат-кат әйтә. Сабырлык. Түземлелек. Менә нинди иммунитет булырга тиеш врач кешедә.

Болары әле читтән ишетеп белү генә. Үз җилкәңдә татып белү икенче төслерәк икән. Икенче төслерәк.

Тормыш дигән үги ана Нурияне сабыр булырга өйрәтеп килә. Түзә ул. Солтанның көйсезлегенә дә, ыңгырашуларына да түзә. Эшне катлауландырмас өчен, азрак сөйләшә, күбрәк күрмәмешкә салыша.

Түзеп кенә калмый Нурия. Чарасына керешә. Өйдәге күңелсезлекне онытыр өчен, ул айга бер мәртәбә театрга бара, Шәфиканы циркка алып керә; кафедрада булган уңышларны иптәшләре белән бергә билгеләп уза. Бу бик гади — хәзинәдә бары белән чәй эчәләр, музыка тыңлыйлар. Мондый тәртипне остазлары Александр Николаевич кертте. Бер генә уңыш та, әйбәт итеп ясалган препараттан башлап фәнни журналларда басылып чыккан мәкаләләргә тикле күренми калырга тиеш түгел. Бер-береңнең уңышына шатлана белү коллективны күтәрә, бердәм итә, кайгы-хәсрәтләргә битараф калмаска өйрәтә.

Яшь профессор Голосов Нуриянең боеклыгын гел күзәтеп килә икән. Шулай бер көнне Казанның рус театрында очрашкач:

— Нурия Аббасовна, кайгыгыз бармы әллә? Тартылып киткәнсез түгелме? — диде.— Институтта да ничектер гел боек күренәсез.

— Ирем бик борчулы, Николай Григорьевич. Партиядән чыгарылган хәлдә яшәү бер ел эчендә аның нервысын тәмам какшатты,— диде Нурия, ихлас сүз башлаган Голосовка ихлас җавап кайтарды.

— Алайсам... та-а-аак. Без болай итик, Нурия Аббасовна, иregезне Казанның атаклы невропатологына күрсәтеп карыйк.

— Бармый бит ул, бармый больницага. Невропатологны, өстәвенә атаклысын мин каян табам ди?

— Та-аа-ак,— ди Голосов тагын бер тапкыр, көрән төстәге костюмының түш кесәсеннән визитка кәгазе алып бирә.— Менә сезгә минем координатлар. Шалтыратыгыз. Кайчан килергә икәнен әйтсәгез, кирәкле кеше белән мин үзем килеп җитәрмен.

Рәхмәт әйтеп, сөенеп, өенә кайта Нурия. Солтаны өйдә юк. Шәфика мәктәптән кайткач, дәресләрен караган да үз бүлмәсенә кереп чумашкан. Күлмәген матурлап урындык башына элеп куйган, ботинкалары — ишек төбендә. «Тәртипле, тәрбияле булып үсә бу бала»,— дип, күңеле булып уйлый Нурия. Шуннан соң ул үзләренең фатирын үз күзе белән түгел, киләсе кунаклар күзе белән карый башлый.

Зал якның тәрәзә шторларын юарга кирәк — кул тимәгәнгә инде бер ел бардыр. Иданнең дә буявы беткән урыннары бар — анысына ук үрелеп булмас, түзәр әле. Ул урынга келәм-паласны каплый төшәсе булыр. Икәүләшеп Суконный базарыннан алган мебельләре — сырлап-сырлап ясалган бик дәү шкаф-буфетның тузаннарын сөртә башларга ярый. Килгән бер кешенең иң әүвәл күзе шуңа төшә. Мебель юклыктан, фатирларының зиннәтле итеп бизәлмәгән булуыннан шул шкаф-буфет коткарып килә.

Профессор хәтле профессор сиңа олы башын кече итеп килә икән, аны нәрсә беләндер сыйларга да кирәк бит әле...

Үзләре генә торган чагында, читтән-мазардан кеше килмәгәндә, тормышлары түзәрлек булып күренсә дә, профессор-медик белән невропатологны каршы аласы булгач, ифрат кыен хәлдә калды Нурия.

Ярлы яшиләр икән бит алар. Ярлы булмый, ничек булсын соң! Нурия алган хезмәт хакы ашауга бетеп бара диярлек. Солтанның бер ел чамасы хезмәт хакы алганы юк. Өстәвенә менә Шәфиканы алып кайттылар. Аны да багасы, өстен бөтен итәсе, кеше арасында кимсенмәслек, үзен ятим сизмәслек итеп йөртәсе бар.

Югарыдан ярдәм эзләгәндәй, түшәмгә күз салды Нурия — бөтенләй кәефе кырылды. Түшәмнең акшары каралган, урыны-урыны белән ярылган, акшарны кат-кат өя торгач, түшәм, җәгъръфия картасы кебек, телгәләнеп-бүлгәләнеп беткән. Моңарчы диссертация мәшәкате, иренең борчулары белән йөреп, әнисе вафат булу сәбәпле, йортны алып бару япа-ялгызына диярлек калгач, аның түшәмгә күзе дә төшкәне юк иде. Фатирлары кешегә күрсәтерлек түгел икән ләбаса!

Нурия, ире хакындагы сүзне Голосовка әйткәненә үкенеп, уйга калып утыра иде, Солтан кайтты.

Чырае караңгы, йөзе — саргылтым.

Нурия аның хәлен сорашырга да өлгермәде, коридор ишегенең кыңгыравы шалтырады. Нуриянең эче «жу» итте. Әллә шулармы?

Әйе, бу шулар иде. Голосов үзе белән кемнедер алып килгән. Нурия коелды да төште — исәнләшә дә алмый, узыгыз дип тә әйтергә онытты.

Уңайсыз, өнсез хәленнән аны Голосов үзе коткарды.

— Гафу итегез, Нурия Аббасовна, мин сезнең шалтыратканны көтеп тора алмадым. Бергә укыган коллегам Максимов очрады да сезгә алып килдем,— дип, төсе уңган пиджак кигән, тәбәнәк буйлы, җирән сакаллы, шундый ук җирән чәчле бер кешене күрсәтте.

Нурия, ниһаять, аңына килде. Үз нәүбәтендә түбәнчелек белән гафу үтенеп, мәнсезлеге өчен үзен-үзе тиргәп, кунакларны өйгә чакырды.

Голосов — озын буйлы, яңа тройка, ак күлмәк кигән, зур төенле итеп галстук бәйләгән, яшь чибәр профессор — Нурия Аббасовнаны уңайсыз хәлдән коткарыр өчен:

— Алла хакы өчен, мине гафу итегез. Тимерне кызуында сугу яхшы. Кайда авыру, күрсәтегез,— диде.

— Туктагыз әле, Николай Григорьевич, бу ничек була инде? Мин бит сезне каршыларга әзер дә түгел идем. Өемнең дә рәте-чираты юк. Иремне дә әзерләп куярга өлгермәдем,— дип тотынган иде Нурия, профессор аны, студент кызга шелтә ясаган төсле, ярты сүздә өзде:

— Бәхәсләшмибез, Уразаева. Без сезгә кунак булып килмәдек. Врач булып килдек. Авыруны күрсәтегез.

— Николай Григорьевич...

— Мин сезгә соңгы тапкыр әйтәм: Иван Максимович Максимовның вакыты юк. Сезнең бәхеттер, ул миңа без сөйләшеп бетерүгә очрады. Менә мин сезгә алып килдем аны...

Эшне тагын да сузу вакланугa әйләнәчәген аңлап, Нурия тынды. Сүз көрәштермәде. Голосов белән Максимовны диванга утыртып, эчкәреге бүлмәгә — ире янына ашыкты.

Невропатолог Максимов, үзе белән алып килгән сумкасыннан кирәкле медик инструментларын алып, Солтанны тикшерде. Ул вакытта Нурия кухняга чыгып чәй әзерләде. Голосов авыруның үз-үзен тотышын карапкүзәтеп утырды.

Нурия аларга чәй әзерләп кергәндә, врачлар эшләрен бетергәннәр. Солтан күлмәген киеп, галстугын тагып, сүзсез генә өстәл буенда утырып тора иде...

Нурия Голосов белән Максимовны озата чыкты.

Гажур йортының парадный ишеге төбендә Голосов Нурияне туктатты, бүтән барырга кушмады:

— Нурия Аббасовна, Иван Максимович кирәкле язуларын язып калдырды, ирегезгә һич кичекмәстән клиникага барырга кирәк. Сез аны җибәрми калмагыз инде,— диде.

Нуриянең төсе качты:

— Нәрсә, Николай Григорьевич, әллә бик куркынычмы?

— Нурия Аббасовна, паника куптарырга ашыкмыйк, анализларны көтик. Шуннан соң бергәләп нәтиҗә ясарбыз.

Нәтиҗә Нурия көткәннән күп өлеш күңелсез булып чыкты. Солтанның үпкәсе шешә башлаган. Күрәсең, теге заманнарда, колхозларга җир бүлеп йөргән чагында кулаклар кадаган сәнәкнең ярасы яңадан яңарган. Менә ни өчен сызлый икән аның сул як кабыргасы...

Солтан алып кайтып биргән анализ нәтиҗәләрен карагач, Нурия көл кебек агарды, Солтанга ашыгып кына әйтте:

— Мин кайтканчы беркая да чыкма. Өйдә генә утыр. Мин эшемә чаптым. Зинһар дип әйтәм, өйдә генә утыр.

Лабораториядә Голосов үзе генә иде. Микроскоп белән кайсыдыр бер студентының препаратларын тикшерә иде. Микроскоп табусыннан башын күтәреп, игътибар белән Уразаевага карап алды да, исәнләшкәч:

— Ни булды, Нурия Аббасовна, төсләрегез качкан? — диде.

— Иремнең ике үпкәсе дә шешкән. Нишләтим инде мин аны? — диде Нурия, аның күзләрен яшь томалады.

— Ай алла...— дигән булды Голосов. Ул Уразаеваларга невропатолог Максимовны алып килгән чакта болай булыр дип башына да китермәгән иде. Каушады. Сулы графинны таба алмый аптырап бетте. Берни дә булдыра алмагач, ассистент Уразаева керәсе дәрескә үзе кереп китте.

Нурия бераз тынычланды. Күз яшьләрен сөртте. Кафедра мөдиреннән рөхсәт алып, өйләренә кайтты.

Кайтса — Солтаны өйдә юк. Язу калдырган да больницага китеп барган. Кайсы больницага — әйтмәгән. Нуриягә үпкәләве микәнни?

Кичкә таба хәлләр ачыкланды. «Старая клиника» дип Казанда даны таралган шифаханәгә салганнар икән аны. Нуриянең моңарчы баш түбәсеннән булган борчу-мәшәкатьләренә инде менә монысы да өстәлде.

Ай буена йөрде Нурия ире янына. Өйдә пешкән җылы ризыклар, чүлмәк белән аш илтте. Тавык шулпасы. Авылда чакта авыруларның тавык шулпасы дип тилмерүләре исендә калган икән...

Алар шифаханәнең бакчасына чыгып, күләгәле тирәк төбендә, эскәмиядә утыралар, әкрен генә сөйләшәләр. Нурия Шәфиканың бик акыллы кыз булуын, өйдә үзе генә тып-тыныч утыруын, мәктәптә аны мактауларын әйтә; озакламый Мәскәүдән, Югары аттестация комиссиясеннән хәбәр киләчәген, хәбәр килсә, хезмәт хакы артачагын әйтеп, иренең күңелен күтәрергә тырыша, тегесе дәшми, җиргә карап, яки еракларга төбәлеп, тып-тын утыра.

Нурия аны больницадан институт аты белән алып кайтты. Кояш күрмәүдән, төрле уколлардан агарып-саргаеп калган Солтан тарантаска иплән кенә чыгып утырды. Урамда июнь кояшы балкый иде. Яктылыкның мул булып бөркелүеннән, агачларның чамасыз яшеллегеннән Солтанның башы әйләнә, күз аллары әлҗе-мөлҗе килә,— аның әле дөньяны беркайчан да шулкадәр якты, ягымлы һәм иркен итеп күргәне юк иде.

«Тормышка кайтуым шушыдыр инде. Өмет кылы өзелмәсә, шат, яшәрмен»,— дип уйлады.

Нуриянең күңелендә путевка юллау уе иде.

Ул төштән соң Җир эшләре халык комиссариатына китте. Элекке елларны Айдаровны бик тә үз иткән кешегә, кадрлар бүлеге мөдире Урманчиевка керде. Үпкәсе авырган кешеләргә тоташтан ике ай ял бирергә тиешлекләрен белә иде ул. Ләкин болар барысы гадәти биографияле кешеләргә бирелә. Элекке иптәшләре Солтан Айдаровка хәзер ничек карыйлардыр бит әле.

Урманчиев, дала башкортына охшаган түгәрәк битле, калку яңаклы, кап-кара мул чәчле, бер кишәрлек хәтле зур авызлы, кырык яшьләрендәге кеше, үтенеч белән килүче ханымны сабыр гына тыңлады. Нурия дулкынланып, бер кызарып, бер агарып үтенечен сөйләгән чагында, аның битендәге бер тамыр да селкенмәде.

Нурия сөйләгән арада ул ике мәртәбә телефон чылтыравына җавап биреп алырга да өлгерде.

Бу хәлләргә сабырлыгы төкәнгән, күңел рәнҗеше өскә калкып чыккан Нурия:

— Госман абый, сез бит Солтан Айдаровны беләсез. Ул бит Җир төзүчеләр техникумында ничә еллар директор булып...— дип кайнарланып сөйләргә тотынган иде, Урманчиев аны сабыр гына бүлдереп:

— Беләм,— диде.

Монысы да чамадан тыш битараф һәм салкын тавыш белән әйтелгәч, Нурия: «Әллә лаборатория нәтиҗәләрен күрсәтеп, вакланып тормыйммы икән?» — дип тә уйларга өлгергән иде инде, мөдир аңа таба кулын сузып:

— Кәгазегез юкмыни? Нигә бирмисез? — диде.

Нурия, кинәт каушап, сумкасын ачты, каударланудан кәгазен таба алмый аптырады, ниһаять, тапты, тирләп чыкканын тойган хәлдә, уңайсызланып, кәгазьне мөдиргә сузды.

Урманчиев баягы төсле үк битарафлык белән, йөзенә бернинди тойгы чыгармыйча, кәгазьне күзеннән ерак тотып укып бетерде дә кырыена нидер язды, шул ук битараф-салкын чырае белән, каршында утыручыга күтәрелеп тә карамастан, кире кайтарып бирде.

— Айдаровка әйтегез, борчылмасын. Кырымга яки Тарловкага путевка табарга тырышырбыз.

Нурия юл буе үзен тиргәп кайтты. Нигә дип әле ул аның турында ямьсез уйлар уйлады? Күңеленнән аны бюрократ, перестраховщик, чинуша дип атады. Хәтта бер мәлне тавышын күтәреп, усаллашып сөйләшергә дә ниятләгән иде бит. Баксаң-күрсәң, кешенең үз вазифасын үтәве аның тышкы кыяфәте белән билгеләнми икән бит. «Сабырлык. Түземлелек. Врачларга кирәкле иммунитет»,— менә кайчан искә төште остазы Майскийның сүзләре.

Ә бит Нурия иренең больницадан бирелгән кәгазен караган чакта да әдәпсез-тактсыз кыланды. Нигә аңар сабыр булмаска иде? Нигә куркуын йөзенә чыгарырга иде? Әгәр ире аңа үпкәләп, дөньясына үпкәләп, урын өстеннән тормаса?.. Аның бит болай да үз кайгысы үзенә җиткән...

Бер яктан үкенечле, икенче яктан юанычлы уйлар белән үткәргән дүрт-биш көн эчендә Солтан Айдаровка Тарловка санаториена путевка табып бирделәр.

## III

Халыкның гыйбрәтле бер сүзе бар: ходай тәгалә әйткән, чирне яраткан адәмнәремә бирермен, дигән имеш.

Нурия, күрәсең, ходай тәгаләнең яраткан баласыдыр — ул аңа чирне дә, мәшәкатьне дә биреп кенә тора.

Солтанын ике айлык санаторийга озатканына бер атна да узмагандыр, кафедрада ямьсез бер хәл килеп чыкты.

Гистология буенча аспирантура узучы ике егет профорг янына махсус килделәр.

— Нурия Аббасовна, сез беләсезме? Кафедрада бик әшәке эш эшләнә бит.

— Нинди эш? — диде Уразаева.

— Атаманова кешеләрне бер-берсе белән бәрелештерә.

— Ягъни? Ничек бәрелештерә?

— Профессор Голосов белән профессор Кабулов арасына чөй суга. Безне, аспирантларны сугыштырып, үзе читтән карап тормакчы була.

Нурия тагын бер мәртәбә: «Ягъни?» — дип әйтергә мәҗбүр булды.

— Инструментларны өстәл тартмасына бикләп куйган, бирәүгә дә бирми.

— Аңладым мин сезне, егетләр. Тикшерербез. Бәябез объектив булсын өчен, комиссия төзәргә кирәк. Кемне тәкъдим итәсез? Иртәгә хәтле уйлап килегез.

«Иртәгә хәтле» дип әйтүенең мәгънәсе бар. Егетләрдән дә бигрәк ул үзе уйлап бетерергә тиеш иде әле.

Уразаева өенә кайтырга чыкты. Уйлары һаман Татьяна Атаманова тирәсендә әйләнделәр.

Татьяна Нурияне яратмый. Юк, яратмый дип әйтү аз — күралмый. Сәбәбе гади — Нурияне профессор Майский яклый һәм моны кафедрадагыларга күрсәтеп эшли. Кабинетына чакырып, хәлләрен сораша, лекцияләренә керә, практик дәресләрне ничегрәк үткәрсәң уңышлы булачагын әйтеп, киңәшләрен биреп тора. Ә Атамановасы үзе әрсезләнеп кермәсә, айга бер мәртәбә дә чакырмый.

Дөньяда үзен бер гүзәл дип, башкалардан өстен дип санаган тәкәббер табигатьле Танечка кафедра мөдире белән, атаклы гистолог белән уртак тел таба алмаганга үрсәләнә.

Әгәр икесен янәшә бастырып куйсалар, Татьяна Нуриядән отышлырак. Җефәктәй йомшак аксыл-сары чәч, декольте күлмәктән мул булып калкып торган күкрәкләр, өздереп карый торган зәңгәр күзләр! Уразаеваның нәрсәсе бар? Күмер төсле кара чәч, күмер төсле кара күз. Ни киенә, ни көязләнә белми. Ә профессор Татьянага түгел, әнә шул татарочкага багына!

Алар фәнни хезмәтләрен икесе бергә башлаганнар иде. Уразаева инде диссертациясен дә яклады, тиздән аны Мәскәү раслар да. Ә Атамановаының диссертациясен яклау көне дә билгеләнмәде әле. Болар барысы да үзе хакында югары фикердә йөргән Татьянаны үрти, үчекли. Ике арадагы киеренкелек арта бара.

Тукта, быелга чаклы андый киеренкелек бар идеме? Күрәсең, булган. Нурия аны Солтан мәшәкате, әнисенең үлеме, Шәфиканы кайгырту белән сизми йөргән.

Нурия, барган уңайга, кафедрадагы былтыргы һәм быелгы үзгәрешләрне күңеленнән барлап чыкты.

Нуриягә хәтле профессор кул астында диссертация яклаган Андрей Балантаев бар иде. Лабораториядә ул төннәр буе утырып эшли ала, меңләгән тәҗрибә-эксперимент ясый ала, кара сипкел сибелгән түгәрәк йөзеннән елмаю китми, ул, гүя, кафедраның көндез дә, төнлә дә сүнми торган кояшы иде. Теләсә кемгә ярдәм итәргә, актык сынык ипие, соңгы инструменты белән уртаклашырга әзер иде. Аны Урал ягындагы бер калага эшкә алдылар. Моңсу булып калды. Моңсулык бер хәл, әнә шуннан соң икесе бер бүлмәдә, бер лабораториядә эшләгән, хәтта икесе бер үк теманы эшкәрткән яшь докторлар Голосов белән Кабулов арасында салкынлык сизелә башлады.

«Бәлки, бу миңа гына шулай тоеладыр», — дип уйлый иде Нурия. Юк икән, аны башкалар да сизеп йөри икән. Ул гына да түгел, яшьләр

моны Атаманованың астыртын эше дип бәялиләр икән бит әле. Бу ямьсез хәлгә чик куелырга тиеш. Юкса синең профорг булып утыруыңнан ни мәгънә?

Иртәгесен Нурия ике кеше белән киңәште. Берсе — парторг, икенчесе кафедра җитәкчесе. Фикерләре уртак — комиссия төзергә.

Төзеделәр. Председатель итеп Уразаеваны, членнары итеп лаборант кызлардан икесен билгеләделәр.

Комиссия бер атна эчендә кафедрадагы аспирантлардан, лаборантлардан, ассистентлардан берәм-берәм сорашып чыкты.

Мәсьәлә ачыкланды.

Голосов җитәкчелегендә фәнни эш башкарган Атаманова, кандидатлык диссертациясен Уразаевадан алда яклый алмаганына үч итеп, көннәрдән беркөнне, Балантаев биредән китеп баргач, хирургик инструментларны бүлә башлый.

Профессор Кабулов аспиранты Макшеев сорый моңардан:

— Татьяна, нигә син алай итәсең? Моңарчы бит барыбыз да тигез эшли идек. Инструментлар уртак иде. Профессорларыбыз аларны, эш беткәч, юып-чистартып куюны гына таләп итә иде.

Атаманованың күзендә — очкыннар, баш бик текә.

— Без башкаларны белмибез. Менә болары — безнеке, профессор Голосов белән минеке. Калганын теләсә нишләтегез! — Иң яхшы ланцетларны, кулга җайлы кайчыларны, тагын башка коралларны өстәл тартмасына бикләп, ачкычын кесәсенә салып куя... Димәк, Голосов Кабулов аспирантларына юл куймый булып чыга.

Комиссия Атамановаңы профбюро бүлмәсенә чакыртты. Исәбе үзара матур гына сөйләшеп, шуның белән эшне төгәлләү, зурга җибәрмәү иде. Кая ул! Атаманова зәңгәр күзләреннән утлы-яшенле очкыннар чәчеп:

— Мине өйрәтергә башың яшьрәк, Уразаева! — диде.— Диссертация яклады дигәч тә, кем булдың әле син?! Кандидат булу ул әле, бик беләсең килсә, галим булдым дигән сүз түгел, галимлеккә кандидат кына дигән сүз. Кандидат, ха! Синең ише кандидат кисәкләрен, профессор ялчысын минем кырыкмаса кырык тапкыр күргәнем бар! — дип, ишекне каты ябып чыгып китмәкче иде, лаборант кызлар, аңардан өлгеррәк булып, юлына аркылы бастылар.

— Чү, Татьяна Васильевна! Сез Уразаевадан шәхси үчегезне алырга кердек дип уйласагыз, ялгышасыз. Биредә партбюро һәм кафедра сайлаган комиссия эшли. Рәхим итеп, утырып торыгыз. Нурия Аббасовна, ә сез профессор Майскийга хәбәр итегез. Хәзер үк, ашыгыч рәвештә чарасын күрсен. Юкса без скандалчы Атаманова белән бер кафедрада эшләргә теләмибез!

Майский килде. Комиссиянең докладын тыңлады. Чырае караңгыланды. Сакалын учлап, байтак вакыт сүзсез утырганнан соң, кискен генә аяк өсте басты:

— Кафедрада таркату эше алып барганы, шәхси милекчелек чире алып кергәне өчен, лаборантка Татьяна Васильевна Атамановага каты шелтә белдерәм. Төзәлмәсә, эшеннән чыгаруны сорап, ректоратка мөрәҗәгать итәрмен,— диде.

Иртәгесен аның имзасы куелган приказ стенада эленеп тора иде инде. Шул көннән башлап Уразаеваның тагын бер дошманы артты.

## IV

Кеше тормышының күп өлеше болытлы соры көннәргә охшаш — эш белән, мәшәкать белән тулы. Тик, болытлар ел әйләнәсе күк йөзен каплап тора алмаган кебек, адәм баласының да кояшлы көннәре була.

Солтан йокысыз төннәре, авырып китүе белән нинди хәсрәт-кайгыларга салган иде Нурияне. Тарловкада дәваланып кайтуга, ул Нурия күңелендә бәйрәм ясады.

Санаторий Солтанга килешкән. Йөзендәге сарылык беткән, битләре түгәрәкләнгән, алсу янып тора. Боегудан тоныкланып барган күзләре дә нурланып, чаткыланып яналар.

Яшь, елмая, шаян сүзләр әйтеп җибәрә Солтан абзыебыз! Кара син моны — әле генә үләргә житкән, йөзенә лимон сарысы чыккан Солтан дип әйтмәссең дә!

Тазарып та киткән ахрысы — өстенә кигән костюмы сыймый, тар. Искерә дә төшкән икән бит. Алыштырырга, яңасын алырга кирәк. Күңеле тагын да үссен. Аңа гына башны иеп, җиргә карап яшәргә димәгән...

Нурия, ирен үгетләп, кием-салым базарына алып чыкты. Әзли торгач, костюмлык йон материал тапты. Аксыл-зәңгәрсу, Солтанга килешле. Аны ательега биреп, бер ай дигәндә тектереп тә алдылар.

Яңа костюмны киеп, ак якага зур төенле галстук та тагып җибәргәч, Айдаров тагын әүвәлге елларына — Җир төзүчеләр техникумында эшләгән күркәм кыяфәтенә кайтып төште.

Әнә шул яңа киемнәрен киеп, Наркомземга рәхмәт әйтергә барган иде, сөенечле хәбәр дә алып кайтты.

Аны Җир төзүчеләр техникумына эшкә чакыралар. Директор итеп түгел, әлбәттә, алары инде аның алсу томаннар артында калды. Хуҗалык эшләрен алып барырга. Ниятләре — аның еллар буе җыйган тәҗрибәсен, практик акылын эшкә кушу. Бу хакта аның үзенә ачыктан-ачык әйтмәсәләр дә, шулай да җепнең очын чыгарып куйдылар. Ничәмә еллар ныгыткан, кадрларын булдырган, үзе өчен газиз булган техникумына, бәлки, әле тагын файда китерә алырмын дип ышанганга күрә, Айдаров завхозлык вазифасына риза булды.

Ләкин эшләр ул уйлаганча ук барып чыкмады шул.

Техникумга кайтканына бер ай да узмады, Мәгариф халык комиссариаты уку йортын Казаннан Свияжскига күчерергә дип карар чыгарды. Солтанга, табигыйдер ки, алдан уйланылган эшләр белән түгел, ягъни аның күп еллар буе тупланган тәҗрибәсен гамәлгә ашыру белән түгел, нәкъ менә хуҗалык эшләре белән генә шөгыльләнергә туры килде.

Ул барыбер канәгать иде. Күңеле күтәренке, кәефе әйбәт. Эшкә нык кул белән, хирысланып тотынды. Күченү мәшәкатьләре күп булганга, студентларны җәйге ялга таратмадылар. Хезмәт хакы түләп, Свияжскида калдырдылар. Июль-август айларында техникумны яңа урынга күчереп бетерергә, димәк, бөтен коллективны көне-төне эшләтергә кирәк иде.

Айдаров машинасын да табарга, студентларның тамагын да туйдырырга, яңа калада техникум өчен кирәкле йортларны да тәртипкә китерергә тиеш иде.

Бәләкәй, ташландык диярлек шәһәр булган Свияжскида унҗиде агач йортка ремонт ясатты Айдаров; студентларны ремонт вакытында өчәр мәртәбә ашатырлык ашханә булдырды; кышкылыкка торакларга ягарлык утын, ашханәгә кирәкле азыкны табу артыннан чаба торгач, арыды, җаны ял таләп итә башлады.

Көннәрдән бер көнне ул Нуриясенә: «Мин кайта алмыйм. Зинһар, бер генә көнгә булса да килеп кит әле»,— дигән язу җибәрде.

Нурия юлга әзерләнде. Иренә чиста күлмәк-ыштан барлады, базардан җиләк-җимеш алып кайтты.

Кояшлы сентябрьнең матур иртәсендә бер палубалы бәләкәй пароход, тәгәрмәч калаклары белән суны ишеп, артыннан ак күбекләр калдыра-калдыра бага башлагач, Нуриянең күңеленә моңарчы уйламаган уй килде:

«Әллә тагын бер нәни табып карыйсы микән?»

Шул уй аны чиксез дулкынландырды. Кояш нурыннан җемелдәп яткан Идел өсте, чыелдап очкан акчарлаклар, яр буйларын тутырган балыкчы көймәләре, әллә кайларга, күз күреме җитмәс ераклыкларга китеп югалган һәм аксыл-зәңгәр күк белән тоташкан офык, Ослан таулары түбәсендәге күгелҗем урманнар — болар барысы киңлек, иркенлек

дөньясы, болар — синең күңел байлыгың, тарихың, яшәешең бит. Җәй буена бер генә мәртәбә дә Иделгә чыкмавыңны нәрсә белән аклый аласың? Ә бит синең бала чагың, үсмер чагың, балигъ булган чагың Иж тугайларында, Кама иделендә узды. Идел кызы бит син...

Солтанына бер почык борынлы малай табып бирү уе, Идел киңлекләре белән кушылып, аның күңелендә отыры ныгый барды. Ә нигә? Хәзер икесе дә эштә. Кандидатлык диссертациясе якланган, Мәскәүдә расланган. Бала карардай нәнке тотарлык кына рәтләре булыр. Ул чагында инде Шәфиканы да үзләрендә тыныч күңел белән асрарга була. Быел инде соңга калынды. Зартугайда татарча укысын, киләсе елда өченче сыйныфны Казанда русча укытырлар. Ике телне дә камил белсә, нинди күңелле. Кемгә тәтегән бәхет бу?

Нуриянең күңеле кояшлы сентябрь көне кебек якты, зәңгәр күк йөзе кебек иркен, шат авазлар белән тулы иде.

Пароход ярга якынлашты. Сераешеп күтәрелгән таш биналары, берсе өстенә берсе ауган тәбәнәк агач йортлары, көз сулышын тоеп саргайган бакчалары белән тау өстендә Свияжск калыкты.

Нуриянең йөрәге тасырдый башлады. Дебаркадер янына өелгән агач мичкәләр, пароходны каршыларга килгән чуар киемле халык арасыннан күпме генә эзләсә дә, ул Солтанын таба алмады. Инде күңелсезләнә үк башлаганда, мичкәләр янына килеп туктаган җигүле атны, биек кара тарантасны күреп, кычкырып җибәрә язды.

Тарантастан аның Солтаны төшеп килә. Өстендә — җиңнәре сызганулы ак күлмәк, кара чалбар, башында ак кепка.

Нуриягә шулкадәр дә рәхәт булып китте, ул инде «солидная дама» икәнен дә, мединститутның ассистенты икәнен дә, янында өлкән яшьтәге кешеләр бар икәнен дә онытып, башындагы җәйге ак эшләпәсен салып ашкынып болгый һәм:

— Солтан! Солтан! — дип кычкыра башлады.

Кемнәрдер аны тыйды, кемнәрдер аны төрткәләп, чыгу юлына ашыкты, ул, берни күрмичә һәм бернинди этеш-төртешләргә дә игътибар итмәстән, халык ташкыны белән бергә, һаман да Солтанына караган килеш, ярга килеп чыкты.

Солтан, җитез генә килеп, аның кулындагы кәрзин-чемоданны алды, култыклап ат янына алып китте...

Күп кирәкмени соң адәм баласына күңел җылылыгы өчен?!

Алар ул көнне бер-берсеннән ягымлылык табып, бер-берсен ярты сүздән аңлап, тыенкы бер сөенеч белән яшәделәр. Солтан вакытлыча урнашкан зур, иске агач йорт, аның койма буйларында үскән кычыткан, ишегалдында чәчелеп яткан каен пүләннәре (әле генә киселеп ташлаганнар булса кирәк!), өй эченең кара бүрәнәләре, агач топчан, кадакта эленеп торган юл кожаны, өйнең яртысын алып торган, күптән инде агартылмаган зур мич — болар һәммәсе Нуриягә — бик тә таныш күренешләр, ник дигәндә, алар аның яшьлеген, Зартугай авылын искә төшерәләр иде.

Солтаны ул килешкә ашханәдән аш, итле токмач, компот алып куйган икән, аларны плитәдә җылытып, шуның янына Нурия өйдән алып килгән җиләк-җимешне дә кушып, тамак ялгап алдылар.

Ул арада бер үсмер егет килеп, Солтан Айдаровны директор чакырганын хәбәр итте.

— Әнисе, мин ә дигәнче кайтып җитәрмен. Син әз генә ял итә тор, яме, бер аягым анда, икенчесе монда булыр,— дип, Солтан капка төбендә торган җигүле аты янына ашыкты.

Ул киткәч, Нуриягә күңелсез булып калды.

Беркавым нишләргә, ире кайтканчы вакытны ничегрәк уздырырга белмичә, ул ишегалдын әйләнде, элек күреп җиткермәгән кайбер нәрсәләр аның күзенә ташланды. Биредә шактый иркен мунча бар, һәм аның аскы ике ниргәсенә яңа бүрәнә сипләнгән иде.

«Әллә Солтан мине дә бирегә күчерергә исәпли микән?» — дип сәерсенеп уйлады Нурия. Бераздан аның уйлары төплерәк нигезгә төштеләр. Ә нигә? Аңа эш табылды. Бу — аның яшәү мәгънәсе. Үзе төзегән техникумны ныгыта икән, булачак авыл хуҗалыгы белгечләре өчен шартлар тудыра икән, ул үзен әлбәттә, бәхетле дип санаячак. Ә бит Нуриянең бәхете — медицина институтында, үзе яратып башкара торган фәнни эшендә. Ул бит, күпме генә ире белән бергә яшәргә теләсә дә, бирегә күчеп килә алмый. Медицина институтына биредән йөреп булмый бит...

Урамга чыкты. Тигез рәт булып тезелеп киткән агач йортларны күрде. Алар һәммәсе яңа рәшәткәләр белән уратып алынган, морҗа башлары агартылган, рәшәткә коймалар буенда турап өелгән утын әрдәнәләре күренә.

«Болар шул Солтан башкарган эшләрдер инде»,— дип уйлады.

Нуриянең күңелендә Солтанына карата янә бер җылылык — якынлык хисе уянды. Шул тойгыны нәрсә беләндер иренә дә белдерергә кирәк иде. Кешелеккә кия торган алсу күлмәген, ефәк оекларын салып куеп, кәрзин-чемоданыннан халат алды, каяндыр иске чүпрәк, мунчала ише нәрсәләр эзләп тапты, су җылытып, идәнне юып чыгарды, бер чиләк су сыешлы ак самавырны агартып куйды. Тарау-таскау яткан әйберләрне дә рәткә китергәч, өй эченә ямь керде, шул мәшәкатьләр белән вакытның узганы сизелми дә калды.

Кояш кыйбла як тәрәзәләрдән китеп, өй эченә күләгәләр сузыла башлады.

Ишекне каерып ачып, бусагадан ук акланып килеп кергән Солтан өй эчендәге тәртипне күреп ах итте, Нуриясен кочаклап алып бөтерергә тотынды.

— Солтан, җүләрләнмә, Солтан, җибәр, башым әйләнә. Уф, бөтенләй хәлемне алдың,— диде Нурия.— Син, әтисе, озаграк тордың бит. Соңгы пароход биредән ничәдә китә?

— Бүген кунып китәрсең инде, Нөркәем...

Карасана, моның теленә яшь чакларындагы иркә сүзләр әйләнеп кайткан бит. Нуриякәй, Нөркәй!

Нуриягә боларны ишетү рәхәт иде, алардан йөрәк кысылып килә, тәннәр рәхәт-рәхәт сулкылдый башлый иде.

Боларның чынмы, әллә ярашу өчен генә әйтеләме икәнен белү өчен, ялындырырга уйлады:

— Ярамый, әтисе,— диде ул, янәшәсенә килеп утырган Солтанның кулын тотып.— Иртәгә иртүк, сәгать сигездән бит минем лекцияләрем башлана. Александр Николаевич, соңга калсам, ачуланыр. Бик төгәл, тәртипле кеше бит минем профессорым.

— Йа ходаем, ирең хакына бер ачуланганны да күтәрмәслек хатынмыни син? Кал инде, Нуриякәем...

Нурия авыр итеп бер көрсенде.

— Ярар, беткән баш беткән — синеңчә булсын,— диде. Куна калырга ризалык бирде. Югыйсә ул бер көнгә рөхсәт алып килгән иде.

Хатын-кызның шундый бәләкәй генә хәйләсе үзенекен итте. Солтаны, аны гашыйк күзләре белән карап, янында гөлдерәп кенә йөрде. Моңарчы күңелендә асрап та, эшләре бик кыенга киткәнгә әйтә алмаган, эшсез йөргән чакларында таштай каткан бәгыре әйттермәгән ихлас сүзләрен ул бүген Нуриясенә тартынып-нитеп тормастан әйтте:

— Беләм, миңа рәнҗегән чакларың да булгандыр, Нуриякәем. Тормыш тормыш инде ул. Авыр сүзләр әйткән булсам, кичер. Сине яратмаганнан түгел ул, тормыш көйсезлеге әйттерә аларны.

Нурия үзе белән алып килгән ак җәймәне ябып, мендәргә чытыр ак тышлык кидергәч, Солтан түзмәде, килеп хатынын кочаклады...

Урамда, авылдагы кебек, этләр өрә, арба шыгырдаган тавышлар ишетелә иде.

Бераздан барысы да тынды.

Әйтерсең, тирә-юньдә беркем дә юк, йортлар да юк, кешеләр дә юк, Солтан да Нурия, икәүдән-икәү генә аулакта торып калганнар. Берберенә җан теләгән сүзләрен әйтә алалар, бер-берен назлап иркәли алалар...

Боларны уйлау рәхәт. Солтанның кайнар пышылдап әйткән назлы сүзләрен ишетү дулкынландыра.

Урын өстендә тынып, нәрсәдер өмет итеп яткан чагында Нурия бил турысында иренең кайнар кулын тойды — дөнья гаме каядыр китеп югалды...

## V

Институтта Александр Николаевич Майскийның кырык еллык хезмәт юбилеена әзерләнә башладылар.

Комиссияләр төзелде.

Җаваплы кешеләр куелды.

Юбилей кичәсендә профессорны котлау өчен кешеләр билгеләгәндә, Нурия Уразаева исеме дә телгә алынды. Моның берничә сәбәбе бар иде. Беренчедән, ул — татар кызы, Майский үзе үстергән кадр. Икенчедән, фәннәр кандидаты. Өченчедән, кафедраның профоргы.

— Бар ягы да килгән, котласын,— диде парторг Алексеев.— Теле дә бар, буй-сыны да сәхнәдән күрсәтерлек, үзен тота да белә.

Комиссия члennары да, кафедрадагы галимнәр һәм аспирантлар да моның белән килештеләр, хупладылар. Уразаева кандидатурасын хупламаган тик бер генә кеше бар, ул да булса — Атаманова.

Котлар өчен Уразаеваны билгеләгәннәрен ишетүгә, ул проректор Сапаров янына йөгерде. Йөгерүен йөгерде, әмма проректор яныннан канаты сынган кош кебек килеп чыкты.

Уразаева мәсьәләсендә бер мәртәбә авызы пешкән Сапаров гистология кафедрасы белән икенче тапкыр конфликтка керергә теләмәде. Өстәвенә, нәкъ шул көннәрдә, Уразаеваның кандидатлык диссертациясе Югары аттестация комиссиясе тарафыннан расланып кайтканын белә иде ул.

Кешенең күзе бер сукырайса, абынганын-егылганын белми икән. Бирешергә теләмәде Атаманова, проректор бүлмәсеннән туп-туры Кремльгә — Сәламәтлек саклау буенча республика халык комиссариатына юнәлде.

Комиссариатта аны ягымлы итеп каршы алдылар. Тиргәмәделәр, юк эш белән йөрисез, Татьяна Васильевна, димәделәр, гади генә итеп аңлаттылар:

— Мединститутта компетентлы җитәкчеләр бар, юбилей комиссиясе төзелгән. Профессорны кем котларга, кем котламаска тиешлеген алар сезнең белән бездән артыграк беләләр. Вакытыгызны уздырып, нервыгызны туздырып йөрмәгез, иптәш Атаманова.

Татьяна Васильевна менә шунда җиңелү ачысын татыды. Менә шунда ул Атаманова фамилиясен лаеклы йөртә алмавын сизде. Туган-тумачасының әйтүенә караганда, аларның җиденче буын бабасы Мефодийга «атаман» кушаматын Пугач яуларында катнашканы өчен биргәннәр. Уральскида яшәгән казак Атамановларны әле бүген дә белмәгән кеше юк.

Уразаева белән дә, кафедра белән дә көрәше барып чыкмагач, гарьлеген кая куярга белмичә, Татьяна булган хәлне иренә сөйләде.

Атамановаың ямьсез эш эшләп йөрүен Нуриягә дә җиткерделәр. (Хатын-кыз андый хәлне бер-берсенә җиткермиме соң!)

Нурия моңа да зур мәгънә салды. Димәк, Татьяна кафедра җитәкчесе Майскийның приказ белән белдерелгән каты шелтәсеннән дә сабак алмаган. Гел шулай барса, эшләре начар бит аның. Бөтенләй түбән

тәгәрәве ихтимал. «Ярый, башка юл белән тәэсир итеп карыйк»,— дип нәтиҗә ясады ул.

Таняга аның кирәкмәгән эшне дәвам итүе хакында ләм-мим бер сүз әйтмәде, гадәтенчә, арада берни дә булмаган төсле, якты чырай белән исәнләште, аның хәлләрен сорашты, иптәшләре белән үзара сөйләшкән чакта Татьяна Васильевна хакында гел уңай сүз генә әйтергә тырышты.

Хәзер ул үз алдына максат итеп Атаманованы ягымлылык ысулы белән тәрбияләүне куйды. Кафедра җитәкчесенең бәйрәмендә үзе белән янәшә Татьяна да булырга тиеш.

Майскийны ничегрәк котлау мәсьәләсендә ул төпле акыллы бер кеше — профессор Кабулов белән киңәште. Юрий Ипполитович Кабулов — университет профессоры баласы. Гражданнар сугышы чорында ул, егерме яшьлек студент, акларга ияреп, Себер якларына киткән, тегеләрнең канлы эшләрен күргәч, гайрәте чигеп, янә дә Казанга әйләнеп кайткан...

— Нурия ханым,— диде Кабулов, киңәш сорарга килгән коллегасына күзлек астыннан карап.— Кафедраның яшь галимнәре исеменнән, хатын-кыз галимнәр исеменнән дә дип өстик, шефны сез котлыйсыз. Ишеткәнсездер, сезгә аяк чалырга тырышучылар да булды...

— Ишеттем, Юрий Ипполитович.

— Онытыгыз сез аны, Нурия ханым. Тик бернәрсәне онытмагыз, шефыбыз үзен мактаганны яратмый. Әйе, яратмый. Чөнки ул аңа мохтаҗ түгел.

— Юбилейда бит мактамыйча булмый, Юрий Ипполитович.

— Мактамаска була, ихтирамсыз булырга ярамый,— диде Юрий Ипполитович. Аның биек ак маңгайлы, юка борынлы озынча битенә, әле генә әйткән сүзләренең ни кадәрле хаклы икәнен тикшереп-үлчәп карау билгесе булып, тынгысыз бер эзләнү галәмәте чыкты.— Беләсезме, Нурия ханым, безгә нишләргә кирәк? Голосов, сез, мин, Атаманова, Гриша Макшеев, профессорның юбилеена багышлап фәнни конференция уздырырга кирәк.

— Аның хезмәтләре хакында доклад сөйликме?

— Киресенчә. Аның кул астында башкарган үз эшләребез хакында доклад сөйлик.

«Акыллы. Акыллы. Бу минем башка килмәс иде,— дип уйлады Нурия.— Чыннан да, Александр Николаевич моңа сөенәчәк кенә бит. Шәкертләрем җүнле кешеләр булып чыкты дип, ихластан горурланачак. Карале, баксаң-күрсәң, мактауның әнә нинди ысуллары да бар икән...»

— Минем белән килешәсезме, Нурия ханым?

— Бу... бу, минемчә, иң акыллы эш булачак.

— Нәтиҗәне башкалар ясар, беренче чиратта шефыбыз үзе,— диде Кабулов.— Безгә хәзер, хөрмәтле коллега, ясыйсы докладларыбызның сыйфатын кайгыртырга кирәк. Тәҗрибә экспериментларыбыз эшләнеп беткәнме? Бу — бер. Бетмәсә, тиз арада, җиң сызганып шул эшкә керешик. Икенчедән, сөйләгән сүзебез мөмкин кадәр кыска булсын. Максимум — ун минут. Димәк, барыбызга илле минут.

— Конференцияне без кайчан үткәрергә тиеш инде?

— Иртәгә юбилей дигән көнне башкарып чыксак, шефыбыз шуны тыңласа, бурычыбыз үтәлгән була.

— Ә юбилей кичәсендә?

— Менә! Бөтен хикмәт тә шунда шул, Нурия ханым. Юбилей кичәсендә сез, шул докладларның барысын бер төенгә төйнәп, Александр Николаевичка һәм аны котларга килгән илебез галимнәренә хәбәр итәсез. Чын галим-җитәкче өчен моннан да зуррак мактау сүзе була аламы?

— Бу бит... Юрий Ипполитович... коточкыч җаваплы эш. Мин аны... башкарып чыга алырмынмы?

— Һы. Бик җиңел булса, без аны сезгә тапшырып торыр идекмени? Без аны Атамановага тапшырыр идек тә — эше беткән. Дөбер-шатыр китереп сөйләп чыксын иде.

Кабулов соңгы сүзләрен Татьянаның бәлачелләгенә Уразаеваның ниндирәк мөнәсәбәттә булуын белү өчен, ягъни яңа сайланган профоргның принципиаль кешеме-юкмы икәнен тикшереп-сынап карау өчен әйтте.

Нуриянең көтмәгәндә кинәт чырае караңгыланды. Аннары башын күтәрде, ике кулын йомарлап, өстәл өстенә куйган нык чырайлы Павлов портретына карап, беркавым сүзсез торганнан соң, көрсенеп әйтте:

— Ә мин, Юрий Ипполитович, Сезне Татьяна Васильевна хакында югарырак фикердә дип йөри идем. Мин аны үзем белән бергә профессорыбызны котларга алып чыгу ягында торам.

Кабулов Нуриягә төбәлде. Аның күксел күзләрендә ниндидер аңлашылмаган, икеләнүне аңлаткан чаткы чагылып китте.

Ул башын кырын салды. Гадәттәге уйчан-уйланучан тавышы белән сүз башлады.

— Киң күңеллелек — кешене бизи торган сыйфат, Нурия ханым. Бу сыйфатны мин сездә күптәннән күреп йөрим. Александр Николаевичка да ул хакта әйткәнем бар. Ләкин безнең бәлачел, тынычмаучан Атамановага яхшылык эшләргә тырышуыбыз арзанлы авторитет яулап алырга теләвебез булып калмасмы?

— Нишлик соң алайса? Алмыйкмыни Татьяна Васильевнаны?

— Без болай итик, Нурия Аббасовна... Та-аак... Атаманованың фәнни конференциядә доклад ясаганын көтик. Әгәр ул акыллы житди доклад ясый икән, димәк, шефыбызны да, ул житәкләгән коллективны да ихтирам итә дигән сүз. Хаталарын да таный башлаган дигән сүз. Ул чагында без аңа, сезнең белән бергә, юбилярны котларга рөхсәт итәрбез. Килештекме шуңа?

— Килештек, Юрий Ипполитович.

— Ярый алайса, рәхмәт. Мин бу сөйләшүне профессор Голосовка да житкерим әле,— дип урыныннан күтәрелде.

Нуриянең коридор яктагы ишекне ачкыч белән ачып керүе булды, эчкәреге бүлмәдә ут күреп, аптырап китте.

Ул да түгел, каршысына Солтан килеп чыкты. Костюмнан, галстуктан, кепкадан. Чырае болыттай караңгы. Хатынына күтәрелеп тә карамыйча:

— Кайда йөрисең син, төн пәрие кебек? Сәгать бит инде төнге бер. Мин бит сине эзләргә Свияжскидан овчарка жибәрә алмыйм. Минем андый мөмкинлегем юк,— диде.

Жавабын да көтеп тормастан, эш бүлмәсенә кереп китте.

Гадәттә, гаепле кеше акланучан була. Бернинди гаебе дә булмаганга күрә, Нурия акланып торуны артык санады. Солтанын юк белән борчымас өчен, аның бүлмәсенә керде.

Махсус керде. Шакып.

— Әтисе, син тыныч булсын өчен, әйтәм: тиздән профессорыбызның юбилее була. Конференция әзерлибез. Сюрприз картлачка! Кичләрем минем операция өстәле янында уза.

— Ярар,— диде Солтан. Күрәсең, ышанмады.

Иртәгесен ул иртүк торып, тәүге поезд белән Свияжскига китеп барды.

Көн сүрән, болытлы, яңгыр сибәләп тора иде.

Нурия, ашкынып башкарган матур хезмәтенә кулгы төшкәнгә, үзен аңламаган, аңларга теләмәгән, юк белән жанын ашаган иренә үпкәләп, көне буе боек йөрде.

Яңгыр кичкә таба да туктамады.

Аның шыбырдаган тавышын тыңлый-тыңлый, ире Солтанны уйлыйуйлый, унбиш көн буе алып барган тәжрибәләренең нәтижәсен язды Нурия.

Төнге унберләр тирәсендә урам як ишектә кыңгырау шалтырады.

«Вакытсыз кем булыр бу?» Нурия ак халаттан килеш ишек ачарга йөгерде.

Ачты. Өстенә юл кожаны кигән, башын кожан якасына яшергән бераү басып тора. Караса — Солтаны.

Нурия каушап калды.

— Ярабби, нишләп йөрисең син төн уртасында? Поезд белән кайттыңмы? Ул-бу булмагандыр бит? — диде ул, ирен эчке якка уздырып.

Солтан институт коридорына кергәч, өстеннән кожанын салып, суын селекте, җавап бирергә ашыкмады.

Нурия, ирен бүтән сорау белән борчымыйча, аны лабораториягә алып керде. Солтан язу һәм операция өстәле, приборлар янынннан әйләнеп килде.

«Үзем генә икәнгә ышандыңмы инде?» — дип уйлады Нурия.

Солтан арыган-талчыккан кыяфәт белән урындыкка килеп утырды.

— Нигә шул хәтле азапланасың син? Синдә генә бетмәгән нинди эш инде ул? — диде.

Нурия аның янына килде, идәнгә чүгәләп, ирен муеныннан кочаклады.

— И Солтаным, Солтаным, иске чабата олтаным! Эшем бигрәкләр дә күп шул. Тәҗрибә кылам, этләрнең нервы очларын эзлим бит мин...

Солтан башын күтәрде. Чыраена ягымлылык чыкты.

— Эзлим дигән буласың... Этләрнең түгел, кешеләрнең дә нервы очларын табып булмый әле монда,— диде.

## VI

Дөнья мәшәкате белән йөреп, Нурия Солтаны янына кабаттан ике ай узмыйча бара алмады. Шулай да ул үзен бәхетле итеп сизә, чөнки теләгенә ирешкән — балага узган иде.

Бөтерчек хәтле малайны аңа Иделдән аккошлар алып килерме, әллә таң алдының әкият кошлары ул үчтекиләп сөясе нәнине коедан алып кайтып бирерләрме — ничек булса да булыр, студентларның укулары бетеп, җәйге каникулга таралган чакларында ул дөньяга яңа кеше китерер. Табигать тәгалә аңардан ир баланы кызганмаса, почык борынлы улы булыр аның. Шәфиканың тагын бер энекәше артыр.

Ноябрь азакларында, ял алды көнен туры китереп, Нурия Свияжскига барырга чыкты. Беренче баргандагы төсле алтын-сары көз түгел иде. Агачлар ялангач иде. Идел суын ярып йөзгән ак пароход та илтмәде аны, акчарлаклар да чыелдап очмады. Баш өстенә үк төшеп, иңне басып торган болытлы соры күктән әллә нинди коры, чәнечкеле кар коела иде.

Рельсларга кага-кага, пошкыра-пошкыра чапкан поезд аны мазутка батып беткән, җимерек кара коймалары янында иске бүрәнәләр, кирпеч ватыклары, кара шпаллар аунап яткан бәләкәй бер станцада калдырып киткәч һәм аны беркем дә каршы алмагач, Нуриянең шундук сөмсере коелды.

Киләсен алдан хәбәр итеп чыкмагач, аның иренә үпкәләргә хакы юк иде, билгеле. Әмма күңел дигәнең хакны-мазарны тикшереп торамыни ул, бер боега икән, син аны тиз генә яктырыр дип уйлама.

Як-ягына каранып алганнан соң, Нурия тимер юлчылар киемендәге какча битле, чал мыеклы бер карттан «Поперечная» урамына ничек барырга икәнен сорады.

Карт өйрәткән юл бик озак булып чыкты. Кулындагы кәрзин-чемоданын алыштыра-алыштыра арып бетте Нурия. Шулай да «Поперечная» урамын да, үзенә кирәкле йортны да эзләп тапты. Тик, игътибар беләнрәк карагач, бераз аптырашта калды. Аның каршысында беренче мәртәбә килгәндәге агач йорт түгел, урамда да, ул күргән яңа коймалар

түгел, аның каршысында кып-кызыл кирпечтән өелгән, калай түбәле, ике катлы йорт тырпаеп тора, аның күршеләрендә бүрәнәләре каралган, кайсы авыш, кайсы җиргә чүккән тәбәнәк агач йортлар тезелеп китә иде.

Солтан, димәк, яңа йортка күчкән. Ә ник ул аны әйтмәде икән хатларында? Теге чакны тарантаслы атка утырып килгәч, шул ук аргамак белән Идел буена кайтып, пароходка утырып киткәч, Нурия бит адреска игътибар да итмәгән, ял йортыннан тазарып-матурланып кайткан ирен күрү бәхетеннән башы күккә тигән иде шул.

Урам уртасында, шыбырдап яуган коры кар астында уйга талып торып булмый, номерларга карый-карый, икенче катка күтәрелде Нурия, кара дерматин белән тышланган һәм шуның белән башкалардан аерылып торган ишекнең кыңгыравына басты.

Көтеп торды. Җавап булмады.

«Бәлки кыңгыравы эшләми торгандыр»,— дип, ишеккә кулы белән кагылып карады. Алай да барып чыкмады.

Нурия инде өметсезлеккә бирелеп, хәбәр итми килүенә үзен тиргәп һәм үкенеп басып тора иде, күрше яктагы фатирдан яулыклы, алъяпкычлы, илле биш яшьләр тирәсендәге бер хатын килеп чыкты.

— Сезгә кем кирәгие, бәбкәм?

— Әйтсәгезче, апа, Солтан Айдаров дигән кеше шушында торамы?

— Айдаровмы, түгелме икәнен белмим, Солтан дигән кеше тушында тора. Син аның кеме буласың соң, туганымы, катынымы дигәндәй?

— Хатыны,— диде Нурия күңелсез генә.

— Белмәм, бәбкәм, ул тиз генә кайтыр микән? Иртән бер чыгып китсә, төн урталары җитмичә кайтмый бит ул. Эше бик күп аның, мәшәкате бик күп...

— Нишлим икән соң, апа, мин бит монда беркемне дә белмим.

— И-и-и, бәбкәм, нигә кайгырасың? Үзебезгә кереп тор. Өебез бик иркен. Гәрәй абзаң әле кичсез кайтмас. Кирбеч забутында эшли,— дип ихлас күңелдән, эш кешеләренә хас беркатлылык белән сөйләп китте ул.

— Сезне кем дип дәшим соң, апа?

— Минем исемем Бәйнәгылмәрфуга. Күршеләребез алай озын итеп әйтә белмиләр, Бәймәрфуга дип кенә йөртәләр.— Алъяпкыч итәге белән ирен читләрен сөрткәләп алды.— Ә син, Мәрфуга түти дип әйтсәң, шул җитәр,— диде.

Нурия, аңа ияреп, фатирларына керде.

— Ә үзеңне кем дип әйтик, бәбкәм?

— Нурия исемле мин, апа.

— Алай икән. Исемең матур икән. Ирең дә бездә эшли икән,— диде Бәйнәгылмәрфуга түти. Кунакның пальтосын, мамык шәлен салдырып, карават җәймәсе өстенә илтеп куйды. Үзләренең эш киемнәре эленеп торган гомуми элгечкә кунак хатынның чибәр киемнәрен элүне яхшысынмады булса кирәк.

Өй эченең гадилеге, җылы итеп ягылган булуы, эш кешеләренә хас бер зәвык белән алма бизәкле мендәрләрнең зур тимер караватка тау хәтле итеп өеп куелуы, алар өстенә ябылган ак челтәр япмалар Нуриянең күңеленә ямь һәм тынычлык халәте урнаштырды.

Тәрәзәләрнең инде икенче катын да куеп, кырыйларына кәгазь ябыштырып чыкканнар, өске кат рамнарның астына, су җыелыр өчендер инде, улаклар куелган — гел авылдагыча; идәнгә озынча палас җәелгән, кулдан сугылган ул палас иске инде, ләкин чип-чиста; галанка мич буенда зур сары самавыр тора, вак итеп туралган агач шакмаклар күренә.

Бәйнәгылмәрфуга түти, Нуриянең хәлләрен сораштыра-сораштыра, ул арада үзләре турында да берничә сүз кушып, самавырын куеп җибәрде.

— Кайда эшлим диден әле, бәбкәм?

— Врач мин, апа.

— Дуктырмыни? Бәрәкалла! Бирсен ходай! Солтанның катыны дуктыр икән, үзе тагын нинди яшь икән, күз генә тимәсен. Иреңне әйтәм, бик ярдәмчел. Әле мена узган атнада ике ат белән утыныбызны ташытып бирде. Ирем Гәрәй сыйламакчы да булган иде үзен — кая ул! Якын да килми. Тик мена, бәбкәм...— Ул, кеше-кара ишетмәсен дигәндәй, әкренрәк, шыпырт тавышка күчте: — Солтан янына бер кыз килеп йөри. Үзе эшли торган техникумнан диме, белмим ул кадәресен, әммәдәген әтчәйни кыз, күзләре — утлы күмер! Исеме Гөлмәрьям бугай. Бу дөньяның, җаным, кеме бар да кеме юк, дигәндәй, сакланганны алла саклармын дигән...

Бәйнәгылмәрфуга түтинең тырышып-тырышып кайнаткан чәе дә, кунакчыллыгы да кирәк түгел иде хәзер аның өчен, күкрәк турысын яндырып, ул әйткән соңгы хәбәр, соңгы сүз көйри иде:

«Гөлмәрьям килеп йөри... Әтчәйни кыз... күзләре — утлы күмер...»

Өйгә караңгылык иңеп, утлар кабынгач кына кайтты Солтан. Күршеләрнең ишеген шакып кергән иренә, исәнләшүдән элгәре, сынаулы-үткен караш ташлады Нурия. Солтан моны сиздe, бер генә мәлгә каушап, аптырап калды. Аңына килеп, хатыны белән ике куллап күреште, чәй янына чакырган Бәйнәгылмәрфуга түтигә рәхмәт әйтеп, хатынын үз фатирына алып чыгып китте.

Сүзләре ялганмады. Моның сәбәбен Солтан белми, ләкин сорарга да базмый, әмма Нурия — хатын-кызга хас сизгерлек белән, бер күз ташлауда өйгә хатын-кыз кулы кагылганны абайлап өлгергән, чөнки бирадә теге чакта килгәндәге төсле тәртипсезлек юк: савыт-саба үз урынында, тәрәзәгә челтәр-пәрдәләр эленгән, галанка мич агартылган — кыскасы, Нурия уенча, аның биредә кирәге калмаган...

Солтан, хатынының күңелен күрергә теләп, нихәтле генә тырышмасын, берни дә барып чыкмады. Иркәләнү өмет итеп, хатынына сырпаланмакчы иде ул, Нурия аңа өзеп кенә әйтте:

— Кәефем бик начар, Солтан. Мине тынычта калдыр әле,— диде.

Тагын бераз сөйләшеп утыргач, йокларга яттылар.

Урамнан, шаңдау сыман, ерак паровоз гудоклары ишетелде. Кайдадыр этләр өрде. Тагын ниндидер авазлар йокларга ирек бирмәделәр. Йокылы-уяулы таң аттырды Нурия. Иртән иртүк, беренче поезд белән үк кайтып та китмәкче иде, әмма икесенең мөнәсәбәтен ачыклап китмәсә, җаны тыныч булмас төсле тоеп, ял көнне ире янында уткәрергә ният кылды.

Солтанның ашыгыч эше бар икән, ул, озак тормам, кайтырмын дип техникумга китеп барды.

Эшкә кул бармый иде. Тәрәзә буенда уйланып утырды. Солтан аңа хыянәт итәме? Әллә бу гадәти бер вәсвәсә генәме? Әгәр чыннан да ире аңа хыянәт итсә? Кирәкме аңардан бала табарга? Кирәкме аның баласын йөрәк җимеше итеп сакларга?

Үзалдына тәшвишләнеп утыра торгач, Нурия ирен аклый торган бер фәлсәфә дә уйлап чыгарды.

Шаулап-ашкынып яшәгән чагында аның юлына аркылы төштеләр. Яраткан эшеннән аердылар. Аның урынында берәү булса, дөньясын каргап йөрер, йә булмаса, эчкечегә сабышыр иде. Ә бу үзе теләмәгән, үз мөмкинлекләреннән түбән булган эшне дә эшли. Туйдырмас дисеңме? Гаделсезлек турында сәгать саен, минут саен уйлап йөрү җаныңа тимәс дисеңме? Әнә шул арыган, талчыккан, бар нәрсәдән җаны бизгән чакларда аның күңеле төшенкелеккә бирелә башлый торгандыр. Гомерем заяга уза, яраткан эшемнән аерылдым, айлар буе хатынымнан аерым яшим, ичмасам, үз күңелемне үзем күреп, рәхәттә яшәп калыйм әле ди торгандыр...

Тәрәзә буенда ике кулы белән яңагына таянып, уйга батып утырганда, Солтан кайтты. Үтә дә көр, чамадан тыш көр тавыш белән:

— Әнисе, безне кунакка чакыралар, барып кайтыйк әле,— диде.

— Кемгә? Ник? — диде уйларыннан айнып җитмәгән Нурия.

— Безнең техникумда эшләүче бер кызның туган көне. Әйдә, музыка тыңларбыз. Син дә никтер авыз-борын төяп килгәнсең әле...
— Кем ул кызыгыз?
— Гөлмәрьям исемле ул. Бездә техник секретарь булып эшли.
Нуриянең битенә ут капты. Ул, аны-моны сиздермәс өчен, сылтау табып, урамга чыгып китте.

Анарда хәзер ике хис тартыша. Барырга — кем икәнен күрергә, мөнәсәбәтләрен аермачык белергә. Бармаска — үзеңне көпә-көндез хурлыкка калдырмаска.

Беренче хис җиңде. Үзен тәртипкә китереп, ул ире белән бергә кунакка барырга чыкты.

Гөлмәрьям, әнисе белән бергә, шәһәр читендәге бер агач йортта тора икән. Нурия чамалап өлгерде — беренче килгән чакта күргән, Солтан яшәгән урыннар ич бу...

Мәҗлестә кеше күп түгел, техникумның ике укытучысы, техник хезмәткәрләр — Гөлмәрьямнең иптәш кызлары, иптәш егетләре, барлыгы ун кеше иде.

Агач йортның мебель-мазар куелмаган иркен бүлмәсендә өйдә пешергән пироглар белән чәй эчеп алгач, кыюлык өчен берәр рюмка да тоткач, күңел ачулар башланды.

Төсе унган иске патефонда пластинка уйнаттылар. Гаҗәп сәер хәл: пластинкаларны егетләр түгел, Солтан куеп торды. Табигате белән моңлы, музыкага яшьтән үк әвәс кеше булуы, авыл егетләре гармун уйнаган чакта да тыныч кала алмавы сәбәп булгандыр дияр идең, патефон энәләре тузган, пластинкаларның кайберләре бозылган, шунлыктан музыка тешкә тияр дәрәҗәдә тупас булып, вакыт-вакыт дырылдап ук ишетелә башлый иде.

Ярый, анысына түзәргә дә булыр иде, нигә соң Гөлмәрьям үз тиңнәре белән биеми? Нечкә билле ак атлас күлмәк кигән, шомырт кара чәчләрен үрмәгән килеш, иңенә таратып төшергән, зифа буйлы, марҗа кызларыныкы төсле киң савырлы, озын матур аяклы Гөлмәрьям бүтән бер генә кеше белән дә биеми, гел Солтанны чакыра. Ник? Ул бит аның биредә хатыны бар икәнен белә. Ник алай кылана ул? Ник Солтан аның кармагына каба? Болай булгач, димәк, Бәйнәгылмәрфуга түтинең әйткәннәре дөрескә чыга?

Музыка моңлы чакта, салмак агышлы чакта, алар икәүләп, буяусыз агач идән буйлап җай гына, ипле генә йөриләр; аларның аяк басышларына, килешле итеп «нәкыш чигүләренә» кунаклар сокланып, күзләрен алмый карап тора; менә патефон музыканы ашкыныбрак сибә башлый, Солтан белән Гөлмәрьям өермәләнәләр,— Гөлмәрьямнең күлмәге әле җилкән булып кабара, әле сүнеп, ботларына сылана. Ул да түгел, Гөлмәрьям инде ялангач ак беләкләре белән Солтанның муенын уратып алган, үзе артка кайшалган, Солтан ике куллап аның биленә тотынган — шаштыра яшьлек Солтанны, битләрен алсуландыра, дөньяга ир кеше булып туганлыгын исенә төшерә...
Өй эче бөркүләнеп китте, һава җитми башлады.
Нурия, алгы бүлмәдән пальтосын, мамык шәлен алып, урамга чыкты. Аның артыннан авыр имән ишек, күгәргән тупсалары белән шыгырдап, ябылып калды. Яшь авазлар, сикерү-тыпырдаулар, ватык энәле патефонның дырылдавы шул имән ишек артында бикләнеп калдылар.

Урамда кар ява. Тирә-юнь күңелҗем томан белән өретелгән. Йортлар, төтеннәр шәүләләнә. Күңелне баса торган рәшә томаны эченнән, ерактан маневр паровозының кычкыртканы ишетелде.

Нурия, аны-моны абайламастан, яңа яуган, әле кер-мазар кунарга өлгермәгән ап-ак йомшак кар өстендә эзләрен калдыра-калдыра, паровоз гудогы ишетелгән якка таба китеп барды...

## VII

— Йә, син үзеңне хаклы дип уйлыйсыңмы инде? Мәҗлесне ташлап, кар-буран эченнән Казанга кайтып китүеңне бик зур мәртәбә дип беләсеңме? Мин дә бит кылана алам, ләкин кыланмыйм.

— Туктатыйк буш сүзне, Солтан. Син кыланып карадың инде. Ничек кенә кыландың әле.

Солтан хатынының үзен мәшәкатьләгәненә, эш муеннан чакта Казанга кайтырга мәҗбүр иткәненә ачулы иде. Бик каты сөйләшергә, өзеп сөйләшергә иде нияте.

Хатынының боек-моңсу күзләрен тәрәзәгә төбәп, үзен мескен генә кочаклап утыруын күргәч, ачуы юкка чыкты. Хатыны аңа кызганыч, бик тә кызганыч булып тоелды.

Ул Нуриянең каршысына килеп басты.

— Әйт әле, җаным-бәгърем, ник син энә чаклыны дөя чаклы итеп күпертәсең, ә? Мин бит җәмгыятьтәге кеше. Азат дөнья кешесе. Совет Конституциясе миңа шәхес ирege биргән. Әгәр мине яшь бер кыз биергә чакыра икән, һәм ул минем эстетик зәвыгыма каршы килерлек дәрәҗәдә ямьсез түгел икән, нигә дип әле мин аның белән биемәскә тиеш? «Юк, сеңлем, булмый, биредә минем хатыным Нурия утыра, ул чамадан тыш көнче, мине синең белән бергә биетмәс өчен ул теләсә нинди адымны да атлый ала, мәҗлесне рөхсәтсез-нисез ташлап китә ала»,— дип әйтиммени? Уйнамый да, көлми дә, җырламый да, биеми дә йөриммени?

— Лозунг белән авызны томалый торган гадәтеңне беләм мин. Беләсеңме, «җаным-бәгърем», без акны ак, караны кара дип сөйләшик, яме?

— Яле, агы нинди дә карасы нинди аның?

Нурия аяк өсте басты.

— Без синең белән, Солтан, яратышып өйләнештекме?

— Шулай да булсын.

— Күзгә карап әйт: яратышып өйләнештекме?

— Яратышып.

— Гомергә бергә булырбыз, дип әйттеңме син миңа?

— Әйттем.

— Ун ел бүе сүзебездә тордыкмы? Вәгъдәбезгә тап төшмәдеме?

— Монысы агы була инде, әйеме?

— Син аны, Солтан, теләсә ничек дип бәялә, теләсә нинди лозунг кысасына этеп-төртеп керт, минем өчен ул еллар кадерле. Һәм мин сиңа рәхмәтле...

— Ә карасы? Карасы нинди була?

— Мине иремнең чибәр кыз белән биюе борчымый.

— Нәрсә борчый соң?

— Карале моны! Кайчаннан бирле әле син шул хәтле сабырсыз булып киттең? Элек бит ун сүзгә дә бер сүз әйтми идең. Син ир булсаң, ир бул — тыңлап бетер хатыныңның сүзен. Кабатлап әйтәм: мине иремнең яшь кыз белән биюе борчымый. Һич! Мине Айдаровның техникумда бергә эшли торган иптәшләре алдында хатынын санга сукмавы, феодаллыгы борчый. Көпә-көндез, бөтен иптәшләрең алдында, ник син миңа чыпчык борыны чаклы да игътибарлы түгел. Инде үзең белмисең икән, әнә безнең институттагы галимнәрдән — Майскийдан, Кабуловтан, Голосовтан үрнәк ал. Үзләре белән бергә килгән иптәшләрен, бигрәк тә хатын-кызны, аларның игътибарсыз калдырганын күргәнең бармы синең?

— Алар — дворян баласы. Игътибарлылык аларның канына гасырлар буена сеңгән. Нәселдән-нәселгә килә.

— Ярар, Солтан, туктатыйк без онсыз тегермән тарттыруны. Син үсмер егет, мин җилкенчәк кыз түгел. Дөньяның кая барганын бик яхшы беләбез. Менә сиңа хакыйкать: капканы багана тотып тора. Баганасы череде ме, капка ава. Моңарчы син безнең гаиләнең баганасы идең — нык-

лыгы. Син саклап килдең мине җил-давыллардан. Нинди генә авыр чаклар булса да, мин сине уйлап, синең барлыгыңа инанып, түздем. Кешегә чыкмадым, язмышымнан зарланмадым...

Солтан күреп тора: хатынының чырае бозыла бара, иреннәре тетри, улниндидер бик мөһим сүз әйтергә тели, ләкин әйтеп җиткерә алмый азаплана.

Шуны аңлаган мизгелдән Солтанның күңеле ничектер йомшап китте, гадәти үҗәтлеге, ирләргә хас мин-минлеге арткы планга күчте.

— Әйт, энисе, нәрсә әйтергә телисең? Әйтеп бетер, яшермә! — диде Солтан, ялыныр дәрәҗәгә җитеп.

Нуриянең күзенә яшь бөялде. Ул, томан пәрдәсе аша иренә карап, сүзләрен көч-хәл белән әйтте:

— Мин... балага уздым... Синнән башка... табыйммыни баламны?..

Башка сүз әйтергә көче җитмәде, үксеп елап җибәрде.

## VIII

Солтан Айдаров Свияжскига кайтты.

Җаны үкенү-газаплар белән тулы иде.

Эш белән күмелеп, булган хәлне онытырмын дип исәпләде. Атна узды — оныта алмый. Гафу үтенеп хат язды — җавап юк. Шул хәтле дә каты үпкәләде микәнни соң? Ничек бәхилләтергә инде менә аны хәзер?

Көннәр, гадәттәгечә, суык тора. Тулай торакларга, уку-укыту биналарына дип әзерләнгән утынның язга тикле җитмәслеге билгеле булды. Ашханә өчен кирәкле азык-төлек тә кимеп бара. Мәшәкать баштан ашкан, берәү дә күзгә күренми. Җандагы газап та кимеми.

Әнә шундый көннәрдә ул никтер янә Гөлмәрьямне исенә төшерде. Тукта, ничек танышты соң әле ул аның белән? Нигә болай газаплы да, күңелсез дә булып бетте соң әле бу танышуның азагы?

...Ул урамнан бара иде. Үзе әле генә килеп төшкән, биредә беркемне дә белмәгән бәләкәй, тузанлы каланың урамыннан бара иде Солтан. Аңа техникумның кайда урнашуын белергә кирәк иде. Урамда аңа нечкә билле ак күлмәк өстеннән зур кара толымнарын атындыргалап барган бер кыз очрады.

— Сеңлем, гафу итегез, Җир төзүчеләр техникумына ничек барырга икәнен әйтә алмассызмы? — дип сорады Солтан.

Кыз туктады. Сорау бирүчегә шомырт кара күзләре белән бер төбәлеп, әллә ничек шунда үзәккә үтәрлек итеп карады.

— Сезгә кем кирәк анда, абый кеше?

— Кем дип... барысы да кирәк...

— Әллә сез безгә эшләргә киләсезме?

— Әйе шул.

— Фамилиягез Айдаров түгелме?

— Нәкъ үзе. Ә сез каян беләсез? — диде Солтан, аптырый төшеп. Ул ак күлмәкле, нечкә билле кызны үзе дә сизмәстән күздән үткәрде, һәм аның аякларының төз, искиткеч матур икәненә сокланып, соклануын хәтта яшермичә: — Пушкин әйткән, безнең Россиядә йөз кызга да бер матур аяклы хатын-кыз таба алмассың дигән. Димәк, даһилар да ялгыша...— диде.

Ак күлмәкле кызыйның чибәр ак йөзе шундук кып-кызыл булып кызарды, шомырт кара күзләрендә хәтәр очкыннар биешеп алды.

— Сез, абый кеше, малны таный беләсез,— диде ул, башын артка чөеп, килешле генә кылтаеп көлде. Һәм дөньяның көләчлеген үзенә җыйган яңгыравыклы тавышы белән, кыңгыраудай чыңлап: — Киттек, абый кеше, мин дә техникумга барам,— диде. Бер тын юл узгач, көтмәгәндә өстәп куйды: — Сез безгә завхоз булып киләсез, әйеме?

— Ә сез аны каян беләсез? — дип Солтан тагын бер мәртәбә сорамый булдыра алмады.

— Дөнья бик күңелсез, абый кеше. Педагоглар әчпошыргыч дәрәҗәдә сүлпән халык. Ә мин берәр яңа кеше, кызыклы кеше килмәсме дип, өмет утында янам...

Аларның сөйләшүләре ул чакта шуның белән бетте шикелле. Әмма Солтанның кыз турында, аның кыю итеп сөйләве хакындагы уйлары бетмәде. Никтер аны күреп тагын-тагын сөйләшәсе килде. Ул аның белән тагын бер мәртәбә сөйләшсә, күңеленә ял табар иде шикелле тоела башлады.

Тиздән ул аны күрде.

Гөлмәрьям техникумда техник секретарь булып эшли икән. Теге көнге сөйләшүенә һич тә охшамаганча, шактый ук кырыс чырай белән:

— Сезгә, иптәш Айдаров, ни кирәк булды? — дип каршылады.

— Миңа лесхоздан ягулык утыны алыр өчен директор имзасы белән кәгазь кирәк иде.

— Булыр. Иртәгә керерсез. Директорга әйтермен.

«Тагын бер күрергә теләү хәйләсе түгелме!» — дигән юанычлы уйны күңеленә салып куйды Солтан.

Яшь егеттәй сабырсызланып, иртәгесе көнне көтте.

Кыз тагын да кырысрак чырай белән каршылады аны, янында ике кеше бар иде, күбрәк алар белән сөйләште. Солтан, инде кәефе китә башлап, кичәге сүзне исенә төшергәч, кызыкай:

— Бер генә минут! Сабыр итегез, абый кеше,— дип, директор бүлмәсенә кереп китте дә ялт итеп килеп тә чыкты. Завхозның кулына кирәкле кәгазьне тоттырды. Бу юлы да ул аңа игътибарсыз-битараф булды, җанны өшетерлек битараф булды.

Чыгып кына китәргә кирәк иде дә бит Солтанга, китмәде шул, хәерсез. Этенеп торды. Кыз аңа шундый итеп күтәрелеп бер карады, күзләрендә шундый бер шелтә бар иде, Айдаров ничек чыгып киткәнен сизми дә калды.

Аннан соң ул, бик тәҗел йомышы чыкмаса, директорның «приемная» бүлмәсеннән ераграк йөрергә тырышты. Аннан соң ялга — санаторийга барып кайтты. Аннары яңа квартирга күченеп йөрде.

Алар очрашмадылар. Ләкин аларның күңелләре очрашты. Солтан, техникумда эшләүче техник персоналдан сорашып, ачыктан-ачык сорашып түгел, сүз чыккан араларда колак салгалап йөреп белде: Гөлмәрьямгә инде егерме биш яшь икән. Кияүдә түгел. Заманында Арча педучилищесын тәмамласа да, укытучы булып эшләргә теләмичә, Җир төзүчеләр техникумына килеп, техник секретарь булып урнашкан. Йөк төяүчеләр, ашханәгә азык ташучылар таң калып, тел шартлатып сөйли: ул буйсын! Ул каш-күзнең, толым-толым кара чәчнең матурлыгы дисеңме! Шаклар каткыч бит. Үземә булсын диярсең! Ходаның хикмәте, сазаган кыз булып барса да, кияүгә дә чыкмый, зуррак эшкә дә күчми, килгән-киткән ир-атның йөрәгенә ут салып утыра бирә...

Солтан, үзе дә сизмәстән, вакыт-вакыт җырлап, үзалдына моңаеп йөри торган булып китте.

Солтанга әллә нәрсә булды. Ир уртасы кеше бит инде, югыйсә — утыз алты белән бара. Карале син бу ахмаклыкны — муеннан гашыйк булып йөр инде, ә?..

Техникум коллективы — укытучылар да, студентлар да — ул арада үзешчәннәр кичәсенә әзерләнә башлады.

Солтанның Гөлмәрьям җырлый беләдер дип башына да китергәне юк иде. Кичәнең баш өлешендә ул, ипләп кенә, берәүгә дә сиздермәс өчен күзләре белән генә, залдан Гөлмәрьямне эзләп карады, таба алмагач, аптырады. «Нужәли үлгән йөрәк икән? Әле бит теге көнне педагогларны сүлпәнлектә гаепләгән булды...» — дип, үзалдына үртәнеп тә куйган иде. Әмма кичәнең азагына табарак, Гөлмәрьям Суфиева җырлый, дип игълан ителгәч, утырган урындыгына сеңде Солтан. «Хур булмаса гына ярар иде».

Сәхнәгә ак күлмәкле кыз чыкты. Солтан аны таныды. Тәүге мәртәбә очрагандагы нечкә билле ак күлмәктән иде ул, шомырт кара чәчен ике толым итеп үреп салган. Ләкин үзгәреш тә бар, толым очларына ул көмеш чулпы таккан, баш түбәсенә энҗеле калфак кадап куйган. Татар кызларының гасырлар буена эзләп тапкан энә шул киемнәреннән кайбер «кызыл авызлар» көлеп йөргән заманда а н ы ң энә шул киемнәрне горурланып киеп чыгуы залны аһ иттерде. Һәр яңалыкны бик тиз күреп ала торган студент халкы а ң а гөрләтеп кул чапты.

Солтан да, аларга ияреп, кул чапты.

Аннары сәхнәгә йотылды.

Гөлмәрьямнең, башкалар кебек кыюсызланып, сәхнә түрендә калмавы, чулпыларын чыңлатып, сәхнә алдына чыгуы, ул гына да түгел, матур төз аяклары белән сәхнә идәненә түгел, егетләрнең йөрәгенә басып килүе — аны әллә нишләтте. Чукынган кыз, хәерсез, таш астыннан чыккан бу, сәхнә өчен яратылган!

Гөлмәрьям, сәхнә алдына, ике яктан яктырткан утызлы лампа астынарак килеп туктагач, халыкка сизелер-сизелмәс итеп кенә баш иде, аннары ак күлмәктән, үтүкләнмәгән соры чалбардан, зур «рабочий» ботинкадан чыгып баскан үсмер егеткә — гармунчыга ым какты.

Менә шуннан башланды...

Җырчының кәгазь юкалыгы гына ачылган алсу иреннәре, буялмаган табигый алсулыгы белән матур иреннәре арасыннан җаннарны иркәли торган моң агыла башлады:

Кемгә сөйлим серләремне,
Йөрәгем ялкын кебек...

Тын калып тыңлады зал. Күңелләр җыр белән беректе.

Ялкынланган йөрәгемә
Берәү бик якын кебек...

Җырның моңлы сагышы кайдадыр болын буйларында бәләкәй көмеш кыңгырауларын чыңлатып йөргән атларны искә төшерә. Зартугайның көмеш чишмәләр тавышы да кебек ул. Йөрәкнең бер кылы киерелеп тартыла, менә-менә зыңгылдап китәр дә, өзелер кебек тоела башлый.

Җыр бетә, йөрәкләргә сеңеп, юк була.

Зал дулап кул чаба, кул чабулар дулкын-дулкын булып килә, керосин лампалары эчендә ут телләре дерелди...

## IX

...Солтан әле генә күңеленнән кичергән кадерле минутларны, Казандагы, үзләренең квартирындагы үзәк өзгеч күренеш белән янәшә куеп карый. Йөрәктән кан тамар дәрәҗәдә авыр аңа. Балага узган хатынын онытып, Гөлмәрьям белән тилереп йөрү авыр. Юк, моңа чик куярга кирәк. Вазифаңны онытмаска кирәк. Ләкин, каһәр суккырысы, Гөлмәрьямне онытып булмый. Йөрәктә утыра ул, кадалган шырпы кебек.

Бик зур гаеп ташлады аңа Нуриясе. Җан ачысы белән елады. Нәрсә эшләде соң әле ул аны елатырлык? Нинди этлек эшләде? Җенси азгынлыкка бардымы?

Шул хакта уйлагач, тәннәре чымырдап китте. Үз гомерендә анын хатын-кыз белән чуалганы булмады. Юк! Ләкин аны бүген хисләреннән мәхрүм итмәкче булалар. Гаилә кысасына бикләп куймакчы булалар аны. Сандугач ректә сайрый. Читлектә сайрамый. Япкан читлеге хәтта алтын булса да, сайрамый сандугач. Ә аны читлеккә ябып куярга азапланалар. Нуриядән хат юк. Аның хатына җавап бирергә теләми «доктор апабыз». Үз иркенә куюы, «Кадалып кит Гөлмәрьямең белән!» — дип әйтүе микәнни? Кадалып китәр идең дә бит, аның туган көн бәйрәмен-

нән соң Солтан белән Нурия арасында гына түгел, Солтан белән Гөлмарьям арасында да аңлашылмау килеп чыкты.

Сәбәпләре моның шактый ук сәер иде.

Техникумга кибеттән келәм алу өчен өч ордер бирделәр. Рөхсәт кәгазьләрен өләшүне директор завхоз Айдаровка тапшырды. Ул аның акыллы, тәҗрибәле кеше икәнен белә, гадел итеп, тигез итеп бүләр, беренче чиратта техникум мәнфәгатен кайгырткан фидакяр кешеләргә бирер дип ышанды директор.

Айдаров нәкъ шулай эшләде дә. Ордерлар барын беркемгә дә әйтмәстән, ул педагогларның да, техник хезмәткәрләрнең дә хезмәт характеристикасын булдырды. Булдырып кына бетергән иде, каян ишеткәндер, завхозның складына уйламаган-көтмәгән җирдән Гөлмарьям килеп керде.

Үз кеше булып, балкып, нурланып керде Гөлмарьям.

Солтан алдында артистларча бер бөтерелеп алды да:

— Иптәш Айдаров! Сездән сорарга әмер бар: келәмнәр кайткан икән... берсен миңа бирә алмассызмы? — диде.

Солтанның төсе качты.

— Юк, бирә алмыйм, Гөлмарьям. Исемлек инде төзелгән. Директор тарафыннан расланган. Миндә артык ордер юк,— диде.

Гөлмарьям кырт борылып, ишекне каты ябып чыгып китте.

Менә шуның белән Солтанның мәхәббәт эпопеясы тәмамланды.

Гөлмарьямнең кем икәнен иң әүвәл үзе түгел, хатыны Нуриянең сизеп алуы, җитмәсә әле үзенең Нурия белән зурдан кубып бәхәсләшүе, шәхес иреге даулавы аның өчен гарьлек иде.

Тагын бер-ике атна газаплы уйлар эчендә яшәгәч, салкын тидереп, корык-корык йөткерә дә башлагач, ул Казанга — Нуриясе янына кайтып килүне кирәк тапты.

Ашыгыч эшләрен бер-ике көндә тәмамлап, директордан рөхсәт алып, поезд белән Казанга кайтты. Нурия аны, әлбәттә, кояш кебек балкып каршыламады. Хәер, ул кадәресен Солтан көтми дә иде.

Аш пешерде Нурия. Солтанның яраткан ризыгын — пәрәмәч әзерләде. Ашны иң алдан Солтанга салды, аннары — үзенә. Мәгънәсез дип уйламасын.

Сүзсез генә ашагач, чәй эчкәч, иренең каршысына утырып, врачларга хас мөлаем бер җитдилек белән, барлык башка авыруларга әйтә торган сүзен әйтте:

— Чибәр егет, чыраең ошамый миңа. Авыруың яңармады микән? Тубдиспансер врачы, профессор Тарибердиевка күренергә кирәк.

Солтанның врачка күренәсе килми, суык тигән булса, өч-дүрт таблетка йоту белән узар дип уйлый иде. Ләкин Нурия нык торды. Солтанны ул кулыннан җитәкләп диярлек Ипполит Дмитриевич Тарибердиевка алып барды.

Профессор, Казанда үпкә авыруларының иң зур белгече, бер дә иренмичә, җентекләп, озаклап карады Солтанны, «авыру тарихын» катькат сорашты. Бу хәлләрдән арыган Солтан тирләп, корык-корык йөткергән чагында, врачның юка иреннәре кысыла, калын пыялалы күзлек астыннан яшькелт-соры күзләре елтырый иде.

Профессорга өч көн рәттән барырга туры килде Солтанга. Кирәкле процедураны үткәреп, барлык анализны ясатып, һәммәсенең нәтиҗәләрен карагач, тәҗрибәле врач-практик, Айдаровны каршысына утыртып, ашыкмый гына әйтте:

— Солтан Садыйкович, сезнең элекке чирегез яңарган, туберкулез учаклары яңадан ачылган,— диде.

— Гафу итегез, профессор, минем бит элек туберкулез түгел иде. Үпкә ялкынсынудан дәваланган идем мин. Тарловкада,— диде Солтан, тагын йөткерә башлап.

Врачның күзлек аша тыныч-сабыр караган күзләрендә әллә ни үзгәреш сизелмәде.

— Бәлки, шулайдыр,— диде.— Ул хакта бәхәсләшмик. Хәзер сездә, Солтан Садыйкович, чын мәгънәсендә туберкулез. Бер көнне дә кичектерми, тубдиспансерда дәваланырга кирәк. Менә шулай, иптәш Айдаров. Кимендә өч ай Каменкада булырга кирәк сезгә.

Солтан өенә кайтты. Чырае бик боек иде. Бер генә сүз дә әйтмәстән, лаборатория кәгазьләрен Нуриягә тоттырды.

Язуларны күздән кичергәч, Нурия артына егылып китә язды. Анда латинчалап түгел, русчалап: «В поле зрения множественные палочки»,— дип язылган иде.

«Менә шулай, чибәр егет. Таза чакта — кызлар, авырып китсәң — хатын кирәк. Тагын наркомземга ялынырга туры килә»,— дип, үз гомерендә беренче мәртәбә үчекләнеп уйлады Нурия.

Тагын бер айдан Нурия зарыгып, шул ук вакытта хәвефләнеп көткән көн килеп җитте. «Ашыгыч ярдәм» машинасы аны төн уртасында бала табу йортына илтеп куйды.

Кайчандыр Нурия белән бергә медицина институтын тәмамлаган, инде ГИДУВ клиникасында доцент булып эшли торган Камушкин — очлы борынлы, тырпаеп торган зур колаклы, гомерлек буйдак — докторлык диссертациясенә материал туплый икән. Ул Нуриягә әйтте:

— Мин авыртусыз бала таптыра торган ысул белән эшлим. Телисезме, Уразаева? — диде.

Нуриягә ничектер кыен булып китте. Ул әле болай да баласын инде икенче мәртәбә ире югында табарга туры килгәнгә борчыла иде, чамадан тыш коры табигатьле, елмаю-көлү дигәннең нәрсә икәнен дә белми торган сабакташына үртәнә биреп җавап кайтарды:

— Мин, Герасим, бала табуны табигый эш дип саныйм. Авыртусыз бәби табуның кире нәтиҗәләреннән куркам.

Әмма бик кыеннан тапты Нурия икенче баласын.

— Ай-һай авырдан булды бу эш! Исән-сау котылуың белән сине, әни кеше! Кызың бар...— диде тәҗрибәле карт акушерка Аверьяновна. Ул җитмеш ел буена җете булып сакланган бәләкәй тере күзләрен күп санлы җыерчыклар арасыннан җемелдәтеп тагын бер-ике сүз өстәүне кирәк дип тапты: — Операция ясарга туры килмәгәе дип ут йоттым. Беләсеңме, анакаем, доктор Камушкин ачуы чыккан чакларда операцияне бик тупас ясый...

Нурия ак биләүсәгә биләп, тәүге мәртәбә ими имезергә китергән сабыена, барлык аналар кебек, озаклап, сынап карады. Җанын тетрәтеп, күкрәгеннән ниндидер кайнар дулкын узды. Баласы исән-сау, гарипгораба түгел, имигә ирене тиюгә, тәннәрен чымырдатып, каты суырып имә башлады.

Нурия сөенечен эчендә генә калдыра алмыйча, күршедәге яшь әниләрдән дә тартынып тормастан, сөйләнеп куйды:

— Сөбханалла! Кызыбыз бу юлы кара чәчле булып туган...

Нуриянең хәлен беренче булып телефоннан күптәнге ахирәте Гөлсем Сөләйманова белеште. Ул бүген генә гастрольдән кайтып төшкән, дустына күчтәнәчләр алып кайткан. Нурия әзрәк хәл алса, өч-дүрт көннән янына килеп чыгарга вәгъдә итте.

Рәхәт булды Нуриягә. Кулларын баш астына куеп, дымлы күзләрен сөртергә дә теләмичә, җанында кузгалган тойгыларга бирелеп, түшәмгә карап ятты ул.

Шулай изрәп, тойгыларга бирелеп яткан чагында аңа зур бер пакет кертеп бирделәр. Гистология кафедрасының котлавы икән. Кырыйларына буяу карандашлары белән чәчәкләр төшерелгән кәгазьгә әни кешене сабые белән котлап, бетмәс-төкәнмәс сәламәтлекләр теләп, Майский, Кабулов, Голосов, Макшеев кул куйганнар, биредә тик Атаманованың гына имзасы юк, ул әле үзе больницада икән.

Кәгазьнең урта бер җиренә җеп белән беркетелгән имезлекне ипләп кенә алып, кабып карады Нурия. Палатадагы хатыннар аңа елмаешып карап тордылар.

Бераздан аның шатлык-дулкынланулары узды, тәненә хәлсезлек җәелде, башы авырта башлады.

Моның нидән икәнен Нурия сизенә иде.

Бергә эшләгән иптәшләренең котлавы, аларны үзең белән янәшә итеп сизү, әлбәттә, рәхәт, әмма бәби тапкан көннәрдә Солтанының янда булмавы күңелне рәнҗетә, ирексездән күзгә яшь китерә иде. Тик еларга ярамаганны белү, гасабилануның нәниенә йогынты ясаячагын аңлау гына Нурияне күз яшьләрен тыеп калырга мәҗбүр итте.

Бу юлы да аңа беренче кызы Миләүшәне тапканда булышкан Мәликә апа ярдәмгә килде. Ул кибеткә товар ташучы иреннән ат җиктереп алып килгән иде. Нурияне больницадан үзе алып чыкты, мамык юрганга төргән сабыйны үзе тотып, үзе саклап алып кайтты.

— И Мәликә апакаем, рәхмәтләр яусын сиңа, дөнья рәхәтләрен күр мине сөендергән өчен,— диде аңа Нурия, күңеле нечкәреп.— Туган-тумачаларым, газиз ирем эшләмәгән яхшылыкларны эшлисең бит син. Гомерем буйларына онытмам изгелегеңне...

Гажур йортының парадный ишеге төбенә килеп туктауга, Нурия аптырап-каушап калды — көмеш башлы кара таягына таянган профессор Майский басып тора.

Ул якынлашып килүче олаудагы Нурияне күргәч, таягын култык астына кыстырып, ашыгып-кабаланып, алар янына килде, Нуриянең кулын үпте, котлады, аңа сиртмә арбадан төшәргә булышты.

Урамнан узучылар ак шәл бөркәнгән ханымны, юрган белән бала күтәргән Мәликә түтине, ханымның кулын үбеп күрешкән сакаллы картны карап-карап уздылар.

Бу очраклы очрашуга Нурия үлепләр дә сөенде, остазы белән сүз куертырга да исәбе бар иде, тик Мәликә түтинең:

— Балам, без өзлегеп куймыйк тагын,— дигән сүзе генә аны аңына китерде һәм ул профессор белән гаепле кеше сыман саубуллаша башлады.

— Кафедра өчен кайгырма, Нурия Аббасовна, дәресләреңне Голосов алып бара, аякка басканчы, өеңдә тыныч кына утыр, яме,— диде аңа профессоры.

Котларга килүчеләр, күчтәнәч китерүчеләр бәләкәчнең исемен сорап аптыратып бетерделәр. Ләкин ул, әтисе Кырымнан кайтканчы, утыз көн буе исемсез яшәде.

Күршедә генә Имаев дигән карт, заманында революция өчен сугышкан кеше, Роза дип кушуны үтенде:

— Роза Люксембург хөрмәтенә булсын. Бу исем кызыгызга бик тә туры килә, ник дисәң — Солтан Садыйкович та заманында революция өчен кан койган кеше бит,— диде.

Нурияне котларга соңгы кеше булып диярлек Зәйтүнә апасы килде. Ул олыгая төшкән, чәчләренә заман кыравы кагылган. Ләкин үзе һаман да чибәр, һаман да пөхтә, бик тә нәзакәтле итеп киенгән, сүзен үлчәп кенә сөйли — алтын бәясенә сата.

Озак килә алмый торуының сәбәбен ул Нурия белән ике куллап күрешкән чагында ук аңлата башлады.

— И сеңелкәем, и Нуриякәем! Күр инде син минем мәгънәсезлегемне! Туганым багалма төсле кыз тапкан, инде тапканына егерме биш көннән артык вакыт узып киткән, шуны күрергә бер генә мәртәбә дә килеп карама инде, ә?! Шуннан соң ходай тәгалә безне нинди әйбәт кешеләр рәтенә кертсен дә, нинди җәннәтләргә якын китерсен! Тәмуг кисәве инде без, тәмуг кисәве!

Ул кулына тотып килгән зур гына бер ак төргәкне урындыкка куеп, затлы мехтан тар гына яка куеп тектергән җәйге күксел җиләнен салды,

пәрәвез җебе кебек нечкә җептән бәйләнгән чытыр ак шәлен салды, бәләкәй кара ридикюленнән уч төбе хәтле генә кулъяулыгы чыгарып, битенә, күз төпләренә кагылгалап алды. Өйгә шундук нәфис хушбуй исе таралды.

Бәби тапканнан бирле кеше янына чыгып йөрмәгән Нурия дөньяда андый нәфислек барын да онытып бара икән инде, борын канатларын киереп, рәхәтләнеп иснәде хушбуй исен.

Ул арада Зәйтүнә апасы төенчеген чишеп җибәрде. Аннан бик матур зәңгәр ефәк юрган, бәләкәй ак батист күлмәк килеп чыкты.

— Нуриякәем, мин менә шуларны алып килгән булдым инде. Ярар микән болар, юк микән? Инде үземнекеләр үсеп бетә язгач, онытып та җибәргәнмен...

«И апакаем, кылтымлыгың әле һаман шул икән»,— дип уйлады Нурия, ләкин теле белән икенче сүзне әйтте:

— Бигрәкләр дә матур инде, апам. Бигрәкләр дә матур! Мондый нечкәлекләрне белсәң, син генә беләсең инде...

Дөньяда теләсә нинди төчелек туйдыра, тик бер ихласлык кына туйдырмый. Чөнки ул — дөньяның үзе кебек, зәңгәр күк йөзе кебек, яшел чирәмнәр кебек табигый.

Озакламый алар табигый халәтләренә кайтып төштеләр. Чөнки эчкәрге бүлмәдәге «бөтерчек», уянып, аваз сала башлады. Аны тыңламый булмый, аның авазына буйсынмый ярамый, ул — дөньяны яңартырга, әти-әниләре эшләгән эшне зуррак итеп кабатларга килгән кеше.

Нурия эчкәреге бүлмәдә байтак кайнашып, кызының биләүсәләрен алмаштырып, сабыйны Зәйтүнә апасына алып чыгып күрсәтте. Тегесе баланың өстенә үк иелеп карады.

— Миләүшәң әтисенә охшаган сары иде, монысы гел дә менә үзең икән. Кара чәчле, күзләре — шомырт. Карасана, елмая түгелме, кодаем?

— Саташып кына әле ул, саташып кына. Без әле, диген, кызым, без әле озак карап торучыларга елмаерга бер дә ашыкмыйбыз, без әле ачулана да беләбез,— дип, кызы өчен сөйләнгән булып, Нурия баласын уңайсызлый башлаган апасына ризасызлыгын белдерде.

Ырым-шырымга ышанмаса да, күз тию дигән нәрсәгә Нурия ышана, чөнки күздән агылган нурлар баланың нервысына кагылып, аны бимазалый дип уйлый иде.

Апасының чамадан тыш текәлеп каравыннан котылу өчен ул, шалкандай тыгыз күкрәген чыгарып, сабыен имезә башлады.

Кызчыкның тамагын туйдырып, авызына буш имезлек каптырып, бәләкәй караватка салгач, апалы-сеңелле ике туган чәй эчәргә утырдылар.

— Аты кем булды инде бәләкәчнең? Әйтмәдең дә бит әле, сеңлем? — диде Зәйтүнә мөгаллимә.

— Атыбыз юк шул әле безнең. Хәзергә әле, апакаем, атсыз гына яшәп торган булабыз. Әтиебез кайткач куйдырабыз инде исемне, боерган булса...

— Алай әйбәт түгел бит ул, Нурия. Борынгыларның әйткәнен ишеткәнең юкмыни: атсыз яшәгән баланың гомере кыска була,— дип ычкындырып ташлады Зәйтүнә мөгаллимә. Саксыз әйткән сүзе өчен үкенеп, хатасын төзәтергә ашыкты.— Атын куймый торган суратта дә, загска барып яздырмасагыз да, күңелеңнән булса да әйтеп йөргән бул атын, яме, сеңелкәем.

— Кем дип әйтим соң, Зәйтүнә апа?

— Әлфия дип әйтергә була, Сания дип... Гөлбикә бар, Айбикә бар. Шәмсекамәр дисәң дә ярый, ягъни кояш белән ай бергә кушылган,— дип, Зәйтүнә мөгаллимә гарәп-фарсы телләрен камил белүен китереп чыгарды. Ләкин шул ук минутта сеңлесен ялыктыра башлаганын сизде бугай, кисәк кенә бер нәтиҗә ясап куйды: — Ярар, тинтерәтмим әле сине. Баладан соң арыгансыңдыр. Солтаныңның да бу елларда мәшә-

кать-борчулары муеннан булды. Баласын таба белгәч, атын гына куша белерсез.

Солтан турындагы кыска хәбәрләр белән генә канәгать булмады Зәйтүнә мөгаллимә, турыдан-туры сорау бирде:

— Карале, Нуриякәем, Солтанның сәламәтлеге ничегрәк? Әзрәк рәтләнә аламы инде, тамагына каба микән?

— Рәтләнә, апа, рәтләнә, хатларын да бик өметле яза.

— Техникумга кире кайтарганнар икән дип ишеткән идем, шул элекке эшенәдер инде? Директор итептер, әйеме?

Нурия, мөгаллимә апасының тагын кылтымлана башлаганын абайлап алып, аның сыман, сизелер-сизелмәс кинаялап әйтте:

— Шул эшенә диярлек. Хуҗалык эшләре буенча директорның урынбасары.

— Алай икән. Кара син аны. Мин бит әле завхоз гына икән дип ишеткән идем. Бәрәкалла, алай булгач, бик әйбәт. Исән-сау гына тереләп житсен дә, бергә-бергә тигез гомер итәргә язсын. Бала үстергәндә, тигезлек бик кирәк ул, бик кирәк, сеңлем.



**Тугызынчы башлам**

### I

Кумәк хуҗалыкларга берләшкәннән соң бишме-алтымы ел узуга, Кама иделе буйларында иген-тару кукрәп уңды. Яздан башланган җылы яңгырлар, җәй үзәгендә ике ай буена сузылган кояшлы матур көннәр үзләре белән муллык алып килделәр.

Минзәлә як болыннарда, халык телендә йөргәнчә әйтсәк, Аргы як болыннарда кукрәккә җитәрлек булып айравык үлән үсте, урманнарда сыер-сарык көтүләре тулышып йөрде, кыр станнарында, Иж елгасы тугайларында таза беләкле ирләрнең чалгы янаган тавышлары ишетелеп торды.

Авыл ярлысының язмышын яр читендә тоткан «корама юрган» басулар ызансыз киң кырларга әйләнеп, көз күреме җирдә офыктан-офыкка игеннәр чайкалып утыра башлагач, Зартугай крестьяннары — Әфләтуннар, Шибайлар, Әхмәтҗан картлар, кыр юлларына чыккан чакларда, кулларын каш өстенә куеп, уйлы-моңсу карашларын еракларга төбәп, сүзсез-нисез озак-озак басып торалар; баш өстендә талпынган сабан тургайлары тавышы, кырлар өстендә тибрәнгән рәшә дулкыннары аларның җаннарын булачак муллык тойгысы белән тутыра; арыш-бодай тулы бураларны, ак он тарткан тегермәннәрне, мичтә чыжылдап пешкән коймакларны күз алдына китерә. Ничәмә-ничә еллар яшәп тә, юл тузаннарын таптап та, кайнар кояш астында чуен кебек каралып та, алар дөньяда шундый рәхәтлек барын тоймаганнарына хәйран калалар иде.

Чокыр-чакыр буйларына, тиреслек башларына чүмәшкән салам түбәле тәбәнәк йортларга кайчан да булса куенга сыймаслык куаныч килер дип кем уйлаган? Көзен, колхоз басуларындагы игенне җыеп суктыргач, ашлыкны крестьян агай йортына, әнә шул җиргә сыенып утырган тәбәнәк йортларга, кызыл олаулар белән китереп аудардылар.

Ни хәтле җыру җырланды, ни хәтле гармун уйналды, ни хәтле тантаналы-дәртле сүзләр әйтелде ул елларны!

Зартугайның дүрт йөздән артып киткән морҗасыннан күпме төтен чыкты, яңа пешкән ипи исе иртәдән кичкә кадәрле авыл урамнарын тутырып торды.

Өздереп уйнагаң тальян моңнары, яшь-җилкенчәкнең Иж буйларын яңгыраткан яңа заман җырлары («Һаваларда очкыч, суларда йөзгеч, кулда мылтык-кылыч!»), манарасы киселгән мәчетләрдә таң әтәчләре кычкыра башлаганчы уйналган спектакльләр авылга бәйрәм тойгысын шулай ук олавы-олавы белән алып килделәр.

Әйе, бу бәйрәмгә, бик зур бәйрәмгә, тигез хокуклылыкка, ирекле азат тормыш бәйрәменә әзерләнү иде.

Авыл советы йортының түбәсенә Мәрдәнша Мурзин үз кулы белән кадаган ал байракны җилләр шаптыр-шоптыр китереп какты. Хәллерәк йортларның урыс капкаларына, колхоз кәнсәләренең түбә асларына беркетелгән куе кызыл төстәге плакатлардан яртышар метр зурлыктагы ак хәрефле сүзләр әллә каян күренеп, үзләренә чакырып, өндәп-ашкындырып торалар иде:

БЕРЕҢ-БЕР КАЛМЫЙ САЙЛАУЛАРГА!

Ликбезда хәреф танырга, гәзит хәбәрләрен иҗекләп укырга өйрәнгән карт-коры, агай-эне, ил агалары авыл урамнарына килеп кергән яңалыкны бавырлары белән сизеп йөриләр: пожар каланчасы, атлар абзары, колхоз кәнсәләре тирәсенә җыелган чакта ил-көн хәбәрләре хакында сүз куертып җибәрәләр:

— Кәнститүтсе булачак икән. Төп закун дип атала.

— Кем әйтте?

— Үзем гәҗиттән укыдым. Влач белән теләсә кем камандавайт итәсе дип язганнар.

— Шалиш, кода. Теләсә кем түгел, халык дигән — рабучи белән керәстиән сыйныфы, белдеңме?

— Син таякка коршау сукма, Сибгатулла! Әнә бит кәнүшнидә тирес түгүче Әхмәтҗан белән Бөкере Гафиятне Пәнҗәргә алып барганнар. Кырандаска утыртып. Хәл белешү сылтавы белән бардымые: адәм әйтеп, адәм ышанмас, Әхмәтҗанның өстендә — кара постаудан өр-яңа кәчтүн, аягында — хырум батинкы, башына Иванай керәшеннәре кия торган фүрәшке чәпәп куйган.

— Фүрәшке чәпәсә — ни булган?

— Токтымалдан кешене биспылатны киендермиләр. Калинин бабай янына аппарасылар ди. Белдеңме?

— Аңысы тагын нәмәстәгә? — дип, ике метрлы буе белән Әфләтун карт алга чыга.

— И аңгыра бәрән дә инде син, Әфләтун абзый! Нәмәстәгә булсын, әнә шул төп закунны чыгарырга, кәнститүтсе дигәннәрен төзергә Калинин бөтен илне чакыра икән.

— Шулаймыни? Әйтәм аны Бөкере Гафият бу араларда уклау йоткан төсле үрә катып, исәннәшер-исәннәшмәс йөри. Хикмәте бар икән әле аның, баксаң-күрсәң...

— Хикмәтсез кисмәк тә ясалмый, Әфләтун абзый. Бөтен нәстәнең хикмәте бар. Влачның бит инде рабучийлар, керәстияннәр кулына күчте дип сөйли башлаганыбызга озакламый егерме ел тула. Аның бит инде шулай икәнен раслап күрсәтергә дә вакыттыр. Барсын Гафият тә, барсын Әхмәтҗан да — и барырга тиешле дә! Ник дип әйтеп әйтсәң, әүвәлгесе елларны бай-бәтчәгә, мулла-мунтагайга бил бөктеләр, инде менә без кәнүшнигә илтеп тапшырган җәмәгать атларын карый башлаганнарына да алты-җиде ел була бит...

Тыңлаучылар баш кага. Ризалар. Барсыннар, эшләгәннәренең әҗерен тапсыннар.

Урамнан, пожар каланчасы яныннан, каты карны шыгырдатып, бүрәнә төягән олаулар уза. Сары чикмәнен кызыл пута белән буган, ап-ак тула оек өстеннән чабата кигән, бәрән бүрекләренең колакчынын төшереп куйган агайлар ил-көн хәбәрләрен сөйләшеп торучыларга сәлам биреп узалар.

Йоклаганга өлеш юк, биләмчегә — бар, дигән халык. Чөнки биләмче яңа бер сүз ишетеп кайта. Димәк, үзеннән-үзе мәгълүм, пожар каланчасы, каравыл өе, колхоз кәнсәләре янында әйләнүчеләрнең һәммәсе дә корыны бушка әйләндерүче түгел. Алар арасында башлары йомры, акыллары түгәрәк булганнары да бар.

Гыйбадулла Ядкаров, халык телендә йөргән кушаматы белән әйткәндә, Бүре Бадул, кыш көннәрендә, умарталыкта эше юк чагында, атна-

сына бер-ике мәртәбә әнә шул халык җыела торган урыннарны әйләнеп кайтуны үзе өчен зарури бер нәрсә итеп саный иде.

Бармаса да булыр иде югыйсә — ил-көн хәбәрләрен ул гәзиттән укып, радиодан тыңлап та белә ала, иллә мәгәр бара: үз колагы белән ишетәсе, халыкны үз күзе белән күрәсе килә.

Гәзиттән уку — бер хәл, халыктан ишетү — бөтенләй башка.

Гыйбадулланың күңел сизгер — җилнең кай тарафлардан искәнен аңлый. Халыкка рәхәт тормыш бирәбез диләр. Бирәләр. Сукыр түгел-ләр, күрә, рәхәт тормыш бирер өчен нәрсә кирәк? Икмәк. Электр уты. Машиналар. Әнә шул эшләргә каршы төшүче, замана куласасына таяк тыгучылар да бар икән. Гәзитләрдә шул корткычларны халык дошманнары дип язалар. Илнең бик олы, бик явыз дошманнарына инде суд ясаганнар, хөкем карары чыгарганнар. Монысы аңлашыла Гыйбадулла Ядкаровка, ул үзе дә андыйлар белән теге заманнарда Кама иделендә үлем баржалары йөргән чагында, урман тулы партизан учаклары үрләгәндә, аз көрәшмәде. Димәк, әле ул явызлар бетмәгән, димәк әле алар зуррак урыннарга барып оялаган. Кабыгын алмаштыра торган җыланнар кебек, безнең яклы булып йөргәннәр, матур-купшы сүзләр сөйләгәннәр, үзләре итәк астыннан ут йөрткәннәр...

Әйе, бу хәтлесе аңлашыла Гыйбадулла Ядкаровка. Җылан — сазлыкта ятса да җылан, куенга салсаң да — җылан. Чага ул сине, чага. Үтерергә, бетерергә, сытарга кирәк аны.

Әнә олы җыланнарын инде бетерәләр. Асалар. Кисәләр. Аталар.

Ләкин аларның тамырлары калмый микән? Җылан балалары юк микән илдә? Менә шулар инде ничә айлар Гыйбадулла Ядкаровның җанына тынгы бирмиләр. Менә шулар хакында ул-бу юкмы икәнен белер өчен Бүре Бадул өеннән чыга: карагыл өе, пожар каланчасы, амбар-келәтләннары нинди сулыш белән сулый? Нинди хәбәрләр халык колагына килеп керә? Керсә — халык шуны ничек бәяли?

Сагаеп яши Бүре Бадул. Куаклар арасына поскан бүре кебек, корбан көтеп яши.

Көннәрдән беркөнне аның колагына килеп ирешә: Пәнҗәрнең карт укытучысы Герасимовны кулга алганнар. Заманында поп булган, совет чыккач, поплыгын ташлап, балалар укытырга керешкән. Әммәдәки халыкка каршы астыртын эш эшләп яткан икән явыз...

Бу хәбәр Бүре Бадулның эченә утлы күмер салып куйган төсле була. Бу хәбәр пешерә Бадулны, уйларга сала, йокысыз итә.

Һәм ул хәзер халык җыела торган урыннарга атнасына бер-ике мәртәбә генә түгел, көн саен чыга.

Бүре Бадулның күңелендә Айдарныкыларга карата бик күптәннән төйнәлеп куелган бер төен бар. Бәлкем, шул төенне чишәр вакыт килеп тә җиткәндер? Бәлкем, вакытны ычкындырмаска, форсаттан файдаланып калырга кирәктер?..

Әле теге заманнарда, революциягә кадәр үк, малайлар ат чабыштырган чакта, Садыйк картның Чаптар биясен унике яшьлек улы Солтан беренче иттереп, хәтта Таминдар байның Тимеркүген дә уздырып китергәч, Бадул бияне үзенә алырга теләде. Бәясеннән тормыйм, диде. Хәерче тәкәббер Садыйк сатмады Чаптарны. Саткан булса, туганнан туган энесе Нухның битенә сугылган камчы эзе дә, Нухның аттан егылып төшеп калуы да онытылачак иде. Юк, сатмады хәерче тәкәббер, шуның белән горур табигатьле, бөркет йөрәкле Гыйбадулланың канына тоз салды, күңеленә авыр бер төен укмаштырды.

Хурлыкны җанында озак йөртергә яратмый иде Бадул. Иң әүвәл Садыйкның Актырнагын — янына берәүне дә китерми торган усал этен, акаеп караган бер карашы белән буйсындырып, үз лапасларына алып чыкты, чалгы пычагы белән суйды, тиресен лапас өрлегенә элеп куйды. Һәм ул Садыйк малае Солтанның, өрлектәге эт тиресен карап, тыела алмыйча елавыннан җанына юаныч тапты.

Аннан соң күп сулар акты. Шаукымлы Шәяхмәтне Бадул үлемнән коткарды. Заманасы шулай иде — революция яклы икәнеңне гамәлең белән күрсәтергә кирәк иде. Алга таба Шаукымлының эшләре гел үргә үрмәләде. Аның Гыйбадуллага кирәге дә чыгып куюы бар бит әле. Кыенга килгән, таш кыяга килеп терәлгән чаклар була. Айдар Шәяхмәте булышыр, минем изгелегемне онытмас, дип фикер йөртте Бүре Бадул. Шаукымлы нишләде? Якладымы Бадулны? Яклар сиңа — бар! Түрә булды да чабатасын түргә элде. Кара наган селкеп, өяз муллалары белән попларны сагайсский биеткән Нажия-башкисәрдән мыскыл иттерде. Тукта, торып тор, ул атаманны хәзер Пәнҗәр төбәгенә күчкән, диләр. Якасына ромбиклар да таккан, имеш.

Бадул участковый Уразаеваның өченче ел аны стенага терәп, колак яныннан уңлы-суллы пуля чатырдатканын исенә төшерде. Аркасына салкын йөгерде, теш казнасы кысылды. Ләкин ул Нажиягә каныгырга исәпләмәде. Милициягә бәйләнеп, кемнең уңганы бар! Бер булмаса, бер туры китерер. Ул чагында инде кансыз Нажиядән әҗәленне көт тә тор. Әгәр дә мәгәр син аның гаделсезлекләре хакында түрәләргә язып бирсәң икән, синең жалуыңны ул башкисәрнең үзенә күрсәтмәсләр дип, кем ышана ала?

Хәер, Бүре Бадулның участковый Уразаевага канығырга теләмәвенең сәбәбе ул гына да түгел. Бүреләр нәселенә хас куркусызлыкны, ныклыкны күрә ул аның холкында, аның шулай кылануын хәтта вакыт-вакыт дөрес дип тә таба. Юк, Нажия Уразаева — ул төбәп ата торган мишень түгел.

Уйлары белән ул Солтан Айдаровка күчә.

Ул аны яратмый, өнәми. Шул чучка гына малайның, кайчандыр Бадулдан куркып, капка янына да килә алмаган малайның, Казан хәтле Казанда, Җир төзүчеләр техникумында башлык булып утырган чакларында ул аңардан көнләшә иде. Солтан эшеннән куылган, партиядән чыгарылган дигән хәбәрне ишеткәч, өстәвенә бу эшнең аның энесе Нух Галләм кулы белән эшләнгәнен белгәч, күңеле канат какты. Теге чакта, ат чабышы үткәргәч, күңелгә төйнәп куйган төен чишелә башлады дигән сүз. Солтан җәзасын алды.

Партиядән чыгарылган адәмнең кемгә кирәге бар? Җитмәсә, ул әле үпкә чире дә эләктергән имеш. Корык-корык йөткереп йөрер дә, көннәрдән беркөнне кәкре каен астына барып керер.

Аңа, ауга чыккан Бүрегә, табыш булып Айдарның Шәяхмәте кала түгелме? Ләкин монысы куркынычрак. Бугазына барып ябышырсың, ә ул үзе синнән көчлерәк булып чыкса? Юк, анысына хәзергә кагылмаска, анысын әйләнебрәк узарга кирәк.

Айдарлар нәселенең туган-тумачасына күчә Бүре Бадул.

Ужил урманында, диләнке кискән чакта, Чишмәбай белән килеп чыккан сугышу-ызгышуны да, шуның аркасында Пәнҗәр «кутузка»сында ике ай утырып чыкканын да онытмаган иде Бүре Бадул. Хәнифәнең Гыйбадулланы көпә-көндез, ил-көн алдында рисвай итүен, аны Чишмәбай белән алмаштыруын да күңеленә таш итеп салып куйган иде.

Тотынсаң — менә кемгә тотынырга кирәк.

Чишмәбай кайтканчыга тикле Гыйбадулла Ядкаров Зартугайның күз өстендәге кашы булып яшәде. Аны телдән төшермиләр, аның булдыклылыгына, таза-баһадирлыгына таң калалар; берәүләре аны ихтирам итә, икенчеләре аңардан курка иде.

Көнлекче Хисмәйнең гомер буе ялчы булып яшәгән, баштанаяк тегермән онтасына буялып йөргән малае, герман әсирлегендә черисе мөртәт, Зартугайга кайтып төште дә, икеме-өчме ел эчендә Бүре нәселен бер кырыйга сыпырды да атты. Зартугайның бер кашык су белән йотарлык Хәнифәсе — аның куенында. Тегермән буендагы Олы Чишмә — аның киртә-курасында. Зиреклектәге таң кошлары аның өчен сайрый, чишмәләр аның өчен ага. Авылның иң яхшы балта осталары алты почмак-

лы, чарлаклы йортны кемгә салып бирде? Көнлекче Хисмәй малаена! Күбрәккә китә түгелме бу?

Боларына да түзәр идең, район газитендә инде ике ел рәттән Каюм Хисмәевне мактыйлар. Аны сорап, күрше авыллардан кешеләр килә — колхоз рәисләре.

Ике ел эчендә Чишмәбай егерме биш кешелек бригада оештырды. Тегермән янын янә дә йомычкага күмеп, буа янына су белән сүга торган ындыр табагы житештерде — сугу машиналарын да, җилгәргечләрне дә куласага төшкән су әйләндерә. Шул ук су үз юлы белән тегермәнне әйләндерергә китеп бара.

Зартугай кешеләре килмешәклектән кайткан Чишмәбайны телдән төшермиләр.

Чишмәбай биш йөз баш ат сыярлык абзар сала. Ужил урманыннан, Бояр урманыннан, Тугызбуй якларыннан олаулар бүрәнә ташый. Тарантаска аргамак җиккән түрәләр, киерелеп утырып, Чишмәбайның эшен карарга киләләр.

Өзәргә, өзәргә, үз балтасы белән чабып өзәргә кирәк моны!

Тота-каба гына булмый. Җаен табарга, нечкә җиреннән, җан җиреннән эләктерергә кирәк.

Болай уйлавы юкка түгел Бадулның. Чишмәбай ялчы булган. Бар, бәйләнеп кара. Чишмәбай егерме беренче елны ачтан үлгән Рамазан солдат кызын өч баласы белән хатынлыкка алды. Берничек тә бәйләнә алмыйсың. Совет власте — юксыллар ягында. Герман пленында ул нишләгән? Шул көннәренә ничегрәк карый? Менә шуны беләсе иде.

Гыйбадулла Ядкаров бер нәрсәне белеп алды.

Элекке елларны азрак сөйләшә, күбрәк эшли торган Чишмәбайның, ил-көн алдында абруе арткач, теле дә чишелгән икән. Әсирлектә, аннары башкортлар арасында үткәргән көннәрен яшерми-нитми сөйли икән. Ул сөйләгәннәрне бригада егетләре авызларын ачып тыңлый икән.

Чишмәбай ниләр сөйләгәнне бригада егетләреннән сорашу шик уятачак. Анысын эшләмәде Бүре Бадул. Икенче бер әмәлен тапты.

Хәйләкәр һәм сак эш йөртә торган кеше буларак, җәмәгать каралтылары салына торган урынга ул төпчек улы Мифтахны йомычка алырга җибәрде. Алты пот бодай сыешлы арыш капчыгы белән чәрәшә-чәрәшә чи йомычка күтәреп кайткан унике яшьлек улын бик хәтәр мактады, капчыкны күтәреп карап, тел шартлаткан булды.

— Анда ничек соң, улым, синең йомычка алып киткәнеңне күрүченитүче булмадымы?

— Күрсәләр ни! Анда бөтен авыл ташый. Персидәтел Миңнулла үзе кушкан бит ташырга. Абзар яны чеп-чиста булсын ыштубыты! — дип әйткән.

— Шулаймыни? — дип гаҗәпләнде әтисе.— Тагын барасыңмы соң, улым?

— Бармый сиңа бик! Шайнурлар, Сәгъдиләрдән кимме әллә мин? Алар әнә әниләренә кыш буена корылыкка җитәрлек йомычка ташып куябыз, диләр.

— Ә син?

— Ә мин нәрсә? Мин дә ташыйм. Түлке, әти, Шайнурларныкы төсле фәнир букча алырсың, яме. Шәмәхә буяу белән чәчәк сурәте төшергәнне.

Гыйбадулла абзый улы Мифтахка чәчәкле фанер букча алырга вәгъдә итте, ә тегесе, үләрен-калырын белмичә, көннәр буе йомычкага йөгерә.

Әтисе улының эшен әледән-әле карарга чыга. Шунда беррәттән сораштыра: абзарны ничек салалар? Персидәтел Миңнулла андамы? Балта осталары нәрсә сөйли? Олаучылар нишли?

Фанер букча вәгъдә ителгән Мифтах, берсен-бер калдырмыйча, күргәнне-ишеткәнне, түкми-чәчми, әтисенә кайтарып аудара.

— Чишмәбай абый без колхозга биргән кара айгырның ялын сыйпый. Бәләкәй бездә атлар, нәселле түгел ди. Менә ул Германиядә ат дисәң дә ат, ичмасам, ди. Бер тартканда безнең ун ат берьюлы тартканны эһ тә итмичә алып китә, андагы йөк атларының тоягы да аш табагы чаклы бар ди.

— Кара син аны, ә? Шулай дип әйтәме? Аш табагы чаклы диме? — Гыйбадулла абзаң битен баскан ала-кола каты төкне учы белән каплап елмая.— Башкалар шуны тыңлап утырамы?

— Тыңлыйлар.

— Чынмы? Авызларын ачып тыңлыйлармы?

— Авыз ачып тыңлыйлар, баш селкәләр.

— Силсәвит Мәрдән дә тыңлыймы?

— Ул юк бит анда.

— Кем бар соң?

— Каравылчы Әфләтун, тегүче Камали абзый, Түбән очның Сибгатулла малае Кара Шәйми, Бөкере Гафият, аннан ары килеп, Аксак Әхмәтҗан, хисапчы Шибай...

— Шибай да килгәнмени?

— Килгән. Мактануын күрсәң, эти! Персидәтел әйтә, әгәр дә мәгәр быел шушы ат кәнүшниләрен салып бетерә алсагыз, бүләккә башмак тана бирәм, бөтен колхозны җыеп, бәйрәм иттерәм дип әйтеп әйтте дигән була.

— Кара син аны, ә? Башмак тана бирәм диме? Бәхет баса икән алайса Чишмәбай абыеңны,— ди Бүре Бадул һәм, ашыгып, өйгә кереп китә...

Карары нык аның: Хисмәев Каюм Советка каршы коткы тарата. Үз кул астындагы балта осталарына, такта яручыларга, бүрәнә ташучыларга ул дошман сүзе сөйли.

Моны кәгазьгә төшерергә кирәк. Кәгазь алдан йөри торган замана.

...Ике атнадан Зартугайда хәлләр үзгәреп китә. Иртә таңнан алмаш-тилмәш тукылдаган балта тавышлары тынып кала. Бу ни хәл бу? Әллә Чишмәбай авырып киткәнме?

Олы Чишмә буендагы чарлаклы йортыннан беркая да чыкмый торган, көннең-көн буе ишле балаларын һәм тавык-чебешен, мал-туарын карап кына көннәрен уздыра торган Хәнифә түтәй авылга күтәрелә, күршеләренә кереп, елый-елый сөйли. Җиде төн уртасында тегермәнгә кара машина килгән: янтыкларына наган аскан ике кеше Каюмны алып киткәннәр. Нигә икәнен дә, кайчанга хәтле икәнен дә әйтмәгәннәр.

Зартугайлар аптырауда. Нинди генә гаепләре булды икән соң? Әллә, ходаем, Герман җиреннән шпион булып кайтканмы? Тәүбә-тәүбә, әстәгыфирулла, үлмәсәң, әллә ниләр ишетерсең әле...

Түбәләре ябылып, капкалары куелган берәр йөз метр озынлыгындагы өч абзарда, Чишмәбайны юксынып, атлар кешни. Калган ике рәт абзар, түбәсе ябылмаган килеш, яралы кош сыман моңаеп утыралар.

Ул тирәдә эш тукталды.

Анда олау-олау бүрәнә китерүчеләр дә юк. Йомычкага килгән бала-чаганың чыр-чуы да ишетелми.

Авыл кинәт юашланды. Давыл көткәндәй, тынып калды.

Кешеләр бер-беренә керми, бергә җыелган урыннарда сөйләшми торган булды. Хәвефле, сагаюлы тормыш белән яши башлады.

Тагын бер айдан авылда дивана Майттыпыра пәйда булды. Ике ел инде аны күргәннәре юк иде. Ул кайдадыр Тугызбуй якларында йөри дип сөйлиләр иде.

Табигать рәнҗеткән һәрбер кешене халык кызгана. Майттыпыра диванадның югалуын да кызганганнар иде. Кайтып төшкәч, ничектер җиңел сулап куйдылар.

Көне буе сүз дивана турында гына барды.

Көндәлек мәшәкатьләреннән арып-талып, авыл халкы саташулы йокыга талгач, урамнар буйлап кычкырып йөргән бер тавыш ишеттеләр.

Бүре Бадуллларда ачы бал белән сыйланып чыккан Майттыпыра капкаларга юан артыш таягы белән суга-суга кычкыра:

— Майттыпыралар! Имансыз кавемнәр! Җиде бабаларыгызның чардуган буралары череп беткере! Кадалгырлары! Кая куйдыгыз минем Чишмәбаемны! Табып китерегез минем Чишмәбаемны! Майттыпыралар! Денсезләр! Чишмәбаемны табып китерегез!

Күпне күргән авыл картлары аны тынычландырырга, өйгә кертеп яткырырга итәләр. Ләкин ул аларга буйсынмый, аларның кулыннан холыксыз ат кебек тибенеп ычкына, капкаларга суга-суга, акырып елый-елый, үзенең Чишмәбаен таптыра иде...



## II

1937 елның июнь ахырларында Солтан Айдаровны Җир төзүчеләр техникумының завхозлыгыннан чыгардылар.

Солтан белә: моңа, әлбәттә, аралары суынганнан соң, Гөлмәрьямнең аның өстеннән директорга һәм партоешма секретарена әләкләп торуы да ярдәм итми калмагандыр. Ләкин төп сәбәп ул түгел. Көндәлек матбугатта — үзәктән килгән газеталарда да, республика газеталарында да — халык дошманнарын фаш итү бара.

Мәгълүмдер ки, эшләр болайга киткәч, партиядән чыгарылган Айдаровны техникумда завхоз итеп тотарга башына тай типмәгән! Эшсез калу янә дә сәламәтлеген какшатты. Ул ютәлләп йөри. Кәефе бик сүлпән, бите-башы көл төсле.

Инде эш урыны да булмагач, Наркомземнан арзанлы хакка путевка алу юлы киселде. Хәзер инде путевканы аларның икесенә — Нурия белән Солтанга эзләргә калды.

Үтенеп-гозерләнеп, йомры телен ясмык итеп, кая гына бармады Солтан — файдасыз. Көне-төне чаба торгач, ул хәлсезләнде, урын өстенә ятар хәлгә килде. Хәзер үк, бүгенле-иртәле Кырымга чыгып китмәсә, аның аяк сузуы да ихтимал иде.

Булган барлык акчасын җыеп, булмаганын профессор Майскийдан алып торып, Нурия ирен көч-хәл белән курортка озатып җибәрде.

Гомердә булмаганча авыр көннәр килде Нуриягә.

Гаиләне ач итмәс өчен, алны-ялны белми эшләргә, институтка керүче яшьләрдән икешәр смена имтихан алырга кирәк иде.

Башлары әйләнгән иде аның. Иренә хат язарга да вакыты юк иде. Анысын Солтан исенә төшерде. Ачуы чыккан чакларда бик тә холыксыз була торган абзыебыз, хатынының кырыкка ярылырга җитүен дә белми, аңардан хат килмәгәнгә үч итеп: «Казан хәлләрен Гөлмәрьям хатыннан укып белдем»,— дип язган иде.

Нурия хурлануыннан утырып бер елады. Аннары әнисе Шәмсенисаның кайчандыр, Нурия әле бала гына чакта да, үсеп житкәч тә, иргә чыккач та, сабыр булырга өйрәтеп әйткән сүзләрен искә төшерде дә, ничектер тынычланып китеп, пәрәмәч пешерергә, бернинди ямьсез нәрсәләргә карамастан, үзенә һәм кызына бәйрәм ясарга ниятләнде.

Барысы әзер булып, чәй эчәргә җыенып кына торган чакта, каты итеп ишек шакыдылар.

Бик аптырап, тагын нииндидер күңелсез хәбәр ишетүдән куркып, ишекне барып ачса, ни күрсен: каршысында чачактан-чуктан гына киенгән, битенә иннек-кершәннәр ягынган... Гөлмәрьям басып тора.

Исәнләштеләр.

— Керегез,— диде Нурия.

Керде Гөлмәрьям.

— Ни йомыш? — дип сорады Нурия; туп-туры сорады, чөнки күз бәйләш уйнауны мәгънәсезлеккә санады.

— Миңа Солтан Садыйковичның адресын бирә алмассызмы? — диде Гөлмәрьям, ишек төбендә таптанып.

— Ярый, бирермен,— диде Нурия.— Тик, сеңлем, безнең халыкта өйгә үз аягы белән килгән кешене бер чынаяк чәй дә эчермичә чыгару гадәте юк. Мин ял көне итеп пәрәмәч пешергән идем, без башта утырып чәй эчик, аннары адресны язып алырсыз,— диде.

Табынны озаклап, бөтен шартын китереп әзерләде Нурия. Гөлмәрьямнең әледән-әле кул сәгатенә караштырып алганын күргән саен озаграк мыштырдады. Ниһаять, утырдылар. Нурия чәйне гәрәбәдәй алтынсары итеп, куе итеп ясады. Техникум хәлләрен, Гөлмәрьямнең әнисенең хәлләрен, Свияжскида көннәрнең ничегрәк торуын, Иделдә халыкның су коенамы-юкмы икәнен озаклап, тәфсилләп, берсен-бер калдырмый сорашты. Кыстый-кыстый, ягымлы сүзләр әйтә-әйтә чәй эчерде. Шуннан соң ул ягымлы-кунакчыл кеше булуын бер якка куйды. Әрсезләнеп килеп йөргән бу таш курчакны тәнәтергә, Солтаннан гомерлеккә биздерергә кирәк иде.

Инде тәмам юашланып калган Гөлмәрьямгә Нурия кинәт кенә ире Солтанның Кырымнан язып җибәргән хатын чыгарып тоттырды. Кызыкайның хатны укыган чакта кызара баруын, аннары шул тоташ кызыллыкка аксыл тимгелләр бәреп чыгуын врач-психолог күзәтеп утырды.

— Күрдеңме, хөрмәтлем, акка кара белән язылган? Гөлмәрьямнән хат алдым дигән минем ирем. Ә сез, миңа килеп, комедия уйнап йөрисез! Сезнең әртисләнүегез бер дә ошамый миңа. Без бит бергә укымадык, егетләр кочарга да икәүләп барганыбыз юк. Шулай булгач, сез миңа килеп йөрмәгез инде. Үтенеп сорыйм сездән: бу ишекнең кай якка таба ачылганын онытыгыз.

Гөлмәрьямнең комедия уйнавы түгел иде бу. Аны Айдаровның адресын белергә техникумнан җибәргәннәр, чөнки техникумда хуҗалык эшләре буенча ревизия бара иде.

Гөлмәрьям үзенең нинди кыен, нинди ялган хәлдә калуын аңлаудан каушады, керфекләрен челт-челт йомгалап, Нурия Уразаевага беркавым карап торды.

— Минем Солтан Садыйковичка хат язганым юк...— диде көч-хәл белән.— Ул сезне алдаган, сезгә үч итеп язган...— Гөлмәрьямнең иреннәре тетрәнде, ул каршысында басып торган мәһабәт, олысымак гәүдәле ханымның аңа ышанмавын, ә үзенең исә көчсез-ярдәмчесез булуын аңлады, чөнки күптән түгел булган җилбәзәклеге аңа ышанычны бетергән иде.

Ул керфек төпләренең кинәт җылынып китүен тойды, авызы чалшайды, сөрмәле күзләреннән бәреп чыккан үкенечле, ачы күз яше, битендәге иннек-кершәннәр арасыннан юл салып, ирен читләренә агып төште.

Бераздан ул айныды, ашыгып, күзендәге яшен сөртте, һәм, башын бик югары тотып, Нурия ханымга әйләнеп тә карамыйча, чыгып китте.

Аңардан соң Нурия бик озак уйга калып утырды.

Бәлки, ул ялгышадыр? Гөлмәрьямне юкка рәнҗеткәндер? Ләкин инде узган эш узган, аны кире кайтарып алып булмый, Солтанына, аны шундый да кыен хәлгә китереп куйган мәрхәмәтсез иренә, хатынының хәлен аңламаган эгоист иренә хат язарга дип, кәгазь-каләм алып килде.

### III

Казанга Әхнәф килеп төште. Сап-сары чәчле, озын-чандыр гәүдәле, авыл малайларының күбесенә хас булганча, тартынучан бу үсмерне Нурия башта танымады, чөнки аның Әхнәфне беркайчан да күргәне

юк иде. Солтанның иң олы абыйсы Мөхәммәтша, завод эшчесе, пенсиягә чыкканчы, гомерен Ижевск каласында, корал кою заводында үткәргән, табигый, Әхнәф тә шунда үскән иде.

Инде менә алар Зартугайга кайтып төпләнгәннәр.

Солтан, әле курортка киткәнче, туганнан-туган энекәшен, хат язып, Җир төзүчеләр техникумына укырга керергә чакырган икән.

Соңгы елларда шактый ук кыю, шактый ук ирекле-мөстәкыйль тормыш алып баруга күнеккән, тартыну-уңайсызлану сыйфатларын бер якка сыпырып аткан Нурия Уразаева салам чәчле, буйчан егетне күргәч, әллә ничек менә уңайсызланып калды, үзе дә сизмәстән дулкынлана башлады.

Уңайсызлану һәм дулкынлануының сәбәбен ул бераз соңрак аңлады. Кулына фанер чемодан тотып, аркасына юл капчыгы асып, ишек төбендә торган үсмер егет Солтанның егет чагын хәтерләтә икән ләбаса! Очлаеп килгән ияк, аксыл-саргылт төстәге кылдай каты чәч, әчү ташы төсле зәңгәр күзләр, өзеп-өзеп кенә, кирәген генә әйтү, дөресрәге иң кирәкле бер-ике сүз әйткәч, тынып калу — әллә кайчангы заманнарны, революция давыллары белән Нурия йөрәгенә сеңеп калган Солтанны искә төшерәләр иде.

Алар бик тиз дуслаштылар. Җиңги белән каениш мөнәсәбәте түгел, апа белән энесе арасында була торган туганлык мөнәсәбәте урнашты алар арасында.

Әхнәф, бер яктан өй эшендә менә дигән булышчы булса, колхоз базарыннан бәрәңгесен-мазарын алып кайтса, икенчедән, ул Җир төзүчеләр техникумыннан Нурия өчен саф һавадан да болайрак кирәкле булган хәбәрләр дә алып кайтты.

Солтан Айдаровны техникум коллективы ихтирам итә. Бер ишеләре, директорыбыз бигрәк яхшы иде дип, икенчеләре, аңардан да булдыклырак завхоз юк иде дип сөйлиләр имеш.

Нурия апасы Әхнәфнең чын күңелдән абзыйсы өчен сөенгәнен күреп тора, әмма ул аның тәҗрибәсезлеген дә белә.

— Син, энем, Әхнәф, анда үзеңнең Солтан Айдаров энесе икәнлегеңне әйтә күрмә тагын. Беләсеңме, тычкан таяк белән йөргән замана, директорлыктан киткән абыеңа үч итеп, сине укырга алмый куюлары да бик ихтимал,— дип киңәш бирде ул аңа.

Яшьлекнең үз законы үзе белән!

— И-и-апа! Алмасалар тагын! — диде Әхнәф. Озак кына сүзсез утыргач, әйтте: — Алмасалар! Математика укытучысы әйтә, мин сиңа «бишле»не квадратта итеп куям. Ничек кенә булса да югары мәктәпкә үрмәләргә тырышырсың. Синең, ди, математикадан сәләтең бик зур, ди. Нишләрмен икән, апа, ә? Дөрес әйтә микән ул?

— Мин, үскәнем, сиңа ул хакта бер киңәш тә бирә алмыйм. Менә абыең Кырымнан кайтыр, аның белән бергәләшеп киңәшерсез, яме,— диде Нурия.— Абыең синең бик акыллы кеше бит. Башы бик йомры аның. Математика, мөгаен, Айдарныкыларның барысында да бардыр. Исәпләү сәләте, башлы булу һәммә кешегә дә бирелмәгән.

Әхнәф, апасы әйткәннәргә тын гына сөенеп, тыңлап утыра.

Луиза белән Санияләй биләмнән кайттылар. Нурия, йөзе алсуланыбрак киткән кызын, күтәреп алып, Әхнәф абыйсына күрсәтте:

— Менә, абыкаем, без нинди булып үсеп киләбез. Бик җитез идек, йөгереп туймыйдыр идек. Безне бер явыз черки тешләде — Анофолез черкие. Малярия таратып йөри икән ул мөртәт. Аппетит бетте, абыкаем. Аппетит юк! Йәле, тәти бәтием, пепсин эчеп алыйк әле без. Әллә соляная кислота да ярап торырмы?

— Кисата, кисата! — диде Сания, башын селкеп.

Нуриянең дуслары, туганнары килгән саен сорыйлар:

— Нишләп бик бәләкәй бу бала? Әллә сез аны ашатмыйсызмы? Әни кешегә моны ишетү авыр. Шулай да бирешмәскә тырыша:

— Маляриясеннән арынгач, үсәр әле,— ди.

Нуриянең башы тубал булган. Институтта имтихан аласы, иренә хат язасы, өен кайгыртасы бар. Нәнкесе Луиза, кызыкае Сания белән уртак тел табып яшисе бар. Көн саен, сәгать саен кайгыртырга кирәк баланы. Аз гына читләштеңме — ул синнән бизә. Аны башка дөнья, башка мохит чолгап ала.

Кайчандыр сабый чакларында ул суык суда йөзгән бака балаларын учына алып, җылытып йөри, идәнгә егылып һәлак булган куян баласы өчен кайнар яшь түгә иде. Инде менә докторлык диссертациясенә кирәк булгач, ул фәнни эксперименталь эш өчен әллә ничә мәчене корбан итте.

Әхнәф Җир төзүчеләр техникумына бик уңышлы бирде сынауларын. Абыйсы Солтан Кырымнан кайтканда, ул Свияжскига студентлар торагына күчеп киткән иде инде.

Солтан Кырымнан азмы-күпме тазарып, түгәрәкләнеп кайтса да, җанының тынычсызлыгыннан, эшсез калу газабыннан бик тиз ябыкты. Яңаклары суырылды, ирен читләренә калын-калын ике сызык ятты. Күзләре, кайчандыр җете зәңгәр булган, чаткыланып янган күзләре, төссезләнә башлады.

Нурия боларны күреп йөри, ләкин иренә берничек тә ярдәм итә алмый. Иренең сары кашлары бөркәп торган, тоныклана башлаган күзләрендә вакыт-вакыт ниндидер моң көйрәвен күргән чакта ул үзен кая куяр урын таба алмый.

Кайгы-хәсрәт килсә, кемгәдер таянырга кирәк.

Солтанның бердәнбер таяныр кешесе — Нурия. Аеруча моңсу, сагышлы минутларда ул Нуриясенең кулын тотып, тик кенә утырып тора, яки әкрен генә, революцион җырлар җырлаган кебек кенә итеп моңая:

Тамчылы гөл чәчәкләре кебек
Башларыңны түбән иясең.
Кайнар башың салып күкрәгемә,
Ай, авыр шул, бәгырем, диясең...

Шушы авыр минутларда җырның сүзләре дә, җаннарны айкап ала торган көе дә, хәсрәтле башны түбән идерә. Җыр беткәч, өй эче тыптын булып кала.

Нурия, аның кайнар кулын үз учында тоткан көе, күзләренә мөлдерәп карап әйтә:

— Син, әтисе, пенсиягә чык инде. Чирле килеш юк-барны уйлап, кайгыга батып утырганчы, азмы-күпме пенсияңне алырсың да өйне карарсың, ичмасам...

Нурия белән танышлыклары хакына Солтанны бик тырышып тикшергән тубдиспансер врачы Анна Аркадьевна да Нурия сүзен кабатлады. Аңардан да арттырыбрак әйтте бугай әле:

— Йә сез, күгәрченем, Солтан Садыйкович, хәзер үк эштән китеп, пенсионер буласыз, ягъни үзегезне үзегез саклап каласыз, йә аяк өсте егылып үләсез.

Солтанның үпкә-бавырларын актарып, эченнән ниндидер кайнар дулкын узды. Шулай ук беркемгә дә кирәге юк кешегә әйләндемени инде ул? Иске киемне ташлаган кебек пенсионерлар арасына ыргыталармыни аны?

«Юк,— диде аның эчкәрге үҗәтлеге.— Юк! Булмас! Китсәм дә, мин вакытлыча китәрмен! Бер елга. Нибары бер елга! Аннары сафка, тагын сафка! Партия әгъзасы булуы ачыклану белән, тагын сафка!»

Тиешле документларны алырга Наркомземга ул үзе бармады, гарьләнде, күңеле тартмады, ничәмә еллар күңеленә юшкын булып утырган үпкәсе, рәнҗеше кузгалды.

Нурия китте документларны юлларга.

Кадрлар бүлеге мөдире Зурганов Нурияне, кашларын җимереп,

үзенә нинди дә этлек эшләгән кешене каршылагандай каршы алды. Бит тиресе сөягенә ябышкан, чамасыз чандыр гәүдәле, шуңа булса кирәк, кыйммәтле шевиот костюмы өстендә капчык кебек кенә эленеп торган ир уртасы кеше сүзне кычкырып башлады:

— Ник килдегез безгә? Котылыр куыш эзләп килдегезме?

Нурия каушамады, үзенең никадәрле итагатьле, ә тегенең никадәрле тәрбиясез икәнен күрсәтү өчен, чамадан тыш сабыр һәм әкрен тавыш белән ник килүенең сәбәбен аңлатып бирде.

Зургановның чигенергә исәбе юк иде. Кычкырудан туктады ул туктавын, әмма ныклыгын танытыр өчен, сүзне теш арасыннан кысып чыгарды:

— Бернинди белешмә дә бирмим. Кем сезнең ирегез? Партиядән куылган бер адәм! Андыйларны тереләй җиргә күмәргә кирәк. Аларның исемен халык хәтереннән сөртеп ташларга, җуярга вакыт!

Нуриянең каннары кайнап чыкты. Теш казналары кысылды. Ләкин көчсезлекне, мескенлекне сиздерергә ярамый иде. Зәңгәр берет астыннан ташып чыккан кара бөдрә чәчләрен рәтли-рәтли, сабыр булыр өчен, барлык ихтыярын туплап:

— Ярар, Зурганов иптәш. Ярар. Тиешле белешмәне мин совет суды аркылы алырмын. Анысы — авыр эш түгел. Ә ни өчен сез миңа кычкырасыз? Ирем минем — гражданнар сугышы герое. Дөньяда Мәскәү бар, ул кемнең кем икәнен аерыр. Сезнең кем икәнегезне дә әйтеп бирер. Гадәттә, артлары чиста булмаган кешеләр бугаз киерә торган булалар,— диде.

Гаҗәп хәйран тамаша: әле генә әллә кем булып бусарынган Зурганов кинәт йомшап китте. Теленнән гафу үтенмәсә дә (ике хезмәткәре карап тора иде!), җылынып киткән күз карашы белән утырырга ымлады. Нинди белешмә кирәклеген сорашты, үзенә карап торган егетләргә кыска гына итеп әйтте:

— Языгыз белешмә!

## IV

Солтан, пенсия чыгып, берничә ай узуга, финанс-экономика институтына читтән торып укырга керде.

Нурия Уразаева да инде бу вакытта докторлык диссертациясенең практик ягын тәгәлләп, кирәкле препаратларны җыеп, мединститут рәссамы Ида Израиловнаның микроскоптан карап ясаган рәсемнәрен туплап куйган иде.

Тагын бер атнадан кафедра җитәкчесе Майский ике профессорны — Кабулов белән Голосовны кафедрага чакырды. Уразаеваның докторлык диссертациясен ашыктыра төшәргә кирәк иде. Хезмәтнең практик өлеше докторлык диссертациясе өчен әзерме — әнә шул кызыксындыра иде галимнәрне. Шуңа күрә иң элек «шәхси күзәтү» бүлеге хакында Уразаеваның информациясен тыңлап, күргәзмә әсбапларын карадылар.

— Йә, ничек, иптәшләр? — диде Майский, өстәл янына утырышкач.

Ул үз фикерен әйтергә ашыкмады. Авторитеты белән башкалар фикерен басып калдырудан курыкты.

— Материалы җитәрлек. Препаратларның да, иллюстратив рәсемнәрнең дә сыйфаты яхшы. Теоретик өлешен язарга да киләсе елга, ягъни 1938 елның апрелендәме, маендамы докторлыкны якларга әзерләнергә кирәк,— диде Кабулов.

— Ә сезнеңчә ничек, Николай Григорьевич? — дип, кафедра мөдире профессор Голосовка төбәлде.

— Кабулов фикере белән тулысынча килешәм,— диде Голосов.— Нурия Аббасовнаның эшләү сәләте мине сокландыра. Авыр гаилә язмышы да аны эшеннән туктата алмады. Профорглык вазифасы да эшләү

темпын киметмәде. Әлбәттә, болар барысы сәламәтлек бәрабәренә эшләнә. Без моны беләбез. Шунлыктан диссертацияне яклау вакытын максимум якынлаштырырга кирәк.

Майский күз карашын Уразаевага күчерде:

— Йә, диссертант үзе ни әйтә?

Нурия дәшмәде. Колаклары ут кебек кызыша башлавын тойды.

— Ни булды Сезгә, Нурия Аббасовна? — диде Майский аптырап.

Нурия, һәммәсен гаҗәпкә калдырып, башын аска иде, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән:

— Мин апрель аенда бәби табарга җыенам... — диде.

Галимнәр кинәт — өчесе берьюлы — селкенешеп куйдылар: нишли бу ханым? Акылы бармы моның? Өендә ике яшьлек кызы, авыру ире. Пенсионер әле житмәсә...

Александр Николаевич Майский, сакалын учлап, уйга калды. Кабулов каядыр тәрәзәгә карап тора башлады. Голосов тынлыкны һәрвакыт авыр кичерә иде, түзмәде:

— Ярый. Зыян юк. Бала булса икәү булсын,— дип, газаплы тынлыктан коткарырга теләп сүз башлады: — Без әнә бер Саша белән торып калдык. Ул-бу булмагае дип ут йотабыз. Хатын малайны тирги башласа, мин баш күтәрәм, мин әрләсәм — хатын килеп кысыла, икәү булсалар, уйлап та бирмәс идек. Житәкләшеп үсәрләр иде...

Тагын тынлык урнашты.

## V

Икенче бәбиен табар алдыннан Уразаевага местком унике көнлек путевка тәкъдим итте. Казандагы йөкле хатыннар санаториена алган бу путевка — Нуриягә үз гомерендә беренче мәртәбә бирелгән путевка иде. Ул әле аны соңыннан ничәмә-ничә еллар исенә төшерәчәк. Медицина институтындагы хезмәттәшләренең мәрхәмәте, изге күңеле белән эшләнгән шушы эш Нуриянең нервыларын кылдай тартылудан саклап калды.

Әгәр Рафаэлен табар алдыннан унике көн ял итеп, күңелен көрәйтеп куймаган булса, бала табу вакытында югалткан каннан ул аякка баса алыр идеме икән?

Улы белән котларга килгән хезмәттәшләре, аның жир төсле булып күгәргән йөзенә карап, бик кызгандылар. Кешене кызгана белмәве белән дан алган Татьяна булып Татьяна да Нуриянең тонык, хәлсез чыраена, ябык ак кулларына шул хәтле дә зур кызгану белән карады ки, Нурия үзе дә, Татьяна Васильевна да елап җибәрүдән көч-хәл белән генә тыелып калдылар.

Кабулов хатыны Анна Аркадьевна белән килгән иде. Алар, Нурияне күргәч, әдәп йөзеннән, курыкканнарын белдермәделәр.

— Нәфисләнеп киткәнсең дип әйтимме, Нурия Аббасовна? Ир бала табу кыз бала табудан кыенрак бугай ахрысы,— дигән булды Кабулов.

Профессор Майский больницага килмәде. Нурия кайткач кына, аларның өенә килде. Бер көн кичекмәстән, профессор Малкин клиникасында ашказанын тикшертергә кушты, андагы абруйлы кешеләргә үз бланкасында хат язып бирде.

Александр Николаевич диагнозны дөрес куйган булып чыкты. Чыннан да Нуриянең ашказаны кислотасы кимегән икән, шуны белеп алу белән, өстәмә чарасына керештеләр, һәм ул әкрен-әкрен аякка баса башлады.

Ләкин тиз генә тернәкләнеп житү мөмкин түгел, азык-төлек кыйбат, базар бәяләрен төшерәбез дип такса куйганга күрә, авыл агайлары итен-маен, йомыркасын дигәндәй, район базарларында гына саталар, Казанга алып та килмиләр иде.

Тормыш отыры кыенлашты.

Авылга, Иж тугайларына кайтып килү, саф һавалы нарат урманында йөрү, яңа сауган җылы сөт эчү Нурияне аякка бастырыр иде дигән теләк уянды.

Солтан финанс-экономика институтының беренче курсын тәмамлаганнан соң — Нурия, Солтан, өч яшьлек Сания һәм ике айдан аз гына артык Рафаэль — ике палубалы Агыйдел пароходына төялеп, туган якларына китеп бардылар.

Пароходта эссе түгел, начар гына булса да каютасы да бар иде. Нурия, ябыклыгыннан оялып, палубага чыкмады, ул каюта тәрәзәсе буенда иягенә таянып, Идел ярларын, яр өстендәге урманнарны, тау итәкләрендә сибелгән авылларны күздән үткәрде.

Иделнең ишелеп-ишелеп менгән уң як ярына елышып, баржалар бара — артларында яртышар чакрымга сузылган сал кәрваннары. Буксир пароходлары төтен бөрки, алар яннан узып киткән чакта, тельняшка кигән таза беләкле матросларның өзек-өзек команда тавышлары, су өсләрен яңгыратып көлешкәннәре ишетелеп кала; яр буе тукталышларында, вак-төяк пристаньнарда тау-тау өелгән ящиклар, сыра мичкәләре, әрдәнәләп өелгән он капчыклары күзгә ташлана; мазутка буялган ир-ат, яшь-җилкенчәк, алар пароходына бау ыргытып, пароходны яр буена тартып китерә, юан тимер бүкәнгә бәйләп куя. Гөрелте, шаушу, чуар киемле кешеләр агымы... Тозлаган балык исе, дегет исе, юеш дымлылык Нуриянең нечкәргән күңелен өтеп-өтеп ала; тозлаган балык белән ипине умырып-умырып ашыйсы килә башлый.

Пәнҗәр пристанендә аларны Шәяхмәт Айдаров каршылады.

Инде чәчләре көмешләнгән, арка-җилкәсе калынайган, өстенә ярым хәрби гимнастерка, галифе чалбар, хром итек кигән бу кеше Солтанга да, Нуриягә дә ничектер тоныкланыбрак, җиргә чүгебрәк калган кебек тоелды.

Ә бит ул заманында Солтанны укырга җибәргән, үзе белән саллар агызырга алып йөргән, дөньядагы иң бәхетле, буй җитмәс югары кеше, хыял канатларында бик еракларга китә алган кеше иде.

Хәл-әхвәлне кыска гына сорашты. Тарантас башына утырып торган түбәтәйле Бәдри карт белән таныштырды. Үзенең озата бара алмавын әйтте. Райком бюросы үткәрәсе бар икән. Мөхәммәтша абзыйсына, аның җәмәгатенә сәлам күндерүләрен үтенде һәм... Солтанны бер читкә алып:

— Кичкә табарак килеп чыгармын, көт, яме,— диде.

Кучер сүзсез иде. Атны ул җай гына юыртып алып барды.

Нуриягә аның шулай булуы ошап та куйды. Баш өстендә чиксез зәңгәр күк бар чагында, юлның ике ягында игеннәр чайкалып утырганда, корыны бушка аударып, тел кашып бару нигә кирәк?!

Авылларны уздылар, урманнарны уздылар, каен урманының матур бер аланына кереп, ял итеп, үләннәр хуш исен иснәп, урман шавын тыңлап чыктылар. Нурия агач күләгәсендә сабыен [illegible] алды.

Зартугайда Солтаннар йортына кайттылар.

Капкадан аларны Мөхәммәтша абзый үзе ачып кертте. Сакалмыек үстергән, башына чигүле яшел түбәтәй, аягына җәй булуга да карамастан авыр күнитек киеп алган бу могтәбәр кеше аларны озак еллар завод гөрелтесендә эшләп, саңгырауланыбрак калган кешеләргә хас тоныграк тавыш белән каршылады:

— Менәтерәк вәйт... Карасана боларны, кичәгенәк кичен, вакытсыз йоклап китеп, төш күреп яттым ие. Солтан Уҗил урманы ягында җир бүлеп йөри, имеш. Нурия, ә Нурия, тукта, ничек дип күрдем әле? Әһә? Кызыл флаглар күтәреп, авыл кызларын мәктәпкә алып бара икән дим. Саумысыз, туганнарым, исән-имин генә кайтып җиттегезме? Бәрәкалла! Малайлары туган дигәннәрие, шушымыни бөтерчек? Атын ничек дип куштыгыз? Рафаел? Ну-у?! Карасана, үзенә күрә генә ту-

гел, күзендә мәгънә бар моның! Айдарлар токымы бу, билләһидер әгәр! Сөбханалла, күз тимәсен, үз бәхете үзе белән булсын! Сания дә Сания дип авыз суларын корыта ие Әхнәфебез — шушы булдымыни Сания? Бәрәкалла, монысы, килен, сезнең якка, Габбас кодалар ягына тарткан дип әйтимме? Үзеннең дә чалымнарың бар төсле, кайсыдыр бер төшендә Солтан да посып тора. Кил әле, балакаем, күрешик әле әйбәтләп. Менә шулай, матурым, мин синең дәү абзаң Мөхәмматша булырмын... Энисе, энисе, дим, Фәтхениса! Каяле кесә төбеңдә аунап яткан берәр кәнфитең юкмы? Минем бит зур сеңлем кайткан. Бәрәкалла!

Улы Әхнәф турында ул соңгы кеше итеп сорашты.

— Ни хәлләрдә студин? Әкәдимик булып житешәме?

Солтан ирен чите белән генә елмаеп:

— Академик булырга ерак әле, абый. Ике-өч ел чиләнәсе бар,— диде.

— Дәрте булса, дәрманы табылыр. Солтан белән Шәяхмәт абыйларына тарткан булса, кайгырасы юк, сәвит аңардан кеше ясап чыгарыр. И фсю! — диде Мөхәмматша абзый һәм, «ыстудин» хакындагы сүзне беткәнгә санап, кучер картка таба борылды.

Хәзер үк кайтам дип, миңа озак юанырга кушмадылар, дип өзгәләнгән Бәдри картның, ай-ваена куймыйча, атын тугарып, йөгән тезгенен лапас баганасына бәйләп куйды хужа абзый.

— Бер ярты сәгать чамасы кипшенсен айгырың, кордаш. Ашыкмыйк. Аннары су эчертеп, алдына яшел печән салырбыз,— диде Мөхәмматша абзый.

Адәм баласы, олыгайган саен, туганнарының кадерен күбрәк белә торган була. Мөхәмматша абзый, сакаллы сабый, энесе Солтан кайтканга, үзе белән Нурия киленне, балаларны алып кайтканга, улы Әхнәфнең, абыйлары юлыннан бара торган егетнең, эшләре көйле булуына тыны-көне бетеп сөенде. Печән өстендә дә суймый калдырган печтергән тәкәсен суеп, Фәтхениса түтигә түтәрәме белән ит кертеп бирде.

— Менә, энисе, сиңа түшкәнең яртысы, калганын базга куйдым. Пешер ашыңны, пешер бәлешеңне. Казан кунаклары көн саен кайтып тормый.

Кадерле кунакларга дип, авыл җирләрендә әзерләнә торган кызыл эремчек — корт чыгардылар. Бавырсак, атланмай, кәрәзле бал куйдылар. Табын түгәрәкләнде дә китте.

— Әйдәгез әле, житешегез, туганнар. Ит-мазар пешкәләгәнче, без, Солтан, очрашу саулыгына мыекларны чылатып алыйк әле бер.

Авыл кешеләре кебек оялып-тартынып кына кыстамый Мөхәмматша абзый, потомственный эшчегә хас ныклык белән, үз-үзенә ышанган бер ныкышлык белән кыстый.

— Йәле, Солтан, этиең урынына калган абыеңны мыскыл итеп утырма, әле. Рабучий сыйныф дигәченнән дә без дә төшеп калганнардан түгел. Әгәренки, бик беләсегез килсә, мин бит кырык ел гомеремне забутка бирдем. Бер тоташтан! Сабындыр-җилемдер кайната торган шырдый-бырдый забутка түгел, патша гаскәрләренә туплар койган забутка, и шулай ук, револүтсене саклап калган забутка.

— Менә шулай инде ул Мөхәмматша абзагыз. Кунак килдеме — теле ясмаклана да китә. Ижау забутын мактый башлый. Башка чагында мүкләк сыер төсле тып-тын йөри, сүзен аркан белән дә тартып ала алмассың,— дип, Фәтхениса жиңги, авыз читен яулык почмагы белән сөрткәләп, сүзгә кушылды.

Мөхәмматша абзый хатын-кыз белән авыз чайкап утыруны кирәкмәс бер нәрсә дип тапты булса кирәк, Фәтхенисасына җавап-мазар биреп тормады, иркенләп бер мәзәк сөйләргә креште:

— Беләсеңме, Солтан, безнең татар халкында әкәмәт тә кызыклы сәер бер мәзәк бар. Абыйлы-энеле ике туган булган. Моның олысы өйләнгән. Өйләнүен өйләнгән дә бит, пнимаеш, беренче баласы тууга,

үлеп тә киткән. Урманда аю ботарлаган моны. Аю бит ул хикмәтле вә гайрәтле җанучар, ата белми атсаң — үтерә ул сине, вата-сыта. Менә шул — олы малай вафат. Килен тол калды бит инде. Бер баласы белән. Нишләргә? Килен шундый сылу, шундый булдыклы, пнимаеш, нәрсәгә генә тотынмасын — гөл итә дә куя! Ярый, хуш, җибәрәсе килми бит картларның киленне. Җибәрәсе килми! Нишлиләр болар! Кече малайны өйләндерәләр. Өйләндерәләр, пнимаеш, килен күңелсез. Пәрәметеки әвене янган кеше төсле бу. Күңелен ачып булмый моның! Балтасы суга төшкән кеше төсле...

— Балта бит ир-атта гына була,— диде Фәтхениса, ирен чите белән елмаеп, Нуриягә күз кысты.

— Тик тор, кортка, анысы аның сүз җилеме өчен генә әйтелә. Карале моны, остабикәләр төсле акыл өйрәтеп утыра, пнимаеш.

— Йә, йә, сөйләп бетер, абый,— диде Солтан, сәгатен чыгарып карады — Шәяхмәт килергә күпме калганны белергә теләве иде.

— Ийе, шулай, килен күңелсез. «Син нәрсә,— ди моңа кече малай,— нигә алай кыланасың? Вә пирвих, син миңнән олы, пнимаеш, вә втарых, мин сине сабый балаң белән алдым. Син мине яратмаска нисмиеш правы!» — ди. Елмая килен, әйтә: «Абыең синең беренче төнне минем өстемә кара мәче атты. Мин тетрәп киттем»,— ди. Ах, менә нәрсәдә икән хикмәт. Кече малай да тапкан кара мәче, килен өстенә дә аткан аны, әммәдәки киленнең бер кылы да селкенмәгән. Ярсыган егет, ник, дип кычкырган, аяк тибеп. «Кара мәчене ничек ыргытасың бит, кайчан ыргытасың»,— дигән килен.

Мөхәмматша абзый берара дәшми торды, кисәк кенә нәтиҗә ясады.

— Кайчан ыргытасың, пнимаеш, ничек ыргытасың... Бер мәртәбә зөфаф кичәсен узган хатын-кызны мәче түгел, юлбарыс ыргытып та куркытып булмый.

Фәтхениса түти белән Нурия, эшләр болай олыга киткәч, шыпыншыпын гына кузгала башладылар.

Мөхәмматша абзый аларга күз кырые белән генә карап алды, туктатмады, әйтер сүзен матур гына итеп очлап куйды:

— Туганым, Солтан, син укымышлы кеше. Дөньяның кая таба барганын белә торгансыңдыр. Утырыйк әле бер сөйләшеп, исән чагында. Бу дөньяда иртәгә әллә кем бар, әллә кем юк. Әнә ярман пленнарын әйләнеп, башкорт далаларын гизеп кайтканые Чишмәбай. Тегермәнче Каюмны әйтәм. Калхузга нинди терлек абзарлары җиткезде, нинди иттереп су белән суга торган әвеннәр корды — һәммәкәе дә аның эше. Куллары алтын ие бит, пнимаеш, менә хәзер безнең табында утырасы кеше ие бит... балаларын ятим калдырып, Хәнифәне тагын тол итеп...

— Нишләде? — диде Солтан ашыгып.

— Нишләсен? Суга төшкән күк югалды.

Авыр тынлык урнашты.

Мөхәмматша абзыйның соңгы сүзләрен ишетеп калган Фәтхениса түти белән Нурия кире керделәр.

— Хәнифә түти тагын дүрт бала белән өелеп калдымыни? — диде Нурия.

— Өелеп калды шул, бахыр.

Нурия кайчандыр үзен тәрбияләп-багып үстергән кече әнисен чын күңелдән кызганды. И дөньялар! Диңгез суларына эләккән йомычкалар төсле чайкыйсың син адәм баласын!..

Нуриягә чиксез кыен булды. Күзенә бәреп чыккан кайнар яшьне кулъяулыгы белән сөртергә керешсә ул. Күңелен бик дәү таш басты. Солтанны партиядән чыгару, аның үпкә авыруы алуы, шулар янына инде менә Чишмәбай. Күбрәк шул, күбрәк бер йөрәккә. Чүлмәк тә бит бер тулгач түгелә...

Табынның яме китте. Фәтхениса белән Нурия, сабыйларны ашату, кичкә аш-су әзерләү сылтавы белән, китеп бардылар.

Мөхәммәтша абзый, Солтанны ияртеп, лапаска тәмәке тартырга чыкты.

Ул арада Шаукымлы Шәяхмәт тә килеп җитте.

Аның аягында хром итек, өстендә ярым хәрби гимнастерка, галифе чалбар иде. Юл кожанын кулына тоткан иде.

Хәл-әхвәл сорашып, кул биреп күрешкәч:

— Бәдретдин абзый кайда? — дип сорады ул.

— Хәзер кайтыр, күрше авылга йомыш белән җибәргәнием,— диде Мөхәммәтша абзый.

— Нинди йомыш?

— Нинди дип сорап торган булма инде. Ир-атның нинди йомышы була, белмисеңмени?

— Сез нәрсә, шулай зурдан кубарга чамалыйсызмыни әле? — диде Шәяхмәт Айдаров, абыйсының сүзләрен бигүк өнәп бетермичә.

— Беләсеңме, энем... Шаукымлы Шәяхмәт. Син теге ни... ривәлүтсе чыкканчыга кадәрле кушаматың белән әйткәнгә ачуланмый торганыең. Ник дип әйткәндә, син чыннан да шаукымлырак иең бит. Инде түрә булгачыннан, безнең белән табында бер чүкердәшеп утырасың да килмимени? Дөнья бит фани, Шәяхмәт. Әнә бит Чишмәбайны ал...

Шәяхмәт Айдаров «рабочий сыйныф» алдында илдәге хәлләрне сөйләшергә теләми, ул бу хакта Солтанның үзе белән, кара-каршы утырып, күзгә-күз карап кына сөйләшергә тиеш иде.

Ул абыйсы Мөхәммәтшага папирос суздьі, тегесе алмады:

— Безгә батмый ул, энем. Рабучий сыйныфка аның бакчада үскәне, махра дип аталганы шәбрәк.

Газета кәгазен шатырдатып ертып, бармак юанлыгы итеп тәмәке төрде, тел очы белән төкереклап ябыштырды, ут алдырды. Сакалмыеклы битен аксыл төтен белән күмеп, рәхәтләнеп көйрәтергә тотынды.

Алар тәмәке тарткан арада Солтан бәрәңге бакчасы ягына чыгып керде.

Күпереп-тулып торган яшел бакча аклы-шәмәхәле бәрәңге чәчәге белән тулган; көндез кояш эссесеннән җылынган бәрәңге сабакларыннан, күңелне кузгатып, әчкелтем бер ис агыла; бакчаның түрендә ак мунча күренә, аның кырыенда ике шомырт агачы үсә, бире табарак — бакча киртәсенең буеннан-буена — сәрби куаклары тезелеп килә; каршы якта, мунчаның турысында диярлек, өч баш умарта сарылы-зәңгәрле, кызыллы төсләре белән балкып утыра; бакча өстендә, сәрби куакларында умарта кортлары гөж килә иде.

Бал кортларының тигез гөжләве, бәрәңге сабаклары арасында, киртә буендагы үләннәр эчендә чикерткәләр сайравы җанны тынычлык белән тутыра, сиңе табигатьнең мәңгелек хәрәкәте белән тоташтырып, үзеңә үзеңне хуҗа итеп куя иде.

Солтан бер генә мәлгә, әллә авылга кайтып төпләнергәме икән, дигән фикергә килде.

Ул арырак, бакча башынарак китте. Биредән тау башын тутырган сап-сары бүрәнәле амбарлар, каршы якта, Аксагыз-тауларының итәгендә, тегермән канавы буенда үзләре бер авыл кадәрле булып урнашкан терлек-туар абзарлары Зартугайга яңалык керткән, аны элекке мескен хәленнән чыгарган иде.

Нәкъ әнә шул амбарлар, терлек-туар абзарлары аны авылга кайтып төпләнү уеннан кире чигендерделәр. Аларны бит Чишмәбай салган. Аларга Чишмәбайның күңел җылысы кушылган, маңгай тире тамган. Ә үзе, үзе кайда соң хәзер Чишмәбай? Себер тайгасында урман кисәме? Шахталарда күмер чабамы? Юк, Солтан авылга кайтып кына җан тынычлыгы тапмаячак. Авыл аны өстенә килгән бәладән коткарып кала алмаячак. Аннары бит әле ул котылып калырга да теләми. Ул гаделлекне табарга, биографиясен чиста-саф итеп күрергә

тиеш. Нух Галләмнең яласыннан аны кайчан да булса бер аралап алырлар әле. Аңа партбилетын кире кайтарып бирерләр. Бу хакта югарыда, Үзәк Комитетта белми торганнардыр. Аларга Солтан Айдаров хакында чын дөреслекне әйтеп бирүче юктыр...

Солтан бакчадан әйләнеп кергән чагында, Бәдретдин карт инде күрше авылдан әйләнеп кайткан, Мөхәмматша абзыйның йомышы да үтәлгән иде.

Кайнар аш, яңа суйган ит, ярмаланып пешкән бәрәңге белән тамак туйдыргач, Шәяхмәт Айдаров абыйсы Мөхәмматшадан, түбәнчелек белән гафу үтенеп, үзен җибәрүне сорады. Салагыштa, Яуморзада, тагын берничә авылда аның урып-җыю эшләренә әзерлекне тикшерәсе бар икән. Ул бүген үк, төн уртасында булса да, Пәнҗәргә кайтып житәргә тиеш икән.

Мөхәмматша абзый тешен кысып кына риза булды.

— Абый, сый-хөрмәтеңә рәхмәт, Солтан мине Ужил урманына хәтле генә озата барсын,— диде Шәяхмәт.

Юл аягына берәр чәшкә чәй эчкәч, кузгалдылар.

— Син инде, энем Шәяхмәт, бик зур түрә булсаң да, абыеңны онытып бетермә. Синең бит миннән дә якын беркемең дә юк, пнимаеш. Авылларга чыкмый тормый торгансыңдыр. Чыккан чагыңда бер генә сәгатькә булса да атаң урынына калган абзаңа сугылып кит. Аның өчен сине ботыңнан тотып асмаслар, пнимаеш,— диде.

Ул аны кочаклады. Шапылдатып Шәяхмәтнең аркасыннан какты. Аннары аерылыштылар.

Яңа печән белән сыйланып өлгергән туры айгыр Мөхәмматша абзый каерып ачкан капкадан, башны бик текә тотып, тыпырчынып-кылтаеп чыгып китте.

Авылдан күптән аерылган булса да, үзе әйтмешли, кырык ел буена завод тузаннарын йотып ятса да, айгырның ыспайлыгына, көязлегенә, үз дәрәҗәсен белеп, хуҗасы кебек иркен кылануына сокланып карап калды Мөхәмматша абзый.

## VI

Зартугай урамыннан атны салмак атлатып алып чыктылар. Солтан күзен алмый карап барды. Яшел бәбкә үләне түшәлгән биек койма буйларында, тыкрыкларда казлар йөри, тавыклар тибенә, киртә казыгына бәйләп куелган кызыл бозау сузылып ята иде. Камалиларның бәрәңге бакчасы әле Солтан малай чакта ук чыршы агачлары белән әйләндереп алынган иде. Солтаннар ул чыршыларны кайчандыр бер санап та чыкканнар иде. Утыздан артык иде алар. Биек төз чыршылар әле дә исән, Зартугайга ямь биреп тезелешеп торалар.

Мәчет тә исән икән әле, манарасы гына юк. Таминдар бай салдырган мәктәп бинасы да исән, анда хәзер медпункт ачканнар.

Урам аулак, үтеп-сүтеп йөргәннәр күренми. Халык кырда, яшелчә бакчаларында, терлекләр янында.

— «Кызыл Зартугай»ның хәле ничек?— дип сорады Солтан.

Абыйсы кепкасын салды, чаларган кыска чәчен, маңгаен кулъяулыгы белән сөрткәч, янадан киде.

— Начар дип әйтеп булмый. Партоешма секретаре Каһарманов та, председатель Батыршин да тырыш кешеләр булып чыктылар. Дөрес, Батыршинны күздән ычкындырмыйм. Халык белән киңәшмичә, башбаштакланып киткән чаклары да булгалый. Карап-барлап тормасаң — киртә сикерергә дә күп сорамый. «Кызыл Зартугай»га яңа кеше килде. Укытучы. Мәктәп директоры. Менә ул мине шатландыра.

— Мин белгән кешеме?

— Юк. Фамилиясе — Муратов, исеме — Зәйни. Беләсеңме, Сол-

тан, бер пычрак сыер бөтен абзарны буярга житә диләр. Киресе дә була икән. Бер Муратов, япа-ялгызы диярлек, Зартугай мәктәбен республикага күтәрде. Балалардан яшелчә үстертә, куян карата. Өстәвенә — динамик белән эшләтеп, электр ала башладылар. Хәзер тирә-як авылларда аны бер дә телдән төшермиләр. Август ахырында Салагышка зона конференциясе җыябыз. Әгерже төбәген. Шунда Зартугай мәктәбенең тәҗрибәсен үрнәк итеп куярга исәп.

Болар яңа хәбәрләр, әлбәттә. Ләкин Шәяхмәтнең Солтанга әйтәсе сүзе шушымы? Шушыларны әйтер өчен ул аны Ужил урманына хәтле алып барамыни?

Авыл урамын чыкканчы алар бүтән бер сүз дә сөйләшмәделәр. Каз-үрдәкләрнең күплегеннән ап-ак булып, күзләрне камаштырып күренгән тегермән буасы янынна: узып, тагын бераз баргач, алты почмаклы, биек коймалы һәм урыс капкалы бер йорт янына атны туктаттылар.

— Төшик әле,— диде Шәяхмәт.

— Төшик,— диде Солтан да, аның белән килешеп.

«Мөгаен, Хәнифәне күреп чыгарга телидер»,— дигән уй килде Солтанның күңеленә.

Аттан төшкәч, икесе дә, башларын югарырак күтәреп, йортны күздән үткәрделәр. Йорт чарлаклап эшләнгән, чарлагы ак-зәңгәр-сары буяуларга буялган, капка такталарына кояш сурәте төшерелгән, тәрәзә йөзлекләре челтәр-челтәр, тәрәзә каршысындагы биек койманың да югарыгы ягы челтәрле рәшәткә итеп ясалган иде.

Солтанның күңеле әллә нишләп китте. Шушыларның барысын юктан бар иткән кеше — көнлекче Хисмәй малае хәзер юк. Аның кайда икәнен, нишләп йөрүен, дөньяда бармы-юкмы икәнен беркем белми.

Шәяхмәт, хром итекләре белән зур-зур атлап, капкага таба юнәлде. Келәне күтәреп, капканы ачты. Ишегалды чирәмендә кыткылдашып йөргән аклы-каралы тавыклар лапаска таба йөгерделәр, кызыл кикрикле зур ак әтәч кенә, башын кыңгыррак салып, шпорлы озын аякларының берсен күтәргән көйгә, ишегалды уртасында торып калды. «Ко-ко-ко-ко!»— дип гайрәтле кытаклады.

— Әллә өйдә юк инде болар?— диде Солтан үзалдына.

Шул сүзне әйтеп бетерүе булды, лапасның бәрәңге бакчасына чыга торган капкасыннан кулына зур табак белән яңа бәрәңге күтәргән унбер-унике яшьләрендәге юка гәүдәле, ак ситсы күлмәкле кыз бала килеп керде. Чит кешеләрне күргән мәлгә каушап туктап калды, аннары нидер чамалап алды, табагын җиргә куеп, ашыгып аларга таба килә башлады.

— Солтан абый! — дип кычкырып җибәрде ул.— Әллә танымыйсыңмы? Мин бит Шәфика...

Солтан бер генә мизгел искиткеч якынлык, туганлык тойгысы кичерде. Аңа үтә дә үз итеп, абыйсы итеп (җизнәсе дип түгел!) йөгереп килгән Шәфиканы ул күкрәгенә кысты, тегесе, карышмый-нитми, аның күкрәгенә сыенды.

— Шәяхмәт абый, таныш бул: Габбас мулла кызы Шәфика,— диде Солтан, әле һаман да дулкынлануын баса алмыйча.— Йа ходай, нинди үскән ул! Эшкә ярый башлаган. Әниең өйдә юкмы әллә, матурым?

— Әни сепарат йортына китте,— диде Шәфика, кулларын күкрәгенә кушырып.

— Әнеләрең кайда?

— Мәхмәй белән Әхмәйне әйтәсеңме? Алар су буенда — балык тоталар. Шамилне әни үзе белән алып китте.— Аның кинәт чырае караңгыланды, иреннәре тетрәнде, әйтер сүзен әйтә алмый торды. Бераз исенә килгәч кенә: — Чишмәбай абыйны алып киттеләр. Кайтмый да кайтмый. Әни көтә, кич саен намаз укый, ходай тәгаләгә ялвара... Әйдә, абый, өйгә керегез. Самавыр куям. Бәрәңге пешерермен.

— Юк, балам, хәзергә кереп тора алмыйбыз,— диде Шәяхмәт Айдаров.— Әниеңә сәлам әйт, менә шушы күчтәнәчне тапшыр, яме.

— Кемнән дип әйтим, абый?

— Солтан абый белән Шәяхмәт абый кергән иде диярсең. Икенче тапкыр иркенләбрәк килербез дип әйттеләр диген, яме.

Алар Шәфиканы аркасыннан сөеп, саубуллашып китеп бардылар. Шәфика яшел чирәмле ишегалдында, тал чыбыгы төсле нечкә булып, ак ситсы күлмәге, ак яулыгы белән дөньяны балкытып торып калды.

Солтанның күңелендә ул ныклык уятты. Аны янә дә Казанга алып китәсе, укытасы, мәктәбен тәмамлатасы булыр...

Кара туры айгыр, дилбегәне кагып җибәрүгә, җәйге яңгырлардан соң каешланып шомарып калган тигез юлдан бик җиңел элдертеп алып китте. Бәдретдин абзый аны шулай, Ужил урманына кергәнче, җилдәй җитез юырттырып алып барды. Урманның күләгәле юлларында салмак адымга күчерде. Чөнки биредә юл чатларында түмгәкләр, киселгәннән соң мүк белән капланган агач төпләре, юлга аркылы авып төшкән коры агачлар, юлны бүлеп, көянтәдәй бөгелгән миләшләр очрый башлады.

Урман эчендә, аулакта үзенә күрә бер тынлык, басынкылык хөкем сөрә, әнә шул тынлык-басынкылык яшәү булмаганнан, тереклек булмаганнан түгел, киресенчә, яшәү күп булганнан, табигать үз законнары белән, тигез һәм иркен яшәүдән туган тынлык иде.

Урманның салкынча-дымлы рәхәтлегенә бирелеп, бераз сүзсез генә баргач, илаһи тынлыкны берьюлы үзенә кочаклап, урман яңгыратып күке кычкыра башлады. Табигать авазларына яшьтән үк тыныч карый алмаган Солтан бу минутларда үзе өчен ачыш ясады: урман кебек зур дөньяда, урман кебек колач җитмәс киң дөньяда бер генә кош та күкене уздыра алмый икән бит. Сандугачның тавышы бер аланга җитә, урман күгәрченнәре баш очында гөрли, бөркет булып бөркетнең коркылдавы күп булса бер кварталга ишетелә торгандыр. Әнә күке, бәләкәй генә бер кошчык, урманны бөтенләе белән кочаклап, барлык аваз-өннәрне үзенә буйсындыра; кеше булып кешене — табигатьтәге иң бөек затны тынып калырга, җир йөзендә күпме яшәргә икәне хакында уйларга мәҗбүр итә...

Шәяхмәт белән Солтан, тарантас башына утырган кучер Бәдретдин абзый, өчесе тиң тын калып, җир йөзендә әле күпме яшәргә тиешлекләрен санап бардылар. Бәдретдин карт бу урында нинди хисләр кичергәндер, әйтүе кыен, әмма заманында утны-суны кичкән, ырымшырымнарга ышанмый торган ике нык кеше, Шәяхмәт белән Солтан, күкенең моңлы да, хәвефле дә тавышына колак салып, үз уйларына бирелделәр.

Шәяхмәт Айдаров — Ужил урманында, Бояр урманында, Тугызбуй якларында урман кистереп, язларын нарат бүрәнәләрдән сал ясап, шуны Кама иделе буйлап, Чистайга, Чаллыга илткән егет — бу яклардагы урманнарның аркылысын-буен белә, ә инде Таминдар бай Тураевларның, Сөләйман хәзрәт улы Динислам Бохараевларның үлем баржасыннан котылганнан бирле гомумән дә урман-суларга, елга тугайларына тыныч кына карый алмый иде.

Зәңгәр күкләр аңа дәрья суларын, диңгезләрне, ак болытлар диңгез киңлекләрендә чайкалган ак җилкәннәрне хәтерләтә; табигатькә гашыйк, кешеләрнең матурлыгына, омтылышлы булуларына, дөньяны яңача, үзләренчә корырга сәләтле булуларына ышанып яшәгән Шәяхмәт үзе башкарган эшләрнең чынлыгына, хезмәт кешеләренә кирәкле булуына да ихлас ышана иде.

Тик менә быелгы хәвефле ел аның имәндәй ныклыгын какшата төште. Колчакка каршы, утызынчы елларда кулакларга каршы сугышып, кан койган берничә иптәшенең, кристаллдай чиста күңелле, намуслы иптәшләренең бәлага эләгүе, шул исәптән энесе Солтанның партия-

дән чыгарылуы аны шактый ук кыен хәлгә китереп куйды. Кем кем — Солтан бит инде үзе өчен яшәгән кеше түгел. «Кызыл Зартугай» колхозының җирләрен күмәкләштерергә, ызансыз басулар итәргә керешкән елларны, үзенең бер карыш җирен бирмәс өчен земляемер баганасы чокырына төшеп яткан әтисен — ярлы Садыйкны — наганнан күккә атып, куркытып чыгарган кеше! Йә, революция алдында, Совет власте алдында аның ни гаебе бар? Инде менә Каюм Хисмәевне алыйк. Чишмәбайны. Аның ни гаебе бар? Имеш, ул Германиядә халык тырыш, эшне үзе белеп эшли, кушып эшләткәнне көтеп ятмый дип сөйләгән. Ул бит алардагы власть Совет властеннан яхшырак димәгән, аларда хезмәткә мөнәсәбәт яхшырак дигән, тәртип нык урнаштырылган дигән. Шуны да әйтерлек иреге булмагач, аның азат илдә, социализм илендә, Октябрь революциясе бишегендә яшәвенең ни мәгънәсе бар?..

Шәяхмәт Айдаровны борчыган сораулар моның белән генә бетми әле. Илләр өстенә фашизм афәте үрмәли. Европада Гитлер акырына, фашизм солдатларының дагалы итеге таш юлларга чакылдап баса. Европа ягыннан социализм иленә салкын җилләр исә.

Шул уйлары белән Шәяхмәт Айдаров, чәчәкле бер аланга җиткәч, Бәдретдин картка атны туктатырга, тугарып ял итеп алырга кушты.

— Мин энекәшкә урманнарны күрсәтеп килим әле,— диде.

Аланның аргы башында күкрәп үскән карт имән янына җиткәч, туктадылар.

— Менә бу имән төбендә мин лашманчылар белән күп яттым. Әйдә, без икәү, истәлекләрне яңартып, җиргә кырын ятып торыйк әле,— диде ул Солтанга.

Җайлап урнашып алгач, портсигар чыгарып, папирос кабызды, тәмәке төтенен зәңгәр боҗралар итеп җибәрде, боҗраларның җилсез тын һавада отыры зурая барып, йодрык сыярлык боҗрага әйләнүләрен балаларча бер мавыгу белән карап ятты, тик шуннан соң гына уйларының очына чыгып, сүзен дәвам иттерде:

— «Күп яттык без мәдрәсәдә, аңламадык бер нәрсә дә» дигәндәй, энем Солтан, без синең белән дөньяның ачысын-төчесен татымадык түгел, татыдык, алда гомер булса, кем белә, бәлки, тагын да күбрәк татырга туры килер әле...— Ул әз генә пауза ясап торды. Папиросын бармак арасында бөтәрләп, җиргә батырды.— Минем сиңа әйтер сүзем бар. Әмма... бу сүз икебезнең арада гына калсын. Без сөйләшкәндә, мин Бәдретдин картның да, Мөхәммәтша абзыйның да булуын теләмәдем... Беләсеңме, Солтан, бу соңгы елларда мин илдә барган кайбер нәрсәләрне аңлап бетермим. «Халык дошманы» дигән термин ул уйлап чыгарылган, күпертелгән бер нәрсә түгелме? Аны иптәш Сталин беләме икән? Белсә — тиешле дәрәҗәдә белә микән? Менә Каюм Хисмәев турында сүз булды. Ягъни без икебез дә Чишмәбай дип белгән кеше турында. Алтын куллы кеше турында. Ә бит аны Гыйбадулла Ядкаровның ГПУга язган хаты буенча кулга алдылар. Ә минем шигем бар — изге ният белән язганмы аны Гыйбадулла Ядкаров. Мине кайчандыр үлем баржасыннан коткарган ул кеше соңгы елларда танымаслык булып үзгәрде. Юккамыни халык аңа «Бүре Бадул» дигән кушамат такты. Ул бит кулакка әйләнеп бара — үз йортына малмөлкәт ташучы каракка. Мин аны Нәҗия Уразаева кулыннан коткардым. Үзгәрер дип өмет иттем. Ул әнә авылдашлары өстеннән әләк яза. Моны Зартугайлар белә, ләкин алар аның белән конфликтка керергә теләми. Ник дисәң — аның явызлыгы өскә чыкты.

— Ни өчен шулай кылана соң ул?

— Ни өченме? Син, Казанда булгач, барын да белеп бетермисең. Авылның сылу яшь хатынына — Хәнифәгә кул салмакчы була Бүре Бадул, кулы кыска булып чыга. Хәнифәгә Чишмәбай өйләнә. Бүре Бадул моны гафу итә алмый. Мәкерле, явыз уен эчкәре яшерә — агулы

кара елан итеп куенында асрый. Вакыты житә — угын китереп кадый: мә, Чишмәбай, ал кирәгеңне!

— Ә син, син, районның хуҗасы нәрсә карадың?

— ГПУда минем белән киңәшмәделәр. Аны Казаннан килеп кулга алганнар.

— Син бит Чишмәбай кулга алынганнан соң сөйләшә ала идең. Аны яклый ала идең. Ул хокукны синнән тартып алмаганнардыр бит?

— Мин нәкъ шулай эшләдем дә. Ләкин...

— Үзәккә барырга кирәк, Мәскәүгә.

— Бик дөрес әйтәсең. Менә ул эшне эшләргә мин сиңа киңәш итәм.

— Барып, телдән сөйләргәме, әллә хат итеп язаргамы?

— Хат итеп язуың хәерлерәк булыр. Ни дисәң дә, югары оешма, каушата ул. Чакырсалар, барырсың, хатта аңлатып житкерә алмаганны телдән сөйләрсең. Ризамы шуңа?

*Ахыры бар.*

# Зөлфәт

## ЧИКСЕЗЛЕККӘ БАГАМ

### Мәл

Баш әйләнә чиксезлекне уйлап,
Төпсез галәм түрләренә багам...
Умырзая сабак турайткананы
Ишетелә дымык урманнардан.

Бер карышка планетадан өстә
Сулык-сулык килә кайнар йодрык —
Минем йөрәк! —
Ул җир белән бергә
Йолдыз өермәсен бара ерып.

Үрел дә күр иде юл ахырын! —
Өметләнеп чиксезлеккә багам.
...Томаннардан килеп чыгабыз да
Югалабыз кереп томаннарга...

### Чегем шарламалары

Биекләрдән су ыргыла аска —
Бәреп шәфкать белмәс гамьсез ташка,
Җанын һәлак итә ләбаса! —
Мәгъруур тауга — утлы манзара бу,
Мәгъруур күккә — шаулы тамаша.

Бәргәләнеп ташка, кайный-кайный
Юлын дәвам итә исән-сау.
Һәм сөйли күк агым:
«Вакыт — мин ул,
Мең яшәрсең, миңа охшасаң!»

Биекләрдә көнен иткәннәрне
Куган язмыш төрле ярларга,
Тик тынмаган,

---

ЗӨЛФӘТ *(1947) — шагыйрь, «Язмышлар ярында», «Утлы бозлар» исемле китаплар авторы. Рус телендә аның «Осенние костры» исемле китабы дөнья күрде. Казанда яши.*

Буйсынмаган һаман
Җырындагы утлы шарлама.

Әнә шулай кичү кирәктер дә
Язмыш дигән төпсез үткелне —
Түбән ташланып та, исән калган
Чегем шарламасы шикелле.

## Эт тоту көне

(КӨНБАТЫШ СЕБЕРДӘГЕ ОЧРАШУЛАРДАН)

*Кибет ишегендә белдерү:*
*«Серьгино урман хуҗалыгының Северный поселогында иртәгә эт тоту көне!*
*Хуҗасы булган этләр бәйдә торсын!*

Поссовет»

— Исемең кем, сеңлем?
— Гөлназ, абый...
— Синең этме соң бу?
— Түгел лә...
Мансылардан калган ятим эт ул.
Исеме дә «Ятим».
Мине күрсә,
Сырпалана килеп гел генә...

— Ә син аны яратасыңмы соң?
— Яратам дип... Җәллим мин аны.
Обь ярына күчкән хуҗалары.
Ә ул, әллә инде үпкәләгән,
Эзләп карарга да уйламый...

Бүреләргә барып караган ул,
Яшимче, дип, сезнең өердә —
«Синнән кеше исе килә»,— диеп,
Талап кайтарганнар бүреләр.
Чакырдым мин, яшә бездә, дидем.
Ә ул... бераз гына тора да
Әллә кемен эзләп чыгып китә
Һаман да шул кара урманга...

...Мин ишеткән идем:
Бу төбәккә
Сазлык-тайгаларны актарып,
Дер селкетеп аю белән черки
Кулда власть тоткан якларны,
Килеп кергәч
Уйлый, эшли торган
Металл җигеп Яңа Замана —
Һәм боргычлап алгач Табигатьне
Егып салырга ук чамалап,

Тайгасында чорлар кичкән халык,
Шул алыштан качып, күрәсең,
Аулаграк күргән
Саф дулкынлы,
Җанга якын сулар тирәсен.

...Син адашып калдың мәллә, Ятим,
Хуҗаларың нарта җыйганда?
Суыктыр бит сиңа, куркынычтыр
Ялгызыңа кышкы буранда?

Металлистик Яңа Заман сине
Үз иттеме әллә шулкадәр —
Тайга кануннарын һәм хуҗаңны
Онытырлык булгач син әгәр?

Кая баш төртергә белмичә син
Йөрисеңме әллә чабулап —
Дошманлашып әүмәкләшкән чакта
Яңа Заман белән Табигать?

Кач урманга, кайтма ешлыкълардан,
Әйткәнемне тыңла син, Ятим!
Яки... әйдә, киттек минем белән —
Иртәгә бит, әнә, нинди көн!

...Күченүләр, аһ, бу күченүләр!
Оя тузгытуның җилләре
Табигатьнең һәр нарасый җанын
Уттан утка чөеп җилгәрде.

Ә ул җилләр
Халык язмышларын
Айкый-чайкый дулый, болгана! —
Өрә-өрә ялгыз Ятим чаба,
Көн суына бара дөньяда.

...Кузгалды да поезд, ары киттек.
Тәгәрмәчләр тату келтери.
Күккә өреп ялгыз Ятим калды.
Ак буранга чумды һәм югалды
Ишектәге салкын белдерү.

# Ат йокысы

Карт ат йоклый колын төшен күреп.
Аягүрә йоклый эш атлары.
Төшкә керә олы юлның шавы,
Сусыл исе яшел сукмакларның.

Дәшә аңа Асылбия-Ана:
«Дөлдөл улы! Кайда синең чабыш?!» —
Нигә ташлады соң әле аны
Йөрәк урынында талпынган кош?

Ул дөньяга килде Тулпар булып
Якты таңда, дала түрләрендә —
Елгыр ефәк канат иде сыртта
Һәм таң кошы иде күкрәгендә!

Көйсезләнде никтер нәни малай —
Ул көткәнчә түгел иде колын...
Юри әйтте эти кеше: «Юләр!
Килбәтсез ат Тулпар була диләр,
Канатлыдыр, бәлки, чү-чү, улым...»

Юш килгән лә иде юраганы
Улын юатучы шул атаның...
Тик, нишлисең? — әүлиялар хәтта
Күрми кала колын канатларын.

Җитте килеп камыт кияр көннәр.
Тулпар-колын, тыңламадың шуны —
Күпме әйтте Асылбия-Ана:
«Камыт үтерә,— дип,— канатлыны!»

Син малайны кызгандың ул көнне —
Күрдең җанындагы пар канатны
Һәм аңладың: бүген — син киярсең,
Иртәгә ул — сасы ыңгырчакны.

Һәм уйладың: күкрәкләрдә безнең
Талпынулы таң кошлары барда
Һич югында бер җилдереп калсын
Дөлдөл үзе тарткан бу арбада!

...Күкрәктән кош озак китми торды —
Талпынды ул күккә кабат-кабат.
Һәм — муенда камыт! Ыңгырчактан
Җанны тетрәндереп сынды канат.

Сүнде шулчак барлык аръякларга
Томырылып чыгар очыш уты.
Тынды шашып артка шуган дала,
Мәңгелеккә тынды... Кинәт сукты
Фәрман биргән иң беренче камчы!
...Аягүрә йоклый эш атлары.
Очып түгел, тартып үтелде шул
Гомеркәйнең юлы, сукмаклары.

Көйсезләнгән нәни малай кайда? —
Колын чакта күрде Тулпар, күрде
Һәм кешнәде шуңа беренче кат —
Канатлыга җирдә сәлам бирде...

Канатташым, ник дәшмисең миңа?
Үз иттеңме камыт-ыңгырчакны?
Арбалыдан сындырттыңмы әллә
Йолдыз моңы сеңгән пар канатны?

...Җил сызгыра абзар кыегында.
Дала түрләрендә яна утлар.
Колын төшен күреп карт ат йоклый —
Тере алаша һәм үлгән тулпар.

## Чык төшкәндә Парнас тавында...

*(Хәсән ага Туфан истәлегенә)*

Йолдыз нурларыннан елтырашып
Чык төшкәндә Парнас тавына,
Чакырадыр Туфан чордашларын
Җылынырга
Шигырь янында.

— Кая гына ашыгасың, гомер?
Ашыкмачы, гомер, туктале —
Дастан-дастан булып актарылып
Укыла бу Вакыт китабы...

Әнә...
Тузанлы юл... Муенчаклы этләр
Ике яктан ырлап барганда,
Мәңгелекнең утлы бер төшендә
Таң гөлләре яфрак ярганда,
Юата бит Муса йөрәгендә
Бөре төрткән яңа шигырен:
«Юк, этләрдән мин талатмам сине,
Без яшәргә тиеш, кадерлем!

Исememне таласыннар этләр,
Язмышымны кара ком бассын! —
Мин курыкмыйм хәзер киләчәктән —
Син бар, җырым, тугры юлдашым!...»

...Күз алдына китерәдер Туфан
Эшафотта чагын Мусаның.
— Җырың хәбәр бирде...
Исемеңне
Эттән талатмабыз! Хуш, җаным...

...Йолдыз нурларыннан җемелдәшеп
Чык төшкәндә Парнас тавына,
Чакыр, Туфан, безне — яшь буынны —

Җылынырга
Шигырь янында!

Яудан җиңеп кайткан ил батырын
Сырып алган сыман малайлар,
Язмышның нәкъ үзен күргән кебек
Текәлгәнбез — саф моңнардан хасил
Сабый күзле ап-ак бабайга.

...Сөйләгәнгә микән
Ялгыз гына
Җанындагы кайгы-шатлыгын
Һаман башын куеп ак каенга —
Чәчләрендә каен аклыгы?

Елмая ул:
— Ни хәлләрдә яши
Бу дөньяның шагыйрь милләте? —
Тукайстан дигән изге илдән
Вәкаләтле илче гүяки...

Тукай, әнә, ябык иңнәренә
Халык өметләрен күтәргән.
Ярасын ул шигырь
Вөҗданыңа,
Намусыңа калкан итәргә.

Ишетәсезме, канлы Моабиттан
Нәкъ сезгә бит Муса эндәшә:
— Эттән талатмагыз туган илне,
Мин китәмен, Илем, син — яшә!

...Сынап карый безгә ил агасы,
Карашында — зәңгәр томаннар:
«Җыр хакына
Гомер багышларга
Кайсыгыз соң әзер, туганнар?..»

## Болытлардан аста

*Галим Равил Фәхретдиновка*

Җиргә сеңгән күләгәләр сыман
Эз калмасмы безнең гомердән,
Самолеттан төшкән күләгәдәй
Шуып кына үтсәк бу җирдән?

Канат asларында —
сөргән кырлар.
Талны назлап ага якты су.
Капша,
фотообъектив,
мәңгелекне,
Терелт
Фаҗигалар Атласын!

Яра булып җиргә иңгән нигез
Тирәннәрдә нинди төш күрә?
Нигә генә һаман телгә килми,
Берни әйтми
Аэрофотосурәт?

Уян, сөйлә, һәлак булган токым!
Аваз килә тирән дәвердән:
— Самолеттан түгел,
коштан төшкән
Күләгәдәй үттек без җирдән.

Сезнең самолетка караганда
Кошның күләгәсе зур күпкә —
Нәтиҗәләр чума тирәннәргә,
Омтылышлар, юкса, гел күккә!

...Кара бәйдән типкән кан табыдай
Сөргән кырда
кемнең нигезе? —
Уят безне, уят, археолог,
Кузгат караңгылык диңгезен!

Дастан моңнарына сеңгән көлне,
Көлгә сеңгән моңын дастанның
Без тоярлык итеп терелтергә
Җаны җитәр микән, археолог,
Күккә менгән фототасманың?

...Болытлардан аста —
ак самолет.
Оя кора җирдә пар тартар.
Микрофонын суза
Чал Тарихка
Чая археолог —
репортер.

# Миргазиян Юныс

# ТАҢДА БОСФОР АША

ПОВЕСТЬ



Тышта буран. Февраль җиле улый, бәргәләнә, тәрәзә капкачларына кар томыра. Өй җылы. Өйдә тыныч. Өйдә табагач тавышы. Кызган май исе килә безнең өйдә. Әнием бүген тәбикмәк пешерә.

Кушма Штатларда тынычлык юк. Анда забастовка. Америка укытучылары дәресләрен ташлап, эш хакын күтәрүне сорыйлар. Кушма Штатларда мәктәпләр ябылган.

— Әмерек балаларын әйтәм. Надан кала бит инде, и-и, мескенкәйләрем,— дия-дия әнием, табагачын мич каршына сөяп, миңа таба борылды.

— Калмаслар, борчылма,— әниемне юатырга тырышам.

— Соң бит, әйтеләр. Ишетмәдеңмени? Сабаклары тукталды, диделәр бит. Акча даулап, сабыйларны надан калдырырга? Бер гөнаһсыз мескен балаларны...

— Юкка башыңны ватма инде. Эш хакы өстәү белән укый башларлар. Башка кайгың юкмыни синең?

Әнием кабаланып табасын мичтән чыгарды:

— Шул мескеннәрне кайгыртып тәбикмәгемне көйдергәнмен. Тутаның сафхуз мәктәбендә укытып йөргән чагы хәтереңдәме синең?

— Бераз хәтерлим шикелле. Ул анда күпме укытты? — Күз алдыма апамның нәкъ шушындый ачы буранда юлга чыгып китүе килеп баса.

Сугышның икенче елы иде. Февраль, тышта көчле буран. Апам Шалты совхозында укыта. Шалты совхозы Караярдан утыз чакрым. Ул юлга чыгарга җыена. Тез астына җитеп торган авыр ике толымын сырма астына яшерде. Башына калын шәл бөркәнде. Гәүдә ябык. Борчулы соргылт зәңгәр күзләр... Мин үземчә аңа киңәш биргән булам: «Ике кесәңә дә авыр таш салып чыкмасаң, үзеңне җил очыртып алып китәр...»

Язмышын ачы буран кулына тапшырырга торган апама шул чакта җылы сүз әйтә алмый калуыма йөрәгем әрнеп куйды.

Әнием чыжлатып табага камыр агызды. Табаны мичкә куйды:

— Төгәл ике ел укытты ул. Аяктан егылып, өзлеккәнче йөрде. Якшәмбе кич аркасына ярты капчык бәрәңге асып чыгып китә иде,

---

МИРГАЗЫЯН ЮНЫС *(1927) — Татарстанның Баулы районында туган. Прозаик. «Толлы җил», «Энҗе эзләүчеләр», «Шәмдәлләрдә янә утлар яна» һ. б. китаплар авторы. Мәскәүдә яши.*

шуның белән дә атна буе яши иде. Шимбәдә, төн урталары уткәч, тагын кайтып керә иде гөлекәем. Көзге яңгырларда, раштуа бураннарында, ташу ташыган чакларда дисеңме — бер генә мәртәбә дә кайтмый калган чагы булмады. Ул бит, бәбкәм, өй җанлы иде... Исендәме икән, сугыш елларында безнең тирәдә бүре күбәйде. Сугыштан куркып, безнең якка качып килделәр дип сөйләде картлар. Мескенкәем, ничә тапкыр бүреләргә юлыкты. Шул куркуларга, капчык-капчык бәрәңге күтәреп йөрүләргә чыдамагандыр инде бәбкәемнең йөрәге? — Әни яулык чите белән күзен сөртеп алды.— Ул өзлеккән көнне син Ютазыга олау белән киткән идең. И-и-и раббым. Һаман сине көтте. Арба тавышы ишетү белән башын түшәктән күтәрә дә: «Инәкәй, карап кер әле, Габдрахман түгелме икән?» — дип сорый. Сине күрү белән күзләре йомылды мәрхүмәнең. Күрү куанычы җан бирүен җиңеләйткәндер инде...

Әниемнең тагын бер тәбикмәге көйде. Үзе һаман яулык чите белән күзен сөртә, тавышсыз гына елый, үзе радио сөйләгәнне тыңларга да өлгерә.

— Ул чакта аңа ничә яшь иде?

— Егерме тулырга ике генә ай калган иде. Аны бит унны бетерү белән укытырга җибәрделәр. Ул чакта ун класс бик зур санала иде. Унны бетергәннәр авылда күпме булды икән? Өч-дүрт кешедән артмагандыр... Әмерек балаларын әйтәм... Мескеннәр, артта калырлар инде. Ярый да куып җитә алсалар...

— Җитәр инде, әни. Гел юкка борчыласың. Башка кайгың юкмыни? Атна эчендә куып җитәрләр. Университетта безне ай ярымга бәрәңгегә җибәрәләр иде. Аңа карап артта калдыммы соң?

Мичтә карабодай тәбикмәге пешә. Өй эченә җәйге чәчәкләр, басу исе таралган. Тышта буран. Йорт эчендә бары тик туган ояда, әниләр янында гына була торган изрәткеч рәхәтлек. Мин эреткән каз мае, кәрәзле бал, чәчәккә күмелгән карабодай басуы тәмен сулап утырам. Каршымда мавритан ысулында уелган мич авызы. Эчтә, мичнең сул ягында, төсен югалтып карала башлаган күмер өеме. Әнием кайнар табага чажлатып сыек камыр агыза, читеннән табагач белән эләктереп, табаны мичкә тыга, күмер өстенә утырта. Уң якта дөрләп янып яткан каен чыбыкларыннан таба өстенә ялкын телләре сузылган. Тәбикмәк астын кайнар күмер, өстен байрактай җилфердәп торган ялкыннар кыздыра. Алдымда бер өем тәбикмәк.

Мичкә янәшә стенада башына йолдызлы шлем кигән кызылармеец, Колчак солдатын штык белән эләктереп, биек ярдан Тын океан дулкыннарына ыргытырга җыена... Плакат астына: «И на Тихом океане свой закончили поход»,— дип эре басма хәрефләр белән язып куйганнар. Тукта! Бу рәсем нәкъ әниемнең намаз укыган җирендә эленеп тора. Сәер тоелып китте. Бу стенага бернинди сурәт элергә ярамый... Ни сәбәп? Кинәт аңлап алдым. Сәбәп көчле. Аның шәригать кануннарын җимерергә көче җиткән. Мин армиядә. Әнием ялгыз. Ул ялгызлыктан туйган, арыган, тәмам гарык булган. Аңа иптәш кирәк. Әнием үзенә иптәш итеп кызылармеецны сайлаган.

Буран тәрәзәгә кар томыра. Җир җылый, бөтен дөнья үкерә, яшь түгә. Күктән төшкән арада туңып карга әйләнергә өлгергән күз яше коела. Җил ач бүре тавышы чыгарып торбада улый. Бу тавыш мине куркытмый. Мичтә утлар яна. Мичтә янган каенның саф, рәхәт җылысына изрәп, мин тәбикмәк ашыйм. Мичтән бөркелгән матди җылылыкка әниемнең йөрәгеннән чыккан мәрхәмәтле кайгырту, аның күңелендәге игелекле теләкләре өстәлгән. Дөнья тигез. Миңа дөньяда башка берни кирәкми...

...Иркен кырлар, киң яланнар өстеннән каңгылдап кыр казлары оча. Аксыл зәңгәр күктә торналар тавышы. Мин тау битендәге чирәмгә кырын ятып курай уйныйм.

Каршыдагы калкулыктан, терекөмештәй саркып, елкы көтүе елга буена агып төшеп килә. Калкулыктан сулдарак, уйсу җирдә карабодай

басуы өстеннән ак дулкыннар йөгерә. Җир йөзе бернинди кысанлык, бернинди мәҗбүрилек белән чикләнмәгән. Тирә-якта иркенлек. Тәндә көч. Күңелдә табигый горурлык һәм хәйләкәр кануннарга буйсынмаган азатлык. Каз мае, каклаган каты казылык, карабодай тәбикмәге шушы тарих белән сеңгән сәер сурәтләрне ясап, күз алдыма китереп бастырды.

— Улым, кала җирендә нәрсә белән кунак сыйлыйлар?

Сискәнеп киттем. Каңгылдап очкан кыр казлары, иркен яланнар, торналар тавышы, туплауга төшеп килгән елкы көтүе, дулкынланып яткан карабодай басулары сүнде, күздән югалды.

— Кала халкы салат ярата,— дидем мин бер тын уйлап торгач.— Аларга витаминлы аш тансык.

— Анысы нәрсә тагын?

— Витамин дигәннәре, әни, шул кузгалак, какы, кычыткан, балтырган шикелле үләннәр инде. Кала кешесенә шул җитми. Кеше шуңа авырый, шунлыктан тиз картая.

— Бәй, алай булгач, каланы ташлап, авылга кайтсыннар. Без бит син әйткән үләннәрне сыерга ашатабыз.

— Юк, кайтарып булмый шул инде аларны...

Әнием АКШ балаларын кызганудан туктап, шәһәрдә яшәүчеләр турында борчылырга тотынды:

— Тиз картаялар дисеңме? Менә сиңа! Без бит кузгалакны кытлык чакта ачка үлмәс өчен генә ашый идек...

* * *

Күзем кинәт мичтән чыгып килгән табага төште, дөресрәге, таба читендәге китеккә. Өченчедә укый идем мин ул чакта. Бәйрәм көн. Кайсы бәйрәм икәнлеген хәтерләмим. Камыр өлгерүгә, табабыз күршедә булуы ачыкланды.

— Габдрахман, табаны Бәдигыльҗамалттәңнәрдән алып чык. Тиз бул, камырым ташый башлады,— диде әнием хафаланып.

Табаны баш түбәмә каплап күршеләрдән чыгып киләм. Иптәшләрем гөж килеп чана шуалар. Мин исә — эш кешесе. Дусларың уйнап-көлеп чана шуганда мондый эш авыр, мәрхәмәтсез тоела... Эш түгел бу, уеннан аеру... Табага утырып инеш ярыннан төшкәндә мин шундый бәхетле идем. Таудагылар дикъкате бәхетне бермә-бер арттыра. Иптәшләрем чана шуудан туктап, миңа карап торалар. Бозга бәрелеп таба чите кителеп чыккач кына айныдым. Әнием мине кыйнамады. Ялгыш эшләгән. Һавадагы торналар артыннан ымсынып йөрүче бу малайны шул чакта ук каты тотып, кыйнап биздерергә кирәк булган, күрәсең. Инде миңа егерме сигез. Сабакташларымның күбесе «башлы-күзле», кайберләре — өчәр бала атасы. Мин һаман «башсыз-күзсез»...

Борынгылар яшәү серен бездән яхшырак белгәннәр. Чыннан да бит, семьялы кеше баш белән уйлап, күз белән күреп эш итәргә тиеш. Минем ерак бабаларым чорында хатын, балалар өчен җаваплылык ифрат катгый булган.

Ә миндә әле һаман шул чана шуу чорындагы файдасыз мавыгулар.

Әниемне күзәтәм. Эшкә тотыну белән ул яшәреп китте. Бөтерелеп йөри. Өлгер, җыйнак һәм һаман матур. Күңел тирәнлегендә мин күргән һәр нәрсәнең бәясе язылып калган бер кулланма бар. Шул кулланманың иң кыйммәтле, иң бөек үзәгендә — әнием һәм туган җирем. Мин аны «абсолют нокта» дип атар идем. Җир йөзендә аларга тиң башка бер нәрсә юк һәм күп нәрсәләрнең асылын шул чиксез бәя белән чагыштырганда гына аңлап була.

Нилектән кешене эш матурайта, нилектән яшәртә икән? Гаҗәп. Мин шул турыда баш ватам. Мәскәү консерваториясенең Кече залында орган музыкасын тыңлаган кичә исемә килеп төште. Шубертның «Аве Мария»сын уйнаучы органчы карт та яшь һәм матур иде. Жданов-

тан Потига барганда кочегарлык вазифасын башкаруым хәтергә төште. Мичкә күмер ыргытканда кочегар Емельянов та шулай яшь һәм матур иде. Адәм балалары эш һәм вазифа мохитендә яшиләр. Кешенең башкарган эшен күрмичә аның яхшымы, яманмы икәнлеген әйтүе кыен. Кешене аның социаль катламына карап кына бәяләүне тарих дәрьясы һаман юа, ул инде юкка чыгып бара. Өстеңә алган эшеңне, аның нинди булуына карамастан, сыйфатлы башкарырга тиешсең. Осталыкның югары бер ноктасында иҗат башлана. Шул илһамландыра, шул матурайта, яшәртә адәм баласын. Әнием, илһамланып, тәбикмәк пешерә.

Өченче көн әнием Турай базарыннан ярты пот карабодай алып кайтты. Кичә иртән хан заманыннан калган кул тегермәне — яргыч чардактан төште.

— Сакланган икән бу нәрсә. Мин аны күптән чүплеккә эләккәндер дип йөри идем,— дидем мин гаҗәпләнеп.

— Бабаңның төсе бит. Бабаң хакына сакладым,— дип аңлатты әнием.

— Азапланмыйк, әни. Кул тегермәне белән хәзер кем ашлык тарта? Үзем тегермәнгә илтәм.

Әни моңсу гына елмая:

— Беттеләр алар, су тегермәннәре. Буалар да бетте. Каз-үрдәк тотарга суы да калмады.

— Онны кайда тартасыз соң?

— Кәҗүннәйне алып ашыйбыз. Без, карчыклар, шулай, ипине үзебез пешерәбез. Яшьләргә он әллә бар, әллә юк. Алар әзерне яраталар. Кәҗүннәй ипекәй дә тәмле, гөнаһлы буласым килми.

Миңа тәбикмәк ашатыр өчен әнием күпме җәфа чикте. Унбиш чакрым җирдән карабодай күтәреп кайтты. Киптерде. Җилгәрде. Кул тегермәне аша үткәреп онга әйләндерде, иләде, чүпрә ясады, камыр куйды, мичкә якты. Менә хәзер янып-пешеп тәбикмәк пешерә. Күпме көч, күпме вакыт әрәм булды? Җитештерүчәнлек түбән, нульгә якын. Безнең буын эшне җиңеләйтергә өйрәнде. Һәм шул җиңеллеккә ияреп, нинди нәтиҗә бушлыгы, нәрсәдер җитмәү тойгысы килде.

Һәр башкарган эш әниемә табигый тантана, балалар уенындагыдай саф, мөлаем куаныч бирә. Әнием самавыр утырта:

— Син хәзер мәтрүшкәле чәйне өнәми торгансыңдыр инде?

— Сагынып кайттым. Яса гына, әчәм.

Чәй янына бал, каймак, кызыл эремчек килде. Өстәлдәге ризыклардан өйгә нур, бәйрәм тантанасы таралган. Аракысыз мәҗлесләр чоры искә төште.

— Каян алдың бу ризыкларны?

— Каймак белән эремчекне Хәдичә китерде,— диде әнием.

Авызымдагы тәбикмәгем тын юлына тыгылды. Үземне көч-хәл белән кулга алдым. Шаярып сөйләшергә тырыштым:

— Балны да кеше китердеме?

— Умарта тоткан чактан калган бал.

— Авылда умарта тотучылар бармы соң?

— Картлар тота. Яшьләр мәшәкатен өнәмиләр. Кибетләрдә шикәр тулып ята. Акча күп. Мин бәләкәй чакта шикәрне иң кадерле кунакка гына куялар иде. Көн саен ашарга — бал. Хәтереңдәме икән, келәттә егерме дүрт чиләк сыешлы кисмәк бар иде. Әби патша заманында урыс бояры безнең авылның иң әйбәт басуларын закунсыз кисеп алган. Безнең Караяр халкы бик үзсүзле бит. Алар элек тә беркемгә баш бирмиләр иде. Сәнәк күтәреп барып, боярны утарыннан куганнар. Бояр гаскәр чакырткан. Фетнәгә катнашучыларның маңгайларына тимер кыршау сугып, Себер җибәргәннәр. Шул чакта бабаңның бабасы елдан артык шул кисмәк эченә качып яткан.

Бала чактан таныш вакыйгалар. Мин шундый хәтерләүләр, тыл-

сымлы риваятьләр эчендә үстем. Мин әле вакыйгаларны тарих белән, тарихны халкымның язмышы белән бәйли белми идем.

Җир өләшү, килмешәк алпавытларның кара халык иманасын тартып алулары санап бетергесез казалар, афәтләр тудырган. Мин шуңа гаҗәпләнәм: маңгайларына тимер кыршау сугып, Себергә озатып торганда да татар хатыннары тәбикмәк пешерү серен саклап кала алганнар. Тәбикмәк пешерү, җыелышып җырлау, дастан сөйләү, өмә ясап өй юулар, җыеннар, кардәшлек тотулар, туганлык саклаулар әкренләп һаман сүрелә, сүнә бара...

Чәй янында әнием белән Ыкның саегуы, урманнар сирәкләнүе турында кайгырып утырабыз. Әнием Бөгелмә белән Стәрлетамак, Богрыслан белән Азнакай арасындагы тауларны, мул сулы салкын чишмәләрне, чиялекләрне, җиләкле аланнарны, дару үләне үскән болыннарны, таш парына утыртканда кулланыла торган шифалы ташларны — тагын әллә нинди табигый байлыкларны белә. Хәйран калып тыңлап утырам. Ул бит агроном түгел. Аның дипломы да юк. Анализга алып, туган җир туфрагын тикшереп йөрмәгән. Кайсы кырда нинди ашлык уңганын, кай авылда кайчан чәчәргә, кай вакыт урырга кирәклеген әнием яхшы белә. Ерак бабаларның телдән-телгә күчеп, буыннан буынга тапшырыла килгән күзәтү нәтиҗәсе, көнкүреш тәҗрибәсе. Шуның бер өлеше минем әниемдә саклана. Әниемнең шушы байлыгы горурландыра.

Тәбикмәк ашаганда,әнием умарталарның мантымавын аңлатып алды:

— Тау Борынында ногыт чикләвеге үскәнен син беләсеңме икән? Ногыт куаклары арасында суер оялый иде. Баулыда нифет чыга башлагач, безгә бик күп читләр килде. Нифтәникләргә нәрсә? Алар Ыктагы балыкларны да шартлатып кына алдылар. Тау Борынындагы суерларны күрү белән атып бетерделәр. Суер беткәч, төклетура үрчи башлады. Ә төклетура бал кортын ашый. Суер булмагач, умарта асрап булмый. Корт мантымый. Ыкта балык бетте дип зарланалар, суер турында кайгыртучы юк. Ходай һәр җан иясен белеп яраткан. Кирәге булмаса, аны яратмас та иде.— Табын янында ул карнын гына түгел, күңелен дә туклandырды.

— Әхмәтсафа малае сабан туена кайткан иде. Ашка җыелган карчыкларга сөйләп утырды: мин хезмәт иткән җирдә ди, тирә-якта гел карурман. Якын-тирәдә шәһәр дә, авыл да юк ди. Ит кирәк булса, ди, мылтык алып урманга чыгабыз да, ди, кирәк хәтле киек атып алып кайтабыз, ди. Үзе синең шикелле ука погоннар тагып кайткан. Бик зур әфисәр диделәр. Баулыга барып, район балнисасында эшләүче бер бик әйбәт доктор кызны алып кайтты да шуңа өйләнеп китте.

Әниемне аңладым. «Офицер чакта өйләнгән булсаң, шундый кыз алырга синең дә көчең җитә иде»,— дигән киная иде бу.

— Бүген дә клубка бармыйсыңмыни инде? — диде әнием бераздан һәм, җавап көтеп, күзләремә карады. «Улым, клубта яшьләр белән аралашсаң, бәлки башлы-күзле итәрлек берәр кыз очратырсың»,— дигән өмет язылган иде әниемнең карашына. Ул борчыла. Әгәр кичләрен беркая чыкмыйча гел өйдә утырсам, әнием озын телләрнең: «Фәрихә малае ялга кайткач беркая чыгып йөрмәде — өйләнгән, күрәсең»,— дип гайбәт таратуларыннан курка иде. Авыл «телеграфы» шәфкатьсез. Әниемнең зирәклегенә кабат сокланып куйдым.

Борчылалар әниләр. Куркалар. Безнең язмышны кайгыртып, көнетөне ут йоталар. Ә без аларның алдагы борчылуларына сәбәпне табып кына торабыз. Аңламыйбыз без әниләребезне, ә алар аңлыйлар. Күз белән түгел, тойгы белән безнең һәр адымыбызны күреп, белеп торалар. Аларның мәрхәмәтле кайгыртулары шуннан.

Әниемнең мине «башлы-күзле» итәсе килә. Миллион кешеле гигант калада, бер-береңнең сулышын йотып яшәгәндә кызлар белән танышып булмаганны аңа ничек аңлатырга? Дөрес, күңел ачу, вакыт уздыру өчен кыз табуы шундый җиңел. Өйләнер өчен — ай-һай... Безнең Караяр кызы әле тәпи дә йөри башламаган, ә аның кияүгә чыккач нинди

хатын булачагын һәркем белә. Монда нәсел, токым өйрәнелгән, буыннар тәҗрибәсендә ныклап сыналган. Әхлак, иман мәсьәләсе — авыл халкына болары да мәгълүм. Безнең Караярда кемнең кемгә тиң булуын әллә кайчан белеп торалар, юрыйлар, җайлаштыралар. Һәм, әгәр шушы «фәнни» эшкә ышанасың икән — абынмыйсың. Уңган кызга уңган егет, чибәргә чибәр, уңмаганга ялкау өйләнә.

Элек безнең Караярда кызлар янына куна керү гадәте бар иде. Бу гадәт тышкы яктан бозыклыкка охшашлы. Яшь кыз белән яшь егет аулакта төн кунып яталар. Хурлык! Киресенчә, куна керү кануннары яшь егетне һәм яшь кызны җенси түземлеккә өйрәтә, аларның сафлыкларын чыныктыра иде. Бер кичне моңа кадәр абруйлы саналган егетне кызлар куна кертми башлыйлар. Егетнең даны чыга. «Ишеттеңме икән? Фәлән егет вөҗдансыз икән. Азгын! Берүк кызыгызны шул мөртәттән саклый күрегез». Андый егет безнең Караяр кызына өйләнә алмый. Ул читкә китәргә мәҗбүр була...

Клубка барырга җыена башладым.

* * *

Җиз кыңгырау тавышы ишетелде. Әллә урамнан кыңгыраулы пар ат үтәме икән? Тәрәзәдән карадым. Әнием сандыгын ача икән. Өй эченә нафталин исе аңкыды. Ак ефәк шарф, зәңгәр петлицалы хәрби тужурка, чиркәү иконасына тиң путалы, сусаль җизгә күмелгән авиатор фуражкасы сандыктан очып чыкты.

— Улым, шушы нәмәстәкәйләреңне ки, яме. Хәзерге яшьләр бик тә ыспай йөриләр. Сырма киеп клубка чыга күрмә, хур булырсың.

Аңлашылды. Ярлы киенеп кайтуыма әнием ут йотып, хафаланып йөргән. Кигән киемең синең күпме алып эшләвеңне, нинди урында утыруыңны, мөмкинлекләреңне күрсәтеп, әллә каян кычкырып торырга тиеш. Феодаллык чоры кануннары. Башкалары бетте — болары яши. Без шуңа күрә киемгә акча кызгана белмибез. Безнең бюджетны кием ашый. Сугыш елларында бер телем ипекәйгә бөтен дөнья малын бирергә әзер идек. Шул чордагы икмәк урынына мода килеп басты. Еллар буе җыйган газиз эш хакын «эһ» тә итмичә күн пиджакка, я булмаса «леви страусс» чалбарына бушатып ташлыйбыз. Нинди фанатизм мәҗбүр итә безне шушы дуамаллыкка? Акылсызлык!

— Боларны киярgә ярамый,— дидем мин һәм әни чыгарган киемнәрне кире сандыкка сала башладым.— Закон кушмый.

Әниемнең хәтере калды:

— Нигә ярамасын! Үзеңнеке бит.

— Мин бит хәзер офицер түгел инде.

— Районда эшләүчеләр дә бит әфисәр түгелләр. Үзләре гел хәрби киенеп, кыланып йөриләр.

— Гафу ит, әни, кимим. Хәзер бит киемнең модасы үзгәрде.

Сугыш вакыты түгел бит. Шуларны киеп клубка керсәм, бу мескен үзен һаман хәрби күрсәтергә тырышып йөри икән, дип кызганулары бар. Без горур нәселдән бит, әни, кызгануны яратмыйбыз.

— Улым, «муда» дигәннәре нәрсә ул? Берәр хастамыни?

Ничек аңлатырга?

...Исемә безнең чордагы модага каршы көрәшүләр килеп төште. Университетта укыганда без тар балаклы чалбар белән көрәштек. Тар балаклы чалбар кигән студентны президиумга сайламыйбыз. Кичләрен Горький урамында тар балаклы егетләрне милиция идарәсенә алып кереп, балакларын җөеннән сүтеп җибәрәбез. Көчебез бушка китте. Тар балак безне барыбер җиңде. Хәзер тар балаклы чалбарны көрәшчеләр киеп йөри. Инде сакал үстерүгә каршы көрәш башланды. Алдан әйтәм — сакал үстерү дә җиңеп чыгачак.

Сырма фуфайка кигән килеш авылдашларыма күренү үземә дә

оят тоела иде. Шинелем тузган. Эти мәрхүмнән калган кайры тунны киярга туры килде. Шунысы кызганыч — тун модасы безнең Караярга житеп өлгермәгән иде.

Әнием озатып калды. Мин киттем...

* * *

Яңа яуган йомшак карга басып, түбән очка төшәм. Көннең төнгә алышынган чагы — кичке эңгер. Авыл йортлары ашыгып ут алалар. Урам як тәрәзәләрдә мәрхәмәтле гаилә яктылыгы кабынып китә: эш вакыты чыкты — ял! Мич томаланган. Өйгә аш исе таралган. Балалар мәктәптән кайткан. Маллар ябылган.

Эш киемен салып ташлау белән йөрәктә көнозын йокымсырап яткан туганлашлык хисе уянганын сизеп аласың. Бер генә сәгать элек киңәшмәдә бригадирларны кыздыручы колхоз председателе чут-чут үбеп, баласын сөя. Бу кичнең кешелеклелек хисе уятучан сихәте карт хисапчыны кибеткә куып кертте, гаилә финансының дебет ягына зур зыян ясап, оныкка конфет алдыртты. Тракторчы көне буе тимер белән яңашә. Аның тракторы кансыз тимердән ясалган. Трактор көчле, кырыс, шәфкать белми. Йөрәгендә наз уянган чакта тракторны кочаклап юанып булмый. Авыл ирләре, үзләре дә сизмәстән, эчтән генә атның уйчан күзләрен, аның җылы сулышын, моңлы кешнәвен сагыналар. Трактор сыртында утырып арыган, бензин иснәп исергән тракторист сарыкларына печән сала. Хайванкайларның аяк атлаулары шундый йомшак, күз карашлары шундый җылы. Их, рәхәт тә соң сарыклар янында.

Тәүлекнең шушы өлеше безгә үзара шәфкать, ихтирам уяту йөзеннән бирелгән. Кичләрен тәнгә туганлык хисләре тарала. Нәкъ синең шикелле игелеккә сусап йөргән адәм баласына бер сәбәпсез җылы сүз әйтәсе, аркасыннан сөеп китәсе килеп, буыннар йомшара. Бәлки ул җылы сүзне бүген дә, иртәгә дә әйтә алмассың? Яхшылык эшләргә җай һаман килеп тормый. Эш анда түгел. Йөрәктә шәфкать тойгысы уяну — үзе бер бәхет. Зур, рәхәт яшәвеңне нурландырып җибәргән шатлык ул. Һәм син шул шатлыктан читкә борылма. Кеше исемен йөртү хакыйкате нәкъ менә шунарда...

Безнең урам очыннан шундый тойгылар кичереп барам. Бала чактан таныш, бала чактан якын кардәш йортлар. Алар мине тыйнак кына елмаеп озатып калалар. Сез бит минем урамымны өзелеп ятратканны беләсез! Сез бит үзегез бала чакта ук мине яратырга өйрәттегез. Аналарга тиң мәрхәмәтле сез, авыл йортлары! Нәрсә телисез сез миңа: бәхет-шатлыкмы, авырлыкмы? Беләм — сез миңа яхшылык телисез. Мин сезне шуңа күрә өзелеп сагындым.

Күземне йомып, бала чагыма кайтам. Әллә клубка барасы урынга һәр йортның эченә кереп, бала чактан таныш мичләрне, сәкеләрне, бизәкле сандыкларны сыпырып, назлап йөримме икән?

Дустым Әбелкарәмнәр йорты. Ишектән керү белән, сул якта зур яшел сандык, анда — акшарлы мич, каршыда — киң сәке. Сәке белән сандык арасында буяусыз, сөян тактадан ясалган аксак өстәл. Сәке өсте, мич читенә турылап, чаршау белән икегә бүленгән. Чаршау артында аш-су әзерләнә. Өй эченә чит ир-ат кергәндә Сәүрәттәй кызларын алып шунда кереп утыра. Бу йортта мин Йосыф белән Зөләйха, Әбугалисина тарихын, пәйгамбәрләр кыйссасын тыңладым. Күпме әкият, ни хәтле мөнәҗәт, җыр, тарих, татлы хәким сүз! Күпме хуҗалык гыйльме, мавыктыргыч, тормышта сыналган, кирәкле мәгълүматлар ишеттем мин бу йортта. Йорт хуҗасының кушаматы Хурдый, исеме Шәрифулла иде. Безнең Караярда кушаматсыз кеше булуын хәтерләмим мин. Караярлылар берберсенә бик зур дикъкать белән карап йөргәннәр булса кирәк. Кушаматлар шундый тапкыр, образлы, эчтәлекле иде. Хурдый Шәрифулласы, Шырый Шәрифулласы, Кара Шәрифулла, Ярпач Шәрифулла. Хурдый-

нықылар, шырыйнықылар, каранықылар, ярпачнықылар — болар аларның улларына, кызларына, оныкларына тагылган исемнәр. Кушамат чыгаруда мәҗүсилек чорыннан исән калган йолалар серен сизәм мин.

Әбелкарәмнәр йортының күзләре йомык. Череп ава башлаган бүрәнә койма аша үрелеп эчкә карыйм. Ишектә түбәтәй зурлыгы тутык йозак. Тәрәзә капкачлары тапкырлау билгесе рәвешендә кадакланган. Шәрифулла агай белән Сәүрә апа мәңгелек йортына күчкәннәр. Әбелкарәм белән аның өлкән абыйсы Зәкиулла Сталинград өчен сугышканда вафат. Минем сабакташым Саимә инде дүрт бала анасы. Менә кем бай! Кече кызлары Рәисә, Мәскәүдә төзелештә эшләгән җиреннән кияүгә чыгып, Таҗикстанга киткән. Уртанчы уллары Мөрсәл — колхозның өлкән механигы. Ул аерым йорт салып, башка чыккан, хәзер шунда тора. Заманалар... Иске оя тузган, картайган, хәлсезләнгән. Череп аварга тора. Йорт гомере дә шактый кыска шул... Шактый кыска — кеше гомере кебек.

Бусы Аксак Йосыф йорты. Ул патша заманында — стражник. Колхоз чорында — авылның иң ярлы, иң ялгыз кешесе. Йосыф агайның хатыны Мәдинә карчык ишан хәзрәт, хаҗи кызы булган. Мәдинә карчыкның әтисе шәкерт чагында ук Мәккәгә хаҗ кылырга барган. Акчасы әз булган, күрәсең, барырга гына җиткән. Кайтыр мөмкинлеге булмагач, шәкерт Мисыр корабына кочегарлыкка ялланган. Шул корабта берничә ел йөзгән, Һиндстанны, Кытайны, Индонезияны, Африка илләрен күргән. Ул кеше тылмач булып та караган. Мәдинә карчык гарәп, фарсы, борынгы төрки телләрен су кебек эчә, русчаны да сукалый иде.

Аксак Йосыфның күз нуры кебек күргән бердәнбер кызы Мөнәвәрә районда Осоавиахим[*] председателе булып утыручы безнең нәсел Харис абыйга гашыйк булып акылдан шашты. Бәлки Харис абый да Мөнәвәрәне яраткандыр. Ул кызга гашыйк булудан тыела алыр өчен, ай-һай, нинди гайрәт, нинди зур ихтыяр көче кирәк булгандыр? Аның матурлыгы турындагы дан Уфа, Оренбург тирәләренә кадәр барып җиткән иде. Харис абый стражник кызына гашыйк булып дан чыгарудан курыккан, күрәсең. Ул башкага өйләнде. Кәләше чибәр иде. Районда эшләгән кешегә кем дә чыга инде ул чорда. Тиздән җиңгәчәй кеше тол калды. Сәбәбен беркем белә алмады. Харис абый авылга, әтисе йортының ишегалдына кайтып, үзен-үзе атып үтерде. «Бер матурны ташлап икенче матурга өйләнгәннең бәхете булмый»,— дигән сәер нәтиҗәгә киләләр авыл картлары.

Йортлар яныннан түгел, тезелеп утырган язмышлар, тетрәндергеч тарихлар яныннан узам. Мин аларны җаным белән диярлек сизеп узам. Авыр, газаплы миңа шулар белән очрашу.

* * *

Бригада йорты. Фәндә социализация дигән бер термин бар. Акыл җыю, аңга ирешү юлында үсмерләр җәмгыять һәм шәхес, шәхес һәм җәмгыять арасындагы мөнәсәбәтләрне, җәмгыять институтларының көнкүрештәге урыннарын, вазифалар бәйләнешен үзләштерәләр. Бәндәдән шәхескә әверелү нәкъ шушы юлда барлыкка килә. Тормыш гыйльмен без шушы йортта үзләштердек. Нәрсәләр генә ишетмәдек без монда. Ниләр генә күрмәдек. Челем көйрәтүгә, чыбыркы ишүгә, тормыш дипломатиясенә, һәр кирәклеккә без шушында өйрәндек. Яхшылык белән яманлык, хакыйкать белән ялган арасындагы чикнең яшерен булуын, аның туктаусыз маскировкага кереп торуын без шушы йортта белдек.

Безнең Караяр авылы дүрт кисәктән тора. Әтәмби ягы, Ур, Казан кешесе һәм Балтач. Әтәмби халкы җыелышта иң артта утыра. Әтәмбиләрнең яшәү кагыйдәсе — кәҗәсе кыйммәт түгел, мөэзәге кыйммәт. Ур якта йомык халык яши. Әз сүзле, сак, җиде кат үлчәп, бер кат кисә белүчеләр. Аларның юмартмы-саранмы, тырышмы-ялкаумы, тугры-

мы-түгелме икәнлеген үлсәң дә әйтә алмыйсың. Казан кешесеннән укытучылар һәм тире җыючылар чыга. Балтачтан, гадәттә, председательләр һәм милиционерлар. Картлар, Караяр авылы Казан кешесе өлешеннән башланып киткән, дип сөйлиләр. Моның үзенә күрә сере дә булырга тиеш.

Казан кешесе урамына җитәрәк сулга борылдым. Алда — күпер. Күпергә кергәч бер тын инешкә карап тордым. Су боз астында калган. Кер юарга бәке тишеп куйганнар. Бәкедән пар күтәрелә.

Күпергне чыккач, үргә менә башладым. Үр өстенә Ватан сугышында һәлак булганнарга һәйкәл куйганнар. Шул һәйкәл янына килеп туктадым, башымны иеп, уйга калдым. Шушы һәйкәл янына килеп туктау белән үз бәхетем, үз иминлегем турында кайгырту юкка чыга. Үз кирәген өчен генә яшәү оят тоела башлый. «Бәхилме сез шулай иртә, шулай вакытсыз, шулай аяусыз үлүегезгә?» — дип сорыйсым килә һәйкәлгә язылган исемнәрдән. Һәйкәл астына беркем күмелмәгән. Тактага язган хәрефләр генә бар. Җаныңны тетрәтә торган хәрефләр.

Без сугышны гадел һәм басып алу сугышларына бүләбез. Җир йөзендә үлемсез сугышның булганы юк әле. Минемчә, яшәештә иң дөрес юл — бәхәсле мәсьәләләрне ызгышсыз, акыл һәм гаделлек белән хәл итү. Без шуңа кайчан ирешә алырбыз икән?

Авыл клубында «Кубань казаклары» дигән кинофильм бара. Караярда тагын бер яңалык: кино тавышын тышка, авыл Советы бинасы каршындагы мәйданга чыгарганнар. Баганага элгән динамикның тимер тамагы авыл өстенә «Каким ты был, таким и остался» дигән җыр көен тарата. Гашыйклар җырлаган басынкы «Уел», «Сагыну» көйләренә күнеккән инеш буе таллары тимер динамик тавышын сәерсенеп тыңлыйлар.

Кинога керергәме, юкмы дип икеләнеп торам. Киноны мин кайда да күрә алам, авылдашларымны — бары тик шушында гына. Кино мәхәббәте шактый туйдырган. Йөрәк сусаган мәхәббәткә һаман көч җитми. Тәвәккәлләп, идарә йортына таба юл тоттым.

* * *

Сөйләшү безнең күпме вакытыбызны ашый. Сүз исертә безне. Әңгәмә, гәп барган җиргә җыелсак, таралырга көч җитми. Идарә йортында бәхәсләшеп ярсыган ирләр тынычланыр өчен тәмәке көйрәтәләр иде.

— Менә тагын бер дезертир, урожай фронтыннан качып киткән кеше,— диде председатель Зәки абый һәм миңа урын күрсәтте.— Рәхмәт, Габдрахман, идарәне онытмавыңа. Исән генә кайттыңмы?

Председательнең адъютантлары, командирлары, штаб офицерлары, погонсыз сержантлар — барысы дәррәү минем якка борылдылар. Тәнем чымырдап китте. Үземне кулга алдым. Хәтта елмайдым. Авыр иде үземне элекке кайтулардагыча абруйлы тоту. Җилкәләрдә погон, маңгайда кокарда бар чакта һәр әйткән сүз ничектер ышанычлы яңгырый иде. Өстәвенә, өстемдә әтиемнең кара туны. Әтисенең тунын киеп йөргән кеше беркайчан үзен иркен, ирекле тота алмый.

— Сабакташ? — диде бригадир Хаҗип хикмәтле көлемсерәп.

Их, өстемдә күн пальто булса әйтер идем мин сиңа!

Бу сорау турыдан-туры касыгыма тондырды. Егылмадым. Күз алларым караңгыланып китсә дә,сиздермәдем.

Без Хаҗип белән беренчедән башлап бергә укыдык. Дуслашып йөргән чаклар да булды шикелле. Сугыш башлангач, бергә мәктәпне ташлап, сабанга чыктык. Бергә яшьтәш булып йөрдек. Кырык дүртенче елны безгә военкоматтан повестка килде. Икенче көнне Хаҗипның бездән, үзенең яшьтәшләреннән, ике яшькә кече булуы ачыкланды. Дөньяда ниләр булмый. Башка вакытта бер елны . туып, бер класста укып үскән кешенең капыл гына ике яшькә кечерәюе әллә ни әкәмәт тә

тоелмас иде. Сугыш вакыты төгәллеккә өйрәтте. Хаҗипның әтисе кибеттә сатучы иде. Кайбер сатучылар күз буарга, фокус күрсәтергә өйрәнәләр бит...

Без каралып кайттык. Хәзер без — «никрутлар». Хаҗип кичләрен урамга чыкмый башлады. Ул безнең армиягә китүебезне көтә иде. Караярда тәртип бозу әллә ни зур гаеп саналмый. Баламишкинлык, шәкүрлек көчле безнең авылда. Армиягә китүдән, гадел хезмәт итүдән, сугышта батырлык күрсәтүдән миллиметрга тайпылу да жуелмаслык җинаять санала. Андый гаделсезлек бәхилләнми. Армиягә киткәнче без намус суды ясарга тиеш идек. Ничек? Нинди юл белән? Әхлак кодексын бозарга туры килде. Сине бер кыз көтә дип ялганлап, Хаҗипны урамга чакырып чыгардык. Суд шунда булды. ...Ипи тотып ант итә алам — беребез дә Хаҗипның башына сукмадык. Аяк-кулларына да тимәдек без. Ул бит авылда калса да фронтка ярдәм итәргә тиеш иде.

Хаҗип — миннән үч ала...

— Мин Одессада яшим,— дидем бераз тотлыга төшеп.— Маршал Малиновский туган җир. Валентин Катаев, Ильф һәм Петров яшәгән кала.— Хаҗипка Одессада торуымны түшкә таккан орден итеп күрсәтергә тырышкан идем, сыеграк чыкты.

— Одесса барыбер башкала түгел инде ул, сабакташ,— диде минем ике яшькә кече яшьтәшем.

— Син, Габдрахман, укуыңны тәмамладыңмыни инде? — диде председатель миңа ярдәм кулын сузып.

— Ишетмәдеңмени, Зәки абый? Аны бит университеттан куганнар.— Хаҗип авызын ерып, тәмәкедән саргайган тешләрен ыржайтып көлде. Көчле кеше беркайчан да башкаларның бәхетсезлегеннән шатланмый. Юк, теге чакта без моны дөрес эшкәрткәнбез икән. Идарә ирләре минем якка борылдылар. Караяр егетенең университеттан куылуы аларга да кагыла иде. Безнең Караяр кешесен кимсетергә ярамый. Юк, ярамый.

— Кумадылар,— дидем мин.— Үзем теләп киттем.

Үзең теләп югарыдан түбәнгә төшү юк ул бу дөньяда. Шуңа күрә, сүземә беркем ышанмады. Түбәннән югарыга, өскә, өстенлеккә үрмәләү — безнең канда, күзәнәкләрдә. Күренекле урынга күтәрелгәч, төшеңтырнагың белән ябышып төшмәскә тырышу — бусы да катгый бер канун. «Ничек инде Мәскәүнең үзенә урнашып, аның иң зур, иң данлыклы уку йортында уку бәхетенә ирешеп тә шуннан үз теләгең белән кит? Юк, ялган бу»,— дип уйладылар алар. Мин рәнҗемәдем аларга.

— Укымадың түгел, Габдрахман, укыдың,— диде председатель, кабат ярдәмгә килеп.— Училище бетереп, маңгаеңа йодрык чаклы кокарда тагып кайттың. Авылдан беренче булып ярапланга утырып очтың. Энем, без синең сугыш вакытында районда беренчелекне алып эшләвеңне дә онытмадык. Авылдашларың турында начар уйлама син. Юк, авылдашларны онытмыйбыз без. Тыңла. Авылның абруйлы кешеләре алдында мин сиңа бер киңәш бирәм. Укымадың түгел, укыдың. Белемең җиткән. Укуның да чиге булырга тиеш. Артыкка киткән нәрсәдән рәт чыкмый, энем. Кайт авылга. Ярдәмчем Мирсәетне председательлеккә укырга җибәрәм. Кайт. Теләсәң, бүгенге көннән Мирсәет урынына үземә ярдәмче итеп утыртам,— Зәки абый дикъкать белән тыңлап утырган ирләргә карап алды да тәмәке кабызды.

Председательнең тәкъдиме Хаҗипне чөеп ыргытты. Аның чалкан барып төшүен, билләһи, үз күзем белән күрдем кебек. Нәкъ теге вөҗдан суды ясагандагыдай булды. Ярдәмчелеккә күтәрелүне, һичшиксез, ул көткән. Әнә ничек кызарды Хаҗип, бүртенде. Аскы ирене асылынып төште. Кызганып куйдым үзен.

— Синең университеттан куылуың безне борчыды,— диде партоешма секретаре Сәләхетдинов.— Ярый, синең яраңа тоз сипмик, энем. Онытыйк. Кайт син, Габдрахман. Төпләп. Эләктер бер укытучы кызны. Эшкә

тотын. Кулыннан эш килгән кешенең дәрәҗәсе — маршалга, академикка тиң бүгенге көндә. Эчми, колхоз милкенә кул тигерми торган кешене без стенага элгән портрет шикелле итеп тотабыз.

— Иптәш Сәләхетдинов дөрес әйтә,— диде колхозның өлкән механигы.— Син, энем, үсәрмен, күтәрелермен дип өметләнә торгансыңдыр? Бер абынган кешене кабат күтәрмиләр. Аның закуны шундый. Кайт авылыңа. Мәктәптә бер кашык суга салып йотарлык укытучы кызлар бар. Син бит вакытында кыз-кыркынның төшләреннән чыкмаган асыл егет. Бывший сталинский сокол, гармунчы. Давай, төплән. Куандыр әниеңне.

Авылдашларымның кыставы Хаҗипның капкасына кара дегет булып чәчрәп тора иде. Минем исә түбәм болытларга тиде. Э-э-эх, авылдашларым! Менә бит нинди безнең Караяр! Мин аларга ни игелек күрсәткән? Алар миңа ярып җаннарын бирергә торалар.

— Ашый калҗа, төнгә марҗа, нигә кайтсын илена,— диде Хаҗип, бераз айный төшеп.— Син, Габдрахман, безгә Одесса турында сөйләп җибәр әле...

Өйгә кайтырга чыкканда этләр өрүдән туктаганнар иде инде. Утлар сүнгән. Караяр авылы йокыда.

Койма янына килеп туктавымны үзем дә сизмәгәнмен. Челтәрле яшел койма. Таныш келәт. Таң алдыннан култык астыма гармун кыстырып шушы келәттән чыккан чакларым эчемне ачыттырып уздылар. Капка шыгырдавыннан куркып, койма аша чыга идем дә су буена житкәнче, кайнар хисләремә күмелеп, әкрен генә бара идем. Инеш буенда гармунымны тартып җибәрә идем. Ерак бабаларымның бәгыре сызлаудан туган моң Ык тугайларын үтеп, башкорт тауларына бәреләидe. Таулар басынкы гына ыңгырашып алалар. Гармун моңы кайтавазга әйләнеп кире Ык үзәненә төшә. Үткән яшьлегемне сагыну ачы төер булып тамагыма килеп утырды.

Аяк астымда яңа яуган гөнаһсыз йомшак кар. Ул да баскан саен ыңгырашып ала. Авылымның шифалы һавасын эчеп, әкрен генә өемә кайтам. Бу дөньяда үз өең, үз әнием, үз авылың булудан да кадерле нәрсә бар? Һәм ниндидер каһәрле көч мине шушы рәхәтлектән читкә, ятлар арасына, тынгысызлыкка куа. Нигә качам мин рәхәтлектән? Урман ягыннан ыңгырашып елаган тавыш тагын ишетелеп китте. Безнең тынгысыз, бәхиллек тапмый интегеп йөрүебезнең сере бәлки шушы шомлы тавыштадыр?..

Җил капканың әлгечен ычкындырдым, шыгырдамасын өчен күтәреп ачтым. Әнием салган тар сукмактан барам. Баскыч. Ишек биксез. Өйалды. Идән такталары коргаксыган. Шыгырдатмас өчен стена буеннан барам. Иплән кенә ишекне ачтым. Өйгә кердем. Рәхәт гаилә җылысы, иминлек, әниемнең газиз кайгыртулары — шуларның барысы берьюлы кысып кочаклап алды.

* * *

— Улым, мин сиңа коймак калдырдым. Мичтә. Алып аша.

Күзем кайнарланып киткәндәй булды. Ярый әле караңгы. Күпме еллар шушы рәхәтлектән, үз иркемнән мәхрүм яшәгәнмен. Тулай торак шыксызлыгы. Артыңнан калмыйча сине эзәрлекләп йөргән ярым ятимлек тойгысы. Тимер каюта. Үзара терәлә язып торган дүрт тимер карават. Аста диңгез суы чупылдый. Гудок тавышы. Әллә чыннан да колхозда калыргамы? Нинди кешеләр минем авылдашларым! Председатель нинди сүзләр әйтте. Калырга кирәк. Ә диңгез? Мәрҗән атаулары? Иртәнге бриз җиле белән пышылдап сөйләшүче пальма агачлары? Диңгез вәсвәсәсе күкрәгемә оялап өлгергән иде инде. Аның чакыруы, татлы нәзберек назы, катлаулы моңы мине агулап өлгергән иде инде. Шул наз уйнашчының хыянәте шикелле адым саен юлыма аркылы төшеп тора. Бу

рәхәтлекләр дә мәңге онытылмый. Кайсын сайларга? Ирек һәм киңлек кошы альбатрос тәкъдиренме, әллә коймак исенә күмелгән тынычлыкнымы?

«Әниең картайган көнендә ялгыз яши,— дип өзгәләнеп кычкырды иманым.— Йөрәгең бозмыни? Алтмыштан узган карчыкның бәләкәй арба белән урманнан утын ташуын, ачы бураннарда көрт ерып чишмәдән су кайтаруын күз алдына китереп кара әле? Бәгырең таш булса, ташлап китәрсең әниеңне...»

«Ана күңеле балада, бала күңеле далада»,— дигән картлар. Азатлык, иркенлек чорында туган бу әйтем. Заманалар башка. Яшьләр күңеле — зур шәһәрләрдә. Алар иркен даланы ташлап, кысынкы шәһәрләргә агылалар. Ниятемне үзгәртергә көч житми. Иманым үгетли: «Офыклар артындагы киңлек, андагы ireклек — мираж гына ул. Тышкы киңлек монда да житәрлек. Адәм баласына эчке ireклек, рухи азатлык житми. Синең ашкынуың, урын таба алмый интегүең шунлыктан. Киңлекләрне, иркенлекләрне күңелеңнән эзлә. Азатлык та шунда...»

Әйтерсең, ике яшь каенны жиргә бөгеп, шуларның очына йөрәгемне бәйләп беркеткәннәр. Ике каен ике якка тартып, жанымны икегә аермакчы була. Түзеп кара әле шушы жәзага!

— Тагын ач яттың инде. Әллә берәр жирең авыртамы? Нигә ашамадың? Хәдичә килгәние. Коймагымны мактады. Фәрихәттәй, син пешергән нәрсә тәмле була — юмартлыктан ул, диде.

— Нинди Хәдичә?

— Соң бит, бергә укыдыгыз. Сабакташың. Онытгыңмыни?

Әйе, онытгым. Күңелемне сызлаткан сагынуны тамыры белән йолкып ыргыттым... Университетта укыганда үз-үземне алдап, Валериянга гашыйк булырга тырышып йөргем дә онышу, юану, тынычлану өчен иде... Юк, минем аны искә алганым булмады... Кичә дә ул яшәгән йортның коймасы буена туктап тамагына тыгылган утлы төерне учы белән уып торучы мин түгел идем. Култык астына гармунын кыстырып, таңда келәттән чыгучы да ят, башка кеше иде. Юк, мин аны күптән онытгым...

— Казанга укытучылар жыелышына барып кайткан. Миңа чәй китерде. Сәйлүн чәе.— Әниемнең сүзләрендә үкенечле горурлык, яшерен офтану, йөрәк кенә сизә торган тагын әллә нинди катлаулы тойгылар бар иде. Акыл аларны аңламаска, инкяр итәргә куша. Их, йөрәк, син нигә акылга каршы баш күтәрәсең? Бел, мин бит акыл ягында. Акыл мине авырлыклардан сакларга тырыша. Ә син, йөрәк, гел кайгы-хәсрәт, борчулар өстәп торасың...

Син бит егет кеше. Житте. Тукта. Бәлки ул минем иске жәрәхәтләрне яңарту өчен юри килеп йөри торгандыр? Хатын-кыз ул...

Мин Сахалинда идем ул чакта. Хәдичәдән хат килде. «Габдрахман, кичер. Сине көтәргә хакым юк. Мин очландым...»

Авыру әнисен, ике сеңлесен һәм дүрт яшьлек энесен карый иде ул. Авыр иде аңа. Шуңа карамастан, барыбер укуын ташламады. Стипендиясен әнисенә жибәрә торды. Гаиләсен ачлыктан коткарыр өчен прокурорның йорт эшен карарга ялланды. Прокурорның хатыны баш врач, иреннән унтугыз яшькә өлкән кеше иде. Шул сволочь...

...Ул, билгеле, миннән жавап көткән. Кичерер дип өметләнгән. Ул көннәрне мин баш сыярлык әлмәктән, үткен пәкедән качып йөрдем.

Тагын йомшак түшәккә чумып яттым. Йомшак йон юрган ябындым.

— Әни, телеграмма килде. Мине эшемә чакыралар. Пароходым ремонтланып беткән, ашыктыралар,— дидем мин, һәр сүземнең ана кеше йөрәгенә аткан уктай тәэсир итүен сизеп.

Өй эчендә тынлык. Мөржә артында чикерткә сайрый. Урман ягыннан шул шомлы тавыш ишетелә. Шуңа кушылып әниемнең, иреннәрен кысып тешләп, тавышсыз елавы.

* * *

— Шушы гына булдымыни инде торуың? И-и-и улым...

Башка сүз булмады. Сүздәмени эш? Без, белемле кешеләр, очрагына карап, теләсә ничек сөйләргә, сүзне теләсә кайсы якка борырга өйрәнгәнбез. Кирәк чакта, алдан уйлап, сүзнең тәэсирлесен сайлыйбыз. Башка вакытта бары чират уздыру өчен генә, бер мәгънәсез дежур сүзләр тукыйбыз! Без оста. Әниләр андый түгел. Әниләр очракка җайлашып яши белмиләр. Дөрес, тойгылары әниемнең эчендә калды. Ул аларны яшерде, тышка чыгармады. Түзде. Әниемдәге түзем...

Без бер атна ялга кайткан арада да әниләр йөрәгендә җәрәхәт калдырып китәргә өлгерәбез. Һәм шуны тормышка, заманга сылтарга өйрәнәбез. Армия хезмәте, яңа төзелешләр, уку йортлары аналар куеныннан газиз балаларын суырып ала тора. Кала жиренең мәшәкатьсез, җиңеләйтелгән, ресторанлы, театрлы тормышы — менә кем аналарның кансыз дошманы. Ул суырып ала, сазлык шикелле ашыкмыйча тәмләп йота. Тиздән син баш өстендәге зәңгәр күкне күрми, сандугач тавышларын ишетми башлыйсың. Шәһәрдә джаз, әзер аш, чәйнәп авызыңа каптырылган әзер җан азыгы. Шәһәр тормышы — мираж. Анда җаваплылык аз. Андагы фани, түләүле куанычлар! Өч бүлмәле квартира — аны бит син үзең төземисең. Бирәләр. Өч бүлмә — җәннәт куанычы ул безнең заман кешесенә. Сатучы кызга өйләнү — тагын бер куаныч. Эш хакы янда кала. Машина сатып алу — бусы инде җиденче кат күкләргә күтәрелү бәхете.

Утын әзерлисе, бәрәңге утыртып чиләнәсе юк монда. Авыл егете тиз шәһәрләшә һәм һәр очракта диярлек муллыкта, җиңеллектә яши. Ә нигә шушы рәхәтлек аша һәр көнне йөрәге ачытканын сизә шәһәрләшкән авыл малае? Туганнар? Чишмә тавышы? Кичләрен чут-чут сандугач сайравы? Шәфәкъ нурларына күмелеп, тау битеннән борыла-борыла көтү төшүе? Безнең күңелне нәрсә ачыттыра? Авыл зиратына күмелгән ата-баба сөякләреме? Нәрсә тынычлык бирми безгә? Шәһәрдәге туклыкны без туган телне, ата-бабадан калган васыятьләрне биреп алдык. Менә нәрсә безнең йөрәк канына туктаусыз тоз салып тора.

Безнең тамырлар — туган-үскән җирдә. Башта тамыр өзелгәнен сизмисең әле. Аның булуын, кирәклеген дә белмисең, белем алып, һөнәр үзләштереп йөргәндә, өлкәнәя башлагач кына тамырсызлык сизелә. Гореф-гадәт безне ата-баба шәфкатенә, аларның яшәү ысулына, тормыш тәҗрибәсенә тоташтырып торган икән. Алар безгә кадәр йөз, биш йөз, мең ел элек яшәсәләр дә, бөтенләй үк үлмәгәннәр. Өзелгән тамырларны авылда калдырып, шәһәр туклыгына ирешкәч кенә авылда чакта җангa ашлама булып борынгыларның васыятьләре кереп торганлыгын тоя башлыйбыз. Шулардан колак каккач безгә акыл керә. Тормыш җиле тәгәрәтеп йөртә башлагач, син нәрсәгә генә тотынып карамыйсың. Җилгә каршы торырга тамыр юк. Шул шәфкатьсез җил сине аракыга, ялкаулыкка, әхлаксызлыкка китереп аудара. Тамырсыз агач корый. Тамырсыз үлән чери. Адәм баласы бит агачтан да, үләннән дә сизгеррәк. Дөнья иминлеге — тамырда.

Әнием тирән итеп көрсенеп куйды:

— Улым, шул парахудның кай җире безнең Караярдан артык?

— Без, әни, монда гасырлар буе бикләнеп яшәгәнбез. Пароход ул чит илләргә йөри.

Тагын тынычлык. Тагын морҗа артында кычкырган чикерткә тавышы ишетелде, тагын урман ягыннан шомлы тавыш килде. Әнием уйлый.

— Чит илләрдә синең нәрсәң калган? Анда бит тормыш ифрат авыр дип сөйлиләр. Мин көн саен радиудан тыңлап торам. Эшләргә эш житми, диләр. Хезмәт ияләрен бик җәберлиләр диләр. Барма, улым, мин куркам.

— Шул эшсезлекне, хезмәтияләрен җәберләгәнне үз күзем белән күреп кайтасым килә,— дидем мин ышандырырлык дәлил таба алмагач.

— Йөрмә, улым. Аларга ярдәм итә алырмын дип уйлыйсыңмыни? Кирәкми, ничек яшәгәннәр — шулай яшәсеннәр. Мин карт инде, аңламый да торганмындыр, кешенең яшәвенә катнашырга ярамый. Катнашу — гөнаһ эш, җәбер ул.

— Мин бит, әни, бөтенләйгә китмим. Бераз түз инде. Җир шарын бер тапкыр әйләнеп чыккач, Караярга кайтып, ындыр артына да чыкмыйча бикләнеп яшим.

— Әстәгъфирулла, дип әйт. Көфер булырсың. Түзмичә нишлисең инде. Үзем исән чакта башлы-күзле булсаң, балаларны карап, сөеп үстерермен дип өметләнә идем. Туган-үскән җирен бер тапкыр ташлап киткән кеше башка беркайда ямь таба алмый. Безгә шулай әйтәләр иде,— әнием күз яшен йотты. Ул аналарча тавышсыз елый белә.— Агачны үскән җиреннән суырып алсаң, кире утыртып буламы? Юк инде. Кемнеңдер каргышы төшкән безнең Караярга. Күпме кеше китеп олакты. Кайда алар, бәхет эзләргә китеп югалучылар?

— Алдан юрамыйк әле, әни. Әйттем бит, җир шарын урап чыгасым килә дип. Шул теләк тынгы бирми. Мине шул куып тора.

— Ярапланда очканда егылып сөякләреңне сындырып бетердең инде, бала. Инде суларга кереп китеп югалырга чамалап йөрисең. Пәйгамбәрләр тарихында әйтелгән, Юныс пәйгамбәрне кит балыгы йоткан, дип. И-и-и бала. Шәвәли малае әнә районда эшли. Өстәл башында боерык биреп кенә утыра. Машина белән китереп куялар, машинага утыртып алып китәләр. Монда калсаң синең башың да шулай кадерле булыр иде. Мәктәптә син бит Шәвәли малаеннан алдынгырак булдың. Кайтсаң, син дә шундый гына урынга утыра алыр идең.

— Бер киселгән икмәк телемен кире ябыштырып буламыни? Сагынам мин Караярны, ә үзем нигәдер монда яши алмыйм. Әллә нишләдем мин.

— Сихерләгәннәрдер. Кал. Кәрәкәшледә бер бик әйбәт өшкерүче бар. Шуны чакырып имләтеп карармын. Терелерсең, алла бирсә. Китмә, улым.

Тынлык каплаган иде җир өстен. Шомлы тынлык. Киеренкелектән өй һавасы куергандай булып китте. Кышкы төндә суына башлаган бүрәнә йортта оясын ташлап китеп ятимлектә йөрүче ир бала белән, ялгыз яшәр өчен балалар үстергән тол ана уй-ниятләренең очына чыга алмыйча газап чигәләр иде. Ике язмыш, ике теләк, ике бәхет һәм ике бәхетсезлек бер-берсенә сырышалар, кушылырга телиләр һәм ниндидер каһәрле көч аларга якынаерга ирек бирми. Кан бер. Кайчандыр тән һәм җан да бер булган. Авыр иде аларның икесенә дә...

Җир йөзендә дүрт миллиардтан артык йөрәк тибә. Дүрт миллиардтан артык теләк, өмет, бәхет һәм бәхетсезлек. Дүрт миллиардтан артык җан иясе туу белән үлем арасындагы татлы һәм газаплы яшәү юлында. Сулышлар тоташ, ә бердәмлек юк. Гасыр саен диярлек кешелек дөньясын тигезләп, бәндәләрне бәхетле итәргә омтылучы көрәшче туа. Бәхеткә ирешү турында әллә нинди даһи кагыйдәләр, кулланмалар бар. Кагыйдә, канун төзүчеләр бер хакыйкатьне аңлап җиткермиләр. Дүрт миллиард кешене бәхетле итү өчен дүрт миллиард төр бәхет кирәк булыр иде. Мин теләгән бәхет әниемә бәхетсезлек китерә. Мәңге шулай. Бер кабынып, бер сүнеп торган сугышлар. Кешеләрне бер-берсеннән аерып торучы сәясәт. Бер-берең якынаю шундый авыр...

Йокы алдыннан бер уй туды: «Киткәнче урманнар, кырларны карап кайтырга кирәк...»

* * *

Бәшәр чокыры буйлап урманга барам. Яланнар кар астында. Каршы җил миңа таба имән яфрагын кыштырдатып куып китерә. Куян

эзе юлымны аркылыга кисеп үткән. Кошлар кар чокып нәрсәдер эзләгәннәр. Чокырның сулъягында, каршыдагы калкулык битендә армиягә китәсе елны сөргән җирем. Узган ел аңа бодай чәчкәннәр. Кар астыннан камыл тырпаеп күренеп тора. Бу җирне Аксак Тимер гаскәре таптап узган. Патша гаскәрләре Казан җирен камаганда бу тирәдә кан елга булып аккан. Ике айдан кар эрер, җир ачылыр, калкулыкны сөрергә монда трактор килер. Мин — җирне ат сабаны белән сөрүчеләрнең соңгы вәкиле...

Ул елны мин сабан сөрүдә районда беренче урынны алдым.

Шушы җир исемемне район югарылыгына күтәрде. Әле дә исемдә, җир сөрү буенча Димскәй егете Әхтәс Зиякаевны узгач, мине председатель айгырын җиктереп районга җибәрделәр. Нәрсә эшләтерләрен мин белми идем. Өмет яхшылыкта иде. Тәрәзәләренә тимер рәшәткә куйган бер йортка алып керделәр. Ишекләрнең дә тимердән булуын күргәч йөрәгем жу итеп китте. Буыннарым йомшады. «Нигә мине тәрәзәләренә тимер рәшәткә тотылган йортка алып килделәр? Мин бит берниндн җинаять эшләмәдем...»

Кулыма машинкада суктырылган текст тоттырдылар да тимер ишектән кертеп, микрофон каршысына утырттылар. Мин җир сөрүдә ничек, нинди юл белән уңышлыкларга ирешә алуым турында сөйләргә керештем. Үзем укыйм, үземә оят. Ә атларым? Шулар аркасында беренче урынны алдым бит мин ул чакта. Кәгазьдә атлар турында бер кәлимә сүз юк.

Атларым турында уйлаганда әле һаман минем вөҗданым сыкранып куя. Шулар күтәрде мине сугыш елларында. Ә аларны искә алучы, тырышып эшләдегез, рәхмәт, дип әйтүче булмады. Без, адәм балалары, шундый инде.

Яз килгәнен көтеп кар астында яткан җирне күкрәгемә кысып елыйсым килеп китте. «Ташлап китте, онытты дип үпкәләмә. Мин кайтырмын әле. Кар эреп, җир җылынгач, һавада тургайлар сайрый башлагач, мин тагын сине сөрергә килермен. Үпкәләмә миңа, җир, яме».

Калку җирдә кар тирән түгел иде. Чокыр аша чыкканда билдән карга баттым. Кар күп төшкән. Кар әйбәт ята. Киләсе елда ашлык уңачак. Күңелем күтәрелеп китте. Ашлык уңудан да зур бәхет буламы игенчегә? Без — шәһәрләшкән крестьян малайлары — ашлык уңганын, уңмаганын белмибез.

Кайтышлый, зират янына туктадым. Зират капкасы туңып җиргә береккән, ачылмый. Зиратка койма өстеннән керергә ярамый. Әтиемә һәм апама койма аша гына сәлам бирдем. Әтием кабере өстендә яфраксыз тирәк моңаеп утыра. Шәрә калган сәрби агачлары күшеккән. Ике песнәк, сәрби агачының ботагыннан ботагына күчеп, җим эзлиләр. Җәй көннәрендә монда яшел чирәм. Җиләк чәчәк аткан чакта зират эче акка төренә. Әтием һәм егермегә дә җитә алмыйча вафат булган апама авылдан китәсемне белгерттем. Ризасызлык белгертмәделәр. Алар исән чакта да аз сүзлеләр иде. Саубуллаштым. Алар тыныч кына озатып калдылар.

Зират коймасы буенда кар эченнән шайтан таягы күренеп тора. Урыслар бу үләнне «татарник» дип йөртәләр. Лев Толстой шушы үләнне Хаҗи Морат белән чагыштырган. Минем дә шушы үләнгә охшыйсым килеп китте. Искиткеч чыдам, түзем икән бу үлән. Көзге яңгырлар, кышкы ачы җилләр шайтан таягына зыян китерә алмаганнар. Хәтта ул төсен дә югалтмаган. Чәчәкләре исән. Бу үләнгә исемне белеп кушканнардыр. Бу исемне аклый алабызмы икән? Чыдамлык җитәме икән бездә? Чәчәкләребезне, яфрагыбызны саклый алабызмы икән соң?

Зиратның тылсымлы, тирән тынычлыгы мине һәрвакыт хәйран калдыра. Монда син үткәнгә һәм киләчәккә башкача карый башлыйсың. Зират мохитында мал — бәясен, дан — кадерен, өстенлек көчен югалта. Теләк-максатларның юнәлешләре дә үзгәрә монда. Барыбызга зарур, котылгысыз тиешле финал рияны юып төшерә. Күңелдә кешелекле көч

уяна. Йоклагыз, авылдашларым. Сездә бернинди мохтаҗлык юк. Сез хәзер үзара тигез. Кәефегезне дә беркем боза алмый. Хәтта гранит һәйкәлгә ымсыну да бетә монда килгәч. Сезне табигать күркәмлеге чорнап алган, һәйкәлләрнең кирәге юк.

Могҗизалы үзгәреш ул сезнең янга күчеп килү. Монда килгәч гомер буе намазын калдырмыйча дин тоткан мәчет карты да аңа каршы көрәшкән сугышчан алласыз белән янәшә ятып тынычлана. Җир йөзенең иң гадел судьясы үлем булып чыга бу очракта. Ул хәерчене патша, патшаны хәерче итеп икесен дә тигезли.

Әти белән койма аша саубуллашу әдәпсезлек тоелды. Рәнҗетәсем килмәде мәрхүмне. Әдәп бозып, зират эченә кердем. Әтиемнең кабере өстендәге сәрби агачыннан кузаклар чүпләп йөргән ике песнәк, күтәрелә-төшә очып барып, икенче бер кабердәге тирәккә кундылар.

Әтием кабере янына килеп тезләндем. Коръән укый белмим мин, гафу ит. Дога да белмим. Әни өйрәткән догаларны онытып бетердем. Купшы сүз, үтәлмәс вәгъдәләрне син исән чакта да яратмый идең. Гомерең михнәтле узды. Гражданнар сугышы, Кырымны алганда Сивашның черек сазлыгында туңып ревматизм ияртеп кайттың. Продразверстка начальнигын ат белән Бөгелмәгә илткәндә кар суына батып, үпкәңә салкын тидердең. Карлар эри башлагач, көзге яңгырларда синең аяк-кулларың йөрмәс була, тының бетә, йөрәгең леп-леп килә башлый иде. Ятып авырырга вакытың булмады. Идарәгә барып җиңел эш сорарга кешедән яшерен йөрткән кырыс горурлыгың каршы килде.

«Мин китәм,— дидең син соңгы сулышыңда.— Балалар, бәхил булыгыз. Сезне аякка бастыра алмадым инде, хәерле булсын... Менә, китәм... Мин сезгә авырлык кына китердем. Хуҗалыкны алып барырга көчем җитмәде. Авыр булды сезгә. Бигрәк тә әниегезгә авыр булды... Зиһенем чуалды, балалар... Әллә нәрсә сөйлим... Зарланыр вакытмыни? Бу сугыш... Э-э-э-х, бу сугыш. Аның казалары... Барысы сезгә. Сезнең башкайларыгызга. Бәхил булыгыз, балалар... Әнкәсе, бәхил бул...»

Әтиемнең кабере өстендәге коймага бер бала тал кайрысыннан үргән нәни чыбыркы кыстырып калдырган. Бозау сакларга килгән бер нәнинең чыбыркысыдыр инде? Бу дөнья...

Кинәт күк күкрәп җибәрде. Башымны күтәреп, һавага карадым. Кышкы төссез күктә, артыннан тигез ак тасма калдырып, самолет очып бара. Очкычның дюраль тәне болытлар артына яшеренгән кояш нурларын чагылдыра. Сау бул, әтием. Кичер. Мин синең васыятеңә тугрылыклы булырга тырышам. Тырышам. Көчем җиткән кадәр. Катлаулы бу дөнья... Бәхил бул... кичер, яме...

Өйгә кайтып, әйберләремне чемоданыма тутырырга керештем.

Өйгә кайтканнан бирле, әниемнең чәчүргечена таккан талир тәңкәләрнең көмеш моңы көне буе яңгырап тора иде. Ә хәзер өнсезлек. Шушындый авыр, йомык тынлык мәет чыккан өйдә генә була.

— Китәсең дәмени инде? — әнием яулык чите белән күзен сөртә.— Бигрәк тә әз булды. Туйганчы сөйләшеп тә булмады. И-и-и гомер. Күрә алырмынмы икән?..

Сәгать дүрттәге самолет белән Бөгелмәдән очарга тиеш идем. Өлгерергә тырышып, ашыга башладым. Без һәркайчан өлгерергә тырышып, ашыгып яшибез. Ашыгабыз. Вакыт агымы бер. Аны тизәйтеп тә, әкренәйтеп тә булмый.

— Улым, юлга төш пешердем. Баргач иптәшләреңне дә сыйларсың.

Әнием чаршау артына кереп яшеренде.

— Шәфкатьләр юлдаш булсын үзеңә. Ай йөре, аман йөре,— бу сүзләр тулысынча күз яшьләренә юылган иде.

Юл чатына чыгып, машинага утыргач, борылып карадым. Шундый бәләкәй, шундый кадерле иде әниемнең ябык гәүдәсе...

* * *

«Бәхетең булып, яшь чагында Парижда яшәп кала алсаң, соңыннан, кайларда гына торма, шунда кичергән тойгылар соңгы сулышыңа кадәр күңелеңдә сакланачак. Париж — мәңге күңелдә кала, саклана торган бәйрәм ул»,— дигән Эрнест Хемингуэй Франциянең башкаласы турында. Шул ук сүзләрне Одессага багышлап кабатлыйсым килә.

Караярда Оренбург ягыннан искән дала җиле агач башларын шаулатып, көне-төне кар ташый иде. Буран туктый. Бер-ике көн һава тынычланып тора. Тагын җил чыга. Тагын буран улый, үкерә, кар ташый. Авыл йортларын көрт басып киткән. Коймалар кар астында.

Одессада көньяк җиле калага җылымса дым ташый. Түбә читләреннән чут-чут тамчы тама. Язгы җылы җил исенә исереп әсәрләнгән кала чыпчыклары чинар ботакларында пыр туздырып сугышалар. Яз килгәнен агачлар да сизә. Бөреләр бүртенгән, бүген-иртәгә ярылып китәргә торалар. Агач тамырлары җирнең җылына башлаган тәненнән дым суыралар. Һавада яз исе. Йөрәктә дә шул. Яз һәр кузәнәккә үтеп кергән. Яз бит ул сине астыртын гына мәхәббәткә өнди. Язны сизү белән йөрәк бер сәбәпсез ашкынып тибә башлый. Тән нәрсәдер тели, сорый, даулый, ашыктыра. Тән акылга, гәвам тәртибенә гыйсьян күтәрә. Тәндә ниндидер яшерен әзерләнү бара. Зарыгып көтү мул, моңлы өмет һәр күзәнәктә. Гармун тавышы ишетелсә, боз киткәнен күрсә, ат муенын кочаклап, аның гөнаһсыз күзенә карап елый-елый хакыйкатькә ант итәсе килә...

Пале-Ройяль бакчасыннан чыктым да бер тын опера театрының фронтонына куелган сыннарга карап тордым. Диңгез буе бульварына тигез, сөзәк асфальт юл төшә. Мин шул якка борылдым. Одесса тирәсендә кайчандыр төрекләр, аларга кадәр кыпчаклар, скифлар, тагын әллә нинди халыклар яшәгән. Монда шул халыкларның сулышлары сакланып калган. Җентекләп, ашыкмыйча, күңел салып карап йөргәндә бу җирдә яшәгән халыкларның зәвыкларын да тоярга була. Одессаны француз осталары, итальяннар, греклар төзегән дип сөйлиләр. Мин һәр йортта, һәр урам почмагында һәм кешеләрнең үз-үзләрен тотуында төрек шаукымын да сизәм. Юк, төрек шаукымы түгел бу. «Олы совет энциклопедия»сенең унсигезенче томын алам. Өч йөзенче бит. Өченче колонка. Утыз тугызынчы юл. «Одесса — беренче тапкыр 1415 елда искә алынган татар авылы, Качибәй урынына салынган. XV гасырда аны төрекләр җимерәләр һәм шуннан соң Хаҗибәй дигән исемдә тагын барлыкка килә». Ә мин әллә нинди катлаулы гипотезалар корып, баш ватам.

Яшәү кайгы-хәсрәтсез булмый. Бу җирдә дә кайгы бар. Әмма монда тормыш кояшлырак. Хәсрәтле көннәрдә диңгез буена төшәсең. Кайгыларыңны диңгезгә сөйләсәң, эчең бушый һәм диңгез юаныч бирә. Диңгез зур, ул шәфкатьле, ул аңлый, кичерә. Диңгез вакчыл, үчле түгел. Яр буена килеп йөгерек дулкыннарга сереңне ачсаң, авыр йөктән арынасың. Ул авырлык дулкыннарга ияреп китә. Шуңа күрә, мондагы тормыштан бәйрәм тәме, бәйге тавышы килеп тора. Миңа шул ошый.

Чемоданымны диңгез вокзалының саклау камерасына тапшырдым. Шәһәр бу. Унбиш тиенгә синең чемоданыңны бер тәүлек саклыйлар. Потемкин баскычыннан Бульварга мендем. Бульвардан — Одессаның кәгъбәсе саналган Дерибас урамына. Монда тәүлек буе диярлек бәйрәм. Урам шыгрым тулы. Халык. Курортчылар. Кораблары портка кайткан моряклар. Хатын-кыз. Студентлар. Әллә кемнәр. Бу урамның ташларына басу белән табан кыза, йөрәк ашыгыбрак тибә башлый. Эчке ярсуны диңгездән искән бриз җиле дә суыта алмый. Сөясе, сөеләсе, мәхәббәт диңгезенә чумып бәхетле буласы килә. «Яшәү кабатланмый. Гомер бары бер генә тапкырга бирелгән». Дерибас урамы колагыңа туктаусыз шушы хакыйкатьне пышылдый. «Бер яшь адәм баласы бу дөньяда

Бер, бары бер генә... Теге дөнья юклыгын фән һәм атеистлар исбат итте». Урам шушы сүзләрне әйтеп, сиңа коткы, вәсвәсә өрә.

Култыклашкан кызлар, егетләр. Бер-берсенең билләреннән кочкан яшь кызлар, яшь егетләр. Әнә бер егет кызын үбә. Оялмыйлар. Монда ярый. Бу — Дерибас урамы. Дөньяда башка мондый урам юк. Әнә, җил-давылда каклanып, тозланып беткән «диңгез бүресе» хатынын күргәзмәгә алып чыккан. Аның газизен, бердәнберен киендерү өчен Сингапур, Аден, Гибралтар, Генуя тегүчеләре яныр-пешеп эшләгәннәр. Ирен зарыгып көтү, ялгызлык газаплары бушка булмаган: диңгезче хатыны өстендәге кием башка кемдә бар? Ә болары? Болары әле өйләнешеп тә өлгермәгән. Егетнең буй-сыны, мыегы, мускуллары, өстендәге пиджагы. Күз тимәсен! Дөньяда бер генә яшибез. Бер генә мәртәбә...

Күн курткасы булмаганның өстендә затлы күлмәк. Андый күлмәккә көче җитмәгәннең муенында күзеңнең явын алырлык ефәк шарф. Ә зәңгәр күзләр? Тылсым сирпеп торган озын кара керфекләр? Әнә, теге кызның тәти күлмәге дә, сөрмәле зәңгәр күзе дә юк. Аңа кием һәм матурлык урынына искиткеч көчле инану бирелгән. Бу дөньяда инанудан көчле, аннан ышанычлы нәрсә бар? Әгәр син үзеңнең матурдан да матур булуыңа инанасың икән, башкалар да сине матурга саный башлыйлар. Шундый ул адәм баласы...

Одесса үз урынында. Дерибас урамы үз вазифасын үти. Одессалылар үзләренчә яшиләр. Дерибас урамын ике тапкыр урап чыккач, тынычланып, пароходчылыкка юнәлдем.

Пароходчылык патша сараена охшашлы бинага урнашкан. Тыштан бераз мавритан ысулына тартым, интерьеры — барокко. Мәрмәр баскычтан икенче катка менәм. Күкрәгемдә кайнар горурлык: «Мин менә нинди учреждениедә эшлим!» Кызганыч, сабакташым Хаҗипка күрсәтеп булмый. Нәрсә ул эш хакы! Безгә авторитет кирәк. Ихтирамлы урын безгә акчадан кыйммәтрәк, горурлык ихтирамнан туа.

Дежур диспетчер түгәрәк тәрәзә каршында утыра иде. Тәрәзә алдына рестораннардагыга охшашлы кечкенә сәхнә куйганнар. Сәхнәнең ике ягында ике якорь, уртасында җиз кыршаулы штурвал. Шул штурвал янына туктап тәрәзәгә карадым. Әчтә бер чибәр кыз. Коңгырт куе чәчен киң кызыл тасма белән тоттырып куйган. Кофтасында алтын җепләр. Муенында көмеш чылбырга тезгән гәрәбә. Пароходчылык эшенә кызларның гел чибәрләре җыела. Монда капитанга кияүгә чыгу мөмкинлеге бар. Картраклары — диңгезче хатыннары. Алар шушында эшләү аркасында диңгезче хатыны булу бәхетенә ирешкәннәр.

— Исәнмесез. «Чолман» пароходының кайда икәнлеген әйтмәссезме?

— «Чолман»? — диспетчер кыз иелеп, каршындагы исемлекне укырга кереште.— Калькуттада — юк, Иокогамада — юк, Лас-Пальмаста юк, Сингапур, Рио-де-Жанейро, Гавана, Генуя, Барселона, Александрия — бу портларда юк. Юлдагы кораблар: «Адмирал Ушаков», «Аргунь», «Мичурин», «Белоруссия» — монда да юк. Заводта ремонтланучы кораблар... «Чолман» — Беренче заводта.

— Ремонт беттеме икән соң?

— Андый информацияне завод кына бирә ала. Ремонт — минем компетенциямдә түгел.

«Информация», «компетенция» — нинди матур сүзләр белән генә сиптерә бит, ә? Мине авылда председатель ярдәмчесе булып эшләргә кыстадылар. Анда исә «тирес чыгару», «абзар тазарту», «силос салу», «чөгендер алу» шикелле гамәли сүзләр белән сөйләшәләр...

«Чолман» чит илләргә чыгып тайганчы өлгерергә кирәк.

* * *

Бульвар — Потемкин баскычы — Диңгез вокзалы. Егерме минуттан мин Пересыпьта идем инде. «Молдаванка и Пересыпь знают Костю-

моряка...» «Молдаванка и Пересыпь знают Габдрахмана-моряка» — болай батмый.

Алга. Вперед. Форвартс. Аванти. Илле адымнан — пароход һәм, бернигә сәгатьтән — сау бул, Одесса, ареви дерче, гут бай, һәм исәнмесез, мәрҗән атоллары! Кәҗә мөгезе тропигы, пассат җиле, тайфун, альбатрослар...

— Пропуск,— сырма якасына яшел петлица тегеп, биленә наган аскан ирдәүкә хатын пәйда булып, юлыма аркылы төште. Кашы җимерек. Кулы кобурасыннан наганны суырып чыгарырга гына тора. Удостовериениены түш кесәмнән алып суздым да эчкә керә башладым.

— Стой. Назад.

— Менә бит пропуск, апа. Мөһер сугылган, срогы чыкмаган. Полный ажур.

— Синең апаң Привозда хамса сата. Мин — сакчы. Бу пропуск ярамый.

— Соң сезгә пропускның ниндие кирәк?

— Завод идарәсе биргәне.

— Кайда соң ул завод идарәсе?

— ...

— Әйтегез, завод идарәсеннән пропуск алу өчен нәрсә кирәк?

— ...

Очрашыр алдыннан, аның кем булуына карамастан, без мәрхәмәт көтәбез. Аңлашу дәрәҗәсенә ирешә алуга без алдан ышанып торабыз. Ялынып та, кычкырып та, хәтта ялагайланып та карадым мин сакта торучыга. Сакчының йөрәге таш иде. Куркыныч икән ул таш йөрәкле кешегә юлыгу. Мин тәмам югалып калдым.

— Апа, рәхим итеп, чемоданны гына сезнең янда калдырып торыйм әле?

Сыбызгы тавышы колак эчен көйдереп алды:

— Минут эчендә! Югал, күз алдымнан! Милиция чакырам.

Икенче мизгелдә мин сакчыдан ике йөз адым ераклыкта тора идем инде. Бәлки, кем дә булса завод капкасыннан чыгар? Экипаж әгъзаларының шәһәрдә йомышлары булмый калмас.

Аякларым өши башлады. Кая соң бу каланың көләч, шаян кешеләре? Хәзер миңа Одессада гел тупас, гел кансыз бәндәләр генә яши кебек тоела башлады. Бәлки, мин сакчы белән сөйләшә белмәгәнмендер? Бәлки, киресенчә, ул, гомумән, сөйләшкән кешене яратмый торгандыр? Сөйләшә белү бит ул... Юк, бу очракта фәлсәфә көчсез иде.

Капкадан бер диңгезче килеп чыкты. Каршысына барып сорадым:

— «Чолман» завод капкасыннан ерак торамы?

— Өченче причалда.

— Мине заводка кертмиләр. Өшеп беттем. Беркем чыкмый. Нишләргә дә белгән юк,— дидем мин елар хәлгә җитеп.

— Полина Поликарповна,— диде диңгезче.— Сездә «Чолман»ның судовой роле булырга тиеш. Карагыз әле бу егетнең фамилиясен. Фамилиясе рольдә булса, сез аны тоткарлый алмыйсыз.

— Башта кеше белән сөйләшергә өйрәнсен. Мин аны эчәгеләре туңганчы тотам, аяклары җиргә туңып катканчы,— диде ирдәүкә.

— Аңлашылды,— диде егет һәм баш бармагын имән бармагына ышкып күрсәтте.— Ул сездән шуны көткән.

— Сатып алырга теләде дип төрмәгә утыртуы бар,— дидем мин, бавырымның сызлый башлаганын сизеп.— Юк, булмый миннән. Андый эшкә әвәслегем юк. Булмый.

— Дөрес, хәзер ярамый. Башта кирәк иде,— диде диңгезче.— «Чолманга» барып әйтим әле. Фамилиягез ничек?

— Рахманкулов.

— Татармыни?

— Әйе.

— Тугандаш икәнбез,— һәм егет проходнойга чумды. Аның кайгыртуы, әйткән җылы сүзләре эчемне җылытып җибәрде. Өмет туды. Мин инде ышанып көтә башладым. Сабырлык кирәк бу дөньяда. Борынгылар сабырлыкны саф алтынга тиңләгәннәр. Һәм мин, кырылган кәефне рәткә китереп, сабырлыкка көйли башладым.

Проходнойдан Виктор Барсуков күренгәндә кырып-себереп җыйган сабырлыкның мыскалы да калмаган иде инде. Виктор сакчының колагына бер сүз, бары бер генә сүз әйтте. Шул җитте. Дустым мине култыклап алды, завод эченә алып кереп китте. Мәсьәләнең шулай тиз, җиңел чишелүенә хәйран калдым мин.

— Син аңа нәрсә әйттең? — дип сорадым.

— Полина Поликарповна, бу минем дустым дидем.

— Элек сөйләшкәндә дуслыкны аңларлык түгел иде ул.

— Эш анда түгел. Гади кеше белән сөйләшә белергә кирәк. Һәркем үзенең югарыда буласы килгәнен сизеп яши. Сакчының да бит начальник буласы, кулында власть тотасы, шуны башкаларга күрсәтәсе килә. Син аңа буйсынуыңны күрсәтергә тиеш идең. Буйсындың — күңеле булды. Һәр очраган кешенең күңелен күреп торырга кирәк. Башкача яшәп булмый бу дөньяда.

Гомер буе кешеләрне аңларга тырышам. Карыйм, күзәтәм, уйлыйм — һәм шушы көнгә кадәр шыр надан.

Завод корпусларын үттек. «Чолман» янына килеп чыктык. Йөрәккә җылы йөгерде. Мондый хис читтә йөреп авылга кайтканда гына уяна иде. Тагын бер туганлык, якынлык хисе барлыкка килде. Туган авылым кебек үк булмаса да, «Чолман» миңа чиксез кадерле иде.

* * *

— Авылда ничегрәк яшиләр? — диде Барсуков каютага кергәч.

— Авыл шәһәргә әйләнү турында хыяллана. Сигез сәгать эш көне, атна саен ял, түләүле рәхәтлекләр, авылда шушы турыда уйлыйлар.

— Авыл бетсә иписез калабыз бит без,— диде Барсуков.

— Ремонт кайчан бетә? — дидем мин авыл турында сөйләшүдән тизрәк котылу өчен. Белмим, авыл турында сөйләшкәндә нигәдер һәрвакыт вөҗдан сыкрый.

— Кәгазьдә ремонт бетте санала. Ә болай тагын бер атна ысланырбыз шикелле.

— «Чолман»ның кайсы илләргә йөрүе билгеле түгелме?

— Италиягә күмер ташырга тиеш, дип сөйлиләр. Без, билгеле, өметләнеп көтәбез. Бераз куркыта да. Ымсындыргыч линия. Италиягә йөргән корабта эшләргә теләүчеләр шундый күп. Мин шуннан куркам. Кадровикларның туган-тумачалары, дуслары бар. Диңгезчеләр арасында «йонлач куллы» агай-энеләре булган кешеләр азмыни?

— Василий Степанович исән чакта куркырга ярамый. Ул каботажда эшләгән диңгезчеләрне калдырачак. Сөйлә, пароходның кай җирләрен үзгәрттеләр?

— Әйдә, күрсәтәм. Ун тапкыр ишеткәнче бер тапкыр күрү артык диләрме әле? — Без палубага чыктык.— Көчне күп түктек без. Ремонтны тизрәк бетерәсе килде. Төн урталарына кадәр эшләгән чаклар да еш булды. Капитан атналар буе корабта яшәде.

— Теге грек пароходын коткарган чакта да шулай булган иде бит,— дидем мин.

Ул чакта без ике генә тәүлек көчәндек. Ә ремонтта инде айдан артык.

Палубада электрод калдыклары, тимер кыйпылчыклары, майга буялган чүпрәкләр, линолеум кисәкләре аунап ята иде. Пароход тапталган. Тәнендә тимер кайнатудан калган кутырлы җөйләр, каткан буяу тамчылары. Пароход больницада яткан авыруны хәтерләтә иде.

— Корабның күп җирен үз кулыбыз белән ремонтладык. Завод эшчеләре беренче атнаны ябырылып килделәр дә акча төшә торган урыннарын сайлап ремонтлап киттеләр,— диде Барсуков.— Вак-төяге өелеп безгә калды. Без хәзер шундый эш белән чиләнәбез.

Яңа куелган трюм капкачларын карыйбыз. Каботажда йөзгәндә трюм өстенә авыр матчалар (лючина) тезеп, өстән брезент белән каплап чөйләү шундый авыр эш иде. Трюм ябуның җиңеләюе мине чын күңелдән куандырды.

— Экипажның әзәйгәнен беләсеңме? — диде Барсуков.— Тугыз кочегарның өчесе генә калды. Аларның да эше җиңеләйде. Көрәк белән топкага күмерыргыту бетте инде. Сыек ягулык форсункаларга үзе агып килә. Матрослар санын да әзәйтәләр дип сөйлиләр. Капитанның политик ярдәмчесе — помполит өстәлергә тиеш.

— Кемне куячаклары билгеле түгелме әле?

— Кеше табылыр. Каботажда эшләгәндә генә табып булмый иде. Инде хәзер «Чолман»да эшләр өчен атлыгып торалар.

Кочегаркага төштек. Таныш җылылык, кызган тимер, кайнар машина мае исе борынга килеп бәрелде, сулыш юлына үтте. Үзгәреш зур иде. Кая идәндәге күмер өемнәре? Көрәкләр, ломнар, һиһаять, стеналарга кунган тузан кая? Хәзер «Чолман» мазут ягып йөрергә тиеш. Топкаларга мазут өрдертеп торучы форсункаларны кулым белән тотып карадым. Күмер ягып йөргәндә, кочегарның эше авыр иде.

— Әллә кочегарлыкка күчәсе инде? — диде Барсуков.— Дүрт сәгатьлек вахтада ике тапкыр форсункаларны чистарттың — бар эш шул. Машина бүлегендә эшләүчеләр илле биш яшьтән пенсиягә чыгалар.

— Син пенсия турында уйлый башладыңмыни инде? — дидем мин гаҗәпләнеп.— Минем ул турыда уйлап та караганым юк.— Һәм кинәт картлык искә төште. Ул киләчәк. Картлыктан котылып булмаячак. Әгәр һаман авиациядә хезмәт иткән булсам, мин дә ике елдан пенсиягә чыга ала идем. Бер елы икегә санала иде очу эшенең. Мине бит озак үгетләделәр, соңыннан үкенерсең диделәр. Акыллы кешеләрнең сүзен тыңлаган булсам, мин чыннан да утыз яшемдә пенсиягә чыга ала идем. Тик нишләр идем икән эшләмичә пенсия ашап ята башласам?

Каютага кердек. Өйдән алып килгән күчтәнәчләрне өстәлгә бушатырга керештем. Бераз тартынам мин әнием пешергән әйберне ятларга күрсәтергә. Һәм кызганам. Кибеттән сатып алган азыкны кызганмыйм. Әни пешергән ашамлыкка мөнәсәбәт бөтенләй башка. Әниемнең чәкчәген, ул кайнаткан кызыл эремчекне тырнак очына алып исни башласалар, җаным рәнҗи, түзә алмыйм мин ул чакта, үләсем килә. Шәһәр урамнарында «биляши» аталган сумса сатканнарын күрсәм дә читтәнрәк урап узарга тырышам. Ул ашамлыкның исеме генә түгел, җисеменә кадәр имгәтелгән.

Ишек ачылды. Үзеннән элек Деримедведьнең елмаюы килеп керде.

— Рахманкулов? Фантастика! — яныма килеп кабыргама төртеп карады.— Әллә сине өйләндереп җибәрделәрме?

— Юк әле,— дидем мин.— Мин авылда чакта буйдакларны көчләп өйләндерергә закон чыкмагандыр бит?

— Бар андый закон. Күптән бар. Лохмачевны әнисе инде менә өч ел туктаусыз көчләп тора. Виктор Филимоновичка генерал кызы кирәк. Ул аннан түбәнгә өйләнми. Шул сәбәп тота.

— Рахманкулов кайткан икән,— дип Белоштан ишектән башын тыкты.— Лохмачев, күрерсез, аны «Чолман»га кайтармыйм дип мактанган иде...

— Ничек инде кайтармый? — дидем мин гаҗәпләнеп.— Лохмачевны капитан итеп куймаганнардыр бит? Аның миндә ни эше бар?

— Кадрлар бүлегендә аның «кулы» бар. Шул кул ярдәмендә ул капитан белән өлкән штурманны да корабтан кумакчы була,— диде Барсуков.

— Егетләр, сез ул кешедән сак булыгыз. Лохмач — чыннан да мәкерле бәндә, куркыныч кеше ул. Әйткәнен үтәми калмый ул,— диде Белоштан пышылдап.

Тиздән чит илләргә йөри башлыйбыз, сүз шул якка борылды.

— Чит ил дигәч исемә төште. Кичә миңа прораб сөйләде: Төркиядә мәчеткә күлмәгеңне кутәртеп, мөселманлыгыңны тикшереп кертәләр икән,— диде Белоштан. Деримедведь исә минем каклаган казымны исни иде. Нәрсәдер йөрәгемне кысты.

— Нәрсә бу? — диде Деримедведь балаларча табигый мөлаемлык белән.

— Каклаган каз.

— Ашарга ярыймы соң аны? Бозылган түгелме? Төсе шактый сәер. Ә үзе, гаҗәп, исләнмәгән.

— Каклаган ит бозылмый ул,— дидем мин. Озак саклар өчен ерак бабаларым иткә тоз сибеп, җиләс кояшлы урында киптергәннән соң аны төеп онга әйләндерүләрен, яуда йөргәндә шул он белән елдан артык туклануларын сөйлисем килеп китте.

Барсуков белән икәүләп табынны җыйдык. Каклаган казның сөякләрен чүплек савытына чыгарып салдык. Төн уртасында Барсуков кораб сакларга вахтага басты.

Берүзем калгач урыныма менеп яттым.

Башымда үзара бәйләнешсез, сукыр чебен шикелле талымсыз фикерләр кайнаша иде. Тиздән чит илләргә йөри башлыйбыз. Озакламый хыялым тормышка аша. Инде бары бер атна вакыт калды. Күптән зарыгып көткән хыялымның кул белән үрелеп тотар хәлгә җитеп якынаюы күңелгә шом сала. «Хәерлегә генә булса иде»,— дип куям карчыкларча. «Юл азабы — гүр газабы» дигән мәкерле әйтем искә төшә. «Юл, син мине кайларга алып барырга җыенасың? Нинди вакыйгаларга юлыктырырга телисең син мине? Нинди чиккә җиткереп туктатырсың? Син бит җанлы көч. Син — сәяхәт, минем киләчәгем».

Диңгез чакыра. Диңгез мине тынгысызлый. Ул миңа хәйран калырлык матурлыклар, могҗизалы хатирәләр күрсәтергә вәгъдә бирә. Мин шуңа ышанам. Шуңа ышанып тынычлыктан, ата-бабадан калдырган таныш, ышанычлы тормыштан баш тарттым. Үтәрсеңме соң син, диңгез, биргән вәгъдәңне?

Тирә-якта төн. Тынычлык. Диңгез каласы Одесса йоклый.

* * *

Ничә еллар зарыгып көткән бөек көн килеп җитте. Март ае. Күктә кояш. Һава саф. Диңгез зәңгәр... Елыйсылар килә...

Завод причалы артта калды. Әнә, без торган җирдә корабтан чыгарып ташлаган чүп-чар өеме. Алда — диңгез. Без «ходовые испытания» дигән эшне башкарабыз. Өч сәгать йөзеп, корабның механизмнарын тикшергәннән соң портка кереп йөк төйи башлыйбыз. Алда юл, яңа күренешләр, чит ил ярлары. Алда минут саен үзгәреп торган диңгезчеләр тормышы.

За каждым валом — даль, за каждой далью — вал...
Плывущие, чтобы плыть. Глотатели широт,
Что каждую зарю справляют новоселье
И даже в смертный час твердят: — Вперед [1].

Без пароходны юабыз. Без өчәү: Деримедведь, Белоштан, мин. Швабраны сабынлы суга манып алам да палубаны ышкыйм. Мин эшләгән җирдә чисталык кала. Их, рәхәт тә инде үз кулың белән иңдергән чисталыкны күрү! Яшәгән җиреңне чистартып, пакьләндереп үтү — иң күркәм, иң изге эш. Әгәр көчем җитсә, палуба юган шикелле бөтен җир шарын юып, чистартып пакьләндереп чыгар идем!

Бу фикерне иман кабул итми: «Күзгә күренеп торган пычраклыкны

[1] Шарль Бодлер. «Плавание». Марина Цветаева тәрҗемәсе.

кем дә тазарта ала,— ди ул.— Әхлак пычраклыгы, шапшак вөҗданнар — менә нәрсәне чистартырга кирәк...» Мин хуплыйм. Дөрес, кыра-кыра юасы бар кайбер кешеләрнең иманнарын. Мохитны чистартмыйча без изге теләкләргә беркайчан да ирешә алмыйбыз.

«Чолман» завод причалыннан ачык диңгезгә чыкканда төш вакыты иде. Хәзер сәгать өч. Өч сәгать йөзеп машинаның эшләвен, механизмнарның төзеклеген тикшердек. Дәүләт регистры вәкилләре пароходны карап йөриләр. Корабның ватык җирен, күрсәтүче приборның тутыга башлаган механизмын тапсалар, кораб шундук кире заводка кайтарыла. Бу очракта ремонтлау дәвам итәчәк. Женевада чыгарылган конвенция буенча. Кораб йөзсен, батмасын, диңгезчеләр исән йөрсен өчен пароходның һәр җире төзек булырга тиеш. Регистр вәкилләре безнең иминлекне кайгырталар. Ә безгә аларның тикшереп йөрүләре ошамый, яшереп кенә йодрык күрсәтәбез, алар әйткән сүздән гаеп тапкан булып елмаябыз.

Кичкә таба тикшерү бетте. Вәкилләр кают-компаниягә җыелдылар. Безнең күзләр кают-компания ишегендә. Өмет, син нигә шундый шикчел буласың? Әллә нинди куркыныч фаразлар ясап, нигә шулай үзәкләрне өзәсең? Нәрсә булыр? Кабул итәрләрме-юкмы? Кул куярлармы? Әллә, ремонтны дәвам итәргә дигән карар чыгарып, пароходны заводка кире борырлармы? Безнең бит тизрәк диңгезгә чыгасы килә. Җирдә туып үссәк тә, без диңгез яратабыз. Эшебез шундый. Һөкем көтәбез.

Кают-компаниянең ишеге ачылып китте. Регистр вәкилләре, коридорга чыгу белән, сулга борылып, капитан каютасына юл тоттылар. Ура! Курбатов — тәҗрибәле җитәкче. Аның каютасында инде күптән табын әзерләнгән. Кок Процыкин — зур борынлы, ябык, моңсу күзле егет — әллә нинди тәмле нәрсәләр пешерде.

Төнге унда, диңгезчеләр телендә «егерме ике нуль-нульдә», «Чолман» Одесса портының җиденче причалында Генуя портына илтү өчен күмер төйи иде инде.

Нинди куанычлы көн бүген! Без нинди бәхетле экипаж. Нинди бәхетле кешеләр яши бу калада!

Пароходның вакытында ремонттан чыгуы, графикка эләгүе, киртәлексез причал табуы, йөк төйи башлавы — барысы да капитан Курбатовның тырышлыгыннан. Ул тәҗрибәле капитан, абруйлы, кеше белән сөйләшә белә. Күпме көч түкте Василий Степанович һәм теләгенә ирешге, ул тырышты, безне максатка ирештерде, сүзен сүз итте. Һәр җирдә яраталар: заводта, портта, пароходчылыкта. Аны ихтирам итәләр. Ихтирам — кодрәтле көч, көчле тылсым.

Капитаныбыз белән горурлану шундый рәхәт, шундый ләззәтле иде.

* * *

Ниһаять, йөк тә төялеп беткән. Барырга һәм әйләнеп кайтырга җитәрлек ягулык — бункер да алынган. Юлда ашарга ашамлык, эчәргә су, кирәк-яраклар: себеркедән алып запас якорьга хәтле бар нәрсә әзер, бар нәрсә житеш. Пароход кияү каршыларга хәзерләнгән яшь киленгә охшаган — саф, пөхтә. Хәтта пароход үзе дә шатлана шикелле. Исең-акылың китәр... Ике тәүлектән — Босфор. Истамбул каласының гүзәл манаралары. Мәрмәр диңгез, Дарданелл, Чыпык-кала, Эгей, Әдрән, Ионик, Тиррен, Лигур диңгезләре, Мессин бугазы, Стромболи вулканы, Олдингтонның «Һәммә кеше — дошман» дигән романында сурәтләнгән Липар атаулары — чыдый алырмынмы икән бу шатлыкка? Бу хәтле яңа күренешләр сыярмы икән хәтергә?.. Италиянең зәңгәр ярлары...

Экипажны кызыл почмакка чакырдылар. Эшне ташлап очтык. Кызыл почмак ялт итеп тора. Аяк киемнәрен салып керергә туры килде.

Капитанга ияреп өч ят кеше керде. Өч чит кеше. Әйе... Алар

өчәүләп кызыл ситса җәйгән өстәл янына килеп утырдылар. Үзгәреш барлыкка килде. Һәм киеренкелек. Без үзебезне башкача, саграк, хәйләкәррәк тота идек чит кешеләр алдында.

— Исәнмесез, моряклар,— диде килүчеләрнең иң юаны.— Мин иптәш Куренёнконың чит илгә йөрүче диңгезчеләр белән җитәкчелек итү буенча ярдәмчесе. Минем фамилиям Кушнаренко. Кушнаренко Олег Дмитриевич. Хәзер мин сезне «Чолман»ның яңа судовой роле белән таныштырам. Иң беренче «Чолман» пароходының яңа капитаны Григорий Григорьевич Деркач — таныш булыгыз.

Сүзсезлек. Аптырау. Курку. Аңларга көч, акыл җитмәү... Тагын әллә нинди катлаулы тойгылар. Шуларның барысы бергә кушылудан барлыкка килгән торараташлык. Кызыл почмакка кешеләр, синең иптәшләрең җыелуын тою бөтенләй юкка чыкты.

Безгә текәлеп карап торган кешедә җан җылысы белән сугарылмаган аяусыз караш иде.

— Шулай ук таныш булыгыз, капитанның политик ярдәмчесе Афанасий Иванович Чоломбитько.

Ят кеше кыяр-кыймас кына урыныннан торды, башын ия төшеп, безгә карады һәм — елмайды. «Бәлки, мин сезгә ошап җитми торганмындыр. Гафу итегез, иптәшләр. Менә, билгеләделәр. Баш тарта алмадым. Нишлисең? Мин баш тартсам, башканы куярлар иде»...

Помполитның елмаюына шушы мәгънә язылган иде. Без, кырык биш диңгезче, җаннарыбыз белән дәррәү Курбатовка сырыштык.

Капитаныбыз исән-сау, безнең янда. Әнә, тыныч кына утыра бирә... Хәтта ул башка вакытлардагыдан да тынычрак, күркәмрәк... Ул исән, ә аның урынына башка кеше утыртмакчы булалар. Ялгышлык бу. Нинди дер аңлашылмаучылык...

Чигә тамырлары тибә. Тынлык. Элек минем стена сәгатенең текелдәвен ишеткәнем юк иде. Әнә ул тек-тек итеп секундларын саный. Вакыт үтә. Яңа капитанның безнең өстән начальник булуы, саркып кергән су шикелле, һаман җыела, көчәя. Василий Степанович бездән читә, ерагая. «Нишлисез сез, туктагыз»,— дип кычкырасым килеп китте.

— «Чистяков» капитаны бит бу,— дип пышылдады Барсуков колагыма.— Бүре. Ялагайланып, аның олтан астын ялап торучыларны ярату чан дип сөйлиләр.

Барсуковның тавышы ерактан, җир астыннан ишетелгән шикелле.

Курбатовның исә битендә бер генә мускул да селкенмәде. Кайбер кеше мондый очракта горур күренергә тырыша. Курбатов кесәсеннән тарак алып чәчен тарый. Иснәнеп куйгандай итте. «Арыдым мин. Ял итәсем килә. Зинһар өчен тизрәк йомгаклагыз»,— дип сорарга тели шикелле. Ә минем бавырым эчемә сыймый.

...Ә помполит дигәннәре болай ару күренә. Тәбәнәк. Шактый юан. Бирәнлек тудырган юанлык түгел шикелле. Иреннәр калын — хис булырга тиеш бу кешедә. Каш куе — җитәкчеләр кашы. Аксыл керфекләр астына яшеренгән сыеграк зәңгәр күзләр йомшак, кыяр-кыймас карыйлар. Чоломбитько. «Челом бить» дигән борынгы сүзләрдән. «Чело» миңа ошый, матур сүз. «Бить» — бәрү. Йөз белән бәрү — ошамый. Юк, бу кеше бәрмәскә тиеш.

Василий Степановичтан күземне ала алмыйм. Ансыз нишләрбез инде? Без бит аны ачуланган чакта да ярата идек. Сүгә, кыздыра, жанынны ала торган җитәкчеләр, аллага шөкер, әз түгел. Аркаңнан сөя белүчеләр дә шактый. Ә Курбатов шикелле ачуланганда синең кешелегеңә кагылмыйча, кимчелекләреңне генә тетә белүчеләр сирәк очрый. Бәлки, без аны шуңа күрә ачуланган чакта да ярата идек. Иң үкенечлесе — Курбатов урынына икенче кеше куюлары. Василий Степановичтан башка кешенең «Чолман» капитаны була алуына ышанасым килми. Башкалар да ышанмыйлар шикелле.

Куренёнконың ярдәмчесе галстугын төзәтеп куйды. Костюм затлы.

Соргылт тукымага иске көмеш төсле бүй кергән костюм төймәләрен ычкындырып җибәрде. Зәңгәр күлмәк. Батистмы, маркизитмы? Шундый юка һәм затлы. Соры, көрәнсу, кызыл һәм зәңгәр төсләр үзара матур бер гаммага берләшкәннәр. Бу кешедә зәвык бар. Зәвык һәм дефицит әйбер сатып алу мөмкинлеге. Безнең заманда әйбәт нәрсә сатып алуны «табу» диләр. Бу сүзләрнең мәгънәсенә үткерлек, шомалык һәм җитәкчелек тәэсирен үз файдаңа куллана белү кергән. Кушнаренко дәвам итте:

— Капитан һәм аның политик ярдәмчесе өлкә комитетында раслан-ган. Бу турыда сез беләсездер инде. Хәзер капитанның өлкән ярдәмчесенә тукталыйк. Кадрлар бүлеге өлкән ярдәмче итеп тәҗрибәле һәм талантлы кораб йөртүче Виктор Филимонович Лохмачевны билгеләде.

— Ә Бригас? — диде партгрупорг Черногорский.

— Өлкән ярдәмче Лохмачев,— дип кабатлады матур костюм кигән кеше һәм бу турыда сүз куерту кирәк түгеллеген сиздереп, укуын дәвам итте.— Икенче ярдәмче Владимир Константинович Лагуткин, өченче — Л. А. Дмитриев, кораб докторы Ю. В. Давыдов, боцман — Ж. Д. Бальменко.

Чират — матросларда. Әлегә шома гына бара: Гаевой, Барсуков, Деримедведь, Белоштан, Стовбуненко. Минеке әле һаман ишетелми. Йөрәк һаман кысыла. Авыз кипкән. Тамак төбе һаман кыза. Авызда тимер тәме. Иренне учым белән сөртеп карыйм. Машинистларны, кочегарларны санап уздылар. Анастасия Аристарховнаның исеме яңгырады. Минем исемем әле һаман ишетелми. Кушнаренко экипаж исемлеген яңа капитанга сузды, безгә карап елмайды. Зур эш башкарылган. Зур, җаваплы эш.

Кинәт кызыл почмакта хатын-кыз елаган тавыш ишетелде. Почмакта, битен сода һәм су ашаган озын бармаклары белән каплап, буфетчыбыз Анастасия Аристарховна үксеп елый иде.

— Сезгә ни булды? Нинди мәсьәләдә елыйсыз? — дип сорады чит илгә йөрүче диңгезчеләр җитәкчесе. Анастасия Аристарховна башын да күтәрә алмады. Ул шулай бөгелеп төшкән, күлъяулыгы белән битен кысып каплаган. Үксү тавышлары ара-тирә аның бармаклары аша бәреп чыга. Нәкъ шушы мизгелдә мин Лохмачевның йөзендәге астыртын елмаюны күреп алдым. Тротил тизлеге белән гасырлар буе буыннан-буынга җыела килгән теш кысу, ыңгырашмый түзә белү, чыдамлык — барысы сынды. Үч аласы килү, кабынып, кыргый гайрәт белән бәреп чыкты.

Лохмачевка таба сузылган кулымны партгруппорг Черногорский эләктереп алды, бөгеп, өстәл астына яшерде.

— Син... Тынычлан!

* * *

Бәлки... Бәлки, ялгышлык чыккандыр? Күренмичә калуы бар. Исемемне күрми узып киткәннәрдер, бәлки? Нәрсә ул кырык биш исем арасында бер матрос исеме? Бәлки, өстәмә исемлек бардыр? Кыска тоелды судовая роль. Бардыр. Көтәм. Һаман көтәм. Вакыт үтә. Стенадагы җиз корпуслы, СОС биргәнне тыңлар өчен өч белән дүрт һәм тугыз белән ун арасы кызылга буялган циферблатлы диңгез сәгате кебек: тек, тек, тек... «Син, Мокамаи, калдың, югалдың...» дигән бәйләнешсез сүзләр хәтер төбеннән калкып чыкты. Алар да югалды. Күз алдымда яшькелт шәүләләр. Тамак төбе кызган.

Курбатов кына тыныч. Ул җыелыш беткәнне көтә. Бригас та, капитанга карап, үзен тыныч тотарга тырыша. Көче җитми. Яшь бит әле. Миннән ике генә яшькә өлкән. Кинәт Карл Яновичны кызгана башладым. Ничектер куркыныч булып китте. Ничек инде?.. Димәк, үзеңнең яхшы эшләвеңә, белемеңә, кешелегеңә, экипажның ихтирамына бер таяныч юк? Кушнаренко укыган исемлеккә керү өчен синең эш белүең, осталыгың, сәләтең, талантың — болар берни түгел? Алар, билгеле, бу җаваплы

карарны исәпсез, уйламыйча чыгармыйлар... Ә вөҗдан тыңларга теләми бу дәлилне. «Лохмачев лаеклы булганда капитан Курбатов, Бригас, Шахсуарзадә ни сәбәп лаеклы түгел?» — дип яман дау куптара. Ни хәл бу? Ничек аңларга? Ничек түзәргә?

Башкаларны кайгырту, үзем яраткан кешеләр белән бергә калу үз кайгымны җиңеләйткәндәй итте. Хәтта капитан Курбатов янында калу, аянычлы булса да, бер чама горурландыра иде. Шулай да... авыр. Канатлар сынды. Көч, вакыт, тырышулар, авырлыклар, зарыгып көтүләр — барысы да бушка. Җанымны ачыттырып университет искә төште. Председатель Зәки абыйның авылда калырга кыставы. Әнием... Авылым. Бәлки туган җиремне ташлап китүем өчендер бу? Сөргән җиремне, ата-бабаларымның сөякләрен ташлап китү җәзасы. Шуның гөнаһы... Житәкче һаман сөйли:

— ...партия, ватан, халкыбыз сезгә җаваплы миссия тапшыра. Бүгеннән башлап, сез чит илләргә йөрүче диңгезчеләр. Анда сез капиталистик чорналышта, буржуаз идеология эчендә яшәргә мәҗбүр буласыз. Чит ил кешеләре сезгә карап совет кешесенең нинди булуын, совет кешесенең буржуаз илләрдә яшәүчеләрдән кайсы ягы белән аерылып торганын беләчәкләр. Сез совет кешесе дигән бөек исемгә тап төшермәскә тиешсез. Чит илләрдә йөргәндә сезнең ватанга тугрылыклы булуыгызны бөтен совет халкы көтеп торачак. Шушы җаваплы миссияне үти алырсыз дип сезгә партия, ватан һәм халкыбыз ышана. Иптәшләр, шушы җаваплы һәм почетлы миссияне өстегезгә алу белән тәбриклим!

Күзем Лохмачевка төште. Аның морадына ирешкән чагы. Звездный час диләр руслар мондый вакытны. Бит алмалары алсуланып чыккан. Шатлыгы эченә сыймый. Аңа чит илләргә йөзү киңлегенә чыгу — беренче шатлык, Курбатовның төшеп калуы — икенче шатлык, өлкән штурманлыкка күтәрелүе — өченче. Берьюлы өч зур шатлык. Ул яңа капитан белән уртак тел таба алачак. Бусы тагын бер шатлык.

Капитан Курбатов урыныннан күтәрелде. Яңа капитан янына килде:

— Тапшыру-кабул итү эшен кайчан башлыйбыз? — диде ул.

— Хәзер үк,— диде Деркач катгый гына.— Ашыгырга кирәк, уналты нуль-нульдә йөк төялеп бетә.

— Сезгә, лачыннар, уңышлык телим,— диде Курбатов экипажга таба борылып.— Бердәмлекне саклагыз. Тыныч диңгез һәрвакыт җиде фунт тирәнлек булсын. Рәхмәт сезгә, лачыннар. Мин сезнең күбегез белән горурланам.

Кабат кул чабу башланды. Кемдер кычкырды:

— Китмәгез, Василий Степанович.

Шундый урынсыз тоелды бу сүзләр. Без, төшеп калучылар, җыелышның тәмамланганын көтеп тормыйча, тизрәк каюталарга таралып, чемоданга әйберләребезне җыярга тотындык.

* * *

Йортларыннан язучылар була. Җирсез, туган илсез калучылар. Йортны, туган җирне йә тартып алалар, яисә кеше аны үзе ташлап китә. Тартып алсалар да, ташлап китсәң дә, йорт һәм туган җир урынында кала.

Бүген безне йортыбыз ташлап китә. Әнә, йорт кузгала, без калабыз. Йорт кына түгел, вазифабыз, эшебез, дусларыбыз, хыял-ышанычлар, өмет һәм иминлек — барысы бергә корабка төялеп китә. Без, нишләргә белмичә, причалда басып торабыз. Кул болгарга кирәк. Әнә, дусларым кул болгыйлар. Кулым — таш, күтәрелми.

Корабның синсез диңгезгә чыкканын карап калу шул кадәр газаплы икән. «Чолман» китә. Кораб белән минем җылы ястыгым, утырып ашый торган өстәлем, каютадагы җылылык, сагынганда, җирсенгәндә юаныч бирә торган урын — уң як шлюпка астындагы ком тартмасы — ул да китә.

Сабын савытын алырга онытканмын. Сабын савыты Италияне күрәчәк, ә мин — күрә алмыйм. «Чолман» белән минем анда үткән гомерем китә. Корабта яшәгәндәге уй-фикерләрем, китапларым, юыну бүлмәсе — барысы да мине ташлап, ярда калдырып китәләр. Алар мине кызгана микән? Шуны беләсе иде. Хәзер корабны беркем туктата алмый. Хәтта Курбатов та. Ул безнең янда. «Чолман»да — башка капитан. Кораб аның боерыгына буйсынмый хәзер.

«Чолман» һаман ерагая. Палубада басып торучылар курчак зурлыгы булып кына күренә башладылар.

Экипаж китте. Без причалда.

Курбатов калды — шунысын аңлап булмый. Алар ничек йөзә алырлар икән? Кораб батмасмы икән? Давыл чыкса? Элек тә, башка капитаннарны күргәндә: «Бу бит безнең Курбатовка охшамаган, ничек кораб йөртә ала икән?» — дип аптырый идем. Дөрес, «Чолман»да әйбәт кешеләр бар. Черногорский анда, Шмаков, Лагуткин... Алар җитәрлек. Китәләр.

...Чынбарлык — аяусыз. Ул синең хисләрең белән чутлашып тормый. Белми дә ул синең кичерешләреңне, белергә дә теләми. Кораб минем хыялымны алып китте. Мине... Исемлектә «Габдрахман Бәкерович Рахманкулов» дигән өч сүз булмау сәбәпле төшереп калдырдылар. Әллә тәкъдир дигәннәре, чыннан да, бармы икән?

Мәктәп елларыннан алып «язмыш безнең үз кулыбызда» дип туктаусыз тукып килделәр. Без шушы турыда сочинениеләр яздык, лекцияләр тыңладык. Һәм мин тәкъдирнең булмавына шиксез, риясыз ышандым. «Теләсәң, бәхеткә дә ирешеп була. Ул да безнең кулда»,— дип тукып тордылар. Моңа да ышандым. Менә хәзер мин — бәхетсез. Бәхетсезлегемне җиңәргә тырышам — берни чыкмый.

— Киткән кешегә юл яхшы, калган кешегә өй яхшы, дип әйткәннәр картлар. Киттекме? — җавап көтеп тормыйча, Шахсуарзадә урыныннан кузгалды.

Уяндык. Боцман уятты. Як-ягыма каранып алдым. Одесса порты. Җиденче причал. Советлар Союзы. Егерменче гасыр. Тузан һәм диңгез исе. Күрше причалда Норвегия пароходына агач мичкәләр төйиләр. Чыгырлар шыгырдый. Артыбызда хан заманыннан калган паровоз, «күке» булып кычкыра-кычкыра, вагоннар җыеп йөри. Ә «Чолман» торган урын буш.

— Ситуация.— Бригас кесәсен капшап карады.— Тартасы килә.

— Сез бит тартмыйсыз,— диде доктор Левицкий гаҗәпләнеп.

— Тартасым килә. Ачырагына да каршы килмәс идем,— диде Карл Янович. Ул хәзер һич үзенә охшамаган иде.

— Нинди паника бу? Без, лачыннар, исән. Баш үз урынында, аяк-кул, акыл. Әйдәгез, минем квартирага.

— Рәхмәт, Василий Степанович, мин тулай торакка барып, урын эләктерергә тиеш. Соңга калсаң, анда урын булмый,— диде Бригас.

— Мин дә тулай торакка барам,— дидем мин.

— Ә син, Гасыйм? — диде капитан боцманга.

— Мин мунчага барам. Мунча керәсем, пакьләнәсем килеп китте,— диде Шахсуарзадә.— Мунча. Шуннан да рәхәт нәрсә бармы икән җир йөзендә!

— Лачыннар, сез башка корабка урнашмагыз,— диде капитан.— Без тиздән яңа кораб алырга тиешбез. Югалтмыйк бер-беребезне. Экипажны саклыйк.

Боцман көләргә тотынды:

— Экипаж. Иләгәндә иләктән коелган чүпне кире чистартылган ашлыкка кушалармы? Экипаж!

— Минем белән киңәшмичә, башка корабка урнашмаска тырышыгыз,— диде капитан боцманның сүзенә әһәмият бирмичә.

— Әллә ресторанга кереп, кайгы-хәсрәтләрне юып чыгыйкмы? — диде доктор Левицкий.

— Нинди кайгы-хәсрәт ул? Син, Борис Яковлевич, ташла! Нинди төшенкелек бу? Без әле... Без... Кара, ничек шыңшый башладылар,— диде капитан Курбатов.

* * *

Агач елаганын тыңлап ятам.

Тол хатыннар тавышы чыгарып каен елый. Имән көчле, ул теш кыса, түзә, бирешми. Түзәр хәле беткәч кенә, ирләрчә, иреннәрен тешләп, ыңгырашып ала. Иң каты елаганы — чаган. Чаган да түзем. Ул да бирешми көрәшә, тыела, тырыша. Түзүнең дә чиге була. Шул чиктән соң, башка чара калмагач, үкси-үкси чаган үкерергә тотына. Иң аянычлы тавыш нараттан чыга. Ул тыела алмый. Оятсыз, шапшак әхлаклы, бәгырьсез кәнтәй ирдән алданган яшь кыз шикелле, бәгырьләреңне корытырлык итеп, чәчләрен йолка-йолка нарат өзгәләнә.

Торып шәм яндырдым. Караңгылык чигенде, барып почмакка посты. Ысланып беткән тәбәнәк түшәм. Түшәмнән чут-чут тамчы тама. Идән уртасына су җыелган. Стена ярыкларыннан сызгырып кереп, шыксыз җил өрә. Шәм ялкыны җилгә баш ия, сүнә башлый һәм дерелдәп торая. Почмакка поскан шомлы шәүләләр әкрен генә кыймылдап алалар. Каршы як стенадан кинәт гигант күз чекерәйде. Убырмы әллә? Тәннәрем чымырдап китте. Йокым очты. Шайтан! Иллюминатор икән. Түгәрәк иллюминатор пыяласы аша зәгыйфь таң нуры беленә башлаган.

Өч мачталы ташландык барк — җилкәнле кораб «Вега»ны саклый башлавыма егерме көн тулды. Барк Одесса портының эчке ягыннан дулкынваткычка бәйләп куелган. Ялгыз корабта бер ялгызым. Салкын дым. Ярыклардан җил керә. Эчке тынгысызлык. Давыл. Кораб дер селкенә. Агач рангоутлар корабның такта тәне елаган тавышлар чыгарып шыгырдый. Нәрсәдер шытырдап сынды. Дөпелдәп ауды. Зыңгылдап бау тартылды, өзелде. Швартов баулары черек, корабны көчкә тотып торалар. Баулар өзелеп бетсә, кораб давыл кочагында калачак. Дулкынваткыч янәшә генә. Шул челпәрәмә итәчәк корабны. Корабны бәйдә тоткан арканнарны тикшереп керергә кирәк. Кирәк... урыннан торып палубага чыгу — гүр газабы. Суык. Юеш. Тән бөрешкән. Чиркандыра.

«Палубага чыкмас өчен бар байлыгымны, киләчәктә аласы акчаларымны бер кызганмый бирер идем». Көлке. Кайда, нинди байлыгың бар синең?

Көч җыям. Ихтыяр көчен. Их авыр, авыр җылынган шинель астыннан чыгуы! Аркама шундук салкын бәрде. Балтырларымны көзән җыера. Оекбашны киптерергә астыма салып яткан идем. Алып кидем, аякларымны ботинка эченә тыктым һәм — утка баскан шикелле сикердем. Ботинка эче тулы салкын су!

Шәмне җил юлыннан читкәрәк күчереп куйдым. Шәм уты стенадагы барометрны яктыртты. Басым һаман төшә. Давыл туктарга теләми әле.

Кызыл агачтан ясаган тартманы идәннән алып өстәлгә куйдым. Тартмада — секстан. Өстәлдә шомарып беткән штурман транспортиры. Кирәксез. Кесәмдәге штурман дипломы да кирәксез бер нәрсә кебек. Имтиханнарны «биш»легә тапшырдым. Авиациядә алган белем ярдәм итте. Миңа диплом бирделәр. Дипломның нөсхәсен кадрлар бүлегенә илткәндә капитан Курбатовны очраткан идем.

— Котлыйм, лачын,— диде ул сабыйларча куанып.— Әлегә чит илгә йөри торган корабка штурман итеп алмаслар сине. Каботажга эләгү дә җиңел булмас. Резерв зурайды. Судно йөртүчеләрне кая куярга белмиләр. Тукта, мин сине «Вега»га өченче штурман итеп алам. Дөрес, штат расланмаган әле. Вакытлыча матрос булып кораб сакларга риза булсаң — дело в шляпе.

— Җилкәнле кораблар заманы үтте бит, Василий Степанович,— дидем капитанның донкихотлыгына сокланып.— Ул кемгә кирәк? Андый эшкә бер капсаң, пенсиягә кадәр утыртырлар.

— Курыкма, аларга да эш табылыр. Мин министрга хат яздым. Безнең чор балаларын эшләтмичә үстерәләр. Мореходка укучы штурманнарның күбесе — белоручка. Эш белмиләр, хезмәт яратмыйлар. Алар арасында эш ләззәтен аңлаучы бик сирәк. Практика вакытында курсантларны җилкәнле корабта эшләтеп чыныктырырга, хезмәткә күнектерергә кирәк. Авырлыкларны җиңәргә өйрәнсеннәр, тазарсыннар, мускулларны ныгысын дисәң, аларны җилкәнле корабта эшләтергә кирәк. Ялкаулыкны диңгез кабул итми. Укуның беренче елында ук курсантларны җилкәнле корабта эшләтеп карарга кирәк. Андагы эшкә ялкау да, аксөяк тә түзә алмый. Алар флотны ташлап китәчәкләр. Шушы юл белән алардан котылып була. Аңладыңмы, лачын?

Капитанның канатлы хыялы мине өч мачталы иске баркка китереп куйды. Әйбәт булды — инде өченче көн бүленеп ятам. Давыл. Катер йөрми. Сәхәрсез, авыз ачусыз «ураза» тотуыма инде өч тәүлек.

* * *

...Давыл басылган иде. Дулкыннар еракта, брекватер артында ялкау гына чупылдыйлар. Кораб тынычланган. Агачлар елаудан туктаганнар. Күк йөзе болытлардан әрчелгән. Өч тәүлек якты дөнья кыйнап җиңә алмавын аңлаган давыл каядыр китеп олаккан.

Диңгез хатын-кыз шикелле ул: котырынып туйгач, йомшара, нәзберекләнә.

«Вега» янына катер килеп туктады. Капитан Курбатовка ияреп минем алмашым карт матрос Арсентий Птицын менә.

— Исән,— диде Птицын мине күрү белән һәм чыпчыкка охшатып тыпырчынып алды.— Исән, исән, исән.

— Мә, эчеңне җылыт, лачын,— дип капитан термоска тутырган кофе һәм бутерброд сузды. Француз булкасын урталай ярып эченә колбаса, баллы борыч, хуш исле тәмле үлән кыстырганнар. Ураза тоту файдалы була икән. Бутерброд — җәннәт ашы кебек тәмле иде. Мин ашаган арада капитан өстен алыштырып чыкты. Палубада Птицын тыпырчынып йөри. Елга буе ташлыкларында йөгереп йөри торган бер кош бар. Сиртмәкәй диләр аны. Русча ул трясогузка атала. Птицын шуңа охшашлы. Күзләр бәләкәй, муен озын. Туктаусыз боргалана, гафу үтенә:

— Ничего-ничего, хәтерең калмасын. Өч тәүлек давыл. Өч тәүлек катер йөрмәде. Өч тәүлек... Ничего-ничего. Э-э-э-э-э, исемеңне оныттым...

— Сиңа, лачын, өч тәүлек ял,— диде Курбатов.— Акчаң бармы?

— Күп. Кесә тулы. Соңгы тапкыр нигәдер мул түләделәр.

— Әйтергә онытканмын. Мин бит сине күтәрттердем. Син, лачын, «Вега»ның өлкән штурманы. Минем ярдәмчем.

«Тагын күтәрелә башладым, хәерлегә булсын»,— дип уйлап куйдым. Кораб безне ташлап киткән көнне яшәп булмас дип курыккан идем. Күк йөзе — һаман зәңгәр. Кояш вакытында калка, вакытында иңә. Диңгез дә кипмәде, үз урынында. Әнә, «Чолман»ның элеккеге капитаны, без белән төрткәләп, агач тәнле җилкәнле корабның черек җирләрен эзләп йөри.

— Йөз утыз мең акча кирәк. Әгәр пароходчылык ремонтка йөз утыз мең бирсә, көзгә, лачын, җилкәннәрне күтәреп, диңгезгә чыгабыз. Әле синең, лачын, җилкәнле корабта йөзү рәхәтлеген татып караганың юк бит. Юк, ул рәхәтлекне берни белән чагыштырып булмый. Мин болай уйлыйм. Җир астындагы нефть бер заман яндырылып бетәчәк. Нефть беткәч нәрсә ягып йөрербез дип уйлыйсың, лачын?

— Атом көче белән,— дидем мин картлачның ярасына бер уч тоз салып.

— Уран рудасы да мәңгегә җитмәс. Ә планетада җил. Пассат, муссон җилләре, афганлы, харара, самум, мистраль, трамонтана, тайфун,

торнадолар. Аларның әле туктарга исәпләре юк. Җилне акча түләп аласы да юк. Ул әзер, диңгез өстеннән туктаусыз йөгереп тора. Җилкәнле кораблар диңгезгә чыкканда флотта җилкән белән идарә итүче калмаячак. Тәҗрибәмне кабергә алып китәсем килми, сезнең буынга калдырасым килә. Шунысын белмим, сез кабул итәрсезме икән?

— Прогресс шулай, Василий Степанович. Кешенең бар җыйганы киләчәк буыннарга кала. «Вега»ны диңгезгә чыгарып булуга ышанып бетмим мин, гафу итегез. Министрлыкта кемнәр утырганын беләсез. Бу эшне бирәү дә үзе теләп өстенә алмас. Җаваплылык бит. «Вега»ны саклап гомерем узар дип куркам мин.

Минем ерак диңгезләрне, мәрҗән атолларын күрәсем килә. Инде түзәр хәлем калмады.

— Син, лачын, үзеңне ни сәбәп «Чолман»нан төшереп калдыруларын ачыкладыңмы?

— Юк әле, Василий Степанович.

— Кадрлар бүлегенә дә бармадыңмыни?

— Бардым. Алар белмибез диләр. Әллә чыннан да белмиләр, әллә әйтергә ярамый.

— Син, лачын, комсомол секретаре булуыңны оныттыңмыни? Комсомол комитеты аша тикшерт.

— Ярдәм итә алмаслар дип куркам. Шунысы үкенечле, сәяхәткә ымсынып, укуымны ташладым.

— Шыңшыма, лачын. Көрәшергә кирәк. Син, Гамлет, комитетка бар. Әйт, мин «Чолман»ның комсомол секретаре, пароходтан төшеп калдым диген. Мондый чакта авыз ачып көтеп тормыйлар. Ял иткәндә китапханәгә йөрисеңме?

— Баргалыйм. Ничектер кәеф юк, Василий Степанович.

— Кәеф юк? Син нәрсә, дворян кызымыни? «Кәефем юк, пардон». Горький китапханәсенә бар да Джозеф Конрадны сорап ал. Укый башлагач, төшеп калуың да, башкалар да онытылыр. Ә синең аны укыганың бармы?

— Хикәяләр җыентыгын гына.

— Джозеф Конрадны, Мелвиллны, Генри Тороны, Киплингны тулысынча укып чыгарга кирәк. Капитан Кук, Магеллан, капитан Роберт Скотт язмаларын инглизчә укып чыгарга кирәк. Ә си-и-ин — «төшереп калдырдылар...» Мин үзем гарәп географларын яратам. Белмим, аларны русчага тәрҗемә иттеләрме икән? Әл-Мөкатдәси, Ибне һәүкәл, әл-Мәгъсуди, Йакут — менә кемнәр җир йөзенең серен һәм могҗизаларын белгәннәр. Син бит капитан буласы кеше. Укымыйча, культураны үзләштермичә капитанлыкка ирешкән кеше ул... Озын сәяхәттә китапсыз яшәве бик кыен. Капитан экипажда иң укымышлы, иң культуралы кеше икән — аны ихтирам итәләр. Ихтирамсыз авторитет — культ кына ул. Капитанга абруй кирәк. Абруйсыз власть — җилкәнсез кораб шикелле ул. Адәм баласы үзе яраткан, ихтирам иткән кешесенә генә җаны-тәне белән буйсына ала. Яратмаган кешегә тыштан гына буйсынган булып күренәләр,— капитан сүзеннән туктап, бер тын уйланып торды.— Син инглизчә сүзлексез укый аласыңмы соң?

— Юк әле.

— Курыкма, укы. Өйрәнеп китүеңне сизми дә калырсың. Көн саен укы. Туры килгән саен сөйләш. Тел өйрәнүнең кагыйдәсе шул. Ярый, мин синең вакытыңны алам. Әнә, катер килә. Ял ит. Вакыттан файдаланып кал.

Начальниклар кабинетына тоткарлыксыз үтеп керү өчен мылтык затворындагы тәвәккәллек кирәк. Мин шушы турыда уйлап кабул итү бүлмәсенә үттем. Секретарь кызны күрмәскә тырышам. Янышнан узып, ишеккә якынлаша башладым.

— Кем кирәк сезгә?

— Комитет секретаре.

— Ул бүген кабул итми. Иртәгә килегез.

— Мин — комсомол секретаре. Эшем җитди, көтеп торырга вакытым юк.

Кыз мине ишетмәде. Сүзләрем бушлыкка күмелде. Ул, арты белән борылып, машинкада суктырырга керешге.

— Әйтеп карагыз әле. Зинһар өчен... Бәлки рөхсәт итәр?

— Мин сезгә русча әйттем.

— Кызганычка каршы, мин русча аңлап җиткермим,— дидем дә туры ишеккә юнәлдем.

Бусаганы атлау белән тәвәккәллек бетте, юкка чыкты. Ялтыравыклы лакка буялган зур өстәл. Китап шкафы. Кыйммәтле радиоалгыч. Суыткыч. Кыйммәтле агачтан ясалган бар. Стенада зур карта. Юлбашчы рәсеме. Секретарь өстендә затлы соры костюм. Ишеккә таба борыла башлаганда кабинет хуҗасы кәгазьдән башын күтәреп елмайды:

— Ә, Рахманкулов... «Чолман»да эшләр ничек бара?

— «Чолман» Италиягә китте,— дидем мин авыз кипкәнен сизеп.

— Ә сез?

— Мине төшереп калдырдылар.

— Кем төшерде?

— Белмим. Мин шуны белергә килдем. Ярдәм сорап.

Кабинет хуҗасы уйга калды. Шикләнү дә сизелә иде инде. Зирәк кеше буларак, секретарь шикләнүен яшерде. Ул бит аңлый. Без, гадиләр, «белмим» сүзен гаҗәп оста куллана беләбез. Белмәмешкә салышу — киң кулланыла торган дипломатия ысулы. Бу кеше «белмим» артына ерып чыкмаслык катлаулы мәсьәләләр яшеренгәнен аңлый иде. Мин дәвам иттем:

— Инспектордан да сорап карадым. Белмим, ди. Кадрлар бүлеге белергә тиеш бит, әйеме? Әйтмиләр. Белмим, диләр. Кайда да шулай.

— Ярый, без аны ачыкларбыз,— диде секретарь шактый сүлпән итеп.— Мин сезгә хәзер бер йомыш кушам. Кичке җидедә опера театры бинасында Тайвань тоткынлыгыннан кайткан «Туапсе» танкерының экипажы белән очрашу була. Сез шунда яшь диңгезчеләр исеменнән агрессорларга карата нәфрәт сүзе әйтсәгез иде. Килештекме?

— Зур аудитория каршында чыгыш ясаганым юк. Каушап калмаммы икән?

Секретарь сузган кәгазьне алып укып карадым. Чыгыш әйбәт иде. Шулай да кеше язганны уку уңайсыз тоелды. Әйтергә кыймадым.

— Ярый, укырмын,— дидем мин сүлпән генә.

— Укымыйсыз,— диде секретарь.— Очрашуга җыелган кешеләр алдында чыгыш ясыйсыз. Һәр әйткән сүзегез йөрәктән чыгарга тиеш. Җаваплы эш бу. Аңладыгызмы?

— Сезгә тагын бер үтенечем бар,— дидем мин секретарьга.— Мин ялда чакта икенче штурман Виктор Филимонович Лохмачевка партиягә керергә рекомендация раслаганнар. Лохмачев партиягә керергә лаеклы түгел. Оешма секретаре буларак, мин каршы. Башкалар да каршы, ләкин алар җыелышта уйламыйча, кул күтәргәннәр.

— Ничек инде лаеклы түгел? Аңлатыгыз.

— Әзер түгел,— дидем мин дәлилемнең көчсез, ышандырырлык түгел икәнен сизә башлап. Тойгылар Лохмачевның начар кеше икәнлеген сизәләр. Аның үз-үзен тотуы, башка кешеләргә булган мөнәсәбәте — боларның барысы да ясалма, күз буяуга көйләнгән. Башкалар да аның шундый икәнлеген аңлыйлар. Ләкин аңа каршы чыккан кешене хәтерләмим мин. Секретарь уйга калды.

— Ничек инде әзер түгел,— диде ул.— Тәртип боза? Эчә? Профессиональ як түбән? Эшен белми? Вазифасын башкара алмый? Конкретно шуларның кайсы?

— Берсе дә түгел,— дидем мин. Әйткән сүземнең яла ягуга әйләнә башлавын тоеп.— Эчми, тартмый, тәртип тә бозмый. Үзенә тиешлесен

эшли. Җәмәгать эшендә дә актив катнаша. Политик яктан үзенең ышанычлы булуын җае чыккан саен күрсәтергә тырыша. Лохмачев — икейөзле, имансыз, әхлак кануннарын таптаучы.

— Иман — аллага ышану дигән сүз түгелме соң? — диде секретарь гаҗәпләнеп.— Әллә сез диниме, Рахманкулов?

— Иман бит ул, иптәш секретарь, вөҗданның шәфкатькә, игелеккә көйләнгән булуы. Иманлы кеше үзенә зыян килердәй булса да яхшылык эшли. Ул яхшылык эшләүдән мәгънә, тәм таба. Иманлы кеше яхшылык эшләмичә яши алмый. Лохмачевның, киресенчә, бар эше, бар гамәле гел үзенә файда ясауга көйләнгән. Үзенә файда буласы җирдә Лохмачев кешене җәберли, кимсетә. Файда өчен түбәнсенә, ялганлый ала. Файда өчен ул бер эштән дә тартынып тормый.

— Абстракт сөйлисез сез, Рахманкулов,— диде секретарь күңелсезләнеп.— Мин сезне аңламыйм. Бәлки сезнең үзара мөнәсәбәтләр начардыр? Бәлки арада үч бардыр?

— Тагын аңлый алмассыз дип куркам. Лохмачев үзенә кирәкле кешегә генә яхшы була ала. Син аңа файдасыз икән — ул сиңа битараф. Аның мөнәсәбәте гел файдага көйләнгән,— дидем мин.

— Ярый, сез Лохмачевның бер конкрет кимчелеген әйтә алмадыгыз. Кеше сиңа ошамый икән, аның кимчелекләрен генә күрәсең. Яраткан кешеңнең, киресенчә, гел уңай яклары гына күзгә ташланып тора. Психология, иптәш Рахманкулов.— Секретарь әңгәмәдән туйган иде. Кабул итүнең тәмамлануын белгертеп, урыннан торды.

Лохмачев турында сүз кузгату кирәксез булды. Хәтта аның зарары да тиде. Беренче үтенечем соңгы сөйләшү артында күмелеп калды. Соң бит мондый җиргә ике үтенеч белән берьюлы килмиләр. Татар акылы тау төшкәч.

— «Чолман»нан төшереп калдыру сәбәбен кайчан ачыклый алырсыз икән? — дидем мин чыгып китәр алдыннан гына.

— Эш күп, Рахманкулов. Ачыклагач, мин сезне чакыртырмын. Чыгыш турында онытмагыз. Кичке җидедә. Ярый, сау булыгыз.

* * *

Кичке тугызда китапханәдән чыктым. Тулай торакта минем караватым бар, корабта — аерым каюта. Күз бәйләнгән чак. Йокы вакыты җитеп килә. Кая барырга? Торган җиремнең икесенә дә кайтасым килми, аларның икесендә дә җанга җылылык юк. Гаиләсез, әнисез, хатынсыз җирләрдәге шыксызлык.

Тулай торакта без бер бүлмәдә дүртәү яшибез. Бүлмә иркен, җылы, төннәрен, троллейбус туктаган чакта, хәтта тыныч та була. Йомшак матрац, кием шкафы, юыну урыны, һәр кешегә аерым тумбочка. Яшәү өчен тагын ни кирәк? Нәрсәдер җитми. Нәрсә? Шуны аңларга тырышам. Адәм баласы әниләр канаты астында үсә. Без әниләрнең йөрәк җылысын тоеп яшәргә өйрәнгәнбез. Бәлки шул җитмидер? Әниләр кайгыртуы, аларның яратуы яшәүгә мәгънә биреп, тормыш кырыслыгын йомшартып, йөрәккә җылылык биреп тора. Җылылык «Чолман»да да бар иде. Капитан Курбатов, Шахсуарзадә, Бригас, Барсуков, Шмаков. Дөрес, алар әти-әниләрне алыштырып, гаилә якынлыгын бирә алмыйлар иде. Якында син яраткан кешеләр булуы эчке бер рәхәтлек тудыра. Дуслар янында яшәү ямьләнә. Бүлмәдәшләр исә көн саен диярлек алышынып торалар. Искеләр урынына яңалар килә. Танышабыз, фикер бүлешәбез, бер-беребездән, өметләнеп, нәрсәдер көтәбез. Дуслык тойгысы уяна башлау белән танышлар китә. Алар урынына яңалар килә. Көн аралаш югалту. Вакытлы кешеләр белән синең ирешелмәгән өметләрең, эшкә ашырылмаган теләкләрең китә.

Мин югында бүлмәдә үзгәрешләр булып алган. Әнә, матрац өстендә чокырланып торган ике урын калган. Тумбочка эчен дә тикшергәннәр —

капкачын кире ябарга онытып калдырганнар. Укыган газетасын кемдер минем мендәрем өстенә ташлап киткән. Китапларымны тикшереп чыктым. Алмаганнар, әмма актарып караганнар. Җаным рәнҗеп алды. Вакытлы оя бит тулай торак — түзәргә кирәк.

Чишендем. Караватыма менеп яттым. Уйларым, ватык граммафон тәлинкәсенә язылган иске җыр шикелле, башлаган урынга кире әйләнеп кайтып, кабатланып торалар. Нигә?.. Нигә?.. Нигә?.. Теңкәмне корытма син, әрсез сүз! Ишек ачылып ябылды. Бүлмәдәшемнең берсе кайтты. Күземне кысыбрак йомдым. Йоклаганга салышып ятам. Күз кабаклары арасындагы ярыктан күрәм: озын буйлы, таза, матур егет. Дулкынланып торган куе, кара чәч. Сокланырлык. Ике генә тәүлек элек шушы караватны тәбәнәк буйлы, төннәрен лач-лоч сагыз чәйнәргә яраткан бер юан матрос били иде. Бүген бу егет. Ә иртәгә кем?

Бүлмәдәшем авыз эченнән генә «Ак акация» опереттасыннан «На краю льдов бить китов, рыбьим жиром детей обеспечивать...» дигән арияне шыңшырга кереште. Тумбочкасын ачып бер сынык ипи алды, консерва ачты. Бүлмә эченә шпрот исе таралды. Тәмле итеп, ләззәтләнеп чәйни бүлмәдәшем. Йотып җибәргәч, иреннәрен ялап куя. Ашавына карап, кайларда булуын, нәрсәләр эшләвен абайладым. Кызы да чибәр булырга тиеш бу егетнең. Икесен бергә күрәсе иде. Ымсынып киттем. Карыным ачу уянды. Тумбочкамда бер генә сынык ипи кисәге калган булса да, торып, бүлмәдәшемә кушыла идем. Белеп торам, ул миңа сөйгән яры турында, аның матурлыгы, уңганлыгы, ятатуы турында сөйләр иде...

Бүлмәдәшем кайту белән тирә-якка канәгатьлек хисе таралды. Бәхетле иде янәшә караватны биләүче егет. «Әллә бәхеттән, чыннан да, шпрот исе киләме икән?» — дип уйлап куйдым.

Ашап туйгач, егет ипиен газетага төреп тумбочкасына яшерде. Рәхәт итеп иснәнде, чишенергә кереште. Урамнан улаган тавыш чыгарып троллейбус үтеп бара иде. Бүлмәдәшем чишенүдән туктап бер тын тыңлап торды. Тавыш тынды. Егет караватына менеп, юрган астына керде һәм, минут та үтмәгәндер, гырылдарга кереште.

Тагын бер йокысыз төн.

Торып киендем. Ишекне иплап кенә ачып коридорга чыктым. Гырылдау монда да ишетелә иде. Бу бәндәнең тамагы нәрсәдән ясалган икән? Үзе шундый чибәр... һәм бәхетле күренә.

— Пароход каршыларга барасыңмыни? — дип сорады дежур торучы хатын. Аңлата башласам, озакка китә иде. Баш кактым.

Бәхетемә каршы, рейдка кеше ташучы катер кузгалырга тора иде. Өлгердем. Ун минуттан мин «Вега»ның палубасында идем. Корабның кутырланган тәнен караңгылык каплаган. Яшь чагында барк көрәнсу лакка һәм алтын путага буялган булган. Нишлисең — кеше дә картая. Яши, тырыша, акыл туплый, мал җыя. Хәтта әкренләп яшәргә өйрәнүчеләр дә очрый. Һәм, бер көнне — мал да, тәҗрибә дә, акыл да кирәксезгә кала. Табигать, син бу канунны аңлап эшләдеңме?

Ишек биксез. Каютага үттем. Ишек шыгырдауга Птицын урыныннан торды, идәнгә төште һәм чалбар сәдәфләрен төймәли башлады.

Птицын катерга утырып киткәч, такта кыйпылчыклары табып, учак яктым. Диңгездән су алып кереп идәнне юдым. Каютама җан керде. Җылы, чиста, тыныч. Башка ни кирәк адәм баласына? Дөрес, бәхет кирәк. Зур теләкләргә буй җитмәгән чакларда шушы өч нәрсә дә бәхет. Бәлки, шушы гади рәхәтлекне санга сукмыйча, күпкә үрелү кешене бәхетсезлеккә дучар итәдер? Чыгып швартов бауларын тикшереп кердем. Һәм йокларга яттым.

Җылы, тыныч, чиста. Шушы рәхәтлекләр бала чагыма алып кайттылар. Татлы төшләр мине күтәп кенә торганнар. Төшемдә мин әти янына утырып Баулыга барганымны күрдем. Баулы диңгез ярында икән. Анда корабым көтеп торган...

* * *

Комсомол секретаренең кашы җимерелде. Ул кәефен яшерде. Елмайды.

— Ну? Барамы эшләр, Рахманкулов? — диде ул ягымлы итеп.

— Бармый, Владимир Сергеевич. Эшләр тукталды. Чакырмасагыз да килдем инде. Борчыйм. Түзәр хәлем калмады,— дидем мин комитет секретаренең узган очрашуда биргән вәгъдәсенә киная ясап.

— Вакыт юк, Рахманкулов. Агымдагы эшләр. Ничек килешкән идек әле без соңгы очрашуда?

— Сез минем ни сәбәп «Чолман»нан төшеп калуымны ачыкларга вәгъдә биргән идегез.

Комсомол секретаре телефон трубкасына үрелде.

— Семен Зиновьевич, сәлам сезгә! Птушкин бу. Ялыгыз ничек узды? — секретарь телефон трубкасын яңагы белән җилкәсенә кысып, кәгазь актарудан туктамыйча, озак кына чыбыкның теге очындагы кешенең сөйләгәнен тыңлап утырды.— Семен Зиновьевич, февральдә акыллы кеше Кырымга барамыни? Дөрес, дөрес. Әйе. Ялны алдан планлаштыра белмибез без. Шулай, шулай. Юк. Әйе. Бик кечкенә. Монда «Чолман»ның комсомол секретаре утыра. Рахманкулов. Хәзер сорыйм,— комитет секретаре учы белән микрофонны каплап, исемемне, этиемнең исемен сорады һәм «шундый тел сындырырлык авыр исем кушмасалар, җир йөзендә җиңелрәк исем беткәнмени?» дигәндәй, кыенсынып торганнан соң, кабатлады.— Габ... Габдрахман Бәкерович. Үзем өчен, Семен Зиновьевич. Кирәк. Важно.

Хәзер ул телефон чыбыгының теге очындагы кешене дикъкать белән тыңлый иде. Хәлиткеч мизгел иде бу. Яшәү дәверендә хәлиткеч мизгелләр. Их! Монда эшли башлаганнан соң гына да дистәдән артык хәлиткеч мизгелләр аша узарга туры килде. Авиациядә, университетта укыганда, укуны ташлап киткәч әле һаман шарлавыкка охшашлы, куркыныч, хәлиткеч мизгелләр. Аларның күренеп торганнары да бар. Күбесе — яшерен. Язмышны бернинди канунга буйсынмаган гигант көч туктаусыз төрле якка борып юнәлтеп тора. Секретарь җанланып китте:

— Так. Так-так. Әйе. Ярый. Әйе, әйе. Киләсе сайлауга чаклы, һәрхәлдә, ул үз пароходында калырга тиеш. Обязательно. Сез аны аңлыйсыз, Семен Зиновьевич. Башкача безнең эштә тәртип урнаштырып булмый. Әйе, мөмкин түгел. Рәхмәт.— Трубкасын куйгач, секретарь учы белән чәчен сыпырды.— Котлыйм, Рахманкулов. Виза ачык. Сезне «Чолман» штатыннан беркем чыгармаган. Сез — «Чолман»да комсомол секретаре.

— Без, Владимир Сергеевич, биш кеше: капитан, өлкән штурман, боцман, доктор. Без бишебез дә рольдә юк идек. Куренёнконың ярдәмчесе үзе укыды. Без юк идек...

— Башкаларны белмим мин, Рахманкулов. «Чолман» рейстан кайту белән эшкә керешәсез. Таләп — катгый. Комсомол эшен таркатсагыз, мин сезне үз кулым белән тагын каботажга күчерәм. Сөйләштек?

*Ахыры бар.*

# Нәби Дәүли

## Мина белән солдат очрашуы

*Бу сугышта булды.*
*Күптән инде...*
*Онытылмаслар ахры ул еллар:*
*Әле һаман*
*Дары исен тоям,*
*Утлы көннәр чыкмый уемнан.*

Иртә белән
Разведкага барам,
Нинди булыр алда язмышым?
Төтен белән
Утлар арасында
Югалганнар әллә азмы соң?

Тыныч иде әле тирә-яклар,
Сугыш килә яңа уянып.
Яраланган каен, башын иеп,
Елый кебек авыр моңаеп.

Барам, барам,
Кинәт шартлау булды,
Мина төште килеп каршыма.
Шундый матур үзе,
Көмеш башлы,
Җаны, күзе аның бар сыман.

Кемнәрдер бит
Ясап, булдырганнар,
Исемнең дә шәбен биргәннәр.
Үлемне дә бала төсле итеп,
Биләүләргә салып төргәннәр...

Ярылмады мина,
Шуып килеп,
Туктап калды тыны буылып.
Мине үлем куып җитәр төсле,
Йөгермәс лә кире борылып.

Тайпылсам да читкә,
Күрер кебек,
Ишетеп алыр минем сулышны...
Бу атаклы нәләт

---

*НӘБИ ДӘҮЛИ* (1910) — шагыйрь һәм прозаик, «Яшәү белән үлем арасында», «Мин җирдә калам», «Яңгырау» һ. б. утыздан артык татар һәм рус телләрендә басылган шигырь, проза китаплары авторы. Казанда яши.

Мыштым гына
Җилкәсендә тота сугышны.

Солдат белә,
Бу мәкерле бомба.
Мыскыллаган кебек котырта.
Тынлык белән кинәт
Күзне буа,
Шартламыйча ныграк куркыта.

Таш шикелле басып
Катып торам,
Карап торам үлем йөзенә.
Хәзер үзем тере һәйкәл кебек
Мина дигән кабер өстендә.

Ялтыр борынын сузып
Мина ята.
Кайчан шартлар, аны кем белә?
Икебез дә хәзер бетәчәкбез,
Икебезгә язмыш бер генә.

Аңлашылды миңа
Шул мизгелдә,
Котылдым мин авыр уйлардан:
Мина аткан
Дошман снайперы
Ориентирны дөрес куймаган...

Вакыт узды,
Белмим ничә минут,
Ничә минут тордык карашып,
Йөзгә-йөзне,
Күзгә-күзне текәп,
Бу билгесез җирдә адашып.

Белеп алдым,
Мина суынып бетте.
Алдан кудым үлем шәүләсен.
Тыныч кына атлап
узып чыктым
Тимер тәнле фашист гәүдәсен.

Үлек төсле
мина калды ятып,
Ә мин киттем алгы тарафка,
Офыклардан кояш чыгып килә,
Кул бирергә килә солдатка.

Уздым кебек
Караңгылык аша
Аяк бастым яшәү ягына.
Минем белән бергә тормыш барды,
Ышыкланып минем яныма.

Барам, барам,
Үзем уйлыйм һаман:
Бу нәләтне әле табарлар.

«Куркыныч юк,— диеп,— бу урында»
Бер тактага язып кадарлар.

Тик беркем дә
Беркайчан да белмәс
Кемнең моннан узып киткәнен —
Иң беренче булып разведчикның
Куркынычны таптап үткәнен.

*1975.*

## Ана тавышы

ҖЫР-ПОЭМА

**1**

Поездлар килә вокзалга, поездлар килә.
Солдатлар төшә вагоннан, солдатлар төшә.
Каршылый дуслар, туганнар, сөекле ярлар.
Чал чәчле ана вокзалда баласын көтә.
— Минем улымны күрмәдегезме?
Сугышта бергә йөрмәдегезме?
Кайда калды ул, белмәдегезме?

**2**

Уздылар еллар, уздылар. Кайтмады улы,
Көтте дә көтте анасы хәбәр килгәнен.
Мөлдерәп акты яшьләре соңгы мәртәбә,
Соңгы мәртәбә ахырда әйтте сүзләрен:
— Минем улымны күрмәдегезме?
Сугышта бергә йөрмәдегезме,
Кайда калды ул, белмәдегезме?

**3**

Каеннар уйга калганнар авыр тынлыкта,
Үләннәр үсә моңаеп кабер өстендә.
Ана сүзләре күңелдә, яшь йөрәктә,
Ул сүзләр калды гомергә халык исендә.
— Минем улымны күрмәдегезме?
Сугышта бергә йөрмәдегезме,
Кайда калды ул, белмәдегезме?

**4**

Ул сүзләр йөри телләрдә, илдән-илләргә,
Йорттан-йортларга тукталып зарын өләшә.
Тыңлагыз, кешеләр, тыңлагыз, тынып тыңлагыз,
Бөтен дөньяга сызланып ана эндәшә:
— Минем улымны күрмәдегезме?
Сугышта бергә йөрмәдегезме,
Кайда калды ул, белмәдегезме?

*1984.*

# Истәлек агачы

*Татарстанда Каракалпак әдәбияты көннәренә карата язылды.*

Булганым юк
Каракалпак җирләрендә.
Ләкин мине
Ул якларга каным тарта:
Истәлекләр
Калган тояк эзләрендә —
Анда барган
Минем бабам аргамакта.

Бармаган ул
Тагып кылыч, мылтык асып,
Кулларына
Китап белән акбур алган.
Колач җәеп,
Азатлыкка җанын ачып,
Тормыш сүзен
Йөрәгенә салып барган.

Ашыккан ул,
Сахраларны уза-уза,
Каракалпак
Дусты белән очрашырга.
Дөньяда бит
Бер үк төрле була нужа,
Зары белән
Чакырып алып кавыштыра.

Килгән бабам
Китап, каләм, акбур алып,
Кышлаклардан
Кышлакларга җәяү йөргән.
Караңгыда
Якты нурлар калган янып,
Каракалпак
Остаз йөзен шунда күргән.

Өсләрендә
Ефәк чапан булмаса да,
Таныганнар
Мөгаллимне бик ерактан.
Каракалпак
Сәлам биргән бусагада,
Бабам шулай
Үзенә дә ватан тапкан.

Сорамаган
Алтын-көмеш, хезмәт өчен,
Риза булган
Әйрән куеп, нан бирсәләр.
Кызганмаган
Үз гомерен, дәртен, көчен,
Рәхмәт, диеп,
Бер ягымлы сүз әйтсәләр.

Хәреф язып,
Күз ачтырган ул мөгаллим,
Китап укып,
Тел ачтырган ул мөгаллим.
Балаларга
Тәти биргән ул мөгаллим,
Аксакалга
Әти дигән ул мөгаллим.

Баш күтәреп
Җиргә баскан Каракалпак,
Богауларны
Өзеп аткан Каракалпак,
Галим булган,
Шагыйрь булган, Каракалпак,
Ил төзегән,
Бакча корган Каракалпак.

Шул бакчада
Минем бабам агачы бар.
Истәлеккә —
Халык аны Дуслык дия.
Ул агачның
Балкып торган алмасы бар.
Ул алмадан
Бар кешегә өлеш тия.

Аму-Дәрья
Гомер буе кая ага?
Дулкыннары
Зур диңгезгә юллар тота.
Саз чыңлатып,
Иделнең дә жыры кала
Гомер буе
Каракалпак торган йортта.

Булганым юк
Каракалпак жирләрендә.
Ләкин мине
Ул якларга каным тарта.
Чөнки анда
Дусты белән янәшәдә,
Мәңге бергә
Тын кабердә бабам ята.

*1980.*

## Ерак, ерак якта ниләр бар?

ЖЫР

Ерак, ерак якта ниләр бар?
Мин күрмәгән анда илләр бар.
Кояш та бар анда, Ай да бар.
Анда юк минем туган җирләрем,
Үз халкым белән торган җирләрем...

Ерак, ерак якта ниләр бар?
Урманнар бар анда, күлләр бар.
Таулар да бар анда, диңгез бар.
Анда юк минем таныш сукмагым,
Каршыма чыкмас якын дусларым.

Ерак, ерак якта ниләр бар?
Бакчалар бар анда, гөлләр бар.
Талга кунган сандугач та бар.
Анда юк минем телем-сүзләрем,
Мин сагышымны кемгә сөйләрмен?

Ерак, ерак якта ниләр бар?
Гашыйкларга гашыйк тиңнәр бар.
Ә мин кемгә гашыйк булырмын?
Син дә юк анда, мин дә юк анда,
Безнең бәхетләр — туган Ватанда.

*1985*

## Икмәк телеме

*Мин дөньяда*
*Бер хикмәт беләм:*
*Космоска да*
*Очалар икмәк белән.*

Мин бәхетемне тоям йөрәгемдә,
Икмәк тотса минем кулларым.
Мин каравай кисәм телемнәргә,
Шигырь булып туа уйларым.

Ә шигырьдә сүзләр гади түгел,
Закон белән алар килешле.
Каравайны олы итәм дисәң,
Валчыкка да табыну тиешле.

Бер валчык та икмәк исемле ул,
Изге зат ул гомер-гомергә.
Икмәк белән дусны, дошманны да,
Бер мизгелдә мөмкин белергә.

Китсә кеше ерак язмышына,
Икмәк ала юлга чыкканда.
Икмәк белән мөмкин ант итәргә,
Гаделлеккә иман тотканда.

Икмәк белән мөмкин яратырга
Туган йортны, туган илеңне.
Без йөреттек солдат капчыгында
Патрон белән икмәк телеме!

*1985*

# А. С. ПУШКИННАН ЯҢА ТӘРҖЕМӘЛӘР

## Һәйкәл

Кеше кулы ясый алмас һәйкәл салдым үземә,
Үлән басмас аңа барыр халык сукмагын.
Патша баганасыннан да ашып менде күгенә
   Горур башы,— тиңе юк аның.

Юк, мин үлмәм бөтенләйгә,— лирасында җаным
Һаман уйнар, җәсәдемне кабер алса да,—
Айлы күк астында яшәр минем үлмәс даным,
   Тик бер шагыйрь җирдә калса да.

Киң таралыр яхшы атым чиксез бөек Русьта,
Исемем йөрер кабатланып барлык телләрдә:
Зурлап сөйләр горур славян, кыргый зат тунгус та,
   Дала дусты калмык, финнәр дә.

Халык мине истә тотар,— аның йөрәгендә
Мин лирамда яхшы-якты хисләр уяттым,
Азатлык дип замананың авыр көннәрендә
   Изелгәнне яклап юаттым.

Буйсын, шигырем, һәрвакыт тик тәңрең кушканнарга,
Кимсетсәләр дә каушама, дан да көтмә син,
Бәхәс тотма ахмак белән, бер дә хуплауларга,
   Хурлауларга исең китмәсен.

●

*А. П. Кернга*

Мин хәтерлим гүзәл бер мизгелне:
Әйтерсең лә күктән индең син,
Кинәт күрдем алларымда сине,
Саф матурлык күрке идең син.

Өметсезгә борчыганда сагышым,
Шомлы, фани шау-шу эчендә,
Чыңлап торды озак нәфис тавышың,
Якты сының керде төшемә.

Еллар үтте, җил-давыллар узды
Тузгытып бар хыял-моңымны.
Мин оныттым нәфис авазыңны,
Фәрештәдәй гүзәл сыныңны.

Еракларда, сөргеннәрдә ялгыз
Үтте көннәр тыныч — күңелсез,
Алиһәсез һәм хаятсез — җансыз,
Илһамчысыз, яшьсез, сөюсез.

Уяныр чак килеп җитте җанга:
Насыйп булды тагын юлыгу,
Пәри заттай пәйда булдың алда,
Саф матурлык күрке — чын сылу.

Йөрәк типте шатлык белән шунда
Һәм балкыды кабат күңелдә
Алиһә дә, хаят, илһамчы да,
Күз яше дә, көчле сөю дә.

●

Хыяллардан тәмам җаным бизде,
Күңелдә юк инде теләк тә,
Тик газаплар гына борчый мине,
Җан бушлыгы салып йөрәккә.

Явыз язмыш давылы харап итте
Таҗга үргән чәчкә-гөлемне,
Мин хәсрәтле, ялгыз көтәм инде
Килерме дип соңгы көнемне.

Кышкы җилләр өне каушап кына
Килә кайчак көзге салкында,
Соңга калган ялгыз яфрак кына
Ботагында тетри-талпына.

## Ялвару

Аһ, әгәр чын булса, тын төннәрдә,
Йоклаганда тере бәндәләр,
Нурлы айдан тыныч каберләргә
Төшә икән якты шәүләләр.
Дөрес булса, нәкъ шул чагында
Бар каберләр бушап кала икән,—
Мин шәүләңне көтәм, Ләйләм-иркәм,
Кил яныма, дустым, яныма!

Пәйда булчы, сөйгән шәүләм минем,
Ап-ак йөзле салкын кыш сыман...
Аерылганда син бит шундый идең —
Соңгы газап җаның борчудан.
Кил син йолдыз булып алдыма,
Кил син шыпырт кына җилдәй шуып,
Я коточкыч шомлы әрвах булып,—
Барыбер миңа, кил тик яныма.

Мин чакырмыйм сине һәлак иткән
Явызларга шелтә ясарга,
Я күңелләр төшкән чакта шиккә,
Я каберләр серен ачарга.
Чакырам, дәшәм,— җаным сагына.
Һаман сөям, мин синеке һәр дәм,
Дип әйтәсе килә сиңа, Ләйләм,
Кил яныма, дустым, яныма!

Нури **АРСЛАНОВ** тәрҗемәләре.

# МӘГЪРУР ИМӘН КЕБЕК...



Татар язучыларының якын дусты булган чуваш халык шагыйре Педер Хузангайга шушы елның январь аенда сиксән яшь тулыр иде...

Шагыйрьнең туган җире дә — Татарстан. Әнә шуңа күрә ул кечкенәдән үк төрле милләт халыкларына хөрмәт белән карарга өйрәнә. Алай гына да түгел — халыклар дуслыгы темасы аның бөтен иҗаты буйлап кызыл җептәй сузыла. Бу мотив шагыйрьнең туган ягын мактау аһәңнәре белән бик табигый үрелә. Туган як турындагы җанга ягымлы ул җырда бик күп татар авылларының, Казан дигән башкаладагы урам-мәйданнарның, шулай ук шагыйрьнең якын дуҫлары — татар әдипләренең исемнәре дә еш ишетелә.

Педер Хузангай язып калдырган истәлекләр дә аның туган җире хакында сөйли. Нәсел-нәсәбен барлап, шагыйрь бер урында болай яза: «Минем бабамның бабасы Кируша Казанда өйләнгән, ә бу шәһәрнең исеме чувашча «Хузан» дип йөртелә. Менә шуннан инде минем фамилиям дә килеп чыга. «Гай» кушымчасын исә мин борынгы мәҗүси исемнәре Улангай, Юмангайга охшатып алдым... Дөрес минем фамилияне революциягә кадәрге халык саны алу вакытында русчага яңадан Казанков дип тәрҗемә иттеләр итүен. Ләкин революциядән соң Чуваш автономияле республикасы төзелеп, киң катлау халык массаларында милли аң уянган елларда, минем Хузангай фамилиям үз милләтемнең яңарган аңын символлаштыра иде...»

Яшь чагын искә алып, Педер Хузангай сабан туйлары турында еш яза, бу бәйрәмдә русларның һәм чувашларның бик рәхәтләнеп күңел ачуларын тасвирлый. Шулай ук чуваш милли бәйрәме Уяу вакытында башка халыкларның катнашуын сөенеп сурәтли.

1924 елда авыл мәктәбенең икенче классын тәмамлаган Хузангай Казандагы Чуваш педагогия техникумына укырга керә.

Кечкенә чагында ук күңеленә сеңдергән һәм тора-бара тагын да якынайткан халыклар дуслыгы темасын Хузангай беркайчан да онытмый. «Туган Татарстаныма» дигән шигырьдә мәсәлән, ул болай яза:

Татар, чуваш һәм рус авылы
Бер-берсенә күрше иде.
Иптәш, юлдаш һәм товарищ
Безнең дуслык сүзе иде.
Бер мәгънәле өч сүз сыман
Бердәм иде бу өч туган.

Татар шагыйрьләре Кол Гали, Габдулла Тукай һәм Мәҗит Гафури

аның өчен иҗат күгендәге юл яктырткыч йолдызлар иде. Ә Һади Такташ, Муса Җәлил, Гадел Кутуй һәм Хәсән Туфаннар белән ул үзе аралашып үсте, әдәбиятның җиңел булмаган сукмакларында алар белән бергә чыникты.

Педер Хузангай талантының табигый чыганагы — туган җир, халык. Аның әнисе дә картаймыш көненә кадәр чигү чигә һәм җырлый торган була. Улы янына Болгариядән Веселин һәм Димитрина Иосифов дигән язучылар кунак булып килгәч, шагыйрьнең әнисе аларга Дунай турындагы җырны җырлап бирә. Ә бу көннәрдә инде аның вафатына өч кенә атна калган була...

Әйе, шагыйрьгә шигъри талантны туган җире, халкы бирде. Ә ул талантны зур итеп, көчле итеп бөек революцион эпоха үстерде. Шагыйрьнең йөрәге илебез тормышындагы һәр вакыйгага сизгер иде, безнең күпмиллэтле ил чынбарлыгы аңа һәр яктан да якын иде. Әнә шуңа күрә ул «Коммунар» исеме белән Мәскәүдә басылган үзәк чуваш газетасының хәбәрчесе буларак бик күп йөри, күп яза. Шулай итеп аның «Егерме алты», «Магнит тавы» дигән поэмалары туа. Бу әсәрләрдә шагыйрь киң масштаблы вакыйгалар аша хезмәт кешесенең күңелендә барган зур үзгәрешләрне сурәтли. Иҗатының баштагырак чорында күбрәк интим лирика белән һәм, рус шагыйре Сергей Есенинга ияреп, иске авылны сагыну белән мавыккан Хузангай утызынчы елларда әсәрләрнең гражданлык яңгырашына ныграк әһәмият бирә башлый. Аның шигырьләрендә яңа матурлыкны тәзү, шуны ныгыту кирәклеге көчлерәк раслана.

Хузангай язмышына Бөек Ватан сугышы зур тәэсир ясый. Сугыш елларында ул Иделдән алып Вислага кадәр юл үтә, гади солдат та, политработник та, хәрби журналист та була. Авыр яралана да. Күп санлы орденнар һәм медальләр белән бүләкләнә. Сугыш чорын искә алып шагыйрь түбәндәгеләрне яза: «Ул елларның үзем өчен иң зур вакыйгасы итеп мин партиягә керүемне саныйм. Сталинград янында булды бу онытылмас күренеш. Кечкенә генә кәгазь кисәген автомат дискысына яисә солдат көрәгенә куеп, яки котелок төбенә терәп иптәшләрем: «Һөҗүм вакытында һәлак булсам — мине коммунист дип санарсыз» сүзләрен еш язалар иде. Мин, гади солдат та, партиягә әнә шулай кердем... Колак төбендә җыр да яңгырап тора иде кебек — «Үлемгә дүрт кенә адым...» Ләкин тора-бара үлемнең артык куркыныч түгел икәнен аңлый башладым. Үз яшәвемнең ниндидер бер дәвамлырак, яшәүчәнрәк көч белән — ил язмышы белән нык үрелеп китүен тоюдан шулай булды ахры бу. Безнең уртак, бик зур һәм үлемсез эшебезнең дәреслеген тоюдан иде ул...»

Сугыштан соңгы елларда П. Хузангай поэзиясе үзенең канатын киң җәйде. «Таня» исемле лиро-эпик поэмасы һәм популяр шигырьләре, җырлары аша халыкка нык танылган шагыйрь сугыштан соң «Аптыраман гаиләсе» исемле күләмле шигъри әсәр өстендә эшләвен дәвам итә. Еллар узгач, бу эштән күп планлы һәм масштаблы роман килеп чыга. Мәскәү тәнкыйтьчесе Г. Кузнецова әлеге әсәр уңаеннан болай дип яза: «Аптыраман гаиләсе» романын бик хаклы рәвештә чуваш халкының тормыш китабы дияргә мөмкин».

Чыннан да, тамыр очы чуваш халкы тарихы буйлап бик еракларга киткән Аптыраман нәселе турында бу әсәр. Әнә шул нәсел кичергән олы вакыйгалар хакында. Аптыраманнар үзләренең кыюлыклары белән Суворов һәм Кутузов вакытында ук билгеле булалар, рус-төрек һәм рус-япон сугышында да танылалар. Гражданнар сугышында һәм Бөек Ватан сугышы кырларында Аптыраманнарның яңа буыны яңа батырлыклар күрсәтә...

Аптыраман — татарчадагы «аптырамаган, күңелен төшермәгән», дигән сүз инде ул. Әлеге нәсел, бу мәгънәгә тугры калып, аны буыннан-буынга күчерә, үзенә хыянәт итми.

П. Хузангай иҗатында эпик һәм лирик башлангычлар бертуган булып, кулга-кул тотынып бара. Аның сюжетлы әсәрләреннән һәрвакыт якты хис, тойгы бөркелә, ә лирик шигырьләреннән сюжет агышы сизелеп тора. «Җәйге тәүлек», «Алмалы Төрләмә» дигән поэмалары һәм «Туган тел», «Идел көзе», «Тукай каены», «Чикләвек» исемле шигырьләре әнә шундыйлар. «Тиллә җырлары» дип аталган циклда да без әлеге ике агымның югары сәнгатьчә үрелүен күрәбез. Бу шигырьләр элек патша армиясендә хезмәт иткән шат күңелле бер җырчының җырлары сыман иҗат ителгәннәр. Тиллә үз гомерендә бик күпне күргән, тормыш сынаулары аңа акыл биргән. Әсәр герое белән бергә уйланып, автор яшәүнең бөек серләрен ачу дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә.

Хузангай әсәрләренә хас булган публицистик ялкын, актуаль яңгыраш турында да әйтми узу мөмкин түгел. Аның «Горкидагы өй», «Сүз», «Минем Россиям», «Туфракта да черемәбез», «Владимир Маяковский» һәм «Бүгенге поэма» дип аталган поэмалары нәкъ әнә шул сыйфатлары белән чуваш әдәбиятының алтын фондына керделәр дә инде. Чорлар каршында искерми торган актуальлеге булганга күрә, шагыйрь әсәрләре башка телләргә дә күп тәрҗемә ителде. «Әдәбиятлар дуслыгы — халыклар дуслыгы» дигән ышаныч аның гомерлек юлдашы булды.

...1928 елның 23 январе көнне Казанның «Казанское подворье» гостиницасында Педер Хузангай һәм аның дусты Микулай Шелеби Владимир Маяковский белән очрашалар, шактый гына вакыт сөйләшеп утыралар. Белгәнебезчә, бу хакта Маяковский үзенең «Казань» исемле шигырендә язып та чыга. Ә Хузангайга әлеге очрашу поэма язар өчен этәргеч була.

...1933 елда П. Хузангай ерак Украинага бара һәм халык шагыйре Павло Тычина белән очраша. Алар гомерлеккә дуслашалар, ике милләт арасындагы егерменче елларда Михаил Сеспель нигез салган дуслыкны ныгыту буенча һәр яктан зур эш эшлиләр.

...Алтмышынчы елларда исә Хузангай Болгария укучыларының яраткан шагыйренә әверелә. Анда Хузангайның әсәрләре еш басыла, ул үзе дә Х. Ботев, Н. Вапцаров һәм үзенең замандашларының шигырьләрен турыдан-туры чувашчага тәрҗемә итә. Аңа хезмәтләре өчен Кирилл һәм Мефодий ордены тапшырыла.

Чуваш халык шагыйре П. Хузангай үз чорының бик күп әдипләре белән якыннан таныш һәм дус иде. Мәсәлән, аның П. Неруда, Н. Тихонов, А. Сурков, М. Рыльский, Р. Гамзатов, Г. Голәм, М. Кәрим, К. Кулиев, Э. Межелайтис, С. Хәким һәм башка танылган шагыйрьләр белән дуслыгы хакында бик күп сөйләргә мөмкин булыр иде. Тәрҗемә эшенә Хузангай шуңа күрә олы хөрмәт белән карады. Тукай, Җәлил, Туфан һ. б. татар шагыйрьләренең әсәрләре аның тәрҗемәсендә еш яңгырады. Ә аның Габдулла Тукай һәм Константин Иванов иҗатын янәшә куеп өйрәнгән «Рухи туганнар» исемле мәкаләсе хәзер дә искерми.

Әйе, күп халыкларның дусты булган Педер Хузангай иҗаты бүген дә — бөек Идел ярында үскән мәгърур имән сыман — һаман шаулап, һаман тирә-юньгә ямь биреп утыра.

**Юрий СЕМЕНДЕР,**
Чувашстанның М. Сеспель исемендәге
комсомол премиясе лауреаты.

*КПССның XXVII съезды карарларын — тормышка!*

Саимә Ибраһимова

# БЕЗГӘ НИЧЕК ХЕЗМӘТ КҮРСӘТӘЛӘР?

Яңа көн тууга, без башкаларның хезмәтенә мохтаҗлык тоя башлыйбыз. Өйнең һавасы сафмы, җылымы, электры-газы бармы, суы-фәләне килеп торамы — боларның һәммәсе белән безне бүтәннәр тәэмин итә. Яшәү рәхәт булсын өчен, кайбер эшләр айлар-еллар буе тукталмый. Шунлыктандыр, мөгаен, без тормыш ямен булдыру-дагы иң мөһим шартларга күнегеп үк киткәлибез. Ара-тирә, электр челтәрендә яки су, җылылык бирүдәге өзеклек килеп чыкса, «аһ!» итәбез, телефонга ябышабыз, гаеплене таптырырга ашыгабыз. Хәер, мондый өзеклек, әллә ни озакка сузылмастан, бетерелә. Без монысын да белеп торабыз. Шуңа күрә күпләрнең исе дә китми.

Әмма көн итәр өчен безгә бу төп шартлардан тыш та бик күп төрдәге хезмәтләрнең җиренә җиткерелеп башкарылуы, ул һөнәр ияләренең үз вазифаларына намуслы мөнәсәбәте кирәк. Шактый еллар элек без яшәгән бер йортта ишегалды себерүче Хәмит абый бар иде. «Кешеләргә хезмәт күрсәтү ничегрәк тора икән?» соравына җавап бирердәй мисаллар туплый башлагач, хәтергә «кылт» итеп шул агай килеп төште. Эшкә китәргә дип ишектән чыгуың була, каршыңа Хәмит агай килеп баса. Ак киндер алъяпкычын буган, эшләпәсен кигән, сакал-мыегын төзәткән. Кулында — себеркесе, йөзендә елмаю балкый.

— Хәерле иртә, Хәмит агай!

— Хәерле иртә, балакаем, исән-сау йоклап тордыңмы?! Ярый, ярый, бар, эшеңә соңара күрмә, хәерле сәгатьтә! Исән-имин эшләп кайт!

Белмим: шушы кечкенә генә йортның ишегалдын чиста тоткан өчен хезмәт хакы алды микән ул. Бәлки, түләгәннәрдер дә, тик аны иң шатландырганы — чүп җыйган өчен акча алу түгел, кешеләрне сөендерү иде кебек. Аның бу омтылышын бәяләп бетерү мөмкинме соң? Эшкә ашыгучы кешенең кәефен күтәрүен генә кара син аның? Ул озатып калган кеше көне буе тырышып эшләргә, башкаларның да кәефен күтәрергә теләячәк. Инде юлда бер юньсезенә тап булып, күңелеңне кырып куйсалар, киресенчә, кулдан эш төшә. Һич урынсызга иптәшләреңә дә тупаслык кылып куюың ихтимал. Кәефсез кешедән теләсә нинди хаталану көтәргә була. Башканың хәтерен калдырырга озакмыни?! Шагыйрә Клара Булатованың бу хакта шигыре дә бар:

...Күпме кирәк хәтер калырга соң?
Күпме кирәк күңел табарга!

Уйламый әйтелгән бер авыр сүз яки җан тынычландырырлык сүзнең әйтелми калган үкенечле очраклары турында хикәяләр, шигырьләр, җырлар язылa. Әйе, язылуын язылa, тик тормышта көнкүрешебездә шул гади хакыйкатьне санга сугарга өйрәнеп җитә алмыйбыз. Бу хакыйкатьнең кагыйдәсе һәркемгә мәгълүм: әгәр барыбыз да үз вазифаларыбызны җиренә җиткереп, кешеләрне шатландырырга тырышып башкарсак, тормышыбызга ямь өстәлер иде. Бик гади кебек. Чынбарлыкта исә без аны шулкадәр катлауландырабыз ки, җепнең очы әллә кайларга китә, һич эзләп таба торган түгел. Беренче карашка, вак-төяк булып күренгән көндәлек йомышлар артыннан йөри-йөри, еш кына җәфа чигәбез, әллә нинди гаделсезлек-

ләргә тап булабыз. Иң күп йомышыбыз төшүчән кибетләрдә, ясау-төзәтү остаханәләрендә, тегү ательеларында — санап кына бетерерлекме? — һич урынсызга тупас сүз ишетеп кыйналабыз, вәгъдәсезлектән интегәбез, рәнҗибез.

Безнең көнкүреш шартлары, үткәндәге егерме-утыз ел белән чагыштырганда, бик нык үзгәрде. Күпчелек гаиләләр күп уңайлыклары булган ташпулатларда яши. Безнең дә Хәмит агай карап-саклап тоткан йортыбыз урынына заманча салынган мәһабәт биналар калыкты. Утын ташып мич ягарга да, су ташырга да кирәкми. Яшәү рәхәт, җайлы, тик вакыт-вакыт... мичле, суын ерактан ташый торган, тәбәнәк, иске өебез сагындыра кебек. Ник дисәң, анда кеше кәефен кадерләргә тырышучы Хәмит абый бар иде. Бер-беребезгә гел яхшылык кына теләп яшәгәнгә, безгә көнкүрешнең кыен яклары сизелми кебек иде.

Яңа йортларда бары да бар: суның салкыны да, кайнары да, газы да, электры да. Көннәрдән беркөнне кран ватылды, суы өзлексез агып тора башлады. Йортлар идарәсе ярдәм итә алмады. Осталары юк икән. Айлык ялга киткән. Шулай да миңа кемгә мөрәҗәгать итәргә мөмкин икәнен әйттеләр. Янәсе, ул булыша ала. Чыннан да, берәү булышырга алынды. Минут эчендә эшен үтәде.

— Бер ярты! — ди бу миңа.

Күңелемнән генә кыймматсенсәм дә, унлыкны чыгардым.

— Мин сиңа ни дидем?! — «Остам» сөзгәк үгез кебек күзләрен алартып карады. — «Ярты» кирәк, акча минем үземдә дә буа буарлык...

Шунысы гаҗәп, әнә шушындый мәгънәсез тупаслыкка берничә тапкыр очрагач, без аларны гадәти хәлгә саный башлыйбыз. Безгә көнкүреш хезмәте күрсәтергә тиешле оешмаларга баруны кирәксенмичә, әлеге законсыз рәвештә көн итүче очраклы «осталар»ны эзләргә тотынабыз. Бер авыз пешкәч, салкын суны да өреп капкан шикелле. Телевизорыбыз күрсәтми башлагач, мин Островский урамындагы остаханәгә мөрәҗәгать иттем. Фәлән вакытта килер, диделәр. Килде. Карады. Төзәтте. Хәтта нинди детальне алмаштырганын да аңлатып бирде. Үзем карыйм, үзем тыңлаган булам, ә кулым алъяпкыч астындагы «кучтәнәч»не капшый. Уйлыйм: ярый инде, әле тупасланып ачуны китерми, дим, барыбер шул «ярты»ны сораячак бит бу.

— Күпме бирим? — дигән булам. Белән бит инде бәяләрен, янәсе. Бусы да шул ук хакны таләп итәчәк.

— Юк, апа, телевизорыгызның гарантиясе бар, бер тиен дә кирәкми, — ди бу. — Киреләнсә, тагын чакыртыгыз. Фамилиям — Ногманов.

Менә сиңа мә! Ямьсез уйларым өчен оялып калдым. Егет иплән кенә саубуллашып чыгып китте. «Карасана, болай да эшли алалар икән бит!» дип, сокланып калдым. Көнкүреш хезмәте күрсәтүчеләрнең барысы да нәкъ шушындый булса, ничек рәхәтләнер идек без. Бер уйласаң, моңа ирешер өчен, бер тиенлек чыгым да кирәкми, бары тик һәркем культуралы иттереп үз хезмәтен башкарырга, бер-ике тәмле сүзен кызганмаска гына тиеш бит югыйсә.

Бу тармактагы җитешсезлекләрне ачып, эшне рәткә салуда үзебездән дә өлеш кертү максатыннан без кайбер язучыларга да мөрәҗәгать иттек, Казан шәһәрендәге көнкүреш хезмәте күрсәтү оешмаларына карата фикер әйтүләрен үтендек. Түбәндә шул җавапларның кайберләрен урнаштырабыз.

**Нәкый Исәнбәт**, Татарстанның Халык язучысы. (Нәкый ага, көнкүрешебезнең бөтенлеген хатыным Нәҗибә апагыз юллап тора дигәч, сүзне Нәҗибә ханым дәвам итте.)

— Тормыш-көнкүрешебездән без бик риза. Татарстан хөкүмәте, Нәкый агагызның хезмәтләрен олылап, безнең һәр ихтыяҗыбызны канәгатьләндереп тора. Әдипкә иҗат итәргә бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Аңа еш кына медицина ярдәме кирәк була. Хәбәрне ишетүгә, врачлар килеп җитә. Шәфкать туташларына йомыш төшсә, алары да бик инсафлы рәвештә, тиешле даруын биреп, уколын салып китәләр. Бәхеткә, күршеләребез дә врачлар, доцент Али Хөсәенович Терегулов, Нәкый аганың хәле ничек дип, гел кызыксына, кирәк булса, ярдәмгә керә. Монысы — безнең өчен иң кирәге инде.

Башкасы турында әйтеп тә тормас идем, алда бик зур эшебез бар шул. Күптән инде өебезгә ремонт ясалганы юк. Йортлар идарәсе, кагыйдә буларак, агарту-фәлән белән шөгыльләнми икән. Ә көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинатында ремонт ясаучыларга зур чират тезелгән булып чыкты. Чиратын күтәрсәң дә иде инде — андагы тәртип тә безгә ярарлык түгел. Алар-

дагы буяучылар, сылаучылар әзер мәйданга килеп, агартып-төзәтеп кенә китәләр. Кем безнең җиһазларны күчереп куяр? Буяу агып төшкән идәннәрне кем чистартыр да купкан таш-туфракны тышка кем ташыр? Комбинат кешеләре хезмәтендә мондый эшләр каралмаган. Бездәй олы яшьтәге кешеләр нишләргә тиештер, белмим.

**Рәисә Ишморатова:**

— Безнең йорт «Татнефтегазразведка» трестының торак-коммуналь конторасына карый. Башка квартираларда яшәгәндә бик интегә идек. Бу йортта шатланырга гына туры килә. Су кранбыз ватыламы, туалет бүлмәсенә берәр нәрсә кирәкме — телефоннан гына шалтыратам. Сәгатендә килеп җитәләр, «ялт» иттереп төзәтеп бирәләр.

Керләр юуда да шәп бер әмәл таптым. Казанның Бондюг урамында бик иркен бинага урнашкан «Химчистка» бар. Анда теләгән һәркем үзе кереп кер юа торган зал да булдырганнар. Кайчан кирәк — барасың да керәсең. Юасың, киптерәсең, үтүклисең. Барын да машиналар үти. Син салып-фәлән итеп кенә торасың. Шунда ук келәм, палас кебек зур күләмле әйберләрне дә чистарталар. Андыйларны машина белән өйгә килеп алалар, китереп тапшыралар.

Телевизор өчен хафаланмаска да бер юл бар: абонементка керергә кирәк икән. Киреләнә башласа, телефоннан хәбәр генә ит, килеп җитәләр, төзәтеп китәләр. Бик уңайлы.

Бөтен кеше көнкүреш хезмәте оешмаларыннан зарлангач, мин үз рәхәтемнең сәбәпләрен уйлаштырып йөрдем. «Аһ-зар» күрми яшәвемнең кечкенә генә бер серен дә ачтым кебек: мин йомышым төшкән кешедән тәмле телемне кызганмыйм. Елмаеп кына сүз кушам үзләренә, түбәнчелек белән үтенечемне белдерәм, соңыннан рәхмәт әйтәм. Алар да шатланып калалар кебек. Кабат барганда, якын дусларын очраткан кебек, ачык йөз белән каршы алалар. Күп тупаслыклар, минемчә, бер-беребез белән юньләп сөйләшә алмау аркасында да башланып китә. Яхшы мөнәсәбәт, культуралы мөгамәлә кешенең үзеннән үк башланырга тиеш. Бигрәк тә безгә, язучыларга, бу хакыйкатьне бер мизгелдә дә онытырга ярамый. Без кешеләр арасындагы иң матур мөнәсәбәтләр үрнәген күрсәтергә тиешбез.

**Әмирхан Еники:**

— Андый оешмаларга зурдан кубып мөрәҗәгать иткәнем юк иде. Кухня белән санузелны кафель плитка белән тышлатырга ниятләгәч, Чернышевский урамындагы горбыткомбинатка киттем. Бик матур үрнәкләрен күрсәттеләр, яраттым. «Акчагызны түләгез, җитәрлек күләмдә кафель булгач, килеп алырсыз», — диделәр. Түләдем мин боларга акчаны. Белешеп тора башладым. Язучылар союзына барган саен керәм. Бер дә кердем, биш тә кердем. Юк кына. Еллар үтте. Кафель юк. Булса да, бик ямьсезе яки ватыкитеге генә калган. Алдым мин болардан акчаны кире.

Аннары, сүз иярә сүз чыгып, минем бу хәлне туганнар ишетте. Бик матур кафель тапканнар. Китереп тә бирделәр. Якында гына торучы бер оста ябыштырып та чыкты. Дөрес, акчасын хөкүмәткә түләнергә тиешле күләмнән шактый артык каердылар.

**Нәбирә Гыйматдинова:**

— Хәзер мин күп эшләрне үзем генә ерып чыгарга тырышам. Дөрес, бик күп вакытым әрәм була. Эштән соң бала белән дә булырга кирәк, яңа әсәрем дә язылуын көтеп тора. Мин йорт эшенә кереп чумам. Кер юуларны, бүлмә җыештыруларны, тегү, бәйләүләрне әйткән дә юк — квартираны да үзебез ремонтладык. Кибет чиратында күпме вакыт исраф ителгәнне исәпләп бетерерлек тә түгел.

Шулай да берсендә, РСФСР язучылар съездына делегат булып сайлангач, Мәскәүгә барыр алдыннан, Бауман урамындагы югары разрядлы «Людмила» исемле ательега күлмәк тектерергә кердем. Казан тегүчеләренең данын илгә таратыйм әле дип уйлыйм. Ниятем гел яхшылыкта гына иде. Съездга ерак-ераклардан киләләр бит. «Аһ!» итсеннәр әле дим, күлмәгемне күреп. Тукымамы да шәп, фасонның да иң соңгы мода кушканын сайладым. Фәлән көнне киеп карарга килерсең дип, ышандырып кайтарып җибәрделәр. Барсам, тукымам киселмәгән килеш ята. Әллә кисүчесе, әллә тегүчесе авырган, имеш. Шулай башланып китте бу йөрүләр. Өмет иткән вакытка өлгертмәделәр. Фасоны да мин әйткәнчә килеп чыкмады. Тукымамны гына әрәм иттем. Үзәкләрем өзелде. Акча тотып йөреп тә үзең теләгән киемгә киенә алма инде?! Булсын иде бер урын: «Рәхим итегез!» — дип, кочак җәеп каршы алсыннар иде. Бәясеннән дә тормас идең. Болай күңелең кителеп кал-

гач, икенче тапкыр аяк та басасы килми. Өендә генә кабул итүче киң күңелле тегүчеләрне эзли башлыйсың. Андыйлар синең хәлеңә дә керә, кирәк чакта хәтта үзе синең янга килеп, үлчәп-нитеп китә. Хәзер ательеларда кием тектерү шактый кыйммәт. Тик кабул итүчеләре дә, кисүче-тегүчеләре дә эш алымнарын һич үзгәртмәделәр.

**Фәнис Яруллин:**

— Тормышыбыз мулдан хәзер безнең. Аһ-зарларыбыз да элеккегеләргә охшамаган. Әмма шул муллыкка ямь өстәргә, матур иттереп яшәргә өйрәнәсебез бар әле. Бездә, мәсәлән, машина ватылса, телевизор күрсәтми башласа, зур мәшәкать туа. Кемгә ялынырга, турысын әйтсәм, акчаны кемгә бирергә белми аптырыйбыз.

Машинаны миңа дәүләт бирде. Аны хатыным Нурсия йөртә. Йөртүен йөртә, әмма төзәтү-нитү аның кулыннан килми. Кечкенә генә чатаклык чыкса да, машинаны караучы кирәк безгә. Көне, сәгате кадерле. Казанда минем кебек инвалидларга ярдәм күрсәтергә тиешле «Автосервис» та оештырылган. Волочаевский урамында ул. Карап торышка рәсми төстә бары да бар, яхшы кебек.

Нурсия машинаның кечкенә генә бер детален алмаштырырга кирәклеген әйтүгә, мин телефонга тотынам. Хәлне аңлатмакчы булам. Тыңлап та бетермиләр:

— Машинаны монда китерегез! — Боерыклары шул. — Үзебез карыйбыз без.

— Ватык машинаны анда ничек илтик?..

Мондый вак-төяк сорауга алар җавап биреп тормыйлар. Беренче мәртәбә йомыш төшкәч, анда бардык без. Ялладык бер йөк машинасын, сөйрәтеп киттек. Капка төбенә барып кына туктавың була, әчкә алып кереп китәләр. Машина хуҗасын анда кертмиләр. Кай җире ватык икәнен дә сорашып тормыйлар.

— Бер айдан соң килерсез, эше беткән булса, алып та китәрсез, бәлки...

Инвалид кешеләр өчен күз тегеп көтеп алган җәй көннәрендә бер ай вакыт хәрәкәттән мәхрүм булып калу бик авыр бит. Монысын алар уйлап та карамыйлар. Үткән җәйдә шулай үзәкләр бик өзелгәч, телефоннан тупас җавап бирүче кешенең фамилиясен дә сораган идем.— «Идиятуллин»,— диде. Миңа калса, сервиста инвалидларның өенә йөрүче дә билгеләргә иде! Берсендә безгә «вкладыш» дигән нибары өч сум илле тиенлек деталь кирәк булып чыкты. «Автосервис»тан гел шул бер җавап ишетелә.

— Үзебезгә генә бирегез, бер сәгатьтә куялар бит аны, — дип тә карыйм.

— Без детальләр сатмыйбыз, — дип, горур җавап кайтаралар.

Гадәттәгечә, дус-ишләргә хәбәр салдык. Бер «рәхмәт төшкересе» теге тимерне 25 тәңкәгә китереп бирде. Шул сезнең сервиста эшләүчедән алдым ди. Икенче «яхшысы» эш сәгатендә, хөкүмәт гаражында төзәтеп бирде.

Төсле телевизорыбыз белән дә шул хәл. Ватылды. Мастер килде дә, караган өчен акчасын алып:

— Монда төзәтеп булмый, мастерскойга китерегез! — дип китте.

Телевизорның авырлыгы — 65 килограмм. Аны безнең кайсыбыз күтәрсен?! Тагын очраклы кеше эзләп китәргә мәҗбүр буласың.

Тагын бер мәсьәлә: Казанда патронаж тәртибендә эшләүче шәфкать туташлары булсын иде. Аларның игелекле хезмәте турында миңа Латвиядәге дусларым сөйләде. Алдан билгеләнгән көннәрдә килеп йөриләр икән алар. Дару-фәлән кирәкмиме, инвалидның башка үтенече юкмы — барын да сорашып, тиешле җиренә җиткереп, ярдәм итеп торалар икән...

Шушы кыска гына җаваплардан да көнкүреш хезмәте күрсәтүдә аяныч җитешсезлекләр күзгә ташлана. Бүген, илебез халкы бердәм төстә үзгәртеп коруга йөз тотканда, үсеш, тизләнеш шартларында без бу кимчелекләрдән дә мөмкин кадәр тизрәк арынырга тиешбез. Кайдан башларга? Кемнәр моңа беренче чиратта җаваплы? Гаепләрне кем җавапка тартыр? Кичекмәстән шушы сорауларны чишәргә һәм барлык башбаштаклыкларга чик куярга тиешбез.

**Редакциядән:**

*Кадерле укучылар! Бу язмада күтәрелгән мәсьәләләр буенча алынган җаваплар журналның алдагы саннарында басылачак. Сездән дә көнкүрешебезне тагын да матурайту, уңайлырак итүгә кагылышлы файдалы фикерләр көтәбез.*



**А. И. Демидов,**

КПССның Алексеевский райкомы
беренче секретаре

# БОРЫНГЫ БҮЛӘР-ҖИРЕНДӘ

Тарих — кешеләрнең иң зур байлыгы. Аны өйрәнмичә, аның тормыштагы гаять зур әһәмиятен бәяләми торып бүгенге эшләрне дөрес иттереп алып баруы мөмкин дә түгел. Безнең район яклары исә тарихи хәлләргә, революцион көрәш вакыйгаларына аеруча бай.

X—XIII гасырларда Идел Болгарстаны башкаласы булып торган Биләр шәһәр-легендә археологик тикшеренүләр ерак-еракларга мәгълүм. Биләр үз чорында Европаның иң зур һәм мәртәбәле үзәкләренең берсеннән саналган. Үзган ел гына мең еллыгы билгеләнгән Борынгы Русь белән Идел Болгарстанының исталекле килешүе дә безнең Биләрдә төзелгән. Аннан бераз алдарак илебезнең әдәби җәмәгатьчелеге болгар-татар шагыйре, мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» поэмасы авторы Кол Галинең тууына 800 ел тулуны зур күләмдә билгеләп үткән иде. Хәзер безнең Биләр зона китапханәсе Кол Гали исемен йөртә. 1969 елны шәһри Болгар һәм Биләр СССР Министрлар Советы карары нигезендә, тарихи-архитектур һәм археологик заповедник дип игълан ителде.

Инде сүзне безнең чорга якынайта төшсәк, бу төбәк халкының Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр шактый авыр тормыш кичерүе күзгә ташлана. Крестьяннар җирсезлектән, булган кадәр җирнең дә уңдырышсызлыгыннан интеккәннәр. Шактый кешеләр, тамак хакына, батраклыкта, көнлекчелектә, асраулыкта бил бөккән. Алексеевскийның үзен сәүдәгәрләр авылы дип йөртсәләр дә, мондагы халыкның да өчтән ике өлеше бик авыр тормыш кичергән. Заманнар үтү белән, көн итүнең кыенлыгына чыдый алмыйча, ризасызлык арта барган, чуалышлар, баш күтәрүләр ешайган. Емельян Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар восстаниесенә дә безнең яктан бик күпләр катнашкан. Төбәктә революцион хәрәкәт куерганнан-куера барган.

1905 — 1907 елларда Алексеевскида РСДРПның беренче ячейкасы оеша. Әүвәлге адымнарыннан ук большевистик эшчәнлек җәелдереп, халыкның тулы теләктәшлеген яулап өлгергән бу оешмада егермеләп кенә член исәпләнә. Аның җитәкчесе ярлы крестьян гаиләсеннән чыккан Аристарх Андреевич Казаков булган. Соңра ул Совет власте өчен җан аямый көрәшә, Урта Азиягә җибәрелә, Төркстан ССРның Үзәк Башкарма Комитеты председателе, Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты члены дәрәҗәләренә күтәрелә. Аның исеме Зур Совет Энциклопедиясендә дә бар.

Районыбызның башка күп кенә кешеләре дә социалистик революциягә зур өлеш кертканнәр. Мәсәлән, якташыбыз, пулеметчылар взводы командиры Александр Павелкин Кышкы сарайны алуда катнашкан. Революция турында беренче аваз салучы «Аврора» крейсерында да безнең район егете Михаил Котухов булган. Совет властен яклап, Колчак, Деникин, Врангель армияләренә каршы кан коюлы көрәшләрдә катнашкан бертуган Александр, Михаил, Павел, Иван Павелкиннар, Федор Маслов, Тимофей Басов, Иван Кольдюшов, Гаврила Поселягин кебек дистәләрчә баһадирларыбыз әле дә халык күңелендә яши. Дошман белән йөзгә-йөз килгәндә дә сынатмаган ялкынлы патриот Василий Тюриков, Иван Абрамов, Соколиков-Строганов, Аросьева-Вертинская кебекләр турында сокландыргыч хәлләр әле дә телдән-телгә сөйләнә.

Утызынчы еллар башында районлагы ВКП(б) членнары — 84 кә, членлыкка кандидатлар саны 130 га җитә. Бу чор коммунистлары крестьяннар арасында бик зур эш алып барганнар. Өч совхоз, кырык дүрт колхоз, ике МТС оештырыла. Районыбыздагы трактор-машиналарның саны арткannан-арта бара. Мәктәпләр, уку йортлары

ачыла, кино күрсәтү җайланмалары булдырыла, больницалар, медпунктлар, телефон элемтәсе, сату-алу эшләре рәткә китерелә.

Алексеевскилылар Бөек Ватан сугышы елларында да кыюлык үрнәкләре күрсәттеләр. Фронтка киткән унике мең якташыбызның 5711 е ил өчен гомерләрен куйдылар. Биш егетебез: Николай Мамонов, Михаил Федин, Иван Кочнев, Хәбибулла Хәйруллин һәм Василий Халев Советлар Союзы Герое исеменә лаек булды.

Бу батырларның исемнәре урамнарга, пионер дружиналарына, мәктәпләргә бирелде. В. Д. Халев истәлегенә багышлап ел саен спорт ярышлары үткәрелә. Калининград өлкәсендәге бер шәһәр Н. В. Мамонов исемен йөртә. Дан орденының тулы кавалеры Михаил Шляпников, Бөек Ватан сугышы ветераннарының район Советы члены буларак, зур иҗтимагый эшләр алып бара. Ул — Биләр авыл Советында халык контроле группасы председателе.

Районыбызның фронтка бармаган кешеләре дә фашизмны җиңүгә зур өлеш керттеләр. Дәүләткә икмәк, ит, йомырка, тире тапшыру башка вакыттагыга караганда нык артты. Колхозчылар әле моннан тыш та, үз мөмкинлекләреннән чыгып, танк колонналары, самолет эскадрильялары оештырырга 8 миллион сум акча тапшырдылар. Бу елларда тылдагы фидакарь хезмәтләре өчен меңнәрчә кешеләребез хөкүмәт орден һәм медальләре белән бүләкләнде. Алар арасында «Мысль Ленина» колхозы председателе Е. М. Максимов, механизатор А. Н. Беспалова да бар. А. Н. Беспалова сугыштан соң терлекчелектә бик тырышып эшләде, Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булды.

Безнең яклар элек-электән укымышлы, тырыш, уңган кешеләре белән дан тота. Дөньяга мәгълүм галимнәребез А. М. Бутлеров, А. Е. Арбузов химия фәне корифейларыннан санала.

Безнең Новоспасскида — шагыйрь Н. А. Некрасов, Ромодан авылында Н. Э. Бауман булган. 1905 елда Алексеевскига Я. М. Свердлов килгән һәм, Чистай-Лаеш өязләренең большевикларын җыеп, яшерен киңәшмә үткәргән.

Тарихыбызга караган документлар шактый. Тик аларны бөртекләп җыясы, җентекләп өйрәнәсе һәм барын да бик яхшы музейга туплап куясы килә. Бу мәсьәләне якын арада хәл итәчәкбез.

Алексеевский районы республиканың Кама аръягына беренче баскыч булып тора. Аның төньяк-көнбатышын Куйбышев сусаклагычы иңләп алган, көньяк-көнбатышы урманнар белән капланган. Җиребез кара туфраклы. Егерме ике колхозыбыз карамагында 133 мең гектардан артык җир, 42 мең мөгезле эре терлек, 36 меңнән артык дуңгыз, 12 мең баш сарык бар.

**Районда җиңел, азык, урман промышленностьлары тармакларыннан сөт-консерв комбинаты аерылып тора. Үткән ел аның эшли башлавына 50 ел тулды. Аның продукциясе Куба, Һиндстан кебек чит илләргә озатыла. Истәлекле бүләкләр ясый торган сәнгатьчә туку фабрикабызның эше шулай ук мактауга лаек.**

Районның төп таянычы булган авыл хуҗалыгы бүгенге көннәрдә материаль-техник базасын сизелерлек ныгыта. Колхоз-совхозларның производство байлыгы, энергия белән тәэмин ителүе арткannан-арта бара. Хәзер безнең һәр хуҗалыкка уртача 43 трактор, 30 комбайн, 19 йөк машинасы һәм күп санлы башка ярдәмчел техника туры килә. Терлекчеләрнең эшен җиңеләйтүче чаралар күрергә дә онытмыйбыз: яңа биналар корыла, кул хезмәте машиналарга күчә бара, эш көне төгәл режимга көйләнә.

Авыл хуҗалыгына тотылган чыгымнар нәтиҗәне дә озак көттермәде. Унберенче бишьеллыкта без сөтне унынчысына караганда меңнәрчә тоннага артыграк саттык. Терлекчелектәге уңышларыбыз республика күләмендә Почетлы диплом белән билгеләп үтелде.

Дөрес, җиргә, терлекчелеккә кертелгән байлык әлегәчә көткән кадәр үк игелек кайтарганы юк. Шушы кадәр куәтле машиналар, ашламалар, югары белемле хезмәткәрләр белән тәэмин ителгән авыл хуҗалыгында ашлык та, ит тә, сөт тә, башка азык-төлекләр дә күбрәк җитештерелергә тиеш иде. Кайберәүләр моны табигать хәлләренә кайтарып калдырмакчылар. Алдынгы хуҗалыкларның тырышлык нәтиҗәсе исә уңышларның башка серен ачып бирә. ТАССРның атказанган механизаторы Алексей Яковлевич Левин председательлек иткән «Россия» колхозына гына тукталыйк. Инде ун елдан артык мондагы һәр сыердан савылган сөт уртача өч мең литрдан күбрәк исәпләнә. Узган бишьеллыкта колхозда игелгән бөртекләләрнең һәр гектарыннан уртача 22 шәр центнер уңыш җыйдылар. Вахитов исемендәге колхоз уңганнары турында да мактау сүзләрен кызганмаска мөмкин. Председателе — ТАССРның атказанган экономисты Нургазиз Кыямов.

Бу колхоз көзге бодайның һәр гектарыннан 35 центнерга якын уңыш үстерде. Ә «Родина» колхозы соңгы елларда азык культураларының гектарыннан 63-64 центнер азык берәмлеге алып, республика күләмендә макталды, күчмә Кызыл байрак белән бүләкләнде.

Алга куелган зур бурычларны үтәү өчен безгә барлык хуҗалыкларыбызны да әнә шушы алдынгылар рәтенә бастырырга кирәк. 1990 елга без ит җитештерүне 1,6 мәртәбәгә арттырырга тиешбез. Бөртекләрне 150-160 мең тоннага җиткерергә кирәк. Күрәсез: максат олы. Димәк, җирне тагын да мулрак сыйлыйсы бар. Әче туфраклы басуларны известьләү җитенкерәми. Андый мәйдан безнең сөрү җирләренең 71 процентын алып тора. Гомумән,басу-кырларның уңдырышын арттыра торган чараларны: ягъни ашлауны һәм сугаруны, тирәннән өйрәнеп үткәрергә кирәк. Терлекчелектә дә шул ук хәл: фәнни ачышлардан кыю файдалану, токымнарны яхшырту, белеп тукландыру, хезмәтне камилләштерү сорала. Бу бурычларны белемле кешеләр, намуслы, тырыш, уңган хезмәтчәннәр белән генә үтәп чыгып була. Әшкә бирелгәнлек, тәртип, яман гадәтләргә каршы бердәм көрәш сизелерлек нәтиҗәләргә китерәчәк.

Бездә иң кирәге, ышанып таянырдай, күпләргә үрнәк итеп күрсәтердәй кадрлар бар. Моңарчы саналганнары янына «Алга» колхозы председателе Хәлилов М. С., «Разумовский» совхозы директоры Әхмәтҗанов З. К., Свердлов исемендәге колхоз председателе Козин М. Н. шикелле алдан күрүчән җитәкчеләрне дә кушарга була. Терлекчеләрдән — Ленин орденлы Лысов А. С., Гатина Ф. Б., Бабыкин Д. П., Иванова Г. Ф., Костеев А. Ф., Мәрдәнов Н. Г. кебек уңганнарны күрсәтергә мөмкин. Комбайнчыларыбыз Нәсыйхов Р. М., Җаббаров А. В., сыер савучыларыбызның һәм дуңгыз караучыларыбызның күпчелеге районыбызның горурлыгын тәшкил итә...

Алтмышынчы елларга кадәр районыбызның күркәм һәм мәрхәмәтле җирендә, бүгенгегә караганда, икеләтә күбрәк кеше яшәгән. Авылларыбызда елдан-ел кеше кими барды; урамнар тынып, күңелсезләнеп калды сыман. Сәбәбен ачыкламасаң, ашыгыч чаралар күрмәсәң, яшьләрнең авылдан читләшүе дәвам итәчәк. Мөмкин кадәр күбрәк мәктәпләр, культура йортлары, тораклар, юллар салырга, авылларны кеше тормышына куаныч китерерлек итәргә иде! Бездә бу юнәлештә дә шактый эшләр башкарыла. Соңгы ике ел эчендә генә дә дүрт-биш авылда урта һәм сигезьеллык мәктәпләр булдырдык. Кайберәүләрендә балалар саны җитеп тә бетми, әмма алар барыбер үзләрен аклаячак.

Узган бишьеллыкта без 15 мең квадрат метр чамасы торак, унбер балалар бакчасы, яңа кибетләр, 17 чакрым юл, алты күпер салдык. Бу бишьеллыкта райондагы күперләрнең калганнарын да яңартып чыгачакбыз. Мурзихада йөк причалын төзеп бетереп киләбез. Район өчен аның ни дәрәҗәдә мөһимлеген аңлатып торуы дә кыен.

Шул рәвешле яшьләрне авылдан читләшмәслек итәргә тырышабыз. Орденлы председателебез Камил Сафин җитәкләгән «Родина» колхозындагы яңалыклар моңа дәлил була ала. Колхозда эш шартлары яхшы. Һәркемне даими хезмәт белән тәэмин итү өчен районда Чистай тегү фабрикасының филиалын ачтык. Өйләргә газ кертелгән. Колхоз үзәгенә кадәр асфальт юллар сузылган...

Борынгы Биләребез дә танымаслык дәрәҗәдә үзгәртеләчәк. Бу мәсьәлә инде хәл ителде, зур төзелеш һәм төзекләндерү эшләре җәелдерелде.

Район үзәгендә дә шатландыргыч яңалыклар бар. Поселокны матурлау, уңайлы итеп үзгәртү монда яшьләрнең артуына сәбәп булды. Хәзер безнең район үзәгендә ел саен йөзләп туй уздырыла, ике йөзгә якын сабый туа. Бу — зур шатлык. Борынгы Буләр җиренең тырыш кешеләре яңа туганнарны тагын да бәхетлерәк тормыш белән тәэмин итү өчен көчләрен кызганмаячак.

Флүс Латыйпов

# НӘФЕС БАТКАГЫНДА

Болыт куерганнан-куера. Әле иртән генә көн нинди матур иде: чалт аяз күк йөзендә ник бер болыт әсәре булсын да ник яфрак селкетерлек җил иссен. Табигатьнең бер генә чалымы да бу гарасат башлануны белгертми кебек иде. Кошлар сайрашканы ишетелә, ишегалдында бер кайгысыз бала-чага шау-гөр килә. Ә хәзер... Каян гына килеп чыкты соң шул бүрек хәтле генә болыт?! Ул күз алдында зурая, җир өстеннән тузан суырып алган өермә кебек кайный, бөтәрләнә башлады, күк йөзен каплап алды. Кинәт искән җилдән балкон ишеге шартлап ябылды, пыялалары зыңгылдап калдылар. Әле генә чыр-чу килеп йөргән балалардан җилләр исте. Яңгыр алдыннан була торган тынлыкны ярып, еракта күк күкрәде.

Людмила Ивановна сискәнеп китте, йомшак кәнәфигә чумып, өнсез-сүзсез инде бер сәгатьләп утыруын шунда гына абайлап алгандай булды. Урта бармаклары белән чигәләрен ышкыды һәм кискен бер карарга килгәндәй, җәһәт кенә урыныннан күтәрелде. Нигәдер соңгы вакытта шулай үз эченә бикләнеп, дөньясын онытып утырырга гадәтләнде ул. Бер ноктага текәлә дә катып кала. Шулай иткәч, күңелдәге шик-шөбһә дә, күңелсез уйлар да таралып китә сыман.

— Юк! Хәрәкәттә бәрәкәт, әйе, бәрәкәт — хәрәкәттә! — дип кабатлады ул эчтән генә һәм үзенең шундый сүз уйнатуыннан көлемсерәп куйды. — Кем әйтмешли, хәрәкәт итәргә кирәк...

Ашыгып килеп, балкон ишекләрен эләктереп куйды, җил уңаена шалт-шолт ачылып-ябылып торган форточкаларны томалады. Бераз уйланып торгач, авыр тәрәзә пәрдәләрен төшерде. Бүлмә эче кичке эңгердәге кебек караңгылыкка күмелде, тыштагы җил-давыл ишетелмәс булды. Шунда гына бераз тынычланып китүен тойды. Кухняга кереп газны кабызды, чәйнеккә су салып плитәгә утыртты да фарфор чынаягына көмеш кашык тутырып эри торган кофе салды.

— Әйе, көтеп утырырга ярамый. Йөрергә, очрашырга, сөйләшергә... Теләсә нинди юл белән булса да бу сүзләрне юк итәргә.

Су кайнап чыгарга да өлгермәде, звонок шалтырады. Людмила Ивановна үзе дә сизмәстән, аяк очларына гына басып, алгы бүлмәгә чыкты һәм шактый караңгы булуга карамастан, ут элмичә генә ишеккә куелган «күз»дән карады. Зурайткыч пыяла аша Владислав Захаровның йөзе, әллә ничек, җәлпәк булып күренде аңа. Пыялага якынрак борыны калынаеп алга сузылган, иреннәре очлаеп кабарган, ә күзләре һәм колаклары кечерәеп, артка күчкән кебек.

— Үзең генәме? — дип сорады Лапицкая.

— Хатыным Галя белән...

Захаровның тавышы нишләптер элеккечә көр, гамьсез түгел иде. Людмила Ивановна ашыгып-кабаланып ишекне ачарга кереште. Бер-бер артлы берничә йозак чыкылдады.

Керә-керешкә керүчеләрнең йөзенә текәлде хуҗабикә һәм, үзенең күңел борчуын яшерергә теләп, ясалма ягымлы тавыш белән эндәште.

— Мактап кына йөрисез икән. Хәзер чәйнегем кайнап чыга. Бер рәхәтләнеп кофе эчик әле...

Әмма Захаров аның бу күтәренкелегенә кушылмады. Караңгы, кырыс чыраенда ниндидер курку да, аңлашылмас тәвәккәллек тә бар иде кебек.

— Без чәй эчеп тормабыз инде. Сүз бар иде.

— Һи, сүз барыбызның да бар ул. Әйдәгез, үтик әле. Тартынмагыз. Дөньяда бер генә тапкыр яшибез ич, рәхәтләнеп гәпләшеп тә утырмагач...

Ирле-хатынлы Захаровлар боеручан, власть сөючән бу хатынның көтелмәгәнчә шулай ачык йөз күрсәтүенә гаҗәпләнә-гаҗәпләнә түргә уздылар, тавыш-тынсыз гына урындыкларга утырдылар.

Хуҗаның кинәт чайпалып чыккан кунакчыллыгыннан соң урнашкан киеренке тынлыкны Захаров бүлде.

— Мин бүген... милициядә булдым. Алар бөтенесен дә белә.

Людмила Ивановнаның әле генә нур чәчкәндәй балкыган күзләре кысылып килде, кыяфәтенә элеккечә властьлылык галәмәтләре чыкты. Ул тәшвиш белән Захаровка текәлде.

— Ә син нәрсә сөйләдең?

— Нәрсә дип... Барысын да булганча сөйләп бирдем инде. Алар бит барыбер сөйләтмичә туктамый.

Захаров калтыраган бармакларын яшерергә теләп, кулларын тез астына тыкты, дөрес сөйлимме дигәндәй, хатынына борылып карады.

— Соң, әлбәттә, дөресен сөйләргә кирәк, — дип хуплады көтмәгәндә хуҗа хатын һәм суыткычка үрелде. Өстәлгә тышына дым типкән коньяк шешәсе, кабымлыклар чыгып утырды. Чынаякка агызылган эчемлекне бер йотуда юк иткәч, Захаров кыюланып сүзен дәвам итте.

— Мин бит акчаны сезгә биреп барганны әйттем...

— Пычаксыз суйгансың икән. Анысын нигә әйтергә иде инде аның... Тинтәк! Ир булып йөрисез шунда...

Лапицкаяның йөзенә кызыл тимгел бәреп чыкты. Ул, зәһәрләнеп, бүлмә буйлап кызу-кызу йөренергә тотынды.

— Ит яхшылык, көт яманлык. Ашаган табагыңа... Нәрсә китереп чыгарганыңны беләсеңме? — Һәм ул еламсыраган тавыш белән дәвам итте.— Ничекләр генә түзим бу кайгыларга? Ирем ташлап киткәнне беләсең ләбаса. Чүп өстенә чүмәлә. Училище дип, эш дип, көне-төне чабасың, ә монда синнән изгелектән башка нәрсә күрмәгән кешеләр өстеңә кара ягa. Билләһи дим, нервым тетрәп, ашказаны рагыннан үлсәм, син генә сәбәпче булачаксың...

— Ә минем гаеп нәрсәдә? Акчаны чыннан да мин алмадым бит, — дип кенә әйтә алды Захаров.

— Ничек алмадың? Ә ведомостька кемнең кулы куелган. — Лапицкая әле генә елаганын онытып, Галяга карап, зәһәр тантана белән елмайды. — Син дә читтә калмассың, күгәрченкәем. Ведомостьта синең дә имзаң бер.

— Мин бит ирем өчен, доверенность белән генә. Ә акчасы сездә бит...

— Аны кем белә? Кем күргән аны? Исбатлап кара. Кайчан бирдең, кайда бирдең? Шаһитларың бармы? Ә мин алмадым диячәкмен, һәм моны сез берничек тә кире кага алмаячаксыз. Намуслы кешегә яла яккан өчен әле үзегезгә утырырга туры килмәгәе. Менә шулай!

Лапицкая ярсыганнан-ярсый барды. Өстәл яныннан торып, бөеренә таянды да Захаровка текәп карап, һәр сүзен кысып чыгара-чыгара сөйләргә керешге.

— Минем янга ялынып килгәнеңне оныттыңмы? Һа, аңа имеш хезмәт кенәгәсендә язу гына кирәк. Ярар, бирдем мин сиңа ул язуны. Ә үзең чүкеп ясалган рәсемнәрең белән кешеләрнең күпме хәләл акчасын җыйдың? Берсен-берсен күпмегә сатасың әле. Унбиш сумгамы? Әгәр мин ярдәм итмәгән булсам, син шуны эшли ала идеңме соң? Әрәмтамак дип, инде әллә кайчан төрмәгә тыккан булырлар иде. Синең спекуляция янында минем йөз тәңкәм төкерек кенә ул. Белеп тор, ул акча да минем үземә түгел, ә училище ихтыяҗына тотылды. Үзеңне жәлләп, әле ундүрт сумын синең коньякка калдыра килдем. Шуның да кадерен белмәгәнсең...

Югалып калган Захаров күзен бер хуҗага, бер өстәлдәге шешәгә төшерә, әмма әйтер җавап таба алмый.

Сүзенең ничек тәэсир итүен, дилбегәне тагын үз кулына алуын ачык тойды Лапицкая.

— Әһә, мәлҗерәп төштегезме? — дип, ачу катыш сөенеп уйлап алды ул. — Кем белән көрәшкәнегезне, кемгә кое казыганыгызны белдегезме инде?

Хәзер дилбегәне бераз бушата төшәргә дә була. Людмила Ивановна яңадан кунакчыл хуҗабикәгә әйләнде.

— Ярый, артык борчылмагыз! Хәлне төзәтергә була әле, — диде ул һәм чынаякка коньяк агызды, аны Захаровка сузды. — Минем сүздән генә чыкмагыз! Иң мөһиме — чапаланмаска! Монда төп гаеп синдә. Әйе, әйе, иптәшкәем. Синдә! Ләкин сине дә йолып алып була... Милициядә сорасалар, эшләдем дип бар, училищега кеше җыю белән шөгыльләндем дип бар. Авызыңны күтәреп, мин берни дә эшләмәдем, акча алып кына яттым дисәң, беркем дә башыңнан сыйпамас.

Лапицкая, зур бер сер әйткәндәй, ярым пышылдауга күчте. — Кыйммәтле алтын балдак кидертелгән бармагын түшәмгә, хрусталь люстрага төртеп күрсәтте.

— Анда да үз кешеләрем бар. Ярдәмсез калдырмаячаклар. Ә бу «эш»не ябу өчен минем бер бармак селкетүем җитә. Инде төшендегезме,— диде ул һәм гасабиланып көлеп җибәрде. — Ә хәзер бер кечкенә генә формальность ясыйбыз.

Ул күрше бүлмәгә кереп китте һәм, күп тә үтми, чиста кәгазь белән ручка тотып килеп чыкты. Өстәлдәге затлы чынаякларны кырыйга этәреп, аларны Галина Захарова алдына китереп салды.

— Яз!

— Нәрсә язарга? Нишләп мин язарга тиеш?..

— Яз, яз. Әйттем бит инде, формальность кына бу. Шунсыз булмый. Югарыдагы иптәшләргә тотынып җеп шуннан башланачак. Кайткач, ул үзе күчереп язар, — дип, башы белән ишарәләде Лапицкая, инде шактый йомшый башлаган Владиславка күрсәтеп. — Күчереп язар да үз кулы белән илтеп бирер. Хәвефләнер урын юк. Барысы да тәртиптә булыр... Әйттем ич, мине тыңлагыз, дип.

Галина Захарова, ручканы алып, хуҗа хатынның әйткәннәрен кәгазьгә төшерә башлады:

«Казан шәһәре, Ленин районы эчке эшләр бүлеге начальнигына утызынчы профтехучилищеның һөнәргә өйрәтү мастеры Захаров Владислав Юрьевичтан гариза.

Мин, беренче тапкыр милициягә сорау алырга чакырылгач, башым әйләнеп һәм тикшерүченең басымы астында дөрес булмаган мәгълүматлар бирдем. Хәзер, боларны яңадан тагын бер кат уйлагач, һәм эш өчен янып көеп йөрүче намуслы кешегә гаеп ташлавымны аңлагач, түбәндәгеләрне хәбәр итәргә зарур дип саныйм. Мин 1980—1981 елларда һәм янәдән 1982 елда училищеда эшләдем. Һөнәргә өйрәтү мастеры дип кабул ителсәм дә, чынлыкта, мин профориентация белән шөгыльләндем, ягъни төрле районнардан училищега укучылар җыйдым. Минем эшчәнлегем нәтиҗәсендә уку йортына илледән артык кеше кабул ителде. Училище директоры моны бары тик укучылар җыюны яхшырту максатларында гына гамәлгә ашырды. Мине училищеда эшләмичә генә акча алган һәм аны Лапицкаяга биреп барган дигән сүзләр ялган. Алар намуслы җитәкчегә көнче кешеләр яласы.

Минем элекке күрсәтмәләремне юкка чыгаруыгызны үтенәм».

Гариза язылып беткәч, Лапицкая кунакларны озатырга ашыкты.

— Тик бер нәрсәне истән чыгармагыз: барыбыз да бер сүздә булсак, безне беркем дә җиңә алмаячак. Бу мәшәкатьләр генә бетсен, әле сезне дә, күгәрченкәем, училищега секретарь итеп кабул итәрбез, — диде ул, Галинага елмаеп. — Тыныч, җылы эш. Ә борчулардан соң банкет миннән. Анысына шикләнмәгез.

Очрашудан өчесе дә бик риза, канәгать калдылар. Баш өстендә куера башлаган болытлар таралып, якты кояш килеп чыккандай булды.

Людмила Ивановна бу «эш»тән чыгу юлын шулай оста таба алуына горурланып, кулларын угалады. Иркенләп, кофе эчәргә утырды. Әмма күңел тынычлыгы озакка бармады. Училищедагы башка мастерларны, укучыларны да, сорау алырга, милициягә чакырулары, башка эшләренең өскә калкып чыгу ихтималы исенә төшкәч, эче «жу» итеп китте. Ләкин кирегә борылырга соң инде. Терсәк якын, әмма тешләп булмый.

— Тагын нәрсәләр беләләр икән? Кем тишкән? — шуларны уйлады, җавап таба алмагач, кискен бер карарга килде. — Бар нәрсәне кире кагарга! Барысын да кисәтеп куярга!

Әле бая гына тарала башлаган шөбһәләре яңарды, күңелен шик корты кимерә башлады.

— Ә барысы да ничек әйбәт башланган иде бит!

* * *

Әйе, барысы да шәп, искиткеч шәп бара иде. Буйсынуындагы кешеләрнең баш июе, олырак, дәрәҗәлерәкләрнең үз итүе, дус итүе — барысы да бар иде. Бар иде бит. Хәер, ничек бу турыда үткән заманда әйтәсең?! Әле болар барысы да бар ич. Бу эшне алар белми ләбаса. Дефицит әйберләр дисеңме, модный курортлар дисеңме... Мәскәү олимпиадасына путевкага хәтле тапты Людмила Ивановна. Акчасын кызганмый иде ул, кызганмый иде. Һәм хәзер дә кызганмаячак.

Директор булып эшли башлаган көннәрен, кешеләр өстеннән, материаль байлыклар өстеннән властька ия булган чакларын, шуны тоюдан исерткеч ләззәт алган минутларын исенә төшерде Лапицкая. Ул кул куйган приказларда, бухгалтерия документларында күпме акча үтә. Иөзләп, меңләп, ун меңләп... Түләргә дә, түләмәскә дә аның ихтыяры. Сырлап бер генә имза куй, фәләнгә премия, фәләнгә өстәмә түләү, фәләнгә стипендия. Иң ачындырганы шул: акчаны үзеңә алып булмый. Ә аласы иде бит. Нигә аңа юлларын эзләп карамаска?! Акыллы кеше тапмаган ысул буламыни? Ә Людмила Ивановна үзен акыллы, тормыш рәтен белгән кешеләрдән саный. Диңгездән бер тамчы кимегәнне кем сизсен. Ә тамчылардан күл җыела.

— Иң башта училищедагы кешеләрне сынап карарга, тирәңә ышанычлы, таянырдай, сүз берләштерердәйләрен җыярга кирәк. — Ясаган нәтиҗәсе шул булды һәм ул үзенә хас энергия һәм үзсүзлелек белән эшкә тотынды. Аңа ошамаган, артык намуслылык күрсәткән, нәзберек кешеләр берәм-берәм училищедан китә торды. Алар урынына яңалары табылды. Владислав Захаров — әнә шуларның берсе. Хәер, ул, җинаятьчеләр теле белән әйткәндә, «умырзая» гына. Аны училищеда беркем дә юньләп белми. Димәк, шаһитлар да рәтле күрсәтмә бирә алмаячак. Монда бары тик ике кеше — Лапицкая үзе һәм Захаров кына дөреслекне белә. Шушы версиядән читкә чыкмаска кирәк.

...Училищеда бимазалы көннәр башланды. Директор кабинетының ишеге ачыла да ябыла. Шикләнгәннәрен дә, үзенә таяныч булырдайларын да чакыра Лапицкая.

— Чакырдыгызмы, Людмила Ивановна?

— Әйе, әйе. Узыгыз, утырыгыз! Бер аңлашылмаучылыкны хәл итәсе бар иде. Кечкенә генә ярдәмегез кирәк.

Директорның һәр сүзен закон дип кабул итәргә яраткан мастер Закиров, «Аңладым» дигәндәй, башын ия-ия, үзенең тыңларга әзер булуын белдерде.

— Менә нәрсә, иптәш Закиров. Училищега укучылар туплау ничек авыр икәнен үзегез беләсез. Районнардан, хәрби комиссариатлардан яшьләр җыю өчен махсус кеше алган идек. Мастер дип аталса да, ул укучылар белән шөгыльләнмәде, командировкаларда гына йөрде. Кайсыдыр юньсезе шуны милициягә чаккан. Имеш ялган кеше, аның исеменә язып, акча үзләштерелә. Аны да, мине дә ОБХССка чакырып, башыбызны әйләндереп бетерделәр.

— Мин нишли алам соң, Людмила Ивановна?..

— Ә... вак-төяк. Бәлки сезне дә анда чакырырлар. Шуны алдан әйтеп куярга теләвем генә иде. Үтенечем шул, сорасалар, үзең укыта торган бишенче группаны мастер Захаров җыйды дип әйтергә кирәк булыр.

— Минем аны күргәнем дә юк бит.

— Күрүегез кирәкми дә. Бары тик, әйе, бу группаны Захаров Зеленодольск хәрби комиссариаты аша җыйды дип кенә әйтерсез. Моның өчен сезгә берни дә булмас. Училищеның яманаты чыгудан саклап калырга ярдәм итәчәксез. Шулай бит. Ризамы?

— Алай булгач, эшлибез аны, Людмила Ивановна.

— Тагын бер нәрсәне әйтергә оныта язганмын. Группада укучыларга да шуны җиткерсәгез иде.

Мастерның ни әйтергә белми җилкә җыеруын күргәч, Лапицкая елмаеп, «Кыюрак булыгыз!» дигәндәй дәртләндереп, Закировка карады.

— Хәер, әйдәгез, болай итик.

Директорның кулы өстәл-кырыендагы кнопкага үрелде. Ишек ярыгында секретарь кызның башы күренде.

— Валечка, бишенче группа старостасын бирегә чакырыгыз әле. Хәзер алар дәрестә булырга тиеш.

Биш-алты минут үттеме-юкмы, группадашлары үзләренең җитәкчесе итеп сайлаган Олег Захаров директор кабинетына килеп керде.

Ышкылган джинсы, кара куртка кигән яшүсмер егет, ишек катында уңайсыз туктап калды, ни әйтерләр икән дип, бер мастерына, бер директорга карап алды.

Бар нәрсәне училище ихтыяҗыннан чыгып аңлатты аңа директор. Укучылар бердәмлеге, кешенең бер-берсен сатарга тиеш түгеллеге, хыянәтнең нинди авыр җинаять икәнлеге турында фәлсәфә корды. Менә шундый бердәмлек белән әшәке яладан бер мастерны коткарып калырга, данлы училищеның яманаты чыгудан йолырга кирәк икән.

— Группадашларыңның күбесе Зеленодольскидан. Алар белән дә сөйләш. Барыгыз бер төрле итеп, безне мастер Захаров кабул итте дип әйтерсез.

— Кайда әйтергә?

— Группагыз белән милициягә барырсыз. Тикшерүче Зиннәтуллинны табасыз да янына керәсез.

— Аңладыңмы?

— Аңладым, — дип, башын иде егет. — Ә Захаров нинди рәк кеше? Сорасалар...

— Анысын онытып җибәрә язганбыз икән шул... Димәк, болай. Озын буйлы, шома коңгырт чәчле.

Лапицкая ялган мастерның нинди рәк сыйфатлары барлыгын исенә төшерер өчен, борынын ышкып алды. Диктант әйтеп торгандагыча акрын гына сөйли башлады.

— Өстендә соры костюм. Галстук такмый, күлмәгенең изүе элэктерелми. Тагын... Чеқанка белән шөгыльләнә. Безгә, бик мавыктыргыч итеп, аны ничек ясау турында сөйләгән иде диярсез. Сез бит булачак төзүчеләр. Бу эш белән кызыксынып китүегез дә аңлашылыр.

Шаһит буларак милициягә чакырылган Закиров та, бишенче группа укучылары да сүзләренд тордылар, тикшерүчегә нәкъ Лапицкая кушканча сөйләделәр. Барысы да җайлана башлады. Әмма училищедан укучыларны, мастерларны ОБХССка чакырулар дәвам итте.

— Нишләп бу хәтле казыналар икән, — дип борчылып уйланды Людмила Ивановна. — Моңа ничек чик куярга? Эш тирәнгәрәк китсә, хәтәргә әйләнүе мөмкин.

Мастерларның берсе — Демахинның милициядә «Захаровны белмим. Күргәнем юк. Әмма табельдә аның фамилиясе һәрвакыт була» дип әйтеп кайтуын ишеткәч, Лапицкая түзмәде, аны аты-юлы белән сүгеп ташлады да шул ук көнне педсовет җыйды. Бөтен халык алдында Захаровның кем булып исәпләнүен, кем алдында отчет тотуын, нинди эш белән «шөгыльләнүен» аңлатып бирде.

— Теләсә нинди башбаштаклыкка юл куеп торып булмый. Безнең уртак эшебезне моннан соң үз каланчагыздан торып кына каралтып йөрмәвегезне таләп итәм, — дип бетерде ул сүзен.

* * *

Ленин районы милиция бүлегенең социалистик милекне урлауга каршы көрәш бүлегендә училищедан килгән сигналга баштарак әллә ни әһәмият бирмәгәннәр иде. Тикшерүче Зиннәтуллин, барлык шаһитларны, шул исәптән ялганнарын да тыңлагач, өлешчә билгеләмә генә чыгарып, «эш»не туктату турында карарга кул куйды. Лапицкаяга канатлар үскән кебек булды. Әмма сөенергә иртәрәк булган икән әле. Таяк тыгып бутаган кырмыска оясын хәтерләткән училище тиз генә тынычлана алмады. Үзләренең хаклыкларын, дөреслекнең сүз астында күмелеп калуын аңлаган мастерлар шәһәр прокуратурасына мөрәҗәгать иттеләр. Архивлардан папкалар тагын күтәрелде. Прокурор ябылган «эш»нең очы-очка ялганып җитмәвен ачыклады. Ул төгәл иттереп тикшерү өчен җибәрелде. Бу юлы аны Казан эчке эшләр идарәсенә йөкләделәр. Тикшерүче тәҗрибәле юрист капитан Иванов иде.

«Эш»кә тагын йөзләрчә тикшерү һәм экспертиза нәтиҗәләре, җавап алу һәм гаепләнүчеләрне күзгә-күз очраштыруларның беркетмәләре өстәлде.

Вячеслав Федорович үзенең Ленин районындагы коллегасы сүтә башлаган һәм Лапицкая «ярдәме» белән чуалтып ташланган җепнең иң очыннан тотынырга булды. Барысын да бөртекләп күздән кичерергә, булган дәлилләрдән һәм фактлардан логик эзлекле конструкция корырга, төгәлсезлекләрнең кайда һәм ничек җибәрелүен ачыкларга кирәк иде. Гаепләнүчеләр тикшерүчене кай тирәдәрәк юлдан яздырган? Әллә чыннан да алар-

ның бер гаепләре дә юкмы? Күнче кешеләрнең нахак яласы белән гадел һәм дөрес җитәкчегә кара ташланмыймы? Чуалган җеп шулай ук сүтеп бетерерлек түгелмени? Ничек кенә булмасын, җепнең очы, әлбәттә, Захаровта. Нәрсәдер әйтеп бетерми, нәрсәнедер яшерергә тырыша ул. Шушыларны кат-кат уйлагач, Иванов беренче эше итеп коллегасы шикелле үк янына Владислав Захаровны чакыртты.

Күптән түгел генә булып үткән борчулардан, тетрәнүләрдән әле айнып та җитмәгән Захаров яңа тикшерүче белән сөйләшүне ризасызлык белдерүдән башлады.

— Бер балык башын күпме чәйнәргә була? Бер генә түгел, мең мәртәбә чакырттылар, сөйләштеләр, тикшерделәр бит инде. Барысы да ап-ачык. Барыбер шуннан артык бер сүз дә әйтә алмыйм һәм... гомумән, мин әйтергә дә теләмим.

— Туктагыз, тукта! Гаепсез икәнсез, сезгә беркем дә җинаять тагарга җыенмый, — дип, сабыр гына эндәште аңа Иванов. — Бары тик берничә детальгә төгәллек кертәсе генә бар иде. Сезне дә шуның өчен чакыруыбыз.

— Сезнең кәгазьләрдә барысы да уч төбендәге кебек ярылып ята бит... Тагын нинди төгәллек ди ул?

— Менә нәрсә, Владислав Юрьевич, баштагы күрсәтмәгездә бер төрле, аннан соң икенче төрле сөйли башлавыгызны ачыклыйсы килә. Бәлки шуннан башларбыз...

— Аның сәбәбе минем гаризамда әйтелгән. Зинһар, юкка башымны катырмагыз.

— Ярый, анысы шулай да булсын ди. Укучыларны нинди хәрби комиссариатларда җыйдыгыз? Менә болары беркетмәләрдә юк. Шулаймы?

Бу сорауны ишетүгә, Захаровның йөзеннән бер генә мизгелгә кара күләгә үтеп киткән кебек булды. Бар нәрсәне хәтеренә сеңдереп, мыегына чорнап утырган Иванов, шушы күз ачып йомар арада булган үзгәрешне шәйләүгә үк, үзенең бик кирәкле һәм мөһим сорау бирүен чамалап алды. Захаров та инде үзен кулга алып өлгерде, йөзенә элеккеге битарафлык һәм ваемсызлык чалымнарын чыгарып, җавап бирергә керешге.

— Күп йөрергә туры килде инде. Каян хәтерләп бетерәсең?

— Ә шулай да...

— Зеленодольск, Арча... тагын башка районнар... — Захаров уйланып, туктап калды һәм кинәт нәрсәнедер исенә төшергәндәй ашыга-ашыга тезеп китте. — Ышанмасагыз, укучылардан сорый аласыз. Алар үзләре шартлатып әйтеп бирерләр.

Тик аның күзләрендә инде баягы ваемсызлык юк, алар менә-менә әләктереп алам дип торган, ярсыган җәнлек күзләре шикелле Ивановны сак һәм кырыс караш белән күзәтәләр иде.

Үзеннән алдагы тикшерүченең кайчан ялгыш юлдан кереп китүен аңлап алды Вячеслав Федорович. Сорау алуны артык дәвам итмәскә булды. Беркетмәгә кул куйдырды, шәһәрдән чыгып китмәскә имза алды һәм хушлашырга ашыкты.

— Юкка казынасыз, капитан, — ризасыз мыгырдап чыгып китте Захаров. Аның артыннан ишек ябылуга ук, Иванов кәгазь, каләменә үрелде. Шул ук көнне хәрби комиссариатларга берничә сорауны эченә алган хатлар очты.

Төп гаепләнүче Лапицкая белән очрашканчы үзенең инде оеша башлаган фикерен ныгытырга, кайбер шикләрне таратырга кирәк иде. Хат көткән көннәрне әнә шуңа багышларга булды ул.

Моңа кадәр үткәрелгән барлык сорау алуларның беркетмәләре һәм башка документлар белән җентекләп танышкач, фикере тагын да ачыклана төште: аның алдында тәҗрибәле һәм бер нәрсәдән дә тайчанмый торган аферистка. Аны көн яктысына чыгару шактый катлаулы һәм авыр булачак. Шәһәр прокуратурасына мөрәҗәгать иткән мастерларның бер дә юкка кешегә яла якмаячакларына да чын күңелдән төшенде. Димәк... Шаһитларның бер көнне болай, икенче көнне тегеләй сөйләүләре, аларның күрсәтмәләрендә бер-берсен юкка чыгара торган капма-каршы фикерләрнең булуы тикшерүне тагын да тирәнрәк катламнардан башлауны, училищега бәйле кешеләр белән яңадан-яңа очрашуларны таләп итә иде.

Гаепләнүчеләр берсе дә, башын иеп: «Әйе, хаталанганмын, кичерә күрегез», — дип килә торганнардан түгел. Лапицкаясы да, Захаровы да — ике

чабата — бер кием. Алар бер үк җинаятьнең ике полюсында торган кешеләр. Берсе оештыручы, икенчесе я җиңел акыллылык корбаны, я булмаса башка бер җинаятен каплау өчен шул чарага керешкән. Шуның өстенә Захаровның дәрес алып баруы турындагы табельләр шиккә төшерде Ивановны. Аларны бит директор үзе тутырмаган. Булмаган дәресләр турындагы бу ялган кәгазьләрдә мастерларның да, директор урынбасарының да имзалары бар. Димәк, бер кешенең генә түгел, ә бер төркемнең сүз берләшүе, уртак җинаяте булырга мөмкин дигән сүз. Тукта, тукта! Шул имзаларны, ведомостьларны да графология экспертизасына җибәреп карасак?..

Уйлаганын прокурор белән уртаклашкач, Иванов тиз арада уйларын тормышка ашырырга да кереште. Үзәк бухгалтериядән 1979 елдан башлап, акча түләүгә бәйле барлык документлар җыеп алынды.

Болар беренче карашка әллә ни әһәмиятле дә түгел кебек. Ләкин әле һаман ул язмаларда кем кулы уйнавын тәгаен әйтү кыен. Шул шикне юкка чыгарырга кирәк иде. Әмма тикшерүче бөтен өметен хәрби комиссариатлардан киләчәк җавапларга баглады, аларны түземсезлек белән көтте. Ул җаваплар кемнең хак, кемнең нахак сүз сөйләвен бөтен тулылыгы белән ачыкларга ярдәм итәчәкләр.

Ләкин аннан соң булган яңалыклар Захаровны да, көтелгән хатларны да онытып торырга мәҗбүр итте.

...Иртән эшкә килеп, киемнәрен шкафка эләргә дә өлгермәде, телефон шалтырады.

— Вячеслав Федоровичмы? Экспертиза бюросыннан әле бу.

— Әйе, тыңлыйм. Берәр нәрсә ачыклый алдыгызмы?

— Хәзергә өзеп әйтүе кыен. Шулай да кайбер нәтиҗәләр бар кебек...

— Кебек кенәме, әллә бармы? Җанымны кыйнамагызсана, ни барын тиз генә әйтеп буладыр ич, шайтан алгыры, — дип түземсезләнде Иванов. Кулына каләмен алып язарга хәзерләнде.

— Ашыккан ашка пешкән ди. Алай бик каударлансаң, бөтен документларны карап бетермичә бер сүз дә әйтмәбез, — дигән җавап ишетелде чыбыкның икенче очыннан. Алар яшь капитанның берәр эшкә тотынса, бар вакытын, белемен шуңа багышлавын яхшы беләләр иде. Аз гына булса да, түземсез тикшерүчене шаяртасылары килде булса кирәк.

— Ярый, биреләм. Гаеп миндә. Тик ни тапканыгызны әйтегез генә...

— Шул-шул...

Трубкадан кәгазь кыштырдаган тавыш ишетелде.

— Без монда училищеның Сабадагы филиалында укучыларга стипендия түләү ведомостьларын карап чыктык. Ай саен җиде-сигез укучы өчен имзалар бер яки ике кеше кулы белән куелган...

— Ачыклый алмадыгызмы — кемнеке икән?

— Берсе шул филиалдагы мастер Колударовныкы, икенчесе училище директоры урынбасары Корнееваныкы булырга тиеш.

— Тиеш кенәме... Әллә шулаймы?

— Тиеш булгач, тиеш инде, ягъни шулай булып чыга, — дип сүз уйнаттылар телефонда.

— Стипендия ничәшәр сум әле?

— Җитмеш дүрт сумнан бара...

Тагын берничә көннән башка ведомостьларда да ялган имзалар барлыгы мәгълүм булды. Инде «эш»не җиң сызганып башларга, тикшерүнең яңа баскычына атларга мөмкинлек туды.

Сорау алу вакытында да, ашыга-ашыга сөйләгәннәрне тәртипкә китергәндә дә, үзенең һаман бер сорауга җавап таба алмаганын сизенә Иванов. Захаровны, ярый, алкоголик, түбәнгә тәгәрәгән кеше дип карыйк. Ә бу мастерларга һәм өлкән мастерларга, директор урынбасарларына ни җитмәгән?! Тыштан караганда, барысы да, кем әйтмешли, интеллигент кыяфәтле, үзләренең ни кылганнарын, иртәме-соңмы җавап бирергә туры киләчәген дә аңлаган бит алар. Илебезнең, халкыбызның иң кадерле нәрсәсе — яшь буынны хезмәткә өйрәтү, тәрбияләү бурычы йөкләнгән кешеләр ничек итеп шулай түбәнлеккә тәгәри алган? Кайчагында, авыз эченнән ботка пешереп, кызарып, тирләп утырган бу мескен җаннарны кабинеттан куып чыгарасы килә башлый. Хәер, алар барысы да мескенләнми. Кайберләре, киресенчә, югарыдан торыбрак, өстәнрәк карап сөйләшергә дә тартынмый. Лапицкая үзе генә дә ни тора! Аның үз-үзенә ышанган, боеручан, кайчагында кычкыруга әйләнеп китә торган тавышында ниндидер ымсындыру да, бу эшкә югарыда юл

бирмәячәкләре турында өметләнү дә, тикшерүче хезмәтендә күңелсезлекләр булачагына ишарә дә аңгырап китә.

Ләкин тикшерүче эмоцияләргә бирелә алмый. Аның төп коралы — дәлил, берничек тә кире кагып булмый торган фактларны логик эзлеклелектә туплау, шулар белән җинаятьчеләрнең гаебен, гаепсезләрнең аклыгын раслау. Нинди җәза биреләчәген бары суд, халык суды гына хәл итә.

— Миңа нинди җәза бирерләр икән соң? Барысын да үзем сөйләп бирдем бит...

Җавап көтеп, үзенә текәлгән пыяла сыман буш күзләрне шунда гына күргән кебек булды Вячеслав Федорович. Әмма күңелендәгеләрне әйтеп тору ны кирәк тапмады, кыска гына җавап кайтарды.

— Гаебеңне ни дәрәҗәдә аңлавыңны, чын күңелдән тануыңны искә алмый калмаслар. Дәвам итик, Анатолий Семенович. Минем бөтен ваклыкларына кадәр беләсем килә. Баштан ук башлыйк, — дип эндәште ул каршында утыручы Колударовка. — Барысын да тәртибе белән сөйләгез.

Ак кәгазь өстенә кара эшләр турында вак хәрефләр төшә башлады.

— Сабада безгә бүлмә бирделәр. Лапицкая ярдәм итте. Хатыныма да йөз илле тугызынчы ПМКга экономист булып урнашырга ул булышты. Мин мастер булып эшли башладым. Беренче тапкыр стипендияне Казаннан җитмеш тугызынчы елда алып кайттым. Ул вакытта инде сигез укучыбыз дәрескә йөрми иде. Аларның кайберләре бер-ике көн генә килде, кайберләренең училище ишеген ачып кергәне дә булмады. Таратканнан соң, акчаның аларга дигән өлеше миндә калды. Кире тапшырырга дип, Казанга киттем. Училище директорына нишләтим бу акчаларны дип кергән идем, ул аларны кире бухгалтериягә бирергә ярамаганлыгын әйтте.

— Нишләп?

— Әгәр укучылар йөрмәгәнне белсәләр, Сабада филиалны ябачаклар, эшсез калачаксың диде.

— Акчаларны нишләттегез?

— Ул ведомостька укучылар өчен кул куярга, ә акчаларны үзендә калдырырга кушты.

— Ә сез куйдыгызмы?

— Әйе, бер мин генә түгел. Безнең белән директор урынбасары Корнеева да бар иде. Ул да куйды.

— Ничә тапкыр шулай эшләдегез?

— Хәтерләмим инде. Гел шулай барды ул. Казанга килгән саең, Лапицкая миннән: «Синең үле җаннарың ничәү әле?» — дип сорый торган булып китте.

— Акчаны аның кая куеп барганы белән бер генә мәртәбә булса да кызыксынмадыңмыни соң?

— Сораган идем. Аларны ул училище кирәгенә тотабыз диде. Аннан соң филиалга тикшерүче комиссияләр килмәсен өчен, югарыдагы җитәкчеләргә бүләкләр алырга кирәклеген аңлатты.

— Дөресен генә әйт әле, Анатолий Семенович. Бу эшләрнең җинаять икәнен аңлый идеңме?

— Аңладым аңлавын, — дип авыр сулады Колударов. — Лапицкая мине башта ук кисәтеп куйды: «Имзаларыңны син куйдың. Ул-бу булса, җавабын да син бирәчәксең», — диде. Соңрак баш тартырга да уйлап караган идем, тик квартира бирмәсләр дип курыктым. Яхшы гына эшләсәм, һичсүзсез квартира булачак дип, директор өметләндергән иде...

Бер факт икенчесенә, өченчесенә барып тоташты. Алар тагын башка төсмерләре һәм төгәллекләре белән ачыла барды. «Умырзая»ларның да бер Захаров кына булмавы беленде. Ниндидер Авербах дигән кеше дә училищеда мастер булып исәпләнгән, аңа да берничә ай хезмәт хакы язып барылган. Аның үзен күреп сөйләшү, шаһитлар күрсәтмәсе, экспертиза нәтиҗәләре кире каккысыз итеп, бу акчаларның да Лапицкая кесәсенә шуа баруын раслады. Шушы юл белән генә дә ул кыска вакыт эчендә бер мең алты йөз илле алты сум акча үзләштергән.

Капитан Ивановның күз алдыннан дәүләт акчасын талауга юл ачкан әллә ничә кешенең язмышы узды, унөч калын томга күрсәтмәләр, документлар һәм беркетмәләр теркәлде.

Айларга сузылган четерекле «эш»не төгәлләргә, гадел хөкем органнарына тапшырырга да мөмкин. Зур һәм мәшәкатьле йөкне өстеңнән төшергәннән

соң була торган рәхәт бер җиңеллек кичерде Вячеслав Федорович. Соңгы тапкыр папкаларны өстәленә тезеп салды, вөҗданы пычрак булган берәүнең күпме кешене үз баткагына тартуын аянып уйлап куйды. Тагын томнарны ачты, күз алдыннан берәм-берәм фамилияләр, кызганыч йөзләр узган кебек булды.

Әйе, бу беркетмәләр шул турыда сөйли. Ивановның колагында әле дә булса аларның тавышлары яңгырап тора кебек.

Егерменче группаның һөнәргә өйрәтү мастеры Орлова сөйли:

— Минем группада сигез кеше укуын ташлады. Бу турыда Лапицкаяга әйтсәм дә, ул аларны училищедан чыккан дип исәпләмәскә кушты. Алар класс журналыннан да, стипендия алу исемлегеннән дә төшерелмәде. Хәтта ялган билгеләргә кадәр куеп барылды.

Училищеның директор урынбасары булып эшләгән Пьянова тавышы:

— Ул вакытта Саба филиалындагы утызынчы группада кырык кеше исәпләнсә дә, егермеләбе генә укый иде. Директор укымаганнарны исемлектән төшермәскә, алар өчен ведомостька кул куярга, ә стипендияләрне аңа китереп бирергә кушты. Егерменче группа мастеры Әхмәтшина шулай эшләде дә. Аның алып килгән акчаларын директорга бирдек, ведомостька үзебез кул куйдык.

Бу хәлләрдән соң мин мастерлардан барлык укучыларны да стипендия исемлегенә кертеп баруларын таләп иттем.

Мастер Корнеев күрсәтмә бирә:

— Кадышевода безнең укучылар интернат төзелешендә эшләде. Лапицкая боерыгы белән мин 1219, 1622 нче ведомостьларга эштә катнашмаган укучыларны да теркәдем. Аларга дигән бер мең биш йөз сум акчаны директорга бирдем...

Кыска гына вакыт эчендә Лапицкая әнә шундый юллар белән унөч мең йөз җитмеш дүрт сум акча үзләштергән булып чыкты. Бу бәхәссез, расланган нәрсә.

Училищеда укымаган яшьләрне, ягъни «үле җаннарны» яшереп баруның бик ансат юлы да табылган. Аларны Совет Армиясенә чакырылу сәбәпле училищедан китте дип, я булмаса, имтиханнарны вакытыннан элек тапшырды дип рәсмиләштергәннәр. Приказларда тагын Лапицкая кулы. Ул гына да түгел, ялган белгечләргә хәтта дипломнары да тутырып куелган. Ялган билгеләр, ялган дипломнар, ялган белгечләр... 1979—1983 елларда училище республика төзелешләренә «үле җаннардан» йөз дә ун «белгеч» җибәргән.

Югары органнарга укучылар җыю, халык хуҗалыгы өчен квалификацияле төзүчеләр әзерләү планнарының тотрыклы үтәлүе турында рапортлар оча. Лапицкаяның исәбе бу юлы да аклана. «Алдынгы» училище җитәкчеләренә «хезмәт казанышлары» өчен премия артыннан премия килә. Тагын йөзләрчә сум дәүләт акчасы җинаятьчеләр кесәсенә күчә.

Вячеслав Федорович папкаларны читкәрәк этеп куйды һәм шунда гына үзенең никадәр аруын, тәне түгел, ә рухының никадәр талчыгуын тойды. Әллә ничә айга сузылган гаять тә четерекле, катлаулы һәм мәшәкатьле, борчулы көннәрнең йомгагы булып, алда бер җинаять тарихы ята. Күрәсең, күңеле чиста булмаганнарның психологиясе бердер. Кылган кыңгыр эшләрен каплап калдырырга тырышып күпме боргалану, законны читләтеп үтә торган әйләнгеч юллар һәм ярыклар эзләү, инде яшереп калдырырга мөмкин булмагач, төп гаепне үзеңнең яраннарыңа һәм кәсептәшләреңә аударырга маташу... Барысы да булды, барысы да күз алдыннан узды.

Сазлык чоңгыллары да шулай бит. Башта тигез, шома булып күренгән, яшел хәтфәдәй мүк белән капланган баткак та бернинди куркыныч тудырмый кебек. Килгән шәпкә түмгәктән түмгәккә сикер дә, юлыңны дәвам ит! Барысы да әйбәт булыр. Сазлы урынны йөгереп үтәрсең дә киң, якты сукмакка килеп чыгарсың кебек. Әмма бу мираж, ялган хәвефсезлек, ялган матурлык. Аягыңны басуга ул инде сине җибәрми. Әле генә ымсындырып торган түмгәкләр дә ярдәм итми. Чыгарга, дәһшәтле пычрактан котылырга теләп тарткаланган, чапаланган саен ул сине тагын да аскарак, эчкәрәк суыра. Салкын, ябышкак ләм тезеңә, билеңә җитә, күкрәгеңә якынлаша. Котылыр өчен әллә ниләр бирердәй буласың. Әмма чигенү юлы юк. Баткак үз кочагына эләккән корбаннарны ычкындырырга яратмый.

Лапицкаяның нәфесе дә аны намуссызлык, вөҗдансызлык, дөньядагы бөтен кыйммәтләрне дә акча белән үлчәү, ришвәтчелек һәм «син — миңа,

мин — сиңа» дип яшәү сазлыгына китереп керткән. Училищены ташлаган укучыларның стипендияләрен кабинетындагы калын сейфка тәүге тапкыр бикләп куйганда әле борын төртә генә башлаган нәфес яшелле-зәңгәрле пачкаларны күргән саен аның җанын котырта, астыртын пышылдый: «Үрел дә ал! Барысы да законлаштырылган ич. Укучылары исемлектә бар, ведомостьта, ялган булса да, имзалары ярылып ята. Бәлки әле берни дә булмас, беркем дә сизмәс. Ул кыштырдавыклы кәгазьләр алтын алкага да, кыйммәтле мехка да, хрусталь һәм затлы келәмгә дә әйләнә ала лабаса. Бары тик теләк кенә кирәк». Нәфес әнә шулай котырта, яшәү ямен модалы киенүдә, тәмле ашауда гына күрә белгән вак җанны үрти, ымсындыра. Баткакка беренче адым ясала. Мәкерле сазлык аны тагын да эчкә суыра, комсызлыкны үсендерә, алгысыта бара. Бер группа стипендиясе генә җитми хәзер Лапицкаяга. Башка группаларда да «үле җаннар» арта, «умырзая»лар үсеп чыга.

Нәфес туктала белми. Нәфес баткагы табигый сазлыктан мәкерлерәк тә, пычраграк та. Сазлыкка бата башлаган җан иясенең котылу өмете бар әле. Ул ярдәмгә чакыра, башкаларны кисәтә, талпына, капшанып-кармаланып, таяну ноктасы эзли. Ә нәфес баткагына чумучылар ярдәм сорап кычкырмый, киресенчә, алар һаман эчкәрәк керергә, үз яннарындагыларны да шул пычракка батырырга тырыша.

Лапицкаяның тикшерү барышында үз-үзен тотышы, кире кагып булмаслык дәлилләрне танырга теләмичә бөтен гаепне башкаларга ягарга маташуы әнә шундый баткаклыкны хәтерләтте капитан Ивановка. Әмма гаделлеккә күпме генә аяк чалырга теләмәсен, ике йөздән артык шаһит күрсәтмәсе, товар белгечләре экспертизасы, суд-бухгалтерия, суд-психиатрия, графология экспертизалары нәтиҗәләре һәм башка материаллар аның үз тирәсенә җинаятьчеләр группасы туплап, еллар дәвамында дәүләт акчасын урлап яшәвен ачык итеп күрсәтте.

Тикшерү нәтиҗәләрен судка җибәрер алдыннан соңгы тапкыр үз янына Лапицкаяны чакырды ул.

— Тикшерү тәмам. Сезгә бер киңәш бирәсем килә иде...

Людмила Ивановна тикшерүчегә зәһәр карап алды, иреннәрен кысып, сүзсез калды. Үзенчә тәкъва булып, һаман әле яшь булып, яшәреп күренергә тырышучы, әмма соңгы көннәрдә шактый картаеп киткән, асыл йөзе ачылган бу хатыннан бүген бернинди сүз ишетә алмаячагын аңлагач, капитан Иванов ашыкмый гына дәвам иттерде.

— Судта да болай киреләнеп, бар нәрсәне кире кагып утырмаска киңәш итәр идем. Гаебегез... җинаятегез ачык. Хәлегезне бары тик саф күңелдән сөйләү генә җиңеләйтә алачак...

«Ә» дә, «җә» дә димәде Лапицкая. Соңгы мизгелгә кадәр ул әле һаман да үзенә кемнеңдер ярдәм кулы сузасына, эшнең башка якка үзгәрәчәгенә ышана иде, күрәсең. Тикшерүченең акыллы киңәше юкка гына булган икән.

Берничә көн инде республика Верховный судында хөкем бара. Гаепләнүчеләр эскәмиясендә Лапицкая һәм Захаровтан тыш, акча урлау һәм үзләштерүдә катнашкан тагын өч кеше — Анатолий Колударов, Семен Корнеев һәм Замирә Әхмәтшина (башкалары, тикшерү барышында амнистиягә эләгеп, иптәшләр судында каралды).

Бер-бер артлы шаһитлар чакырыла. Суд членнары, халык утырышчылары алдында җинаятьнең нечкәлекләре, гаепләнүчеләрнең җинаятькә ни дәрәҗәдә катнашуы ачыла. Берәүдән кала барысы да үз гаепләрен таный, суд алдында, халык алдында башын түбән ия. Ә берсе һаман чекерәеп күзгә керә, барысын да кире кага.

Залда суд председателенең тавышы яңгырый:

— Гаепләнүче Лапицкая! Сезгә ни өчен гаепләнүегез аңлашыламы?

— Гаепләүне аңлыйм, әмма урлашуны танымыйм. Барысын да училищеда эшне яхшырту максатында эшләдем. Бөтен мәсьәләләрдә урынбасарлрыма ышана идем, бәлки гаебем шундадыр. Укуга кабул итү һәм чыгару белән дә урынбасарларым шөгыльләнде. Захаровка килгәндә, аннан да, хатыныннан да бер тиен акча алганым юк.

— Ни өчен аның училищеда исәпләнүен яшереп килдегез?

— Коллективта үзләрен рәнҗетелгән дип санаучы кешеләр бар иде. Әгәр барысын да әйтеп барсаң, аларның моны миңа каршы борулары мөмкин иде... Ә соңыннан Захаров турында мин барысын да игълан иттем...

Сорау арты сорау бирелә. Тагын яңа мәгълүматлар, җинаятьнең детальләре һәм төсмерләре ачыла. Әле суд залында да вак үпкәләр, янаулар һәм бер-берсен намуссызлыкта гаепләүләр яңгырый.

Владислав Захаров сөйли:

— «Акчаңны ал»,— дип, миңа училищедан ай саен киләләр иде. Ундүрт сумын үземә калдыра идем, калганнарын Лапицкаяга биреп бардым... Анда гел барып йөрмәс өчен аның исеменә берничә доверенность яздым. Доверенность буенча алганнардан Лапицкая миңа ундүрт сумын бирми иде.

Икенче тапкыр мине училищега үземнән башка гына кабул иткәннәр. Бу турыда мин акча алырга чакыргач кына белдем.

Лапицкая дәшми. Колударов һәм башкаларның күрсәтмәләреннән соң гына тагын сүз аңа бирелә.

— Колударов та, Захаров та, Корнеева да — барысы да ялганлыйлар. Сүз берләшеп, бөтен гаепне миңа аударырга маташуларын әле хәзер генә аңладым мин. — Аның һәр сүзе ярсып һәм ачуланып чыга. Элеккеге яраннарына ачу белән карап-карап ала.

— Захаров белән Колударов танышлар идемени?

Судьяның тыныч һәм ачык тавыш белән әйткән бу соравы ярсыган Лапицкаяны үз урынына утырткандай итә. Ләкин бирелергә исәбе юк аның.

— Танышлармы, юкмы — анысын белмим. Ә Захаровның мине акча үзләштерде дип күрсәтүе ялган. Колударовка килсәк, ул Корнееваны агартырга тели. Чөнки акчаны ул аңа биреп барган. Хәзер ул Корнеева тәэсирендә сөйли.

Бу кадәр оятсызлыкка түзмәде ахры, Колударов урыныннан кычкырып җибәрде.


— Кабинетыңда синең белән, Корнеева белән бергә ялган имзалар ясаганыбызны оныттыңмыни?

— Булганы юк. Андый хәлнең булганы юк... Андый хәлне мин хәтерләмим.

Лапицкаяны истерикага бирелеп кычкыра башлагандыр дип уйлаучылар нык ялгыша. Юк! Ул барысын да алдан уйлаган, һәр сүзен, хәрәкәтен мөмкин кадәр эффектлырак итеп күрсәтергә тырыша. Ләкин — юкка, дөреслекне күмеп булмый инде.

Хөкем карары ачык һәм аңлаешлы: җинаятьчел төркем башында торган Людмила Лапицкая — сигез, калганнары өчәр елга ирекләреннән мәхрүм ителә, урлап җыйган мал-мөлкәтләре конфискацияләнә. Шуның өстенә Захаровны алкоголизмнан мәҗбүри дәвалау турында карар кабул ителә.

P. S. Россия Федерациясенең Верховный суды хөкем карарын үз көчендә калдырды.



Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романына иллюстрация



Казанда Г. Ибраһимов яшәгән йорт (Комлев урамы, 33)

Т. Хажиахматов эше.

**Риф Хәйретдинов,**

тарих фәннәре докторы, профессор

# ОЛЫ ЮЛ БАШЫНДА

Бөек Октябрь социалистик революциясен Галимҗан Ибраһимов күренекле әдип, педагог, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе буларак каршы ала. Аны прогрессив интеллигенция һәм киң катлам халык массалары заманның социаль каршылыкларын оста чагылдырган әдәби әсәрләр, югары методик таләпләргә җавап бирә торган дәреслекләр, катлаулы иҗтимагый проблемаларны күтәргән мәкаләләр авторы, демократик карашлы җәмәгать эшлеклесе дип беләләр, ихтирам итәләр. Ә кайберәүләр исә аның инде күптән революцион көрәш юлына басуы турында да хәбәрдар иделәр. Г. Ибраһимовның халык бәхете өчен көрәшчеләр сафына басуы бик табигый иде. Чөнки аның үткер акылы, актив табигате, кешене-кеше эксплуатацияләүгә корылган җәмгыять каршылыкларын күрмичә үтә алмый, яшьтән авыр крестьян тормышын үз җилкәсендә татыган кеше буларак ярлы авыл һәм шәһәр халкын азатлык юлына алып чыгу турында уйламый булдыра алмый.

Халык бәхете өчен көрәшкә бөтен көчен һәм сәләтен биргән Г. Ибраһимовның иҗаты һәм эшчәнлеге күптәннән галимнәрчең игътибарын үзенә тартып килде һәм бүген дә игътибар үзәгендә кала бирә. Бүгенге көндә аңа багышланган берничә монография һәм брошюралар, йөзләгән мәкаләләр бар. Алар арасында филология фәннәре докторы, профессор Мансур Хәсәновның фундаменталь хезмәтләрен аеруча басым ясап күрсәтеп үтәргә кирәк. Ләкин ул яшәгән чорның катлаулы һәм эшчәнлегенең гаять күпкырлы булуы күренекле язучының иҗатын һәм тормыш юлын җентекләп өйрәнүне дәвам итүне таләп итә, күп кенә фактлар, чыганаклар махсус тикшерүне сорый.

Менә шундый темаларның берсе — Галимҗан Ибраһимовның Совет властеның беренче елларында ленинчыл милли политиканы үткәрү юлындагы эшчәнлеге. Милли мәсьәләнең асылы, аның чишелеш юллары Г. Ибраһимовның уйлануларында инде яшьли үк шактый зур урынны алып торган булырга тиеш. Изелгән халыкларның тормышын яшьтән күреп үсүе, ил тормышы һәм аның халыклары турында киң мәгълүматлы булуы, политик һәм матур әдәбиятның төрле юнәлешләрен яхшы белүе аның иҗатында инде революциягә кадәр шактый ачык чагыла. Һәм ул милли мәсьәләне хәл итүнең иң мөһим юлы — иске режимны бәреп төшерү һәм илне идарә итүне хезмәт ияләре кулына, алар мәнфәгатьләрен яклаган көчләргә бирү кирәклеген яхшы аңлый. Шуның өчен дә Февраль буржуаз-демократик революциясеннән соң Галимҗан Ибраһимов революцион эшкә чума һәм тиздән үзен хезмәт ияләре мәнфәгатьләрен актив яклаучы зур абруйлы политик эшлекле итеп таныта. Аны Бөтенроссия Учредительное собраниесенә член итеп сайлыйлар.

Билгеле булганча, үз заманында патша самодержавиесенә каршы көрәштә барлыкка килгән, асылы белән буржуаз-демократик эчтәлекле бу политик оешма, Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң контрреволюцион көчләр тарафыннан совет властена каршы көрәштә файдаланылды. Купчелеге уңнардан торган Учредительное собрание 1918 елның январь башында Петербургта җыелып, Совет хөкүмәтен һәм аның киң халык массалары мәнфәгатьләрен чагылдырган декретларын танымады, тарих тәгәрмәчен кирегә әйләндерергә азапланды. Шуның өчен дә В. И. Ленин аларны «теге дөньядан килгән кешеләр» дип атады.

Нәтиҗәдә, большевиклар һәм алар яклы политик көчләр бу контрреволюция оясын ташлап чыгалар. Алар арасында Галимҗан Ибраһимов та була. Ул шушы адымы

белән Учредительное собраниедә «мөселман социалистик фракциясе» дигән исемдә оешкан группаның бердәмлеген боза. Чөнки бу төркемнең күпчелеге фактта совет-ка каршы көчләр ягында булалар. Г. Ибраһимовның бу адымында аның күптән формалашкан карашы чагыла. Чөнки төрле буржуаз-милләтче оешмаларга, аларның матбугатына каршы ул моңа кадәр дә сыйнфый позициядә торган революционер буларак көрәшеп килде. «Милли бердәмлеккә» өндәгән милләтчеләрнең үз сыйнфый өстенлекләрен шул юл белән саклап калырга маташулары аңа күптән ачык иде инде.

Мөселман фракциясенең сул канаты Учредительное собраниене большевиклар белән бергә ташлап чыгуы В. И. Ленинның да игътибарын җәлеп иткән. Һәм ул аны контрреволюцион көчләрнең мөселман хезмәт ияләре арасында да йогынтысы кими баруын күрсәткән бер факт дип бәяли. Петроградка Бөтенроссия Учредительное собраниесенә кичегебрәк килгән күренекле революционер М. Вахитов һәм Ш. Манатов Г. Ибраһимовның бу адымын хуплыйлар, аны дөрес дип табалар.

Учредительное Собраниенең күпчелеген тәшкил иткән уң канат тоткан юл илдә политик һәм идеологик көрәшнең шактый кискенләшүенә китерде, хезмәт ияләре, шул исәптән элек изелгән халыклар эшче-крестьяннары арасында политик-агарту һәм бигрәк тә революцион үзгәртеп кору эшләрен тагын да киңрәк җәелдерүне таләп итте. Партиянең ленинчыл милли политикасын, аерым алганда совет хөкүмәтенең В. И. Ленин имзасы белән чыккан «Россия халыкларының хокуклары декларациясе», «Россия һәм Көнчыгыш мөселман хезмәт ияләренә!» мөрәҗәгатьләрендә күрсәтелгән милләтләрнең үзбилгеләнү хокукларын тормышка ашыруны тизләтергә кирәк булды. Менә шушы юлда заман таләпләреннән чыгып, бер яктан, үз халкының ихтыяҗларын тирән белгән, аның алдында абруй казанган, икенче яктан, партия политикасын эзлекле тормышка ашыра ала торган яңа милли совет органнары кирәклеге көн тәртибенә килеп басты. Алар «Милли Комиссариатлар» дип аталдылар һәм, 1918 ел башында оештырыла башлап, Милләтләр эше буенча Халык Комиссариатлары янында формалаштылар.

Татарлар һәм башка төрки халыклар арасында совет милли политикасын тормышка ашырырдай махсус милли комиссариат төзү эшенә Г. Ибраһимов беренчеләрдән булып алынды. Учредительное Собраниене ташлап чыкканнан соң ук ул Милләтләр эше буенча Халык Комиссары И. В. Сталин янында була һәм үз фикеренә яклау таба. 1918 елның январенда Учредительное собрание мөселман фракциясенең сул канатын тәшкил иткән М. Вахитов, Ш. Манатовлар башта И. В. Сталин тарафыннан кабул ителәләр, ә аннан соң аларны В. И. Ленин белән әңгәмәгә чакыралар. В. И. Ленин Идел һәм Урал төбәкләрендәге милли-азатлык хәрәкәте турында җентекләп сораша, буржуаз милләтчеләрнең тактикасы белән кызыксына, Учредительное собраниенең совет власте яклы депутатларына Үзәк Мөселман учреждениесе оештырып, мөселман халыкларына кагылышлы декретлар хәзерләргә киңәш итә. Ягъни алар алдында совет дәүләтенең политикасын, мөселман халыкларының милли үзенчәлекләрен исәпкә алып, тормышка ашыру бурычы куела. Бу зур бурыч, үз гомерләрен революция эшенә багышлаган М. Вахитов, Г. Ибраһимов һәм Ш. Манатов тарафыннан зур күтәренкелек белән кабул ителә.

1918 елның 17 январенда В. И. Ленин декреты белән «Эчке Россия мөселман эшләре Комиссариаты» оештырыла, соңрак ул «Үзәк Мөселман Комиссариаты», «Үзәк Татар-Башкорт комиссариаты» дип тә йөртелә. Аның комиссары итеп күренекле татар революционеры М. Вахитов, урынбасарлары итеп Г. Ибраһимов һәм Ш. Манатов билгеләнәләр. Яңа совет органы алдына бик күп мәсьәләләр килеп баса. Иң беренчесе — ул нинди конкрет эш алып барырга тиеш? Нинди юллар белән? Ул үзәктәге һәм урыннардагы партия һәм совет органнары белән ничек хезмәттәшлек итәргә тиеш? Яңа органның структурасы ничек булырга тиеш?

Бу мәсьәләләрне чишү дөньяда беренче мәртәбә барлыкка килгән эшчеләр диктатурасының мондый үзенчәлекле органнары җитәкчеләреннән иҗади һәм тәвәккәл эш таләп итте. Бу эштә Г. Ибраһимов М. Вахитовның иң якын көрәштәше булды, алар барлык мәсьәләләрне дә киңәшеп хәл иттеләр. Кайбер мәсьәләләр буенча фикер башкалыклары булса да, төп максатлар бер булгач, ахыр чиктә уртак фикергә килә алдылар.

Комиссар М. Вахитовның урынбасары буларак Г. Ибраһимов барлык бүлекләр эшенә дә игътибар бирә. Комиссариатның органы «Чулпан» газетасының беренче редакторы сыйфатында ул һәр бүлекнең эше анда тулы чагылыш табуын кайгырта. Моннан тыш Г. Ибраһимов Комиссариат составындагы җир эшләре бүлегенең дә җитәкчесе була. Бу уңайдан, ирексездән сорау туа: ни өчен соң киң җәмәгатьчелеккә күренекле әдип, педагог һәм журналист буларак билгеле булган Г. Ибраһимовка — матбугат, мәгариф эшләре һәм культура-агарту бүлекләрен җитәкләү тапшырылмыйча, аның төп шөгыленнән шактый ерак торган эш — җир эшләре бүлеген җитәкләү йөкләнгән? Һәм ни, өчен язучы моңа риза булган? Бу мәсьәлә шактый уйлануларны, шул ук вакытта ул заман проблемаларын тирәнрәк аңлауны таләп итә.

Россия халкының күпчелеген тәшкил иткән, гасырлар буе ачлыктан-ялангачлыктан җәфа чигеп килгән крестьяннар үз тормыш хәлләрен яхшыртуны җир мәсьәләсе белән бәйләп килделәр. Патша нярченнәрә алпавытлар, чиркәү кулында тупланган, гади халык кулы һәм тире белән эшкәртелә торган җирне крестьяннар арасында гадел итеп бүлү — аларның күптәнге хыялы иде. Илнең милли районнарында бу мәсьәләнең тагын бер үзенчәлеге бар иде. Патша самодержавиесе тарафыннан изелгән рус булмаган халыклар крестьяннарында бу хәл аларда милли азатлыкка омтылыш белән дә бәйләнгән иде. Шуның өчен дә В. И. Ленин Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр үк милли мәсьәләне хәл итү асылда аграр мәсьәләне хәл итүдән тора дип күрсәтеп үтте.

Дөрес, крестьяннар ачлыктан, сыйнфый изелүдән чыгу юлларын башта бик ачык күз алларына китерә алмадылар. Җирне халык арасында тигезләп бүлү, алар уенча, сыйнфый изелүдән дә, ачлык-ялангачлыктан да коткарырга тиеш иде. Тик коллектив хуҗалык нигезендә генә мул тормышка чыгарга мөмкинлеген ул чакта авыл халкы әле аңлар дәрәҗәдә түгел иде. Безнең уебызча, Г. Ибраһимовны җир бүлеге комиссары итеп билгеләү, аның авторитетын һәм энергиясен бу катлаулы, шул ук вакытта социаль-политик һәм милли яктан гаять мөһим революцион проблеманы чишү юлында файдалану булырга тиеш.

Чыннан да, Г. Ибраһимов аграр мәсьәләгә инде күптән игътибар бирен килде. Һәм крестьяннар арасында бу өлкәдә дә шактый зур авторитет казанган дип әйтә алабыз. Бу уңайдан аның Учредительное Собраниегә «авыл халкы списогы» белән сайлануын һәм Уфа губернасы Стәрлетамак өязе крестьяннарының гомуми җыелышы тарафыннан тәкъдим ителүен дә әйтергә кирәк. Икенче яктан, Г. Ибраһимовның бу вазифаны башкаруы Совет власте ягына сул эсерларны да тартырга мөмкинлек бирде. Бу мәсьәлә буенча да Г. Ибраһимовның җир бүлегендә эшләве политик яктан бик урынлы иде.

Социалистик җәмгыять төзү эше авыр һәм катлаулы сыйнфый көрәш шартларында барды.

Эшче-крестьян һәм киң халык массаларының аңын үстерү, алар алдында буржуаз-милләтчеләрнең чын йөзен ачып салуны Г. Ибраһимов үзенең төп бурычларыннан берсе итеп карады. Аның инициативасы белән чыккан татар телендәге беренче совет газетасы «Чулпан» совет хөкүмәтенең милли политикасын эзлекле яктыртты, буржуаз милләтчеләрнең һәртөрле уйдырмаларын фаш итте.

1918 елның январь аенда, «Чулпан» газетасының беренче санында ук Г. Ибраһимов Үзәк Мөселман Комиссариатының территориаль автономия нигезендә милли дәүләт төзү юлында эш алып барачагын язып чыккан иде. «Федерация, туфраклы мохтарият һәм шуралар хакимияте» дигән баш астында «Чулпан» (24 январь, 1918) газетасында басылган мәкаләсендә Г. Ибраһимов Советларның III съездында кабул ителгән милли политикага кагылышлы документларны җентекләп аңлата, буржуазиянең үзбилгеләнү хокукын бозып күрсәтүен һәм аның бу политиканы үз мәнфәгатьләрендә генә файдаланырга омтылуын яза. Шушы Идел һәм Урал территориясендә советлар платформасында милли республика төзү мөмкинлеген әйтә. Бу мәсьәлә газетада дөнья күргән башка мәкаләләрдә дә алга сөрелә.

Нәкъ менә шушы вакытларда ук Г. Ибраһимов инициативасы белән һәм аның актив катнашында беренче совет автономиясе проекты өстендә эш башланган булса кирәк. Һәрхәлдә, «Чулпан»да басылган мәкаләләр әнә шундый нәтиҗәгә килергә мөмкинлек бирәләр.

1918 елның 23 һәм 24 мартында бөтен үзәк газеталарда Милләтләр эше буенча халык Комиссариаты тарафыннан әзерләнгән «Татар-Башкорт Совет республикасы» турында декрет басылып чыга. Үзәк газеталарның шул ук саннарында бу мәсьәлә хакында Милләтләр эше буенча Халык комиссары И. В. Сталин мәкаләсе дә дөнья күрә. Анда яңа оештырылачак республика турындагы «Положение»нең татар һәм башкорт революцион массалары теләге белән Советларның III Бөтенроссия съезды карарлары нигезендә Халык Комиссарлары Советы ризалыгы белән төзелүе һәм аның иң авторитетлы «татар һәм башкорт совет оешмалары тарафыннан» эшләнүе күрсәтелә. Декретка кул куючы җитәкчеләр арасында Г. Ибраһимов имзасы да бар.

Совет автономиясе проектын пропагандалауга Г. Ибраһимов бөтен көчен бирә: аның турында мәкаләләр яза, конференцияләрдә һәм митингларда чыгыш ясый, оештыру эшләрендә дә актив катнаша. Г. Ибраһимов бу эшне «бөек бәйрәм» дип атый. «Чөнки,— дип яза ул «Чулпан» газетасында дөнья күргән бер мәкаләсендә,— халкыбызның федерация, туфраклы мохтарият һәм аерым җөмһүрият хакында күңеленең тирән җирендә сакланган бөек өмете юлында олуг, бик олуг бер адым атланды». «Ләкин,— дип дәвам итә мәкалә авторы,— бу ышанычлар тик совет власте булганда гына тор-

мышка ашырга мөмкин, шуның өчен дә һәр революционерның изге бурычы — совет хакимиятен, халыклар туганлыгын урнаштыручы властьны ныгыту». Мәкаләдә буржуаз милләтчеләрнең мәкерле планнары, патша һәм вакытлы буржуаз хөкүмәтнең рус булмаган милләтләргә карата тоткан юллары фаш ителә. Совет автономиясендә хакимият тик эшче-крестьян кулында булырга тиешлеген, буржуаз милләтчеләрнең дәүләт мәсьәләсендә тик үз сыйнфый мәнфәгатьләрен генә кайгыртулары турында бөек язучы кат-кат басым ясый. «Хәзер юл ачык,— дип дәвам итә Г. Ибраһимов.— Татар, башкорт һәм рус буржуазиясе бер якка ыргытылсын... матур азат җөмһүриятебезне төзү эшен татар һәм башкорт революционерлары, татар һәм башкорт эшче һәм ярлы халкы башка милләт демократиясе белән кулга-кул бирешеп үз җаваплылыкларына алсыннар».

Шулай итеп, Г. Ибраһимов милли дәүләтчелек мәсьәләсен партия куйганча, сыйнфый позициядә торып аңлата, аңа пролетар интернационализм күзлегеннән карый. Бу фәнни метод аңа милли өлкәдәге шактый четерекле мәсьәләләрне дә уңышлы чишәргә ярдәм итә.

Мәгълүм булганча, совет властеның беренче елларында Идел һәм Урал шәһәрләренең күбесендә җирле советлар янында татар-башкорт комиссариатлары (бүлекләре) төзелде. «Мөселман комиссариаты» исеме астында төзелгәннәре дә асылда шул регионддагы татар һәм башкорт халыклары арасында эш алып бардылар.

Уфа шәһәрендә эш башкачарак тора. Монда губерна халык комиссариаты янында бу ике халык арасында совет эше алып бару өчен ике милли комиссариат — «Башкорт комиссариаты» һәм «Мөселман комиссариаты» төзелә. Эш барышында килеп туган кайбер аңлашылмаучылыклар 1918 елның 20 апрелендә Мәскәүдә Мулланур Вахитов җитәкчелегендә Үзәк Татар-Башкорт комиссариаты коллегиясе утырышында махсус тикшерелә. Мәсьәләне чишү өчен коллегия зур вәкаләтләр белән Уфага Г. Ибраһимовны җибәрергә карар бирә.

Үзенең беренче адымнарын ул монда хезмәт ияләре белән аралашудан башлый. 1918 елның 28 апрелендә Г. Ибраһимов Уфада татар һәм башкорт эшчеләре алдында доклад ясый. Аның дәлилле, ышандырырлык чыгышы эшчеләргә хуш килә. Алар бертавыштан Үзәк Татар-Башкорт комиссариатына ышаныч белдерәләр, беренче совет автономиясе проектын хуп күреп, илне эчке һәм тышкы дошманнардан саклау өчен татар-башкорт хәрби частьлары оештырырга кирәк дип табалар. Икенче көнне Г. Ибраһимов татар һәм башкорт совет оешмалары вәкилләре җыелышында рәислек итә. Г. Ибраһимов үзенең чыгышында Мәскәүдә Мөселман эшләре Комиссариатының Үзәк Татар-Башкорт Комиссариатына үзгәртеп корылуын һәм урыннарда да шул юнәлештә эш баруын сөйли. Нәтиҗәдә аңлашылмаган мәсьәләләр ачыклана, сорауларга тиешле җаваплар алына. Бердәм совет оешмаларында кулга-кул тотынып, совет властен ныгыту юлында яңа эшләр башларга мөмкинлек туа.

Дөрес, совет автономиясе мәсьәләсен чишү соңрак башкачарак формалар алды. Бу мәсьәләне җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә Идел һәм Урал буенда яшәгән һәр рус булмаган халык өчен аерым совет автономиясе төзү кирәклеге ачыклана. Һәм шуның нигезендә гражданнар сугышы барышында 1919 елның март аенда Башкортстан АССР, ә 1920 елны Татарстан АССР төзелә. Татар һәм башка халыкларның совет властe нигезендә төзелгән милли республикалары барлыкка килүе һәм бу юлда күп кенә мәсьәләләрнең чагыштырмача тиз һәм уңышлы чишелүе, һичшиксез, беренче совет автономиясе проекты булган «Татар-Башкорт Совет Республикасы» турындагы положениене бөтенхалык белән һәрьяклап тикшерү, фикер алышу нәтиҗәсе дип тә әйтә алабыз. Бу юлда Үзәк Мөселман Комиссариатының башка эшлеклеләре белән беррәттән Г. Ибраһимовның да хезмәтләре, тырышулары бушка китмәде. Алар күпмилләтле Совет Социалистик Республикалар Союзы төзү эшенә үз өлешләрен керттеләр. Илебездә социализм төзү һәм СССР халыкларының дуслыгын ныгытуга Галимҗан Ибраһимов бөтен көчен, сәләтен бирде. Дәүләт эшлеклесе буларак та, әдип һәм журналист, педагог һәм галим буларак та — кайда гына һәм кайсы өлкәдә генә эшләсә дә, ул пролетар интернационализм, халыклар дуслыгы байрагын югары тотты.

Равил Кукушкин

# ГОМЕР КИТАБЫНЫҢ БИТЛӘРЕ...

ШАГЫЙРЬ РОБЕРТ ӘХМӘТҖАНОВНЫҢ ИҖАТ ПОРТРЕТЫ

Поэзия сөючеләрне үзенең оригиналь һәм талантлы әсәрләре белән сөендереп килгән, аларның тирән ихтирамын яулаган шагыйрьнең иҗаты әле лаеклы бәясен алды дип әйтеп булмый. Өч дистә елдан узган иҗат гомерендә берсеннән-берсе үзенчәлеклерәк дистә ярым китабын бүләк иткән авторга багышланып матбугат битләрендә нибары унлап мәкалә басылу (аларның да теге яки бу җыентыгы чыгу уңае белән язылган 2—5 битлек мәкалә-рецензияләрдән узмавы) әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләренең активлыгы турында сөйләми... Шагыйрь иҗатының бай, катлаулы булуы һәм шактый гына каршылыкларны үз эченә алуы да, әлбәттә, биредә билгеле бер роль уйнамый калмагандыр. Ни генә булмасын, без, замандашлары, үзебезнең талантлы бу каләмдәшебез алдында зур бурычлыбыз. Укучыларына гына түгел, авторның үзенә дә җанлы тәнкыйть һәм ярату сүзен ишеттерү — бүген барыбызның да уртак шатлыгы була алмыймыни?!

Роберт Әхмәтҗанов шигърияткә үзенең «Егерменче яз» (1958) китабы — эчкерсез яшьлек, якты өмет, ашкынулы хисләре белән, һәрбер сулышы ялкынга, һәрбер сүзе образлы шигъри фикергә күчәргә әзер торган романтик рухлы кыю шагыйрь булып килеп керде. Шунысын да әйтик, беренче мөстәкыйль җыентыгында ук авторның гражданин буларак та, шигъри сүз осталыгы ягыннан да шактый өлгергәнлеге күзгә ташлана. Инде моннан соң бер-бер артлы тезелеп киткән китаплары: «Гасырлар юлы» (1960), «Синең кояшың» (1962), «Йолдызстан» (1964), «Кызыл усаклар» (1966), «Еллар яна» (1968), «Сәгать суга» (1970), «Идел-йорт» (1972), «Таң шәһәре» (1974), «Олы юлның җилләре» (1976), «Сабыйлар хоры» (1979), «Хәтер елгасы» (1980), шулай ук рус телендә чыккан «Страна июнь» (1976) җыентыгы рецензентларның бик хаклы билгеләп үтүенчә, исемнәре белән үк үзенчәлекле бер шигъри дөнья барлыкка китерәләр.

Алар шагыйрь иҗатының үсеш сызыкларын билгеләгәндә төп ориентир хезмәтен үтиләр. Дөрес, бу китапларның идея-эстетик кыйммәтен бүген бер дәрәҗәгә куеп булмый. Әйтик, фикер һәм хис тыгызлыгы, поэтик накалның соң чиккәчә киеренкелеге, тематик колачы белән «Кызыл усаклар», «Еллар яна» һәм «Идел-йорт» китаплары шагыйрь иҗатында аерым урын тота. Шигырьләре белән генә түгел, аларның укучыга сайлап тәкъдим ителүе, авторның үз-үзенә куйган таләбе белән дә... Хәер, ничек кенә кабул ителмәсеннәр, гомум «Гомер китабы»ның аерым сәхифәләре була-

---

РАВИЛ КУКУШКИН — *тәнкыйтьче, филология фәннәре кандидаты. «Шигъри бишек», «Канатлы дөнья» исемле китаплар авторы. 1949 елда туган. Казанда яши.*

рак, өстәвенә, шагыйрьнең иҗат йөзен, үсеш юлын тулы чагылдырган «сайланма»сы юклыктан, безнең кулдагы әлеге җыентыклары бүген төп чыганак хезмәтен үти.

Роберт Әхмәтҗанов поэзиягә аяк баскан чор — илленче еллар уртасы — мәгълүм булганча, илебездәге экономик һәм политик тормышның, рухи яшәешнең яңа борылыш-үзгәрешләр кичерүе, яңа казанышларга ирешүе белән характерлы. Сугыш дәһшәтен генә түгел, илдәге зур җимерекләкне һәм рухи тормыш кыенлыкларын да тиз арада җиңеп чыга алган каһарман совет халкы яңа чор — фәнни-техник революция чорына аяк басты. Гигант электростанцияләр кору, атом энергиясен эшкә җигү, яшьләрнең зур күтәренкелек белән чирәм җирләрне үзләштерүе, ватандашларыбызның дөньяда беренче булып галәм киңлекләренә үтеп керүе — болар барысы да яшь буынның үз күз алдында, үз күңел кичерешләре булып җанлы яшәеш тапкан тормыш яңалыклары иде... Авыр сугыш елларында ятимлекнең бар әчесен үз җилкәсендә татып үскән малайлар-кызлар, күңел яраларын эчкә яшереп, ВУЗ ишекләрен ачып керделәр, комбайн-трактор, самолет-корабль штурваллары артына бастылар.

Әлеге чорның ашкынулы җиле, табигый ки, поэзиябезгә дә килеп керде.

Роберт Әхмәтҗановның шигъри әсәрләре тематик яктан бай һәм күп төрле. Әмма шагыйрьнең кайта-кайта мөрәҗәгать иткән даими темалары да юк түгел. Шундый «хикмәтле» темаларның берсе — табигать. Автор иҗатында өч шигырьнең берсе турыдан-туры табигать күренешләрен тасвирлауга багышланган.

*Таралды инде болытлар,*
*аязды һавалар.*
*Иделдә зәңгәр дулкыннар*
*ярларга кагалар;*
*«Саумы, кояш,*
*саумы, иртә,*
*исәнме!» — диләр...*

(«Саумы кояш!»)

Табигать күренешләренең болай җанлану, «кешеләшү» хасияте Р. Әхмәтҗанов шигырьләренең аерылмас бер үзлеге: аның тирәкләре «күтәрелгән кошлар артыннан зәңгәр биеклеккә җилпенә» һәм алар, сары кошлар төсле тезелеп, озын юлга чыга. Балачак кышының уйнак өермәсе муйнак булып чабудан каба («Балачак кышы»). Җил, йомышчы малай сыман, капкадан-капкага шакып йөри («Туу хәбәре»), я булмаса, җыр китабы итеп, тополь яфракларын актара («Без — топольләр»). Кызыл яфраклар, кызыл листовкалар кебек, материктан материкка йөгерә... («Кызыл яфраклар дөрлиләр...»)

Икенче яктан, табигать Р. Әхмәтҗанов өчен тематик язу объекты гына да түгел. Аңардан шагыйрь башка темаларны ачуда төп җирлек, фон, шигъри бер алым буларак та иркен файдалана. Туган авылы турында язамы ул, әти-әнисе яки якташлары — игенчеләр тормышын тасвир итәме, балачагын искә төшерәме, мәхәббәте яисә яшәү мәгънәсе хакында сүз алып барамы — янәшәдә һәрвакыт табигать! «Чиста табигать шигырьләре»ндәгечә тоташ ачылмыйча, өзек-өзек «ялтырап» китсә дә, геройның эчке халәтен, холыкфигылен, фикерләү үзенчәлеген предметлаштыру-сынландыруда ул авторның ышанычлы, сыналган ярдәмчесе. Димәк, Р. Әхмәтҗанов әсәрләренең икенче бер өлешендә без, киресенчә, Кеше — Табигать берлеге, аларның органик бөтенлеге белән очрашабыз.

*Үкенгәндәй, иске ярын ташлап,*
*Куке үкси якын урманда...*

(«Мирәт куаклары...»)

Шул рәвешчә, Роберт Әхмәтҗановның бер генә әсәре дә дип әйтерлек,

табигатьне читләтеп үтми. Бер ишләрендә ул төп тематик тасвир объекты булса, икенчеләрендә кешенең рухи дөньясын ачуга ярдәм итә.

Яшьлек һәм мәхәббәт темалары да Р. Әхмәтҗанов иҗатының үзәгендә ята. Дөрес, турыдан-туры кешенең үзенә караганлыктан, аның үз күңел хасиятен чагылдырганлыктан, алар тышкы тема булып күзгә артык бәрелеп тормый, күбрәк эчке тема рәвешендә, әсәрләрнең психологик үстерелеше сыман кабул ителә. Әмма ни генә булмасын, шагыйрь иҗатында алар шулай ук төп урынны алып тора. Яшьлек һәм мәхәббәтнең күп төрле чагылыш-төсмерләре каршы ала безне биредә. Ә инде «яшьлек» һәм «мәхәббәт» төшенчәләренә киңрәк фәлсәфи мәгънә салып күзаллыйбыз икән, ул чакта бу темалар, табигать темасы кебек үк, авторның бөтен шигырьләренә дә үтеп керә һәм аларның эчке психологик-фәлсәфи яңгырашына әверелә.

Шагыйрьнең иҗатын берләштереп, бер бөтен итеп торган өченче үлчәм дә бар. Ул — Кеше мәхәббәте! Вакыт-пространствоның чиксез арасын гына түгел, үзенең һәм кешелекнең сөю-нәфрәте кебек көч-каршылыкларны да йөрәгендә төйнәп торган кеше мәхәббәте. Егерменче гасырның 60—80 елларында яшәүче лирик герой мәхәббәте! Бу хис тәрәз төбендәге гөлдән алып ерак галактикаларгача сузылган арада яшәеш тапкан Табигать — Кеше берлеген дә, томан-караңгылык эчләренә, билгесезлеккә кереп югалган Үткән белән Киләчәкнең уртаклыгын да эчке яктан яктыртып, нурландырып, җылытып тора. Кеше яшәешенең мәгънә тирәнлеген, кеше күңелендәге яктылык һәм җылылык нурының көчен күрсәткән бу берәмлек шигърият дөньясының да иң мөһим үлчәмнәренең берсенә әверелә. Шулай итеп, шагыйрь иҗатында без табигать — кешелек дөньясының бөтен чорларына да уртак булган, аларны үзендә берләштереп торган Вөҗдан, Хаклык, Кешелеклелек, Намус, Яшәү максаты темаларына — яшәүнең үлемсезлеген яктырткан зур темаларга килеп чыгабыз.

Роберт Әхмәтҗановның сәнгатьле фикерләү үзенчәлеге бөтен тулылыгы белән шигъри образлар дөньясында ачылып китә. Образлылык — чынбарлыкны сәнгатьле-шартлы күрү хасияте — гомумән, Р. Әхмәтҗанов иҗатының иң көчле һәм иң үзенчәлекле якларыннан берсе. Иҗатының башында ук шагыйрь поэзиясенең пафослы сөйләп чыгу булмыйча, аның иң элек сәнгать әсәре икәнлеген, хис-фикернең образлы шартлылык призмасы аша үтеп кенә эстетик тәэсир итү көче алуын, шигъри канатлануын яхшы аңлый. Үзалдына ул шундый зур таләпләр куеп эш итә. Мәгълүм булганча, сугыш вакыты һәм сугыштан соңгы еллар татар поэзиясендә образлы фикерләүнең әһәмиятен исәпкә алып бетермәү, еш кына фикер-хис, идеяне коры декларатив сөйләп чыгу белән канәгатьләнү шактый киң урын алды. Күп кенә авторлар шушы такмаклап язу чиреннән арына алмый йөргән бер вакытта, яшь шагыйрь Р. Әхмәтҗановның беренче шигырьләрендә үк диярлек образлы фикерләүгә кыю омтылыш ясавы әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә тиз тартты. Поэзиябездә талантлы шагыйрь килүе шигырь сөючеләр тарафыннан зур сөенеч белән каршы алынды.

Роберт Әхмәтҗанов — шигъри әсәрләрендә дә, тормышта да гаять нечкә күңелле шагыйрь. Изоляцияләнмәгән электр чыбыгы кебек һәм җиңелчә генә җил кагылганда да дөрләп кабынып киткән ут сыман, ул, тормышның һәрбер кечкенә генә җитешсез, каршылыклы, нәфрәтләндергеч якларын да күңеленә якын ала һәм аңа кискен реакция белән җавап бирергә әзер тора. Күңел кылларының нечкәлеге, һәрвакыт ачык һәм эмоциональ киеренке хәлдә торуы, әлбәттә, шагыйрь кеше өчен бер дә гаҗәп түгел. Киресенчә, бу аның табигый халәте, ул гына да түгел, бу аның гадәти эшләү халәте. Шул нечкә күңел сизгечләре һәм сизгер күңел кыллары ярдәмендә бит инде ул яшәештәге тәэсирләрен, җан тирбәлешләрен шигъри юлларга күчерә, шулар ярдәмендә үзенең укучысы күңеленә дә үтеп керә.

Башлыча лирик шагыйрь, хис-эмоция, метафора шагыйрьне булуга карамастан, Р. Әхмәтҗанов поэтик образларның, хис-акыл эшчәнлегенең күп төрле мөмкинлекләренә мөрәҗәгать итә. Шуларның берсе — һичшиксез, ло-

гик образлар. Алардан автор башлыча кеше халәтенең каршылыклы үсешен атап тасвирлаганда файдалана:

*Өйдән чыктым «олы кеше» булып,*
*Сабыйларча инде сагынам.*

(«Өйдән чыктым...»)

Берәр логик фикерне арттыру, кечерәйтү яисә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләренең шартлы үзгәртелүенә таянып та шигъри чишелеш барлыкка килә:

*Кояш нурын син мул итеп*
*эчеп үскән,*
*ләззәтеннән күзкәйләрең*
*кысыла төшкән.*

(«Казах кызы»)

Шунысы гаҗәп, бу «шигъри ялганга» — күзләрнең ләззәттән кысылуына — без теләп ышанабыз, әлеге шартлы уенга кушылу безгә эстетик ләззәт бирә... «Гаяз солдат» шигырендә әнә герой сугышны тәмамлап, фронттан туган авылына кайтып төшә:

*Исән кайтты. Аны әле*
*нинди шатлыгы көтә!..*
*Тик карчыкны ике куллап*
*кочаклауга ни җитә?!*

Инде бу халәт каршылыгы алга таба тирәнәя — предметлаша.

*Коймаларны сыйпап үтте*
*татлы каушуның җиле.*
*Араларда Карпат түгел,*
*тәрәзә генә инде...*

Бу конкрет контрастлыкны инде теләсә кем түгел, ераклык-якынлык, үлем-яшәү кебек төшенчәләрне җаны аша уздырган, ярты Европаны җәяүләп сугышып үткән солдат күңеле генә барлыкка китерә ала. Логик образның көче дә шунда — халәт мизгелләрен, күңел хәрәкәтен ул каршылыклары белән тотып алып, бер бөтенгә әверелдереп, үстерү мөмкинлеге бирә.

Логик образ тышкы яктан гади сөйләмне генә хәтерләтсә дә, оста художник кулында кинәт тылсымлы гомумиләштерү-символлаштыру хасияте ала: образны күп сыйдырышлы итә, тирәнәйтә. Шагыйрьнең публицистик кайнарлык белән турыдан-туры белдергән сүзләренә дә сәнгатьле бер канат куя:

*Иң беренче булып сәгать керде,*
*Вакыт керде безнең бусагадан.*
*Телен бордык. Сәгать йөреп китте*
*Үз исәбен башлап өр-яңадан.*

Бу инде коры логик сөйләм — информация генә түгел. Биредә реальлек һәм шартлылык икесе бер бөтен. Шуңа да авторның әйтер сүзе турысызыклы булып түгел — ә конкрет, сизгер һәм гомумиләшеп яңгырый. Алдагы шигъри фикер очышында ул трамплин хезмәтен үти:

*Ике угың, ике гашыйк сыман,*
*берсен-берсе һаман табышып торсын,*
*сәгать саен бергә кавышып торсын;*
*ике угың икесе бер-бер артлы*
*бәхет ягына һаман авышып торсын!*

(«Иң беренче булып сәгать керде...»)

Шагыйрьнең күзе үткен, күңеле сизгер. Шуңа да логик образлар белән беррәттән шигырьләргә әледән-әле картиналы халәт образларының килеп керүе бер дә гаҗәп түгел. Р. Әхмәтҗанов бигрәк тә табигать күренешләрен тасвирлаганда үзен иркен хис итә; аларның сизелер-сизелмәс үзгәрешенә, кечкенә бер ишарәсенә дә шигъри җаны белән җавап бирергә омтыла. Нәтиҗәдә, табигать дөньясының, шагыйрь күңеленең җанлы бер кисәге, мизгеле булып сиземле конкрет детальләрне үз эченә алган шигъри картина барлыкка килә:

*Шундый тонык: өстән яфрак йөзә,*
*төптән бара аның шәүләсе...*
*Юл буена шулай биетеп бара*
*наратларның зифа гәүдәсен.*

(«Сигулда усаклары»)

Табигать, шул рәвешчә, үзеннән-үзе җанлана, хәрәкәткә килә; лирик геройның эчке халәт нюанслары дулкыннарга кушылып тирбәлә башлый; күңел түренә кагылып, бер-бер артлы ассоциатив тойгыларны уятырга керешә. Әлеге шигъри юлларда барыннан да бигрәк геройның халәт тирбәлешләре чагылыш таба:

*Җилгә йотылып капшый күңел*
*Туган якның зәңгәр урләрен.*

(«Мирәт куаклары»)

Мизгел-тойгы халәтен генә түгел, абстракт фикер йөртү, уйлануларның реаль-предметлы сурәтен гәүдәләндерергә кирәк булганда да шагыйрь картиналы образларга таяна. Алар әсәрнең эчке «потенциаль көчен» хасил итә.

*Гадел кешелек бүркен салып керә*
*Ильич турындагы уйларга.*

(«Ленин»)

Ә инде метафоралы, чагыштырулы образлар иҗат итүгә килсәк, алар Р. Әхмәтҗановның үз стихиясе. Тәнкыйть мәкаләләрендә аның «метафора» сүзен еш телгә алуы очраклы түгел. Лирик шагыйрь буларак, ул әлеге чараны бөтен тулылыгы белән эшкә җигә. Бу яктан безнең татар поэзиясендә Роберт Әхмәтҗанов белән тиңләшерлек икенче бер шагыйрьне табып булыр идеме икән?! Метафора аның төп шигъри җегәре, хис-фикер канаты, аның иҗат горурлыгы. Шагыйрьнең әсәрләре башлыча әнә шундый образлар «эскадрильясеннән» тора да.

Роберт Әхмәтҗанов әсәрләрендә без йөзләрчә чагыштырулар трансформациясе аша үтәбез: биредә болыт түтәлендә карлар чәчәкләнә («Юк, фанатиклар түгел без...»), Идел өстендә офык сызыгына эленеп акчарлаклар җилферди, ак күбеккә батып ап-ак атлар кешнәп чаба («Иртәдән җил...»), таулар артында җиргә тияр-тимәс, сары яфрак сыман тирбәлеп, кыска җәен эзләп җәйге болыннарның җаны җәяүле күбәләк оча («Җәяүле күбәләк»), диңгез буендагы җылы җилдә кышның ак очкыны — кар бөртеге сүнә («Диңгез ритмнары»), дулкыннар ак эт сыман аякка сарыла («Без — топольләр»).

Күпчелек очракта кеше яшәеше әлеге чагыштыруларда турыдан-туры үзе үк катнаша. Һәрбер образның нигезендә кеше психологиясе ята. Шуңа да бит әнә егетнең сөйгәне аяк астына күпернең ксилофондай җырлап керүе («Таш йортлар»), гашыйклар йортында бүрәнәләрнең яфрак яруы («Бер тәрәзәләр...»), ничек кенә хыялый булса да, безне ышандыра. Шуңа күрә лирик геройның яраткан кешесеннән башка күңелен караңгы, салкын йортка тиңләве (рухи халәтен предметлаштырып күрүе) бер дә гаҗәп тоелмый:

*Син кер анда. Калдыр бусагада*
*икеләнү тулы уйларны.*
*Син кер анда. Ут ал күзләремә,*
*үз,*
*тәртипкә китер дөньямны.*

(«Каеннарны үт тә...»)

Инде хәзер Роберт Әхмәтҗанов иҗаты тудырган шигъри дөньяның таҗы — Кешегә тагын да якынрак килеп карыйк. Шагыйрьнең кешегә булган мөнәсәбәте, аның эчке дөньясына үтеп керү рәвеше, аны аңлау, ярату дәрәҗәсе, геройларның психологик хасиятләрен чагылдыру үзенчәлекләре белән ныклабрак танышыйк.

Роберт Әхмәтҗанов әсәрләрендә Кешенең (лирик героймы ул, әллә бер хикәяләү сюжетының героемы — барыбер) нигездә өч төрле чагылышы күренеп тора.

Беренче төргә авторның «без», «алар» дип күмәклек исеменнән тасвир ителгән әсәрләрен кертеп карыйбыз. Шагыйрьнең укучыларга яхшы мәгълүм «Солдатлар»ын гына искә төшерик: сүз бирелә балалар һәм аналар хакында бара. «Өч йөз мең һәм бер» шигырендә дә автор әсәргә Хиросима, Нагасаки корбаннарының уртак тавышын лейтмотив итеп ала: «Бу без — өч йөз мең!..»

Шулай итеп, әсәрләргә билгеле бер группа, профессия, коллектив, җәмгыять, чор һ. б. төркемнәргә караган күмәк кешеләр язмышы килеп керә. «Узды бәйрәм»дә бүгенге көн яшьләре («дуслар бар да кояш иде табында»), «Якты юраулар»да халыкның бөтен гореф-гадәтен бергә туплаган олы буын вәкилләре («офыктан таң бөркелүгә, кыштыр-кыштыр уяна картколар») гәүдәләнә. Кайчакта хәтта «син» дип мөрәҗәгать иткәндә дә (әйтик, автор «Яшьлек бронепоезды» шигырендә яшьлеккә, «Казах кызы»нда бөтен бер халыкның җыелма милли образы булган кызга шулай дип эндәшә) сүз нигездә миллион кешеләр турында бара. Димәк, автор бу очракта да үзенең геройларын укучыга күмәклектә — тарихи-социаль аспектта тәкъдим итә.

Икенче яктан, Р. Әхмәтҗанов иҗатында индивидуаль башлангычка корылган әсәрләр дә аз очрамый. Мондый поэтик үрнәкләр геройларны чагылдыруның икенче төрен тәшкил итә. Конкрет язмышлы геройлар кичереше аша сурәтләнгән «Гаяз солдат», «Аккош юлы», «Күршем нигезе», «Сурәт», «Илгә исән кайткан агайлар», «Янгын сүндерүче турында баллада», «Тукайны озату», «Фидаи», «Биш минутка ода», «Сәгать суга» һәм лирик геройның төрле рухи халәтен чагылдыруга багышланган башка бик күп әсәрләре моңа мисал булып тора.

Роберт Әхмәтҗанов иҗатындагы өченче төр геройларны күзаллап, шартлы төстә Кешенең космик чагылышы дип атарга мөмкин булыр иде. Биредә шагыйрь Кешегә башлыча табигать һәм кешелек дөньясының бер вәкиле буларак мөрәҗәгать итә. Аны антропологик-философик күзлектән чыгып, вакыт һәм пространствоның космик ераклыгыннан торып сурәтли. Психологик эчке яшәешенә кереп, аны анализлап, таркатып тормастан, кешене автор олы дөньяда, тулаем бербөтен итеп, бөек бер зат буларак кабул итә:

*Күреп белдем: ерак офыкларга*
*бу тормыштан үткән киң юлның*
*күк күкрәтеп, җир тетрәтеп чапкан*
*аргамагы, Кеше, син булдың.*

(«Бер карыйсым килде...»)

Шунысын да әйтеп үтик, мондый тасвирлауда герой һәм лирик геройның «мин» яки «ул» дип берлек санда, «без» яки «алар» дип күплектә

килүе психологик яктан әллә ни зур әһәмияткә ия түгел — бу ахыр чиктә, формаль, грамматик бер аерымлык кына. Ә геройларның асылы исә нигездә бер үк затка карый: бу — билгеле бер дәрәҗәдә конкретлашып килгән җәмгыять, чор кешеләре. «Төнбоеклар чәчәк аткан таңда...» шигырендә лирик герой үзен өч тапкыр «мин» дип, өч тапкыр «без» дип атый. «Мин»дә билгеле бер дәрәҗәдә шәхси башлангычны, «без»дә гомумилекне тоеп торсак та, бу — шартлы бүленеш кенә:

*Галәмнән әйләнеп кайттык без,*
*кактык без*
*ак каен төбендә йолдыз тузанын...*

(«Без җирдә яшибез...»)

Хәер, әсәрләрдә зат алмашлыклары бөтенләй төшеп калырга да мөмкин:

*Ыргый йөрәк ярсу ракетадай...*
*Күңел риза илнең аманәтен*
*еллар түренә илтеп бирергә...*

(«Таң шигырьләре»)

Монда инде «йөрәк», «күңел» сүзләре алдына «минем» дип тә, «безнең» дип тә куярга мөмкин булыр иде. Р. Әхмәтҗанов әсәрләрендәге бик күп геройлар әнә шундый «космик ераклыктан» торып тасвирланган «нейтраль» кешеләр. Аңлашыла булса кирәк, шагыйрьнең Табигать — Кеше, Кеше — Табигать берлеген раслауда әлеге эре планда һәм гомумилектә, масштаблы бөтенлектә алынган Кеше һәм аның фәлсәфи-социаль аспектта яктыртылган язмышы шагыйрьгә зур хәрәкәт иреклеге калдыра. Гомумкешелек хасиятләрен үзендә туплап килгән бу ярым конкрет, ярым абстракт заман герое, автор чынбарлыкның башка хикмәтле үзенчәлекләрен эзләп йөргәндә, Атлант кебек, әсәрдәге төп фәлсәфи шигъри фикерне, формаль логик йөкне үз җилкәсендә тотып тора. Табигатьнең дәвамы итеп күрсәтелсенме ул, аңа параллель яисә контраст итеп алынсынмы — кешенең бөтенлеген саклау, аны индивидуаль психологик анализга таркатмау — шагыйрьгә фикерен зур колач белән, романтик бер көч белән саллы-берәгәйле итеп әйтү мөмкинлеге бирә.

Шул ук вакытта, табигый ки, сәнгать сәнгать булып, тагын да дөресрәге — кеше кеше булып кала. Аның төп хасияте, төп матурлыгы, байлыгы макро- һәм микродөньяларны бердәй берләштергән катлаулы, каршылыклы рухи яшәешендә, җанында. Ә аңа гомум планда, билгеле бер формаль логик аспекттан чыгып якын килүнең плюслары белән берррәттән, һичшиксез, үз минуслары да бар.

Хикмәт шунда, беренче төркемдәге күмәк геройларны тасвирлаганда да, икенче төркемдәге конкрет язмышлы геройларны тасвирлаганда да авторның конкрет җир кешеләре белән эш иткәнлеге сизелеп тора. Биредә шагыйрьнең күзәтүчәнлегенә дә, психологик сизгерлегенә дә, рухи халәтләрне җанландыру осталыгына да сокланмыйча калып булмый. Ә менә өченче төркем — космик позициядән торып тасвирланган геройларны үз эченә алган әсәрләрдә эш башкачарак.

Иң элек шунысын әйтеп үтик, дөньяны масштаблы, романтик бер рух белән иңләп күрү — һичшиксез, заманыбызның типик бер үзенчәлеге. Җир һәм йолдызлар системасының, табигать, тереклек дөньясының бөтенлеген раслау, ерак тарихи үткәннәрне бүгенге көн фонында киләчәк еллар белән тоташтыру, Бөек Октябрьнең дөньякүләм әһәмиятен күрсәтү, Бөек Ватан сугышының дәһшәтле авазларын бүген тынычлык өчен барган көрәш сүзенә әверелдерү, заманыбызның космик тизлекле яшәешен, илләр арасында беркайчан да күрелмәгәнчә якынлыкны һәм ераклыкны ассызыклау — күрәсең, мондый мәгънәләр колачлы фикер йөртүдән башка мөмкин дә түгелдер. Әлеге темаларның автор иҗатында киң чагылыш табуы да очраклы түгел. Шагыйрьнең дистәләрчә уңышлы шигырьләрендә космик сулыш, ялкынлы яшьлек, канатлы мәхәббәт, кискен нәфрәт хисе ярылып ята. Заманыбызның бу хасияте, димәк, Роберт Әхмәтҗанов иҗатының үзәген, эчке рух үсешен билгели. Һичшиксез, бу — авторның зур уңышы саналырга тиеш.

Әмма мәсьәләнең икенче ягын да күрсәтеп үтмичә булмый: заманның бер типик үзлеге булган әлеге чынбарлыкны космик танып белү тора-бара шагыйрь иҗатында тема гына, геройларның эчке дөньясына үтеп кергән заман рухы гына булып калмыйча, кеше күңелен шигъри үзләштерүдә, кеше җанын психологик чагылдыруда да авторның яраткан иҗат алымына әверелә. Җирдән күтәрелеп, кешене билгеле бер космик ераклыктан торып сурәтләү — әсәрдән индивидуаль психологик анализ көткәндә, укучыга ераклыкта гомумиләшкән мөнәсәбәтле кеше язмышлары тәкъдим итү безне канәгатьләндерә алмый. Бит художестволы танып-белү, чын сәнгать әсәре киңлек һәм масштаблылык кына түгел, тирәнлек тә — кеше язмышының кабатланмас каршылыклардан торган иң нечкә капиллярлы хис һәм фикер агышын күздән кичерүне дә үзенең нигез таләпләреннән берсе итеп куя. Инде ул юк икән, аңлашыла булса кирәк, эчтәлек гомумиләшә. Һәрбер сәнгать әсәреннән ачыш, оригинальлек таләп иткән укучы күңеле алдында ул үзенең әйдәп баручы көчен югалта. Әсәрнең тәэсир итү көчен арттыру өчен автор игътибарын эчтәлектән форма ягына күчерә. Эчтәлек үзеннән-үзе икенче планга чигенә, алга форма чыга. Психологик ачышларны формаль поэтик табышлар — шигъри образлар алыштыра.

«Йолдызстан» поэмасында әнә «Галилейлар, Брунолар янган» дип санап китә автор. Фән-акыл үсешен мондый зур тарихи чорлар ераклыгыннан торып күзәтү, әлбәттә, әсәрнең герое булган Кешене дә шартлы-символик берәмлеккә әверелдерә. Поэма, образлы шигъри тел белән язылуга карамастан, каһарман шәхесләрне бер җепкә тезеп типиклаштырган тарихи очеркка тарта башлый. «Йолдыз гөлләре» шигырендә, геройларның гомумән җир кешесе булудан туктап, Аэлиталар, марсияннарга әверелүе дә һич очраклы түгел. Димәк, шагыйрьне индивидуаль шәхес психологиясеннән бигрәк, гомуми типик Кеше (Кешелек) язмышы кызыксындыра.

*Һәркем елмаеп:*
*— Яңача башлыйбыз,— диде,—*
*яңача*
*Башыннан!*

(«Яңа елга кергәндә»)

Бу мисалда да, күрүебезчә, автор «Һәркем» дип типиклыкны ассызыклый. Ә еш кына шагыйрь Кеше күңелен ачуда ниндидер бер табигать яисә тормыш күренеше уяткан ассоциацияләрне теркәү белән канәгатьләнә. Әйтик, «Бодай кыры» шигырендә Кешегә мөнәсәбәттә түбәндәге күчеш ясала:

*Миллион куллар гуя күтәрелгән*
*теләп тук һәм имин елларны.*

Бу — шигырьнең финалы. Димәк, лирик герой, иген басуында йөри торгач, игътибарын кеше язмышына юнәлтә. Табигать — Кеше берлеге раслана раслануын, әмма, күрүебезчә, әсәр Кеше психологиясен анализлау юнәлешендә үстерелми. Кешегә килеп җиткәч, әсәр тәмамлана. Авторның максаты биредә яңа психологик катламнарга үтеп керү түгел, ә бәлки мәгълүм бер идеяне укучыга яңа поэтик образлар аша җиткерү, яңа эстетик тәэсир итү формасы табу. Бу шигырьләрнең яңалыгы һәм кыйммәте дә башлыча, әнә шул шигъри табыш, шигъри форманың оригинальлегенә кайтып кала.

Шагыйрьнең табигать, яшьлек, мәхәббәт җырчысы булуын без алда ассызыклап үткән идек инде. Чынлап та, аның геройлары бөтен барлыклары белән җанлы тормышта яшиләр: яшүсмер чактан зур өметләр белән рухланып алар авылдан яңа төзелешләргә, чирәм җирләргә, укырга, һава, диңгез киңлекләренә юл тоталар. Дәртләнеп янып зур эшләргә алыналар. Дуслашалар, яратышалар, яңа тормыш коралар. Балачакларын искә төшерәләр, әти-әниләре, балалары нигезен сагынып туган якларына кайталар, яшәү мәгънәсе турында уйланып, кабат олы тормыш эченә ташланалар. Дөнья ваклыкларына бик игътибар итмәстән, тормыш каршылыкларын максималистик бер кискенлек, кайнарлык белән хәл итәргә омтылулары, уй-хисләренең эре штрихларда, канатлы романтик очышта тасвирлануы, дөньяга мәхәббәт, дошманга тирән нәфрәт күзе белән карау һ. б. сыйфатлары аларны яшь укучыга якын итә. Авторның сәнгатьле фикерләү үзенчәлеге дә нәкъ әнә шул чиксез билгесезлеккә ашкынган яшүсмернең күңел дөньясын хә-

терләтә: ул хыялый да, кыю да, масштаблы да. Лирик герой чынбарлыкны танып белүдә космик очыштагыча — җирнең әле бер материгына, әле капма-каршы икенче бер төбәгенә килеп чыга. Очышның кызу тизлеген искәрткәндәй, җир тормышы укучы күз алдында кисәк-кисәк, этюд булып чагылып калган композициягә әверелә. Ә инде дөньяны психологик үзләштерү мәсьәләсенә, авторның кешеләргә булган мөнәсәбәте, үзенчәлекле мәхәббәтенә килгәндә, без Роберт Әхмәтҗановның нәкъ менә яшьләр шагыйре булуына ышанабыз.

Җанлы-«гөнаһлы» җир кешесеннән читкә китү, ераклашу тенденциясе, гомумән, Р. Әхмәтҗанов әсәрләрендә әледән-әле сизелеп тора. Алда әйтелгән «космик позиция» геройларның барлыкка килүе дә автор иҗатында очраклы түгел. Дөрес, башлангыч чор иҗатында аның үз геройлары рухи халәтенә шактый якын килеп эш итүе, гыйбрәтле язмыш кичергән конкрет кешеләрнең күңел тирбәлешләрен үзәккә алып сурәтләве күзгә ташлана. Бу уңайдан, беренче китабына кергән «Су кызы» шигырен генә алып карыйк:

*Көнләштерми синең үткәнең,—*
*ай нурыдай сарылып иңнәреңә,*
*елап-көлеп ятны үпкәнең!*
*Тарихыңны инде еллар юган...*
*Мин үзем дә сөйдем тилереп...*
*Синең утлы карашыңнан бүген*
*җаным тора сусап, тилмереп.*

Биредә язмыштан һәм дөнья ваклыкларыннан өстен калып, олы сөюне байрак итеп яши белгән лирик герой җаны гәүдәләнә. Укучы бу кичерешләргә битараф түгел, герое белән бергә ул зур хисләр ташкыны эченә барып керә, аның өчен дулкынлана, көрәшә, аны үз итә, ярата башлый. Кеше халәтенә кереп борчыла белү, аңа теләктәшлек итү — сәнгатьнең нигез таләпләреннән берсе түгелмени?!

Укучыны дулкынланырга мәҗбүр иткән, мәхәббәт нуры иңгән мондый геройларны без авторның алдагы җыентыкларында да очратабыз. Бу яктан «Кызыл усаклар» (1966) китабы аерым игътибарга лаек. Кеше кичерешләренә якын килүдә, аларны шигъри биеклеккә күтәрүдә, хис-эмоцияләрнең муллыгы, эчкерсезлеге, сафлыгы белән шагыйрьнең башка бөтен җыентыкларыннан ул аерылып тора. Соңрак чыккан китапларында Р. Әхмәтҗановның конкрет язмышлы җир кешесеннән ераклаша төшүе, еш кына геройларының конкрет йөз сызыклары югалып, гомум кешегә күчүе билгеле бер даими үзлеккә әйләнә. Р. Әхмәтҗановны геройларының психологик язмышыннан бигрәк, аларның шигъри үзкыйммәте кызыксындыра. Шигъри образлар иҗат иткәндә конкерт деталь-сурәтне алда тоткан шагыйрь кешене тасвирлаганда ни өчендер гомумилеккә, типиклыкка күбрәк тартыла. Герой кичерешләрендәге индивидуальлекнең җитмәве Р. Әхмәтҗанов әсәрләренең иң четерекле ягына әверелә. Хосусый бер кимчелек кенә булмыйча, үз чиратында, ул автор иҗатының тагын башка бик күп каршылыкларын да китереп чыгара.

Психологик аспекттагы эзләнүләрнең, табышларның җитәрлек булмавы, әйтик, авторны форма активлыгына китерә — уңышсызлыкларын ул шигъри форма ярдәмендә компенсацияләргә омтыла. Эффектлырак шигъри образ, эстетик чара табу шагыйрь иҗатының әйдәп баручы төп көченә, үзмаксатка әверелә. Шагыйрьнең төп иҗат каршылыгы, безнеңчә, әнә шунда. Ул каршылыкның бөтен иҗат процессларына, шул исәптән авторның хәтта иң көчле ягы — тел һәм образлар ясалышына да үтеп керүе — әнә шул хакта сөйли:

*«Топольләрем... хлорофиллны сагынып ярсына»...*
*«Метроном тавышын ишетәм»*

(«Тополия»)

*Шампиньоннар,*
*пигмалионнар*
*эшләпәсен сала бүген.*

(«Гөмбә чоры»)

Авторның биредә фәнни терминнарга мөрәҗәгать итүен дә, «пигмалион» атлы яңа гөмбә уйлап табуын да хуплап булмый. Шагыйрьнең оригиналь-

леккә омтылышын ассызыклаудан гайре, тасвир теленең гадилеген, табигыйлеген югалтудан гайре аларның әсәргә әллә ни яңалык китерүе күренми.

Шартлылыкның психологик әзерләнеп җитмәве нәтиҗәсендә зарар күргән образлар Р. Әхмәтҗанов иҗатында байтак кына. Беренче укуда шактый матур, оригиналь һәм эффектлы кабул ителгән образлар да, күз явын алырлык чәчәкнең кәгазь икәнлеге беленгән кебек, кайчакта уфтанып куярга мәҗбүр итәләр. «Орчык җыры» шигыреннән бер өзек китереп узыйк:

*Мунча ташлары ята таралып,*
*каралып чыкты болыт, эссе салды.*
*Койды яңгыр...*
*ташлар чыңламады.*
*Алар салкын...*
*Янәшәдә генә яшь каеннар.*
*Себерке исе белән тулды һава!..*

Әлеге алогизмнан соң салкын мунчада һаваның себерке исе белән тулуы да, шигырьдә алга таба табигатьнең җирне чабуы да инде безне ышандырмый.

Образларның психологик нигезләнмәве кайчакта шигырьнең гомумән җитдилеген үк бетерә:

*Бу сүзләрем белән явар өчен*
*туры килде элек яшьнәргә.*

«Ленин» поэмасының беренче юллары әнә шулай башланып китә. Әмма «сүз белән явуны» да, бу темага «явар» өчен нигә «яшьнәргә» кирәклеген дә тәгаен генә аңлату кыен... Р. Әхмәтҗановның «Син — тик рәсем» дигән шигыре бар. Лирик герой биредә сөйгән кешесенең стенадагы рәсеме белән сөйләшә. Тик рәсем рәсем инде. «Сокланмый иртән яуган өрпәк йолдызларга», «Төнге поездларга битараф» — күзләре генә тик «еллар аша, карлар аша карый көлеп...» Шуның кебек, авторның геройлары да кайчакта төрле образлар, төрле ассоциатив хис-тойгылар уятсалар да, психологик яктан күңелдә бер тирән эз калдырырлык булып ачылмый. Алар — сүзсез. Кеше язмышы белән ныклап торып беркетелмәгән, яшәеше эскиз һәм этюдларны хәтерләткән бу образлар шагыйрь иҗатының буеннан-буена сибелеп ята. Шигырьләрдәге композицион таркаулык, деталь-сурәтләрнең очраклылыгы, төрле алогизм, психологик акланмау, купшылык «әле ярый күзгә шул чүп кергән, тумас иде юкса бу җырым» («Күзгә чүп») дигәндәй, тик торганда язылган юллар әнә шулай барлыкка килә. Авторның «Йолдызстан» поэмасы, «Шәһәр язы», «Яңа ел утлары», «Кояшка, кояшка» һ. б. шигырьләре бу хакта уйланыр өчен бай җирлек булып тора.

Шагыйрь язмышын аның геройлары язмышы, ул геройларның чынбарлыкка карашлары, психологик эчке дөньялары тудыра. Р. Әхмәтҗанов-ка да, димәк, үз иҗатында геройларына булган иҗади позициясен үзгәртә төшүен, кешеләр тормышына эчкәрәк керүен, игътибарлырак булуын, аларның күңел җәрәхәтенә сизгеррәк, психологик үзенчәлекләрен һәм җан хәрәкәтен ачуга җаваплырак каравын телисе килә.

Бит беркемгә дә сер түгел: кешеләрдән ераклашкан саен шагыйрьнең фәлсәфи фикер чыганагы саега, кибә, көрәшче буларак, замандаш укучыларына оригиналь һәм хикмәтле яңа сүз әйтүе кыенлаша бара. Кеше язмышы аша үткәрелмәгәндә, әйтелгәннәренең дә тәэсир көче бермә-бер кими. Ул коры схематик фикер сөрешенә, публицистик идея белдерүгә әверелә.

Психологик конкрет тасвирланганда исә шагыйрьнең әсәрләре шундук үзгәрә. Роберт Әхмәтҗановның без башка бер генә шагыйрь белән дә бутамаслык кыю, саллы, тәэсирле шигырь юллары белән очрашабыз. «Җирдә — июнь», «Кар кеше», «Узды бәйрәм», «Күңел догасы», «Гөмбә чоры» һ. б. әсәрләрен генә искә төшерик.

Янып, көрәшеп яшәү, халыкка игелекле хезмәт итү кебек темаларны үз эченә алган әсәрләр шагыйрьне классик әдипләребез иҗатына аеруча якынайта. Тикмәгәмени ул әнә үзенең җанын уяулыкка чакыра:

*Йоклама, җан,*
*оема, җан.*

*Син йоклый дип әллә кайчан,*
*баш калкыта җаһил гакыл,*
*һәм уяна*
*мәләк — шайтан!*

(«Йоклама»)

Йоклап, бушка гомер уздыруның зур җинаять булуын ул замандашлары колагына да әледән-әле ишеттереп тора. Кайчакта бу сөйләшү катгый, аяусыз:

*Ил әҗәтен кайтарырбыз тик шунда:*
*Күтәрелсә бер орлыктан мең орлык.*

(«Узды бәйрәм»)

Көрәшеп яшәүнең асыл мәгънәсе — гадәти гомер, гадәти вакыт төшенчәсеннән, аның үлчәмнәреннән читкә чыга. Аларга алмашка шагыйрь үз үлчәмен: геройларның дөньяга булган үз фәлсәфи карашларын тәкъдим итә. «Биш минутка мәдхия» шигыренең герое Ю. Фучик: «Рәхмәт, тормыш, биш гомергә тиңдән биш минутың өчен онытмам!..» — дип белдерә. «Сәгать суга» шигырендә дә вакыт үзенең гадәти үлчәмен югалта, ул фәлсәфи яшәеш ала:

*Сабыр итче, тукта, сәгать,*
*коммунистлар, ленинчылар*
*узар сине*
*бер эрага!*

Кешелек бәхете өчен көрәшнең үз тарихы бар. Шагыйрьнең әледән-әле дөньяның даһи сәнгатьчесе — бөек Ленин образына мөрәҗәгать итүе дә очраклы түгел. Әнә «Сәгать суга» шигырендә лирик герой сәгатькә: «җир сәгате, синең бит мин телең беләм, телим икән, телләреңне уникегә төрләндерәм»,— дисә дә, сәгать аны тыңламый. Лирик герой төгәл вакытны ачыклар өчен яңа дәвер башына — кешелекнең вакыт галиҗанәбен «бер эрага узган» чорга кайта:

*Ишетәмсез, сәгать йөри —*
*Җирнең кырыс хисапчысы!*
*Күрәсезме,*
*планетада Ленин йөри —*
*яңа вакыт, яңа дәвер иҗатчысы!..*

Хәтер — вакытның бер канаты. Аның икенче канаты — киләчәк. Шуңа күрә кеше күңеле үткәннәргә генә түгел, киләчәккә дә сак һәм сизгер булырга тиеш. Кеше йөрәге заманнар каршында җавап бирергә әзер торырга тиеш.

«Сандугачның нәни йөрәгенә дөнья сыйган сөю аркылы» («Йолдызстан») дигәндәй, шагыйрь җаны аша да тормышның «тугыз балл ы давылы» үтә. Бу давылда көрәшче булганда гына, көрәш рухын тормышны сөю хисе аша уздырганда гына шагыйрьләр кешелек бәхете өчен янучы изге сафка басалар.

Роберт Әхмәтҗановча — гади җир мәхәббәтен җуймыйча йөрәгендә саклап кала алса гына, аның сүзләре киләчәктә җыр булып яңгырар. Шул чакта гына ул киләчәк буын кешеләренә сөйгәненә эндәшкәндәй гади һәм эчкерсез итеп болай дия алыр:

*Минем күк сөеп, чәчеңнән*
*язгы давыллар тарасын.*
*Соңыннан,*
*сагынып үзеңне,*
*рәсемеңә еллар карасын...*

# ШӨБҺӘЛӘНЕРЛЕК БУЛМАСЫН!

Соңгы елларда татар тел гыйлеме күзгә күренерлек уңышларга иреште. Моның шулай икәнен раслау өчен дистәләрчә тел галименең фамилиясен атарга, аларның хезмәтләрен санап чыгарга кирәк булыр иде. Максатыбыз тел гыйлеменең гомуми казанышлары хакында сөйләү булмаганлыктан, аларны атап-санап торуның кирәге юк. Урта гасыр болгар-татар теленең җәүһәре саналган «Кыйссаи Йосыф» китабының бик матур итеп басылып чыгуы, татар теленең өч томнан торган аңлатмалы сүзлеге дөнья күрүе кебек культурабыз тарихында вакыйга булырлык хезмәтләрне атау гына да тел гыйлеме өлкәсендә фундаменталь эшләр башкарылуы турында сөйли.

Әйе, татар тел гыйлеменең лексикология өлкәсендәге уңышлары шатлыклы. Бигрәк тә моңа кадәр игътибар ителми килгән тармак — ялгызлык исемнәр (җирсу, авыл атамалары, кеше исемнәре һ. б.) буенча башкарылган хезмәтләр куандыра. Болай дигәндә, без соңгы биш-ун ел эчендә генә басылып чыккан топонимик атамаларга караган хезмәтләрне, гидронимнар сүзлеген, татар исемнәре сүзлеген һ. б. күздә тотабыз. Аларның кайсын гына кулга алсаң да бер исем — профессор Гомәр Саттаров исеме белән очрашасың. Аның фамилиясе республикабызда чыга торган газета-журналларны укып баручыларга да бик таныш. Гомәр Фәезович тел гыйлеменең бу өлкәсендә гаять зур һәм бик кирәкле эш алып бара. Туган телебезгә, туган төбәгебезгә, тарихыбызга һәм культурабызга мәхәббәт тәрбияләүдә зур әһәмиятле эш башкара.

Татар тел гыйлеменә, әдәбиятына бәйле һәм үз төбәген яраткан кеше буларак, миңа Гомәр иптәш Саттаровның һәр китабын, газета-журналларда басылган һәр мәкаләсен игътибар белән укып барырга туры килә. Аннан соң мине моңа икенче бер максат та мәҗбүр итте. Мин озак еллар буе үземнең туып-үскән Шөгер-Лениногорск якларының, гомумән, Кама аръягы Көньяк-Көнчыгышының тарихы буенча материаллар туплап килдем һәм үземчә аларны бер системага салдым. Бу эшне башкарганда, әлбәттә, авыл исемнәрен читләтеп узу мөмкин түгел. Шуңа да, Г. Ф. Саттаров хезмәтләрен кат-кат карарга, өйрәнергә һәм, еш кына, күңелдән генә автор белән бәхәсләшергә туры килде. Бу мәкаләдә әнә шул бәхәсле уйларым белән уртаклашасым килә дә инде минем.

Профессор Г. Ф. Саттаров эзләнүләренең әһәмияте турында югарыда әйтелде инде. Шунысы аяныч, аның топонимик атамалар өлкәсендәге хезмәтләре әлегә укучыларны канәгатьләндереп бетерми дип әйтәсе килә. Эш шунда ки, безнең хөрмәтле профессорыбыз теге яки бу авыл исеменең килеп чыгышын аңлатканда, күбрәк, «алай түгел микән», «болай түгел микән», «шулай булырга тиеш», «тегеләй булырга тиеш» дигән кебек фараз кылулар белән эш итә, кисеп кенә раслаудан кача, димәк, үз гипотезасына үзе дә шөбһәләнә. Авыл исемнәрен болай икеле-микеле аңлатулар еш кына, файдадан бигрәк, зыян китерүе мөмкин. Нигә дисәң, башка төбәкче-тарихчыларның, татар теле, тарихы белән кызыксынучыларның, теге яки бу авыл-кала хакында сүз йөрткәндә: «Әнә ич, профессор шулай дип әйткән — димәк, шулай»,— дип эзләнүләрне туктатулары, чын хакыйкатькә барып җитмәүләре бар.

Ни өчен болай килеп чыга соң? Ни өчен авыл исемнәре шөбһәләнеп кенә, алай түгел микән, болай түгел микән дип аңлатыла, төрле гөман-фараз итүләргә, гипотезаларга кайтып кала? Минемчә, төп бәла шунда: авыл исемнәрен аңлату башлыча сүзнең тышкы формасына, теге яки бу сүзнең бүгенге көндә нинди мәгънә белдерүенә карап кына башкарыла. Автор ашыга, ул төрле тарихи чыганакларга, борынгы китапларга, архив материалларына бик сирәк, очраклы диярлек кенә мөрәҗәгать итә. Өстәвенә, үзе туган төбәктән башка, авыл аксакаллары белән киңәшүне кирәк дип тапмый. Ә бит Татарстанда яңа авыллар, ягъни шушы гасырның егерменче-утызынчы елларында гына күчеп утырганнары да байтак, хәтта аларга башлап күчеп утыручыларның исән-иминнәрен дә очратырга була.

Дөрес, Гомәр Фәезович, тел галиме буларак, теге яки бу сүзнең башка төрки телләрдәге мәгънәләренә игътибар итә, чагыштырып карый һәм, шулардан чыгып, билгеле бер нәтиҗәгә килә. Ләкин, укучы игътибар иткәндер, авторның чагыштырулары, башка төрки телләргә мөрәҗәгать итүе, теге яки

бу авыл исеменең алдан фараз ителгән аңлатмасын расларга омтылу гына икәне сизелеп тора, укучыны бик үк ышандырмый. Кыскасы, фән белән шаяру сыманрак килеп чыга. Мин бу ысулны бөтенләй инкарь итәргә җыенмыйм. Аерым очракларда, бигрәк тә Казан янындагы борынгы татар авыллары исемнәрен аңлатканда, ул үзен аклый булыр. Чөнки һәр авыл исемен фәнни нигезләгән тарихи документларны табып бетерү мөмкин түгел. Аксакаллар да һәрчак дөресен генә әйтеп бирмәве бар, өстәвенә аларның күбесе үлеп беткән. Алай да, безнеңчә, мондый әһәмиятле эшкә тотынган кешегә, башлап язма чыганакларга, архив материалларына, авыл аксакалларына мөрәҗәгать итү фарыз. Тегe яки бу авыл исеменең килеп чыгышын ачыкларлык тарихи чыганаклар, архив материаллары, яки авылның атамасын төгәл белүче картлар булмаган тәкъдирдә генә төрле чагыштырулар, фараз-гөман итүләр, гипотезалар эшкә җигелергә тиеш.

Югарыда әйткәннәребез коры сүз генә булып калмасын өчен, берничә мисал китерик. Дөрес, мин мисалларны бөтен Татарстан буенча алырга җыенмыйм, үземә яхшы таныш булган Лениногорск районы авылларына гына мөрәҗәгать итәм. Мәсәлән, «Социалистик Татарстан» газетасының 1985 ел 15 май санында басылып чыккан мәкаләсендә иптәш Саттаров безнең райондагы Сугышлы авылының исемен болай дип аңлата: «Элек шул төбәктә булып үткән тарихи вакыйгаларга, шул исәптән сугыш-орышка мөнәсәбәтле рәвештә дә җирле географик атамалар барлыкка килгәннәр... Сугыш һәм орыш сүзләренә әйбернең, билгенең булуын белдерә торган **-лы** кушымчасы кушылу юлы белән Сугышлы һәм Ормышлы авылларының атамалары барлыкка килгән булырга тиеш».

Беренче карашка, өстән-өстән генә фикер йөрткәндә, шулай, бар да дөрес — исемгә сыйфат ясый торган **-лы** кушымчасы ялганган да, шуннан авыл исеме барлыкка килгән. Әмма архив материаллары һәм тарихи әдәбият актара торгач, мәсьәләнең шактый катлаулы икәне ачыкланды. Әйтик, хәзерге Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарында, ягъни Оренбург губернасы Уфа провинциясе Казан юлының Нәдер волостенда 1746 елда үткәрелгән беренче перепись (чираттагы Икенче ревизия) документларына (ЦГАДА — Борынгы актлар үзәк дәүләт архивы, 350 ф., 2 тасв., 3793 китап, 19—34 битләр) караганда, хәзер **Сугышлы** дип телгә кереп киткән авылның «сугыш» сүзенә бөтенләй катнашы юк икән. Без югарыда телгә алган документта, ягъни 1748 елда төпләп куелган «Книга переписная ясачных крестьян татар» фолиантында акка кара белән: **«В деревне Надырово, что на речке Сагушлы»** дип язылган һәм башлап килеп утыручыларның исем-фамилияләре теркәлгән. 1762 елда үткәрелгән Өченче ревизиядә дә сүз «Сагушлы» елгасы хакында бара. Архив материалларының башкаларында да бүгенге көндә Алешкино һәм Кузайкино дип аталган авылларның «Вершина речки Сагушли» (Алешкино) һәм «Мордовское Сагушле» (Кузаикино, Сугышлы җиренә килеп утырганга башта шулай дип йөртелгән) дип язылулары мәгълүм. Күренә ки, сүз сугыш хакында түгел, гап-гади «сагыш», ягъни «Сагышлы» елгасы хакында бара икән. Бүгенге Сугышлы авылының исеме нәкъ менә әлеге сагышлы елгасы исеменнән (бозып язу һәм фонетик үзгәрешләр нәтиҗәсе) алынган да инде. Бу хәл исә шактый соң, Әлмәт районындагы Яңа Нәдер авылы барлыкка килгәч кенә, ике авылны бутамау йөзеннән булган. Аңа хәтле исә, хәтта революциягә кадәр, бүгенге Сугышлыны «Нәдер» дип, соңрак, «Иске Нәдер» дип йөрткәннәр.

Гомумән, бу авылның тарихы бик кызыклы. Аңа нигез салучы — Нәдер волостеның (бу волостька заманында хәзерге Әлмәт, Лениногорск, Бөгелмә һәм өлешчә Азнакай районнарындагы авыллар кергән) старшинасы, Россиядә беренче булып нефтьне эшкәртеп, керосин алырга маташкан, шул максат белән завод корган Нәдер Уразмәтов. Сугышлы гына да түгел, Куйбышев өлкәсе җирендәге Нәдеравыл (Надыровка, ул хәзер Сергеевск шәһәре территориясендә калган) һәм Әлмәт районындагы Яңа Нәдер авылларының барлыкка килүләре дә Уразмәтов исеме белән бәйле. Бу тынгысыз старшина, һичшиксез, Шушма елгасы буендагы, ягъни хәзерге Сугышлы, Шөгер урыннарындагы нефтьле чишмәләрне, дегет базларын да белгән. Һәм аларны файдалану нияте белән Сок елгасы буендагы Нәдер авылында яшәүче эшчеләрнең бер өлешен Сагышлы елгасының Шушмага койган җиренә, ягъни бүгенге Сугышлы авылы урынына китереп утырткан. Шуңа да анда башлап килеп төпләнүчеләрне «зимагурлар» дип йөрткәннәр. 1746 елгы ревизия документларыннан күренгәнчә, авыл башлыгы үзе дә «Зимагур Шәмгунов» дип теркәлгән. Шунысы да кызыклы, Россиядәге азатлык хәрәкәте җитәкчесе Батырша явы җиңелгәннән соң, 1755-56 елның рәхимсез кышында, шәкерте һәм көрәштәше Яхъя белән шушы Иске Нәдер (Сугышлы) авылының мәчет базында качып яткан. Инде килеп, Сугышлы авылында Акулина бәете туа, аның геройлары Акулина (Хәдичә) белән Җамалетдинның, Акулинаның шулай ук татар егетенә кияүгә чыккан сеңлесе Анастасия (Гайшәнең) шушы авылда гомер сөрүләрен дә әйтеп китик. Безнең чорга килсәк, бу авылда ике Советлар Союзы Герое (шул исәптән Газинур Гафиятуллин), ике Социалистик Хезмәт Герое туып үскән.

Инде шул ук «Социалистик Татарстан» газетасының 1985 ел 3 апрель санында басылган (ул тегe мәкаләнең дәвамы) язмага килик. Анда Лениногорск районының **Кирлегәч** авылы исеме түбәндәгечә аңлатыла: «1. Электә бабаларыбыз **Кирлегәч** дип тауның түш кебек киерелеп, алга чыгып торган урынын атаган

булулары мөмкин (?) Шундый урында барлыкка килгән авылга **Кирлегәч** исеме кушылган булуы бар. 2. Борынгы төрки телдә **кирлик** сүзе **кир-кер «грязь»** сүзенә **-лик/-лек** кушымчасы кушылып ясалган «пычрак» (русча «грязь») мәгънәсен белдергән. **Кирлегәч** терминының «пычрак урын, баткаклык» мәгънәсен аңлату ихтималы бар булып чыга».

Күренә ки, бу аңлатуларда бернинди дә фәннилек юк. **Кирлегәч** сүзен «киерелү»гә охшату бу әле фәнни нәтиҗә ясау түгел. Инде **Кирлегәч** авылының «борынгы төрки тел» заманында түгел, бәлки XVIII гасырның 30 елларында нигезләнүен искә алсак, икенче аңлатуның бернинди «ихтималы» булмавы, авторның бары тик кабинетта, өстәл артында утырган килеш, «алай булуы бар», «болай булуы ихтимал» дип фараз кылуы гына ачыклана. Ә топонимик атамаларны кабинетта утырып кына аңлатырга маташуларның никадәр күңелсез нәтиҗәләргә китерүен беләбез инде. Мәсәлән, В. А. Никонов төзегән «Краткий топонимический словарь»да (М., 1966) Бөгелмә термины «Бугульма — ... возможно, из тюркского буга «бык» дип аңлатыла. Ә бит әле XVIII гасырда ук Россия Фәннәр академиясенең беренче член-корреспонденты П. И. Рычков үзенең 1762 елда басылган (аннан соң ул китап тагын берничә мәртәбә күчереп бастырыла) «Оренбург топографиясе» дигән хезмәтендә үк Бөгелмә шәһәренең исеме Бөгелмә елгасы исеменнән алынуы, «бөгелмә»нең исә төрки сүз булып, бөгелү-борылуны аңлатуын язып калдырган. Бу китапта шулай ук В. А. Никонов «этимологиясе билгеле түгел» дип мөһер суккан «Бугуруслан» шәһәр исеме һәм башкалар да аңлатыла... Күренә ки, бүгенге галимебез XVIII гасырда яшәгән коллегасының хезмәтенә дә күз салмаган икән.

**Кирлегәч** авылы исеме аңлатмасы белән дә шундыйрак хәл килеп чыккан. Ә бит 1746 елда үткәрелгән Икенче ревизия документларына күз салсаң, бернинди фаразның да кирәге калмый. Анда бик ачык итеп **«Деревня Сеитово на речке Карлигач»**, диелгән. **Сәет** сүзе билгеле, ул беренче килеп утырган кешенең исеме — анысын иптәш Сattаров та шулай яза. Ә менә башта бернинди Кирлегәч тә булмаган, авыл кырыеннан **Карлыгач** елгасы аккан. Ярына бик күп яр карлыгачлары — керәшәләр оялаганга шулай дип аталган ул. Димәк, **Кирлегәч** бернинди дә «пычрак, сазлы урын» түгел, «Карлыгач»ның фонетик үзгәрешләрдән соң барлыкка килгән варианты гына икән.

**Керкәле** авылына килсәк тә шул ук хәл. Иптәш Саттаров аның исемен «Керкә» геофизик терминының «саз, түмгәкле урын» төшенчәсен белдерүе башкорт телендә сакланган»,— дип аңлата. Әмма уйлана-тикшерәнә торгач, эшнең бөтенләй башкача торуы ачыклана. 1781 елда Бөгелмә өяз каласы итеп расланганч, аның гербы да булдырыла. Ала балыкка (безнең якта аны «керкә» дип йөртәләр) гаять бай якта, елгаларның берсе аның исеменә бәйле рәвештә Керкәле дип атала икән, аның ни гаҗәбе бар.

Мисалларны тагы да дәвам итәргә мөмкин. Ләкин максат аларны санап чыгу түгел. Хәл болай да аңлашыла булыр. Халык яши торган 80 гә якын торак пункты булган бер райондагы географик атамаларны аңлатуда гына да никадәр төгәлсезлек! Ә Татарстан буенча һәр авылның исемен чын фәнни нигездә ачыклый башласаң, хәлнең тагы да аянычлыгы ачыкланыр иде. Димәк, нидер эшләргә, бәлки республикабыздагы топонимик атамаларга тулы ревизия ясап, аларның аңлатмаларын дөресләүне оештырырга кирәктер. Бу исә бер кеше кулыннан гына килә торган эш түгел. Моңа тулы бер коллектив, ягъни барлык тарихчылар, төбәкчеләр, телчеләр, язучылар, журналистлар — кыскасы, киң җәмәгатьчелек җиң сызганып тотынганда гына максатка ирешергә мөмкин.

Авыл исемнәрен аңлатуның нигезе итеп иң элек язма чыганаклар, архив материаллары, белешмәләр каралырга тиеш. Алар исә җитәрлек. Әйтик, мин югарыда телгә алган ревизия документлары. Архивта һәр фолиантның ахырында чиста бит бар. Анда документлардан файдаланган кешеләрнең фамилиясе языла. Мин караган фолиантларда татар фамилияләре юк диярлек. Димәк, аларны әле безнең Казан галимнәре күрмәгән, яки ныклап файдаланмаган. Мәгълүм булганча, күптән түгел, 60 елларда Уфа дини назарәтенең архивы БАССР Үзәк дәүләт архивына тапшырыла (295 фонд). Анда Татарстан, Башкортстан һәм Оренбург җирендәге мәчет-мәдрәсәләр турында материаллар тупланган. Шул уңай белән күп кенә авылларның тарихлары да яктыртыла. Иренми актарынганда, алар топонимия фәненә дә зур ярдәм итә алырлар иде. Россиядә даими рәвештә ел саен чыгарылып килгән «Адрес-календарь»лар, губерна үзәкләрендә шулай ук ел саен чыгып килгән «Памятная книга»лар (Казан, Оренбург һәм Уфа губерналары буенча), системалы рәвештә бастырылып торган «Россия империясенең халык яши торган урыннары исемлеге» белешмәләре, XVIII гасырда яшәгән галимнәрдән Паллас, Лепехин, Рычков хезмәтләре һ. б., һ. б. дистәләрчә архив материаллары, күп кенә авылларның исемнәрен ачыклауда төп чыганак булырлар иде. Хәзергә исә, күргәнебезчә, аларга кул тимәгән диярлек. Инде эш кузгатылган икән, әйдәгез, аны чын фәнни нигезгә күтәрик, төрле шөбһәләнүләргә урын калдырмыйк!

**Җәмит РӘХИМОВ,**
язучы.



## ЭШЛЕКЛЕ ОЧРАШУ

4 ноябрьдә КПСС өлкә комитетында театрлар һәм филармония житәкчеләре, иҗат работниклары белән очрашу булды. Алар үз коллективларының эш йомгаклары турында сөйләделәр, иҗат планнары белән уртаклаштылар.

Очрашуда КПСС өлкә комитеты беренче секретаре Г. И. Усманов чыгыш ясады. Ул Татарстанның социаль-экономик үсешендә ирешелгән уңышлар турында сөйләде. Г. И. Усманов театрлар һәм филармония коллективларына ару-талусыз хезмәтләре өчен рәхмәт әйтте, хезмәтияләренә коммунистик тәрбия бирүдә аларга яңа уңышлар теләде.

Очрашуда ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ш. Ә. Мостаев, ТАССР Министрлар Советы Председателе М. Ш. Шәймиев, КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев, профсоюзларның Татарстан өлкә Советы председателе Г. С. Баштанюк, ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, ВЛКСМ өлкә комитетының беренче секретаре Д. К. Шәяхмәтов, башка җаваплы партия, совет работниклары, республиканың масса-күләм информация һәм пропаганда органнары житәкчеләре катнашты.

## ТЕАТРДА БӘЙРӘМ

5 ноябрьдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының яңа бинасын ачу уңаеннан театр алдындагы мәйданда тантаналы митинг булды.

Митингны халык депутатларының Казан шәһәр Советы башкарма комитеты председателе Р. Р. Идиятуллин ачты.

Сүз КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляевка бирелә. КПСС өлкә комитеты



бюросы, ТАССР Верховный Советы Президиумы һәм Министрлар Советы исеменнән ул проектлаучыларның, төзүчеләрнең, архитекторларның, художникларның, иҗат оешмалары коллективларының, промышленность предприятиеләренең зур отрядына, бу бинаны төзүдә актив катнашкан һәркемгә кайнар рәхмәт белдерде һәм аларга яңа хезмәт уңышлары теләде.

Төзүчеләр исеменнән митингта Главтатстрой начальнигының беренче урынбасары Г. Ф. Самойлов һәм 5 нче трестның 3 нче төзү-монтаж идарәсе штукатурчысы, комсомол-яшьләр бригадасы бригадиры Е. Ф. Васильева чыгыш ясады.

Төзелеш штабы исеменнән Г. Ф. Самойлов театрның яңа бинасының символик ачкычын театрның баш режиссеры, СССРның халык артисты М. Х. Сәлимжановка тапшырды.

Республиканың иҗат союзлары исеменнән ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе драматург Т. А. Миңнуллин чыгыш ясады.

Көчле алкышлар астында КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Г. И. Усманов театрның яңа бинасына керү юлындагы ал тасманы кисте.

Тантаналы митингта КПСС өлкә комитеты һәм КПССның Казан шәһәр комитеты бюролары членнары һәм членлыкка кандидатлар катнашты.



*Уңнан сулга: артистлар Р. Мотыйгуллина, Ш. Биктимеров, А. Гайнуллина, Д. Нуруллина.*

## ЖУРНАЛ ЮБИЛЕЕ

27 октябрьдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында иҗтимагый-политик һәм әдәби-нәфис «Азат хатын» журналының 60 еллыгына багышланган тантаналы җыелыш булды.

КПСС өлкә комитеты исеменнән котлау сүзе белән җыелышта катнашучылар алдында өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире А. И. Афанасьев чыкты.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы секретаре Д. С. Дәүләтшина «Азат хатын» журналына Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасын тапшырды. Журнал бу олы бүләккә хезмәт иярләренә коммунистик тәрбия бирүдә актив эшләве өчен лаек булды.

Журналның иҗат юлы турында доклад белән аның баш редакторы В. Ф. Ихсанова чыкты.

Җәмәгатьчелек вәкилләре, хезмәт коллективлары, иҗат союзлары вәкилләре, күрше автономияле республикалар кунаклары редакция коллективын, аның авторлар активын, күп санлы укучыларын кайнар тәбрикләделәр.

## САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВАНЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

1 ноябрьдә Әлмәттә нефтьчеләрнең Культура һәм техника сараенда танылган шагыйрә Саҗидә Сөләйманова иҗатына багышланган тантаналы кичә булды.

Шагыйрә һәм актив җәмәгать эшлеклесе С. Сөләймановаының тормышы һәм иҗаты турында язучы Кояш Тимбикова сөйләде. Чыгыш ясаучы шагыйрьләрдән РСФСР Язучылар союзы идарәсе консультанты, республиканың Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Г. Рәхим, РСФСРның М. Горький, БАССРның С. Юлаев исемендәге дәүләт премияләре лауреаты Н. Нәҗми, ТАССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Г. Афзал, язучы Л. Ихсанова, шагыйрә К. Булатова, Татарстанның атказанган нефтьчесе Н. Закирова шагыйрә турында җылы истәлекләр сөйләделәр, аның иҗади мирасын югары бәяләделәр.

Юбилей тантанасында шулай ук Казаннан шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов, Әлмәт язучылар оешмасы язучылары һәм шагыйрьләре, шәһәрнең партия, совет органнары һәм җәмәгатьчелек оешмалары вәкилләре катнашты.

Кичәнең икенче өлешендә Әлмәт Татар драма театры артистлары һәм үзешчән сәнгать коллективлары көче белән зур концерт булды.

## «ҖИДЕГӘН ЧИШМӘ» КУНАГЫ

Түбән Кама шәһәрендә эшләп килүче «Җидегән чишмә» әдәби-музыкаль берләшмәсенең 25 октябрьдә узган кичәсенә кунак булып прозабызның күренекле вәкиле Әмирхан Еники килде.

Кичәдә язучының «Гөләндәм туташ хатирәсе», «Рәшә» повесте һәм башка әсәрләреннән өзекләр яңгырады.

Аннары язучы белән укучылар арасында татар әдәбиятының тарихы, бүгенгесе һәм киләчәге, милли культурабызның, аерым алганда, аның нигезе булган туган телебезне яхшы белү һәм баету турында эшлекле сөйләшү, фикер алышу булды.

Ә. Еники укучыларның күпсанлы сорауларына җавап бирде. Ахырдан үзешчәннәрнең зур концерты булды.

## ИҖАТ ЯШЬЛӘРЕ БЕЛӘН ЭШЛӘҮ КОМИССИЯСЕНДӘ

13 ноябрьдә Татарстан Язучылар союзының иҗат яшьләре белән эшләү комиссиясенең утырышы уздырылды. Анда Роберт Батуллаләның Казан телевидениесе аша алып барган «Кечкенә экиятләр» тапшыруы, «Яшь ленинчы» һәм «Ялкын»да балалар иҗатын яктырту тәҗрибәсе, Татарстан китап нәшриятында яшь авторларның китапларын бастыру мәсьәләләре турында эшлекле сөйләшү булды. Фикер алышуларда И. Юзеев, Ш. Галиев, Л. Ихсанова, Р. Мингалим, Р. Хәмид, М. Галиев, С. Маннапов, К. Кәримов, Г. Моратов, Р. Зәйдуллин һ. б. катнашты.

## ЯҢА СЕКЦИЯ

13 ноябрьдә Татарстан Язучылар союзы каршында юмор һәм сатира секциясе оештырылды. Оештыру утырышына прозаиклар, шагыйрьләр, рәссам-карикатуристлар, фельетончылар җыелган иде.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателенең урынбасары Р. Хәмид кереш сүз белән чыкты. Фикер алышуларда әдипләрдән А. Яхин, Ш. Галиев, М. Галиев, К. Кәримов, Л. Леронов һ. б. сөйләде.

Секция җитәкчесе итеп А. Яхин сайланды.

## РЕДАКЦИЯДӘ ОЧРАШУ

9 октябрьдә «Казан утлары» журналы редакциясендә «Новый мир» журналының баш редакторы урынбасары, танылган язучы Феодосий Видрашку белән очрашу булды. Ул «Новый мир» журналының эшчәнлеге, анда басылып чыккан һәм басылачак әсәрләр турында сөйләде, редакция хезмәткәрләренең сорауларына җаваплар бирде.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНЫҢ УКУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

14 октябрьдә Чиләбе шәһәренең татар-башкорт өлкә китапханәсендә «Казан утлары» журналының укучылар конференциясе булды.

Конференцияне китапханә каршында эшләп килүче М. Җәлил исемендәге әдәби берләшмә членнары оештырды. Татарстаннан килгән язучы Газиз Кашапов бүгенге татар әдәбияты, «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр турында сөйләде. Татар әдәбияты турында җанлы әңгәмә булды. Шагыйрьләр Салисә Гәрәева һәм Әхмәт Рафыйков үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

Конференция Нил Минажев җитәкчелегендәге «Таң нурлары» исемле үзешчән сәнгать түгәрәгенең концерты белән тәмамланды.

## Хөрмәтле укучыларыбыз!

**Сезнең хатларыгызны истә тотып, сатуда бар татар китаплары хакында мәгълүмат бирәбез. Бу китапларны почта аша соратып алдырырга да мөмкин (адрес 420057, г. Казань, ул. Октябрьская, 18, «Книга — почтой»). Бәясе, китаплар килгәннән соң, үз элемтә бүлегегездә түләнә.**

Аяз Гыйләҗев. Татарстан могҗизасы. Повесть һәм очерклар. 1985 ел. 334 бит. Бәясе 1 сум 40 тиен.
Әхмәт Гадел. Көмеш кылган җыры. Шигырьләр. 1982 ел. 72 бит. Бәясе 15 тиен.
Әхмәт Рәшитов. Киек каз юлы. Шигырьләр һәм поэма. 1982 ел. 64 бит. Бәясе 30 тиен.
Галимҗан Латыйп. Җир җыры. Шигырьләр, җырлар һәм поэма. 1983 ел. 328 бит. Бәясе 75 тиен.
Галиәсгар Камал турында истәлекләр. 1979 ел. 192 бит. Бәясе 1 сум.
Гариф Ахунов. Чишмәләр белән сөйләшү. Мәкаләләр, очерклар, әңгәмәләр. 1985 ел. 462 бит. Бәясе 2 сум.
Гомәр Бәширов. Әсәрләр. Дүрт томлык. 1982—1984 еллар. II том. Туган ягым — яшел бишек. Повесть. 456 бит. Бәясе 1 сум 90 тиен. III том. Җидегән чишмә. Роман. 424 бит. Бәясе 1 сум 80 тиен. IV том. Сиваш. Повесть һәм хикәяләр. 528 бит. Бәясе 2 сум 20 тиен.
Диас Вәлиев. Әгәр үзеңә хыянәт итсәң. Пьесалар. 1985 ел. 224 бит. Бәясе 95 тиен.
Ибраһим Гази. Чикләвекләребез төшле булсын. Мәкаләләр, истәлекләр, очерклар һәм көндәлекләр. 1984 ел. 280 бит. Бәясе 65 тиен.
Кадыйр Сибгатуллин. Авазлар. Шигырьләр. 1981 ел. 80 бит. Бәясе 15 тиен.
Лена Шакирҗанова. Мөлдерәмә күңел. Шигырьләр. 1982 ел. 80 бит. Бәясе 20 тиен.
Ренат Харис. Алтын тәрән. Шигырьләр. 1983 ел. 120 бит. Бәясе 35 тиен.
Рәдиф Гатауллин. Йөрәк сөйли. Шигырьләр, кечкенә поэмалар. 1982 ел. 96 бит. Бәясе 20 тиен.
Шамил Маннапов. Кайту. Шигырьләр. 1982 ел. 128 бит. Бәясе 20 тиен.
Рөстәм Мингалимов. Шигырьләр, поэмалар. 1983 ел. 224 бит. Бәясе 1 сум 10 тиен.
Суфиян Поварисов. Тел — күңелнең көзгесе. Мәкаләләр. 1982 ел. 160 бит. Бәясе 25 тиен.
Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская турында истәлекләр. Беренче татар артисткасына багышлана. 1982 ел. 136 бит. Бәясе 50 тиен.
Туфан Миңнуллин. Монда тудык, монда үстек. Пьесалар. 1985 ел. 464 бит. Бәясе 2 сум 10 тиен.
Шамил Рәкыйпов. Аяз күктә карлыгачлар. Очерклар, документаль хикәяләр. 1982 ел. 224 бит. Бәясе 55 тиен.

**Татарстан китап нәшрияты 1986 елда түбәндәге китапларны бастырып чыгарды:**

Гамил Афзал. Кышкы кичләр. Шаян хикәяләр. 158 бит. Бәясе 35 тиен.
Батулла. Алып батыр мажаралары. Әкиятләр. 160 бит. Бәясе 60 тиен.
Равил Вәлиев. Мәңгелек ут җылысы. Хикәяләр. 112 бит. Бәясе 20 тиен.
Әхәт Гаффар. Бодай бөртеге һәм тегермән ташы. Роман. 240 бит. Бәясе 1 сум.
Габдрахман Минский. Повестьлар һәм хикәяләр. 424 бит. Бәясе 1 сум 60 тиен.
Мөхәммәт Мәһдиев. Мәңгелек яз. Роман. Исәнме, Кәшфи абзый. Повесть. 336 бит. Бәясе 1 сум 30 тиен.
Илдар Низамов. Мәхәббәт хакы. Повестьлар. 392 бит. Бәясе 1 сум 70 тиен.
Ибраһим Салахов. Имәннәр тамыр җәйгәндә. Роман. 456 бит. Бәясе 1 сум 70 тиен.
Альберт Сафин. Күз карашы. Хикәяләр. 136 бит. Бәясе 45 тиен.
Атилла Расих. Сайланма әсәрләр. 1 том. Язгы авазлар. Роман. Хикәяләр. 488 бит. Бәясе 1 сум 90 тиен.
Җәвад Тәрҗеманов. Лобачевскийның яшьлеге. Повесть. 342 бит. Бәясе 75 тиен.
Мәхмүт Хәсәнов. Саф җилләр. Роман. 424 бит. Бәясе 1 сум 60 тиен.
Афзал Шамов. Чын хикәяләр. 440 бит. Бәясе 1 сум 70 тиен.
Габдулла Шәрәфи. Гомернең агышлары. Повестьлар һәм хикәяләр. 352 бит. Бәясе 80 тиен.

# БОЛГАР БИЗӘКЛӘРЕ

## ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ БОРЫНГЫ ЮВЕЛИРЛЫК СӘНГАТЕ

Халкыбызның металлны сәнгатьчә эшкәртү традицияләре бик борынгы заманнарга, Идел болгарларының зәркан, ягъни ювелирлык сәнгатенә барып тоташа. Аның бөтен дөньяда дан тоткан үрнәкләре күпләргә мәгълүм. Болгар осталары ясаган алтын һәм көмеш бизәнү әйберләре нәфислек һәм эшләнеш дәрәҗәсе ягыннан төрле илләрдәге иң яхшы үрнәкләр белән ярыша ала. Академик Б. А. Рыбаков сүзләре белән әйткәндә, Идел болгарлары урта гасыр Европасында беренче булып «металлны бөтереп эшләү һәм бөрчекләү культурасын барлыкка китерделәр». Бөтереп һәм пәрәвездәй үреп, асылташлар белән бизәп эшләнгән бу әйберләр өрфиядәй җиңел тоелалар, нәфислек өлгесе хасил итәләр.

Кош сынын гәүдәләндергән сыргалар, колак алкалары, үтә вак бөрчекләрдән пирамидалап эшләнгән асылма бизәкләр, ат башын сурәтләгән парлы алкалар, баш-башына арслан йөзе төшерелгән яссы беләзекләр, чулпылар әнә шундыйлардан. Бу чорда сәнгатьтә бердәм стиль юнәлеше барлыкка килә һәм ул бердәм дәүләт, уртак мөселман культурасы шартларында тагын да үсә; шәһәрләрдә генә түгел, авылларда да һөнәрчелек чәчәк ата. Болгар, Биләр, Сувар, Җүкәтау, Кашан һәм башка һөнәрчелек үзәкләрендә ясалган ювелир әйберләр безнең көннәргә кадәр килеп җиткән.

Болгар шедеврлары — алтын һәм көмештән үрдәк фигурасы рәвешендә бөтереп ясалган колак алкалары хәзерге вакытта Мәскәүнең Дәүләт тарих музеенда һәм Ленинград Эрмитажында саклана.

Бизәнү әйберләреннән өч-дүрт чыбыктан ишелгән муенсалар, асылташ, гәрәбә белән бизәлгән көмеш беләзекләр аеруча киң таралган була. Хәситәләрнең сәнгатьчә эшләнешенә бөрчекле бизәкләү аерата нәфислек өсти. Гадәттә күкрәктә йөртелә торган бу зиннәтле әйберләр еш кына асылташлар белән дә бизәлә. Яссы тартмачык рәвешендә медальон кебек итеп ясала торган бөтилек яки коръән савытларына да техник камиллек һәм нәфислек хас. Бөтен асылташлар да калку ояга утыртыла, бөтерелгән дулкынсыман чыбык белән каймалана. Шушы бизәү алымы Казан татарларының коръән савытларында да сакланып калган.

Болгар бизәнү әйберләренең художество стилендә Кара диңгез һәм Азов диңгезе буйларында борынгы Греция тәэсирендә үскән шәһәр сәнгате, Иран һәм Кавказ аръягы халыклары традицияләре йогынтысы аеруча калку гәүдәләнә. Бу орнаментлаштыру алымнарына да, полихром стиль үзенчәлекләренә дә кагыла. Алар болгар зәркәнчылыгында саклана һәм аннан Казан татарларының ювелирлык сәнгатенә күчә.

Борынгы бабаларыбыз ювелирлык сәнгатенең эстетик кыйммәте дә нәкъ менә шунда — утрак һәм күчмә халыклар традицияләренең үрелеп үсүендә. Татар ювелирлары иҗатында исә гасырлар тирәнлегеннән килгән шушы үзгәлекләр һәм милли үзенчәлекләр кадерләп саклана, тагын да баетыла. Болгар мотивлары, формалары һәм сурәтләү алымнары халык сәнгатенә бүген дә илһам бирә.

Гүзәл ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА,
сәнгать фәннәре кандидаты.

**Тышлыкның беренче битендә: ЮРИЙ ФИЛИМОНОВ фотосы.**

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казанның Ирек мәйданында В. И. Ленин һәйкәле.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотосы.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210




# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)


Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)